ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2009



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## 2009 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимнәрен карагач, шулай ук Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән хезмәтләрнең югары сәнгати дәрәҗәләрен исәпкә алып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимен кабул итәргә һәм 2009 елда, искәрмә буларак, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дүрт Дәүләт бүләген бирергә.

2. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) **Мансуров Зиннур Мөҗип улына** «Җәрәхәтле йөрәк җылырак» дип аталган шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2003 ел) һәм «Күңелдә фидаи яшәсә» («Мәгариф» нәшрияты, Казан, 2006 ел) китабы өчен;

2) Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының түбәндәге составтагы иҗат төркеменә: **Хәкимханов Зөлфәт Зөфәр улына** (Зөлфәт Хәкимгә) (язучы-драматург), **Скоморохов Сергей Геннадьевичка** (рәссам-сәхнәгә куючы), **Хәсәнев Рим Мәхмүт улына** (композитор), **Төхфәтуллин Рамил Чыңгыз улына** (төп рольне башкаручы) Зөлфәт Хәкимнең театраль романы буенча куелган «Телсез күке» спектаклен иҗат иткән, сәхнәгә куйган һәм төп рольне башкарган өчен;

3) В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театрының түбәндәге составтагы иҗат төркеменә: **Романова (Славутская) Светлана Геннадьевнага**, **Прытков Геннадий Николаевичка** классик рус драматургиясе образларын—А.П. Чехов пьесасы буенча куелган «Чия бакчасы» («Вишневый сад») спектаклендә Раневская һәм Гаев образларын иҗат иткән өчен;

4) **Муллашев Камил Вәлиәхмәт улына** «Сөембикә-ханбикә», «Евразия яисә Кыпчак кызы», «Сабантуй», «Ватан турында уйлану», «Әтил суы башланган урында» дип аталган художество әсәрләрен иҗат иткән өчен.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ кул куелган көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **М.Ш.ШӘЙМИЕВ**

*Казан, Кремль.*
*2009 ел, 24 апрель № ПУ-228*

# Казан утлары
# Qazan utları

2009

# 5
**(1039)**

***ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:***
***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

***НАШИРЕ:***
***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр. ... 5

**«АГЫЙДЕЛ» ЖУРНАЛЫ БЕЗДӘ КУНАКТА**

Әмир ӘМИНЕВ. Рухиятебез елъязмасы. ... 11
Рамил ЯНБӘК. Яңа буын. *Шигырьләр.* ... 15
Талха ГЫЙНИЯТУЛЛИН. Суга баткан кеше. *Хикәя.* ... 18
Сабир ШӘРИПОВ. Карак. *Хикәя.* ... 25
Тамара ГАНИЕВА. Минсез дөнья. *Шигырьләр.* ... 32
Гөлнур ЯКУПОВА. Күгәрченем. *Шигырьләр.* ... 35
Фәрзәнә АКБУЛАТОВА. Атай икмәге. *Хикәя.* ... 37
Рәлис УРАЗГОЛОВ. Сандык. *Хикәя.* ... 47
Салават ӘБҮЗӘР. Гулливер. *Шигырьләр.* ... 54
Гөлназ КОТЫЕВА. Әй,моңым... *Шигырьләр.* ... 56
Әмир ӘМИНЕВ. Танкист. *Повесть.* ... 59

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

ХӘЗЕРГЕ ХИКӘЯ. «Түгәрәк өстәл» сөйләшүе. ... 88

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВКА 75 ЯШЬ**

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ, Җәүдәт МИҢНУЛЛИН. Эш күрсәткән ирне ил онытмас! ... 98

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Бирелмичә калган сораулар. ... 102
Марсель ӘХМӘТҖАНОВ. Нәкый Исәнбәт турында хатирәләрем. ... 120
Шаһинур МОСТАФИН. Бабам васыяте. ... 129

**ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВКА 70 ЯШЬ**

Резеда ГАНИЕВА. Күренекле галим-педагог, чын хатыйп. ... 134

**ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ**

Ризван ХӘМИД. Язылмаган драма. ... 141
Фаил ШӘФИГУЛЛИН. Түзә шагыйрь башлары. *Хикәя.* ... 145

**РАВИЛ РАХМАНИГА 60 ЯШЬ**

Миргазиян ЮНЫС. Чакрымнарын югалткан мең чакрым. ... 148

**ФӘН**

Болгар–татар чыгышлы 500 рус фамилиясе. ... 156
«Татар энциклопедиясе»» битләреннән. ... 162

**КАРДӘШ ӘДӘБИЯТЛАР**

Фатих КУТЛУ. Ике китап һәм бер хикмәт. ... 159

**АК ҖИЛКӘН**

Камил КӘРИМОВ. Яшел читлек. *Хикәя.* ... 171
«Казан утлары» архивыннан. ... 184
Иҗтимагый–мәдәни тормышыбыздан. ... 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Поэзия»: новые стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА.
«У нас в гостях журнал «Агидель»: вступительное слово гл. редактора; повесть А. АМИНОВА, рассказы Т. ГИНИЯТУЛЛИНА, С. ШАРИПОВА, Ф. АКБУЛАТОВОЙ, Р. УРАЗГУЛОВА; стихи Р. ЯНБАК, Т. ГАНЕЕВОЙ, С. АБУЗАРОВА, Г. КОТЫЕВОЙ, Г. ЯКУПОВОЙ.
«Литературная критика»: разговор за круглым столом о современном рассказе.
«К 75-летию М. Усманова»: статья И. ГИЛЯЗОВА и Дж. МИННУЛЛИНА.
«Память»: М. УСМАНОВ. «Незаданные вопросы»; М. АХМЕТЗЯНОВ. «Воспоминание о Наки Исанбете»; Ш. МУСТАФИН «Завещание деда».
«К 70-летию Х. Миннегулова»: Р. ГАНЕЕВА. «Знаменитый ученый-педагог».
«К 70-летию Ф. Шафигуллина»: Р. ХАМИД. «Ненаписанная драма», рассказ Ф. ШАФИГУЛЛИНА.
«К 60-летию Р. Рахмани»: статья М. ЮНУСА «Потерянные версты».
«Наука»: в номере отмечается 90-летие археолога А. Халикова. Публикуются выборки из его книги «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения».
«Братство литератур»: Ф. КУТЛУ. «Две книги».
«Белый парус»: рассказ К. КАРИМОВА «Зеленая клетка».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Хозяин оберегов. Автопортрет»—работа А.ФАТХУТДИНОВА; поэт Идият АШИРОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Poetry»: new poems by R. FAYZULLIN.
«Our guest magazine «Agidel»: introductory by chief editor, A. AMINOV, stories by T. GINIYATULLIN, S. SHARIPOV, F. AKBULATOVOY, R. URAZGULOV; poems by R.YANBAK, T. GANEEVA, S. ABUZAROV, G. KOTYEVA, G. YAKUPOVA.
«Literary Criticism»: conversation at round table on about contemporary story.
«To 75th anniversary of M. Usmanov»: article by I.GILYAZOV and J. MINNULLIN.
«Memory»: M. USMANOV. «Unsettled questions»; M. AHMETZYANOV. «Memories about Naki Isanbet»; S. MUSTAFIN «Grandfather's testament».
«To 70th anniversary of H. Minnegulov»: R. GANEEVA. «Famous scientist teacher».
«To 70th anniversary F. Shafigullin»: R. HAMID. «Unwritten drama», story by F. SHAFIGULLIN.
«To 60th anniversary of R. Rahmani»: article by M. YUNUS «Lost miles».
«Science»: 90th anniversary of archaeologist A. Khalikov. Publishing parts of his book «500 Russian names of Bulgarian-Tatar origin».
«Brotherhood of literatures»: F. KUTLU. «Two books».
«White sail»: story by K. KARIMOV «Green Box».
From photo-archive of mafazine.
Diary of socio-cultural life.
On our cover: «Master of preservings. Auto portrait" —work by A. FATHUTDINOV; poet Idiyat ASHIROV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 27.04.2009, график буенча 27.04.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–578 Тираж 4491.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210. Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2009 ел.



Равил
Фәйзуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## Үзгәрәдер...

Меңләгән шигырьләр язды.
Тагын язып утыра...
Шуннан дөнья үзгәрәме?—
тукталып уйлап тора.

Бакыйлыктан күпме хикмәт
төйнәлсә дә җиһанда,
үзгәрәдер: сабыйларга
дөнья бит ул—өр-яңа!

...Әнә бер кыз кулъяулыкка
шигырь юллары чиккән.
Мизгел шатлык тойса кемдер,
шагыйрь җанга шул җитә.

## Дөньяны каргарга ашыкма!

Төксе йөз кемгәдер кирәкме?
Тәмсез сүз кемгәдер тансыкмы?
Үзеңнән ямь өсти алмасаң,
Дөньяны каргарга ашыкма!

Карап бак: сабыйлар елмая,
челтерәп чишмәләр ашкына,
болында чәчәкләр ташкыны!..
Кичкырын сызылып ай чыга,
кемгәдер күк-капу ачыла...
Гашыйклар аулакка ашыга...

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943)–*Татарстанның халык шагыйре; алты томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

...Хәсрәтләр ишелеп ауса да,
Дөньяны каргарга ашыкма!
Иң әүвәл, кешеләр күзеннән
үзеңә бәяне ачыкла!

Кыла алсаң игелек, ул гамәл
гөл булып Ватанда бер шытар!..
...Кадерсез булдым, дип, бу илдә
Дөньяны каргарга ашыкма!

## Шигырьләр яздым...

*(автобиография)*

Килешли—
Буй-сын ныгыттым.
Гыйлем эстәдем.
Кызлар күзләдем...

Хыялда йөзеп
шигырьләр яздым.

Үтешли—
Ирлекне тойдым.
Нигез-йорт кордым.
Уллар үстердем...

Ил! дип җирсенеп
шигырьләр яздым.

Китешли—
Әти-әнигә
чардуган кордым.
Дога укыдым...

Сагышта йөзеп
шигырьләр яздым...

## Иң зур толерантлык—колда ул!

*Толерантлык—соңгы елларда,*
*кирәк-кирәкмәсә дә, асылына бик*
*үк төшенмичә, еш әйтелә торган сүз.*

Улмы-кызмы, яшьме-картмы син—
халкың хакы өчен юлда бул!
Иелә калсаң, шуны онытма:
иң зур толерантлык—колда ул!

Көрәшчеләр рухы шуны раслый
(тарихлардан бөек тәҗрибә!):
ятлар хакын көйләп йөрми чын ир—
йә көрәшеп үлә, йә җиңә!

***

Йөрәк белән яшәп карадык!
Хәзер үпкә[1] белән яшәлә...

...Бик-бик теләсәң дә яшьнәргә,
бу дөнья кала яшьләргә.

Ә безгә соң менә нишләргә?
Сукыр тычкан кебек, җир ертып,
эшләргә,
эшләргә,
эшләргә!

...Яшьләргә дә килер мондый уйлар
безнеке күк матур яшьләрдә.

* * *

Без бу якты дөньяда
күп нәрсә югалтабыз...
Бик кайгырма, бүртер өчен,
суга батса балтабыз.

Югалтуларның иң зуры:
ташлап китәләр дуслар!..
Мәңгелеккә... Өлгермичә,
васыятьләрен багышлап.

* * *

"Хәсрәт арасында хәсрәтләр күп",
Әрнү эчләрендә—әрнүләр...
Хәзер инде аңлыйм: сызып шулай
гомер кичкән икән әниләр.

Яккан учаклар да гамьсез түгел,
җилләр иссә, көйри күмерләр...
Ерак йолдыз нуры кебек саркып,
калыр, ахры, безнең гомер дә!..

## Үзең булып кал...

Гөләп куагындагы җимешме син,
туфрак ерткан сукыр тычканмы,
Айга карап улаган бүреме,
йә, ниһаять, усал җан иясе—Кешеме син?..
Үзең булып кал!

Бүтән сурәтләргә кермәсәң,
аңлаучылар табылыр Дөньяда.

[1] Үпкә – бу очракта ике мәгънәдә.

* * *

Үлемсезлеккә омтылыш—
гөнаһмы, савапмы икән?
Балаларың һәм иҗатың—
була алыр җавап микән?

...Балалар да төрле була...
Җырларда да—шул ук хәл!
Җавапны үзем бирәм! дип,
сагалап тора Әҗәл.

* * *

*Себер белән куркытмагыз!—*
*Себер—үзебезнеке!*
Зимагурлар җырыннан

Янә бер бак карта-харитәгә!—
Татар бугазыннан Алып (Альп)ларга чаклы,
Киек Каз юлыдай, сибелгән
җанга якын үзебезнең атамалар!
(Һаманча бетерә алмыйлар!)—
елга-таулар, авыл-шәһәр исемнәре!
Галәм-глобусның уртасында билбау булып
уралып ята Урал таулары.

...Кемнәр, кайда, ничек ишетә бит
Мәңгелекнең ничек шаулавын!

* * *

"Улым!" дигән газиз сүзне
бүтән ишетмәм инде...
Әти җәсәде белән ул
мәңгелек гүргә иңде.

Бер юаныч: "Улларым! дип,
әйтер балаларым бар.
Бу сүз яңгыраган чакта
әле минем җаным бар!

## Дүртьюллыклар

### Тома ятим

Күпне югалтканнар тиеш
булырга сабыр, түзем...

Әти-әнисен, дәүләтен
җуйган ятим ул—үзем.

* * *

Бүтән телләргә тәрҗемә
итеп булмас сүзләр бар.

Бәлки, Туган Телнең җанын
саклаучылардыр алар?

## Гөнаһ шомлыгы

Кайчандыр ләззәт китергән
гамәлләр булган... Чынлык.
...Еллар үткәч сискәндерә
гөнаһтан туган шомлык.

* * *

Унның бере генә яши.
Калганы—гомер кичә.
Шул—калганнар: "Мин яшим!" дип
җыр суза эчә-эчә...

## Сайлаулар алдыннан

Үнәремнән[1] мәхрүм итмә!
И, халкым, асыл гынам!
...Бишенче кат сайланмасам,
билләһи, асылынам!

* * *

Ә кем белә! бәлки, әле тагын
янә янып, янә көярбез!..
Бүгенге көн бакырыбызны да
алтын булган икән диярбез.

## Әрнү

*2008 елның сентябрь ахырында татар халкы өчен изге булган бинаны—заманында Тукай яшәгән "Болгар" кунакханәсен җимереп, җир белән тигезләделәр.*

*Бирердә, кайдадыр якында,*
*Тукай җаны бәргәләнәдер...*

Без Тукайны саттык. Булдырабыз!
Толерантлы "бөек" халык без!
Бу очракта, көлеп мыскылларлык
бәяләмәләргә лаек без.

Үткәннәргә төкереп, вандаллыкның
үрнәкләрен күпкә уздырдык.
Горурлык дип йөрткән даһи затның
күшеккәндә җанын җылыткан
соңгы оясын да туздырдык.

[1] Үнәр—һөнәр, профессия мәгънәсендә.

Бөек шагыйрь миллион күңелләрдә
шигырь сарайлары салса да,
үзенә йорт сала алмаган шул...
Вакытлычасы да... вәссәлам!

Җанда әрнү. Ваемсызлык өчен.
Көрәшмәгән өчен үкенү.
Төшләремдә яңгырый: дивар ава,
бульдозерлар, яман үкерү...
Бу җимерү гади җимерү түгел,
бу—тарихка, телгә, моң-көйләргә,
символ булган Җанга төкерү.

Күпме халык ихлас табыну белән
иелеп уза иде бу йортка!
Нигә "Туган тел"ең, "Тәфтиләү"ең
рок-поп буынына—маңкортка!

Нәрсә булыр монда? Бер бардакмы,
йә заманча толчок-мазармы?
Акча—иман булып йөргән чакта
бар дөньясы—колхоз базары.

Әйдә, байлар тагын баесыннар...
Изге җирдә маемласыннар!..
Тукайҗаннан курыкмасагыз да,
Ходай хөкеме сезне бер сынар!
Рәнҗешләре төшәр,
төшми калмас,
каргасалар мең-мең юксыллар!..

Беткәнне дә төзеп бирәбез бит
космополит килмешәкләргә.
Баскын варислары уйлыйлардыр:
"Шулай кирәк сез—ишәкләргә!"

Күпме милли ядкарь вәйран булды!
Җирләре "этләргә кала"ла!...
Күктишәр манаралар үрлиләр
тамырсыз меңъеллык калада.

Болгар номерлары...
Кырыгынчы бүлмә. Шигъри учак..
Килеп кара: урыны—тап-такыр...
Дәүләти ятимлегеңне шунда
кичерерсең тагын бер тапкыр.

Шагыйрь җаннар, уйламагыз: мине
урап узар диеп бу хәлләр.
Тукай кирәкмәгән чорда безне,
сайлап-сайлап, аерым бөгәрләр!..

Без Тукайны саттык! Дөресрәге,
үзебезне саттык... Күпмегә?
...Тамырларың бетсә, кала бары
Изге дога белән Күк кенә.

*1 октябрь 2008*

# РУХИЯТЕБЕЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Мөхтәрәм «Казан утлары» журналы аша бүгенге башкорт әдәбиятының кайсыбер өлгеләрен татар укучысына тәкъдим итә алуыбызга бик шатбыз. Ике республика—ут күршеләр... Тормыш агышларында аралашып, бер-беребезгә йөрешеп, шатлык уртаклашып, кайгы килсә, аны да бергә күтәрешеп, көн итәбез. Бу әдәбият, сәнгать, мәдәният өлкәләренә дә кагыла. Ә моның өчен чаралар күп: әдәбият көннәре, иҗади союзларның, аерым шагыйрь һәм язучыларның юбилейлары, тоташ театрлар, филармонияләр гастрольләре, алмаш китаплар нәшер итү һәм, әлбәттә, рәсми делегацияләрнең, республика житәкчеләренең сәфәре... Уртак нокталарны саный-барлый китсәң—бихисап инде. Без бүгенге, бүгенге генәме икән, Рәсәйнең геополитик картасында күршелек, телләребез, мәдәниятләребез якынлыгы белән генә түгел, нәкъ шул дуслыгыбыз, күп нәрсәгә уртак фикерләребез, уртак карашларыбыз булуы белән көчле дә. Иншалла, алдагы көннәрдә дә шулай булсын.




Шул уртак нокталарның берсе—ике республиканың төп әдәби-нәфис журналлары «Казан утлары» белән «Агыйдел»нең, бик үк еш булмаса да, татар һәм башкорт иҗатчылары әсәрләрен кардәш халыкларга житкерә баруы. Бу хезмәттәшлек элек тә бар иде. Мондый алыш-биреш әдәби яңалыклар гына итми, рухыбызны баета, бер-беребезгә якынайта, гомум төрки дөньясында барган вакыйгалар, үзгәрешләр, яңалыклар белән танышып барырга мөмкинлек бирә. Бу бер-беребезне имән терәүдәй тотып торды, ялгыз калудан саклады.

«Агыйдел»нең төрле елларда чыккан тупланмаларына күз салсаң, анда байтак татар шагыйрьләренең шигъри шәлкемнәренә, прозаикларның хикәя, повесть, романнарына юлыгырга мөмкин. «Казан утлары» шулай ук башкорт әдипләренең әсәрләрен әледән-әле нәшер итә килде. Ә классикларыбызның шәхси дуслыклары соң? Х. Туфан, Г. Бәширов, С. Хәким, Н. Исәнбәт, М. Әмир, Г. Ахунов, янә күпләр безнең Мостайның, Назарның, Галинең, Атнабайның, Маратның, Рафаэльнең генә дуслары булып калмады, ә башкорт әдәбиятының уртак дусларына әйләнде. Г. Тукай белән М. Гафури салган бу дуслыкның нигез ташларын һәм ул бүген дә, хәзер инде чагыштырмача яшьрәк буын вәкилләре тарафыннан, дәвам иттерелә. Әйтик, республика үзенеке итеп Т. Миннуллин пьесаларын карый, Р. Миңнуллин, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Ш. Галиев, Р. Харис, Зөлфәт, Р. Гаташ шигырьләрен, А. Гыйләжев, Р. Мөхәмәдиев романнарын укый, Татарстанда исә М. Кәрим, Н. Нәҗми, Ә. Атнабаев, Н. Асанбаев, М. Кәримов, Р. Бикбаев, Ф. Бүләков иҗаты билгеле. Әлбәттә, моның белән генә чикләнми, ике журнал битләрен бизәгән исемлекне тагын да дәвам итеп булыр иде.

Бүген, XXI гасыр башында, ике тугандаш әдәбият һәм ике рухташ журнал арасында мөнәсәбәтләр ничек соң? Дөресен әйткәндә, СССР дигән зур ил таркалгач әдәби бәйләнешләр, мәдәни аралашулар кимеде һәм күбебез, атап әйткәндә, элекке милли автономияләр вәкилләре, арага бик-чикләр салып үз-үзебезгә бикләндек. Дөресрәге, бу җәһәттән элекке шикелле «планлы» эш алып барылмый, олы чаралар юк, булганы да теге яки бу төбәктә, шәхси пландарак үтә сымак. Мин, бәлки, ситуацияне катлауландырамдыр, хәлбуки, барысы да алда телгә алган өлкән буын каләмдәшләребез аралашкан, дуслашкан мәлдәгечә яхшырыр. Әгәр шулай икән, моңа мин куаначакмын гына. Ә безгә, яшьрәк буынга, аларның җылы мөнәсәбәтен, кулларының, йөрәкләренең кайнарлыгын суындырмаска кирәк. «Агыйдел» журналы редакциясе, ике йөздән артык союз әгъзасы булган Башкортстан язучылары исеменнән ихлас рәвештә шуны тели.

Хәзер журнал турында бер кәлимә сүз. Басма турысында күпмедер мәгълүмат шулай ук кызыклы булыр дигән уйдамын. «Агыйдел»нең тарихы бай: 1923нче елның мартыннан «Яна юл» исеме астында сәяси-әдәби һәм иҗтимагый-фәнни айлык журнал буларак нәшер ителә башлый. Исеме үк әйтеп торуынча, басма яңа тормышта, яңа тәртипләрне пропагандалый, художестволы әсәрләрнең дә төп герое—социалистик корылышның яңа кешесе. Чөнки шул дәвердә рәсми идеология нәкъ шуны таләп итә. 1924нче елның башыннан журнал «Белем» дип атала башлый. Хәзер инде ул Башнаркомпроснын фәнни-педагогик, әдәби айлык журналы дигән статус ала. Басма, нигездә, ликбез-агарту, халык массаларына белем тарату үзәкләренең берсенә әверелә һәм шул юнәлештә шактый эш башкара. 1927нче елда журнал янә исемен алыштыра—инде «Сәсән» тип атала. «Сәсән» башкорт әдәбиятында якты эзләрен калдырган башкорт шагыйрьләре һәм язучылары иҗаты белән таныштыручы, шулай ук башка даирәләрне, фәһемле мәкаләләре белән яктыртучы әдәби-художестволы басма. Исеме милләт рухына, анын акыл һәм хис-тойгыларына бик туры килә, чөнки, чәчәнлек башкортка хас сыйфат. Тәүге елны гарәп шрифтында гына чыгып килсә, соңгы ике елында латин шрифты белән катнаш басыла башлый. Үзенең бай эчтәлекле булуы белән Шәрык җөмһүриятендә чыга торган төрле журналларның алдынгылары сафында исәпләнелә. Мәсәлән, тәүге санын М. Гафури, Т. Янәби, Г. Амантай шигырьләре, К. Иделгужа, Т. Насыйри хикәяләре бизи.

20нче еллар азагында оештырылган БАПП (Башкирская Ассоциация Пролетарских писателей—Башкорт пролетар язучылар ассоциациясе) төзелү башкорт язучылары алдына яңа бурычлар куя: илне индустрияләштерү, коллективлаштыру, яңа совет кешесен тәрбияләү. «Сәсән» партиянын идеология коралы буларак бу эшкә дә җиң сызганып тотына.

Сәяси таләпләрдән чыгып журнал үзенең исемен янә үзгәртә:

«Октябрь»! Журналның тышлыгы 30нчы еллар башында исеме җисеменә туры килә дә инде. «Социализм реконструкциясе» дигән производство: торбадан төтене чыгып торган завод күренешләре, станокта эшләүче эшчеләр, ударник колхозчылар. Шушы ук таләпкә басманың эчтәлеге дә туры килә: «халыклар атасы» Сталинның чыгышлары һәм хатлары, сәяси темага язылган мәкаләләр, язучыларның шул рухта иҗат ителгән әсәрләре. «Октябрь»нең тәүге актив авторлары М. Гафури, А. Таһиров, Д. Юлтый, Б. Ишемгол. 30нчы елларда шулай ук Т. Янәби, Р. Нигъмәти, С. Кулибай, С. Агиш, Г. Амантай, Г. Сәләм, Б. Бикбай, Г. Әмири һ. б. еш чыгыш ясый. Журнал Октябрь революциясенең «давыл хәбәрчесе» М. Горький, шулай ук Д. Фурманов, А. Фадеев, И. Эренбург, М. Шолохов, А. Толстой, Н. Островский, А. Чехов, А. Пушкин, М. Лермонтов әсәрләрен, хәтта

«Слово о полку Игореве» эпосын тәрҗемәләп бирә. Игътибарга лаек әсәрләрдән янә М. Бурангулов язып алган башкорт халык эпосларын («Идукәй белән Моразым», «Гилмияза», «Карасакал һәм кара ат»), С. Злобинның «Салават Юлаев» романын, П. Ищериковның Салават батыр турындагы яна мәгълүматларын әйтергә мөмкин.

Журналның камилләшүен, үсүен 1941нче елның 22нче июнендә башланган Бөек Ватан сугышы бүлә. Шул сәбәпле, сугыш беткәнгә кадәр «Октябрь» чыгуыннан вакытлыча туктап тора. 1946нчы елның азагында гына журнал янадан чыга башлый.

«Октябрь» 1949нчы елдан башлап «Әдәби Башкортстан» дип нәшер ителә. Партия язучылар алдына совет җәмгыятенең тормышы, совет кешесе хакында художество ягыннан ачык, тулы әсәрләр тудыру бурычын куя. Бу чорда иң актив иҗат итүчеләр—С. Агиш, Ә. Вәли, Н. Нәжми, С. Кулибай, К. Даян, Р. Нигъмәти, Б. Бикбай.К. Мәргәннең «Нарыштау итәгендә», Б. Бикбайның «Акчелән ташкайда», Ә. Вәлинең «Май янгыры», Һ. Дәүләтшинаның «Ыргыз», З. Биишеваның «Кимсетелгәннәр» кебек күләмле һәм башкорт прозасында яна күренеш рәвешендә кабул ителәчәк әсәрләре басыла. Шигъриятә җирдә тынычлык, демократия өчен көрәш темасы киң урын ала. Бу елларда лирик поэзиянең югары өлгеләрен М. Кәрим бирә.

Журнал бүгенге аталышта («Агыйдел»), 1961нче елның гыйнвар аеннан бирле чыгып килә.

Шулай итеп, хөрмәтле кардәшләр, без төрле елларда төрлечә исем белән чыккан бүгенге «Агыйдел» журналының тарихына сәяхәт кылдык. Дәвер бөгелешләрендә аның исемнәре үзгәреп торса да басма үзенең төп Вазыйфасыннан беркайчан да тайпылмады: менә 85 ел инде башкорт әдәбиятын, мәдәниятен, сәнгатен пропагандалап, республикада яшәгән халыкларның рухый дөньясын баетуга, яна ижади көчләр тәрбияләүгә тугры хезмәт итә. «Агыйдел» милләтнең рухый байрагы, маягы, тел сакчысы. Күп кыйммәтләр, нигъмәт-һиммәтләр, казанышлар югалган, сатылган, сәүдәгә куелган бүгенге заманда анын шул сыйфаты бик тә мөһим. Милли идея матбугат, мәгълүмат дөньясы, күңел, хис-тойгы кыйбласы, матурлык, гүзәллек, алдагы көннәрдә өмет-ышаныч тудыручы геройлар, җыр-моң ул. Безнең һәр кайсыбызны гражданлык нныклыгы, тарихыбыз, рухият тотып тора, туплап берләштерә, журнал исә шул рухиятне тудыручы, саклаучы чыганак. Мина калса, «Агыйдел»нең илһамлы чыгып килүе һәм халыкка рухый азык өләшүе—Урал батырның, авызына уртлап, изге табигатькә тере су бөркүенә бәрабәр ул. Журнал безне үз анныбыз коргаксуыннан саклый, йөрәкләребезне моң-хисләр белән тутыра, акыллырак, мәгълүматлырак булырга ярдәм итә, күңел очышы бирә. Әгәр республикабызда канкоеш юк, социаль тетрәнүләр урап үтә, төрле милләт кешеләре килешеп яши икән, мин монда шулай ук матбугатның, шул исәптән «Агыйдел» журналының да, зур тәрбия көчен күрәм. Ул хата адымнан, теге яки бу милләткә ачу, үпкә йөртүдән саклый—югары мәдәният булган җирдә вак ыгы-зыгыга урын калмый.

Гәрчә журнал битләрендә дөнья күргән әсәрләрне саный-барлый китсәң, бихисап томнар сыйдырган әллә күпме китапханә киштәләре тулыр иде. Нигездә, бар башкорт әдәбияты «Агыйдел» битләре аша үтте һәм бүген дә үтә килә. Бөек замандашыбыз Мостай Кәримнең: «Минем беренче шигырем «Октябрь» журналында 1937нче елда басылып чыкты... Һәм менә шул көннәрдә үземнең яна басманы—биш томлыкны—кулга алгач, уйланып тордым, ә бит шул томлыкка тупланган бар әсәрләрем дә «Агыйдел» аша, аның югары критерие, укучылар бәһасы аша үтте...»—

дигәне моны раслау булыр.

Халык шагыйренең әйткәннәренә 1923 елдан башлап бүгенге көнгә чаклы әсәрләре журналда чыккан бар башкорт әдипләре дә кул куя алыр иде. «Башкорт милләтенең рухый үсешендә, туган телне саклауда, халкыбыз язмышын хәстәрләүдә ни тиклем катлаулы чорларда тынгысыз эш алып барган «Агыйдел» журналы белән тиңләшерлек башка басма бездә юк...»,— ди халык шагыйре Равил Бикбаев. Бу сүзләргә ни өстисең, хак сүзләр.

Басма үз-үзенә бикләнеп кенә яшәми, үзенең тәүге саннарыннан ук республика укучысын тугандаш республикалар, шулай ук чит ил әдәбиятларының иң яхшы әдәби үрнәкләре белән дә таныштыра килә. 20-30нчы елларда бу тенденция нинди дәрәҗәдә үзебездә югары художестволы әсәрләргә кытлык кичерелүе аркасында булса, соңрак ул халыклар, илләр, кыйтгалар арасына дуслык күперләре салучы буларак танылды. Нәтиҗәдә Рәсәй, СССР, дөнья дәрәҗәсенә күтәрелгән байтак югары художестволы әсәрләр бихисап укучыларыбыз күңелен яулады.

Калын әдәби-художестволы журналы, энциклопедиясе, милли театры, операсы, эпосы, милли герое булган милләт бөек милләт ул. Төрки әдәбиятлары арасында милли әдәби-художестволы журналларының меңенче саны чыгуы белән горурлана алган басмалар күп түгел. Бу да бит тарихыбызның борынгылыгын, мәдәниятебезнең тирән тамырлары барлыгын дәлилләүче факт.

XX гасырның икенче яртысы, бу гасыр башы башкорт әдәбиятының нык күтәрелгән чоры. Бу күтәрелеш, миңа калса, беренче чиратта, халык шагыйрьләре М. Кәрим, Н. Нәҗми, Ә. Атнабаев, М. Кәримов, Р. Гарипов, Р. Бикбаев, Т. Юсупов шигърияте, Р. Назаров, Х. Назар, М. Гали әсәрләре, Һ. Дәүләтшина, З. Биишева, Д. Исламов, Я. Хамматов, Ә. Хәкимов, Б. Рафиков, Н. Мусин романнары, С. Агиш, Ш. Янбаев, Ш. Насыйров, Р. Солтангәрәев, Т. Гыйниятуллин повесть, хикәяләре, Н. Асанбаев, Ф. Бүләков пьесалары, Г. Хөсәенов, К. Әхмәтҗанов, Ә. Вахитов, М. Минһаҗетдинов фәнни эшчәнлегендә, аларның тәнкыйть, әдәбият гыйлеме эшендә чагылыш таба. Бүген Г. Якупова, Т. Ганиева, М. Ямалетдин, Ф. Тугызбаева, Г. Котыева, С. Әбүзәр, Х. Тапаков җаваплы эшли. Димәк, башкорт әдәбиятының өметле киләчәге бар, дип ышанычлы әйтеп була. Саналган, саналмаган әдипләрнең барысының да төп әсәрләре укучыга, нигездә, «Агыйдел» журналы аша барып житә. Бу шулай ук алар артыннан килгән яшьрәк буын вәкилләре өлешенә дә төшәчәк.

Ә хәзер, алда әйткәнемчә, төрле тематикалы һәм жанрлы, төрле манералы һәм стильле башкорт әдәбиятының кайсыбер өлгеләре белән таныштыру мәле житте. Хәерле сәгатьтән, туганнар!

**Әмир ӘМИНЕВ,**
*«Агыйдел» журналының баш мөхәррире.*



## Рамил Янбәк

### Яңа буын

Юк, ул бүтән булыр—яңа буын.
Безнең буынны ул кабатламас.
Акыллырак булмас, әмма алар
Безнең хаталардан сабак алмас.

Тагы басар алар шул тырмага.
Баш бәрерләр шул ук түбәләргә.
Антлар әйтеп кабат ялгышмаска,
Иртә саен килер тәүбәләргә.

Үткәннәрдән сабак ала белсәк,
Кабатланмас иде шул ук хата:
Тормыш гөрләр җирдә Үлем йөри,
Ә дөньялар кырылышып ята.

Бар Җир шарын буйсындырып алып,
Кул сузсак та чиксез җиһаннарга,
Кеше белән кеше һич сыешмый—
Кот очарлык бәндә кылганнарга...

Безнең буын үтәр чал тарихка—
Яңа буын сабак тирәчәкме?!.
Әллә зәһәрерәк тар маңгайлар
Җирне түгел, Җиһан буләчәкме?..

### Башкорт җыры

Киртләч-киртләч Урал тавы илнең
Билкәйләрен ята уратып.
Ярым-ярты булмый аны сөеп,
Уралымны булмый югалтып.

Шундый бөек, шундый газиз
Башкорт җире.
Урал кебек биексең син,
Башкорт җыры.

Рамил ЯНБӘК (1952)—*шагыйрь, берничә китап авторы; З. Биишева исемендәге әдәби премия лауреаты. Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. «Агыйдел» журналының баш мөхәррир урынбасары.*

Агыйделнең, Сакмар, Юрүзәннең
Дулкыннарын гасыр буйламый.
Бер көн түгел, мизгел мөмкин түгел
Туган илкәйләрне уйламый.

Шундый татлы, шундый затлы
Башкорт җире.
Суларыңдай тирәнсең син,
Башкорт җыры.

Тере сыны булып узганнарның
Тик җыр гына кала бүгенгә.
Тарих кайтавазы, сызландырып,
Сеңеп кала безнең күңелгә.

Шундый моңлы, шундый уйлы
Башкорт җире.
Чал тарихтай серлесең син,
Башкорт җыры.

## Язгы җыр

Ак каеннар,ап-ак каеннар,
Тузларыгыз нидән каелган?!
Сез—тезмәсе иң саф хисләрнең,
Әллә шуңа күңел нечкәрде...

Нечкә генә билле сылулар,
Сыннарыгыз сутка тулырлар:
Соратырга язгы җил килгән,
Туй күлмәге инде тегелгән.

Тере җанга—илһам иле сез:
Сокланудан мин—бер тилегез—
Кәләшләргә сезне охшаттым,
Никах укып, туйга озаттым.

Озакламый сөю җимеше,
Гашыйк йөрәкләрнең тибеше—
Яшь яфраклар күзне назларлар.
Әлдә генә җирдә язлар бар!

## Туган көн

Ун меңенче яшем тула бүген,
Котлаучы юк—һичкем белмидер.
Шагыйрь яше—адәм яше түгел,
Күпләр моны, хәер, сизмидер.

Нәкъ йөз гасыр элек, хәтеремдә,
Мин ут булып җирдә яралдым.
Кыргый кешеләрнең йөрәгенә
Тәүге хисне, беләм, мин салдым.

Һәм бүлендем алсу чәчкә булып,
Ярты җаным калды ялкында.
Чүлләрдә мин чишмә идем берчак,
Җылы куыш булдым салкында.

Кара көчләр илгә ябырылгач,
Изге яуга чапкан батыр мин.
Кирәк булса, бүген мин яңадан
Шушы сыйфатыма кайтырмын.

Гашыйкларның моңсулыгын күреп,
Җаным күчеп китте былбылга.
Шуңадыр да мин—мәңгелек Мәҗнүн,
Гашыйк булам әле быел да.

Гасыр саен мин яңадан туам,
Җаным беткән меңгә бүленеп.
Һәр уландә—минем сутым ага,
Җырчы кошта—сайрый күңелем.

## Бәгырькәем

«Бәгырем» дип кемгә эндәшергә?
Хәлләремне шуннан үзең бел дә:
Үткәннәрдән килеп җылың тия.
«Бәгырем» дип кемгә эндәшергә...

Яшәгәнем әллә хата булды?
Яратканым гелән ятлар булды—
Януымны басар көч булсачы?!
Яшәгәнем, ахры, хата булды.

Бәгъзе көнем тик сырхаудан тора.
Язмыш кына шулай уен кора:
Мәңге тапмам ул Мәхәббәт дигәннәрен
Тоташ көнем тик сырхаудан тора.

«Бәгырем» дип кемгә эндәшергә?
Тиң түгелмен сиңа ярәшергә—
Тып-тын үтәр Янбәк дөньялыктан.
Бәгырькәем, кил син җирләшергә...

## Ялкытты

Беркемгә дә сине юк бирәсем,
Әмма ятныкы син, ятныкы.
Булсаң иде тик минеке генә—
Уртак ярлар сөю ялкытты!

Ярат идең мине Аллаң күреп,
Барлык җирдә бердәнбер итеп.
Ярат идең мин яраткан кебек,
Бозларымны минем эретеп.

Шул вакытта дөнья чагуланыр,
Фәрештәләр җиргә төшәрләр.
Керсен алар безнең йөрәкләргә
Салкын карда, юкса, өшерләр.

Беркемгә дә сине юк бирәсем,
Тик китәсең, син бит—ятныкы.
Гомер буе уртак ярлар сөеп,
Ялгыз калулары ялкытты!

❋



Талха
Гыйниятуллин

## СУГА БАТКАН КЕШЕ

ХИКӘЯ

Менә өченче ел инде авылны, аның бакчаларын, иген басуларын, печәнлекләрен корылык яндыра. Кайчандыр үтә алмаслык булып яткан сазлыклар кипте, аларның төпләре ялангачланып, ярылып, ташка әйләнде, тау башлары карайды, үләннәрен тамырына кадәр мал ашаган калкулыклар сырты чаңга әверелде. Колхоз малын ерактагы таулар артына кудылар. Картлар әйткәнчә, урман дымны тарта, дымны саклый икән. Тик анда шәхси малны алып барып булмый. Ач сыерларның бакыруларыннан хуҗабикә үзләре шашыр чиккә житте...

Үткән елгы корылыкны ничек тә үткәргәннәр иде әле, өченче елгы дым жиреннән бөтенләй китмәгән иделәр—саеккан сазлыклардагы түмгәкләрдә күрән баш калкытты. Сарай, чорма, чолан почмакларыннан күптән онытылган, тутыгып беткән уракларын эзләп табып, кешеләр шушы яшел массаны урырга ташланды. Кайдандыр, ялан як-яклардан колхоз малына салам ташыдылар.

Ә быел кыш карсыз килде, май, июнь айларында ерактагы тау аръягында авыр болытлар йөрде, ажаган ялтырады, яшен яшьнәде, тик кеше зур өмет белән еракта яуган янгырга күпме карасалар да, ул тауның бу ягына чыкмады. Авыл өстенә, ялан-тугайлар өстенә бер болыт әсәре булмаган яндыргыч зәңгәрсу пыяла каплап куйдылар мыни?! «Ахырзаман килә, бар тереклек һәлак булачак»,—диде картлар, баш чайкап.

Сирәкләп булса да авылга район түрәләре килеп чыккалый да кешеләрнең башына төшкән афәтне жиңеләйтергә теләгән йөз күрсәтә: уйлашырбыз, хәл итәрбез, ярдәмнән ташламабыз. Бу афәттә бер генә кеше, әйтик, председатель яки агроном гаепле булса, һич уйламый, алып ыргытырлар иде. Күк кәнсәләре белән алар ни генә эшли алсыннар инде? Күк житәкчелеге жирдәге чиновник алдында жавап тотмый шул.

Элекке парторг, хәзер инде пенсиядагы Абдрахманов Шәрип кайчандыр

Талха ГЫЙНИЯТУЛЛИН (1925)—*Уфада, Мәскәүдә һәм чит илләрдә чыккан күп китаплар авторы. Ватан сугышы ветераны. Хәрби бүләкләре бар. Аксаков исемендәге әдәби премия лауреаты.*

картэтисе ишеткэн Коръэн аятьлэрен хэтеренэ төшерде дэ, картларны жыеп, аларны яланга алып китте. Алар, Аллаһы Тэгаләнен ярлыкавына ышанып, аяусыз кояш нурларыннан янган иген басуында дога кылды. Юк, барыбер да ишетмәде Аллаһы Тэгалэ авыл картларынын ялварулы тавышын, эллэ башка мэшэкать-эшлэреннэн бушамыйча, аларнын сүзлэрен игътибарга алмады. Июньдэ жиргэ бер янгыр тамчысы да төшмэде, э июльдэ ни булачак?..

Июль башында картлар янэ басуга чыкты, дога кылды, ашыкмый гына кайтканда башларына төшкэн элеге бэла хакында сөйлэштелэр.

—Берэрсен суга батырмый булмас,— диде араларында ин өлкэн Шэйхислам карт.

—Ничек суга?

—Эүвэлге шундый йола бар иде: корылык килгэн елда берэрсе суга батса, биш көн рэттэн янгыр ява торган иде. Утыз бишенче елда нэкъ шулай килеп чыкты. Тегермэн буасында Абдулхак батты—янгыр яуды. Сиксэн тугызынчы елда күпер астында ике исерек балыкчы ауга уралып үлде, шуннан сон янгыр ике атна буе яуды да яуды. Э туксанынчы елда Гайнетдинов Шэфкать батты—корылык бетте.

—Э хэзер кайда батасын? Тегермэн буасы юк. Кичэ минем карчык елганы галошлары белэн кичеп чыккан. Күпер астындагы су малайларнын кендегенэ дэ житми. Комлы карьерга гына бармасан... Анда тирэнлек биш метрга житэ, төбеннэн чишмэ чыга. Балыкчы Нэжметдин батмасмы икэн? Көтик.

—Көттен, көтми ни! Нэжметдин йөзэ белэ, эчми дэ. Шулай булгач ничек батсын?

Көннэр үтэ торды, эмма беркем дэ батмады, ирлэр очрашканда ачулы шаяра да башлады: «Берэрсенен муенына таш бэйлэп, карьерга ташламый булмас! Өтэ бит, өтэ».

Июль июньгэ караганда да эссерэк килде. Көньяктан өермэ жиллэр исте, янган басулар өстеннэн кара тузан-туфрак күтэрелеп, юлларда өерелде.

Элекке парторг Абдрахманов Шэрип белэн Шэйхислам карт авыл түрэсенэ керде, шулай-шулай, берэрсен суга батырырга кирэк, юкса барыбыз да кырылып бетэчэкбез, тик берсе дэ батмый, нишлибез, дилелэр.

Кайчандыр авыл хужалыгы институтын тэмамлаган, яшь чагында үзенен туган колхозын алдынгылар рэтенэ чыгару турыда хыялланган, тик бу хыялдан күптэн өмет өзгэн, уңышсызлыкларыннан һэм махмырдан ачулы колхоз рэисе Салават, Шэйхислам картка мыскыллы гына карап, болай диде:

—Син, Шэйхислам абый, уже артыгын яшисен, шулай булгач, нигэ үзенэ батмаска?

—Бик батыр идем дэ,—диде Шэйхислам карт председательнен сүзлэренэ бер дэ үпкэлэми,—карчык бар шул. Ул чирле, минем ветеран пенсиясыннан башка ничек көн күрер икэн сон?

—Бэлки, болай итэргэдер, халыкны жыярга да шобага салырга кирэктер, э?!—диде элекке парторг.

Авыл администраторы Урал, түрэлек креслосына яңа гына утырган яшь егет, йөз-чыраена ясалма талэпчэнлек чыгарып, болай диде:

— Андый мөһим чара жинел генэ башкарылмый. Башта район белэн сөйлэшергэ кирэк. Син бит, Шэрип абзый, парторг булып эшлэгэн кеше, райком белэн килешми берэр чара үткэрэ торган идеңме? Юк.

—Ул чактагы чаралар бит партия, дэүлэт эше иде, э бу—безнен шэхси,

гаилә эше дигәндәй. Кеше бата, баткач, янгыр ява башлый. Монда районның ни хаҗәте дә, ни кысылышы бар?

—Теләсәгез ни эшләгез, тик бу эшкә без катнашмыйбыз,—диде рәис канәгатьсез генә.—Белегез, бу турыда сүз булмады; сез әйтмәдегез, без ишетмәдек.

Иртәгесенә элекке парторг идарә йорты алдына халыкны җыйды. Кешеләр Шәрипнең парторг икәнен яхшы белә, һаман хәтерли, иске гадәт буенча һаман аңа ышаналар, аны тыңлыйлар иде.

—Җәмәгать!—дип мөрәҗәгать итте ул халыкка.—Хәлебезне барыгыз да яхшы белә. Гомердә күрмәгән корылык. Унышка өмет юк, чәчкән игеннәребез янып-көеп бетте, яңгыр яуса, үлән күтәрелер әле. Малтуарны чыгара алырбыз, ичмасам. Көздән туфракка дым сеңеп калса, кыш карлы килсә, киләсе елда, Алла бирсә, тын алырбыз, дим. Болар барсы да үзебездән тора, җәмәгать. Табигатьтә шундый тәртип бар икән: корылык елында кеше суга батса гына янгыр явачак. Андый хәл безнең авылда элек тә булган. Тик быел бездә кеше суга батмый, шуңа да корылык һаман дәвам итә. Көчләп беркемне дә бу эшкә күндерә алмыйбыз. Мин шобага тартырга тәкъдим итәм. Хатын-кыз, балалар катнашмый. Ризасызмы?

Кешеләр эндәшмәде. Алар элекке парторгка тулысы белән ышанырга өйрәнгән иделәр, ул грамоталы, фикер-тәкъдимнәрен ихтирам иттеләр, әмма бүген әйткәннәре бердә адәмчә түгел, шуңа да аптыраашта калдылар.

— Ә син үзең тартасыңмы ул шобаганы?—дип кычкырды склад мөдире Мортаза, бераздан.

—Ә нишләп тартмаска!—дип җаваплады элекке парторг.

—Батасыңдамы?

—Батам да.

— Ә мин риза түгел!—дип чыелдады тракторчы Рифатның хатыны Зөләйха.— Иремә чыкса, мин ике бала белән утырып каламмы?

—Без дә риза түгел!—дип гөжләде башка хатын-кыз бердәм рәвештә.

—Ярый алайса,—диде Шәрип, тавыш ышанычсыз чыкты.—Алайса мәсьәләне икенче төрлерәк хәл итик. Сугышта мөһим, куркыныч эшкә доброволецларны җибәрә торган иделәр. Ротаны тезәләр дә, кем дә кем үз теләге белән барырга риза, ике адым алга, дигән боерык бирәләр. Чыгалар, баралар, үләләр. Менә мин дә шулай дим, кемнең үз теләге белән суга батасы килә?

Янә дәшмәделәр. Исерек Әхәт кенә, давай, син үзең бат, шәп булгач, дип әйтеп караган иде, халык канәгатьсез генә гүләгәч, ул да хәбәрен дәвам итүдән тыелды. Элекке түрәгә, олы яшьләрдәге ихтирамлы кешегә үз теләге белән үлемгә бар, дип әйтүе ничектер кыен шул.

Ә Шәрип тагы сүз башлады:

— Арагызда, бәлки, коммунистлар бардыр! Ул фронтта да алда булды. Менә син, Шәрифулла, карт коммунист, моңа ничек карыйсың?

— Без фронтта түгел,—дип җаваплады пенсионер Шәрифулла.—Аннан килеп, мин нинди коммунист? Синең ул партияң кайда соң? Таралды бит...

— Безнең яктан Александр Матросов коммунист та булмаган, шулай да күкрәге белән дошман амбразурасын каплап, барыбызны да Гитлердан коткарды. Шуның сыман, кем дә булса, безнең балаларны ач үлемнән коткарып калырга тиеш тә инде?

Янә дәшмәделәр.

Алга колхоз шоферы, хәзер пенсионер, законга, тәртипкә ябешеп ятучы, жыелышларда сөйләргә яратучы Ваһапов Хан чыкты. Анын турында, эче кара, кеше хакында гомер буе бер жылы сүз әйткәне булмады, дип сөйлиләр.

—Без монда юк-бар сөйләп, нәрсәгә вакыт әрәм итәбез? Шобага, доброволецлар, имеш. Авылда бернәрсәгә ярамаган, ялкау, эчкече, урлашкан кешеләр беткәнмени? Менә шундыйларнын берсен тотарга да батырырга. И вәссәлам, бетте-китте.

—Йә, кемне тәкъдим итәсен?

—Ну, әйтик, минем күрше Исмәгыйльне. Айлар буена эчә. Эшләми. Аракыга кайдан акча таба? Значит, урлый. Жәмгыятькә бер тиенлек тә файдасы юк.

— Хайван, үзен бат!—дип кычкырып жибәрде Исмәгыйльнен хатыны Шәүрә, наркологиядә дәваланып кайткан алкоголичка.—Авылда ләчтит сөйләп йөрүче бер кеше кимер, ичмасам.

—Жәмәгать, тынычланыгыз. Бик житди мәсьәлә тикшерәбез, бер-беребезнен бугазына ябышмыйк,—диде элекке парторг, гүли башлаган халыкка карап.

—Гатаулланын кызын батырсак? Акылга бер төрле нәрсәдән безгә ни файда? Хөкүмәткә дә зыян. Пенсияне миннән күбрәк ала, ә акчасын Гатаулла эчеп бетереп тора,—дигән тәкъдим кертте пенсионер Шайморат.

—Без бит бу эштә хатын-кызлар белән балалар катнашмый, дип килештек.

—Алайса, әйдәгез, Моталлап картны. Яшәве бик озакка китте, үзе дә үлә алмый йончый шикелле.

Моталлап картка тагын бер елдан туксан яшь тула. Күптән түгел генә ана операция ясадылар, сидек куыгыннан тышкы якка резина шлангы чыгып тора, очы шешәгә тыгылган. Карт, ихатасына яки урам буена чыкса, шул шешәсен тотып йөри.

— Олы кешене үтерү—гонаһ!—диде Гөлбикә карчык.—Вакыты житкәч, Аллаһы Тәгалә сезсез дә, аны үз янына чакырып алыр әле.

— Нигә жәллисен? Ул бит заманында сүз йөртте, шикаятьләр язды, күп кешене төрмәгә утыртты.

—Әгәр анау «бизнесмен»ны корбан итсәк?—дип тавыш бирде янә Ваһапов Хан.—Өченче көн калага барган иде. Исәр дигәч тә исәр инде, шешә тулы биштәре белән автобуска кереп утырды да сүгенә, юк-бар сөйли башлады, шуннан, чалбар төшереп, оят жирен күрсәтергә тотынды. Ә автобуста хатын-кыз, бала-чага. Андыйлар дурдомда утырырга тиеш, утырмый икән, үтерергә кирәк—бер файдалары да юк.

«Бизнесмен» дип олигофрен егетне йөртәләр. Ул буш шешәләр жыя. Бәләкәй кул арбасы сөйри дә авыл тирә-ягы, елга буйлап чыгып китә, арба тутырып, шешә төяп кайта, шуларны юа, капчыкка тутырып, калага тапшырырга алып бара.

— Нишләп файдасы булмасын?—дип каршы төшә бу тәкъдимгә кырык яшьләр тирәсендәге мыеклы Әнвәр, эчмәгән, тартмаган, бөтен эшкә дә кулы килешкән ир—балта остасы, мич чыгаручы, телевизор ремонтлаучы, житмәс картиналар да яза.—Ул булмаса, авылны күптән буш шешәләр басар иде. Хәзер бит шундый мода китте—өйдә эчмиләр, яланга чыгып эчәләр. Елга буен сәрхүшханәгә әйләндерделәр. Бала-чага шуны вата да

суга ташлый, аякларын кисәләр. Шулай булгач, шешә җыю безгә файда түгел мени? Гаиләсенә дә файда: төсле телевизор сатып алган, энесенә мопед бүләк иткән.

Каршы төшүче булмады Әнвәргә, аның сүзләре белән барысы да килеште.

—Һаман акыл сатабыз, әйтерсең дә безнең арада файдасыз кешеләр юк,—дип янадан сүз кыстырды Шаймөрат карт.—Буранбай шушы эшкә ярамый мыни?

—Бөтен Русия дәрәҗәсендәге алкоголик,—диде берәү.

«Бөтен Русия дәрәҗәсендәге алкоголик» дигән почетлы исемне Буранбай үзенә-үзе таккан: «Мин, Хәкимов Буранбай, ягъни, Зәйнәпович, Зәйнәпыч, Бөтен Русия дәрәҗәсендәге алкоголик»,—дигән.

Кырык яшьлек Зәйнәпыч юньләп беркайда да эшләми. Пилорамга урнаштырып караган иделәр, колхоз такталарын сатып эчте, аннан пожаркага күчте янгында йоклап калды. Бер мәл «шабашка»да йөрде: эчү хакына кемгәдер өй, мунча бурады. Әнисе пенсиягә чыккач, пенсия акчасын тартып алып, эчә башлады, бирмәсә, тукмады. Әнисенә кул күтәргәне өчен, бер елга утыртып та карадылар, кайткач та иске гадәтен ташламады. Атасын хәтерләми. Хәер, авылда белмиләр аның атасы кем икәнен. Берәүләр, аның тууын бу якларга каяндыр килеп чыккан старатель белән бәйли, икенчеләр—урлашканы өчен төрмәгә утырттылар, шунда үлгән, дип сөйли. Шуңа да аны, Буранбайны, әтисенең исеме белән түгел, ә шаяртып, әнисенең исеме белән Зәйнәпович яки кыскача Зәйнәпыч, дип йөртәләр.

— Дөрес, нәкъ аны батырырга кирәк, нишләп шундук искә төшмәгән?—дигән авазлар ишетелде халык арасыннан.

—Алайса тавышка куям, җәмәгать. Кем дә кем Буранбайны суга батырыйк ди, шулар кулларын күтәрә. Бер тавыштан. Каршылар юк.—Ниһаять, мәсьәләнең очына чыккан элекке парторг канәгатьлек белән тирә-ягын карап, әйтерсең лә, дәүләт дәрәҗәсендәге проблемасын хәл итте.—Кайда Буранбай?

—Ул юк, килмәгән.

—Чакырыгыз.

Буранбай идарәдән ерак түгел, зиратка бара торган тыкрыктан өченче йортта яши. Көн иткән йорты чигеп, кыйшайган, җитмәсә, авылда бердәнбер телевизор антеннасы булмаган йорт. Аларга керүче бик сирәк, юк фигылендә, сугылганнар да ярлылыкны, мескенлекне күреп: «ничек яшиләр, ой, ничек яшиләр?»—дип баш чайкап чыга.

Буранбай белән әнисе өйләреннән чыкты да кеше төркемәнә кушылды. Шешенгән, бит-йөзен сакал-мыек баскан, күзләренә кан сауган, сәләмә киемле Буранбай чүп-чар, ашамлык калдыклары ыргыткан чокырдан пәйда булган нииндидер сәер бер җан иясе кебек иде. Бөтәшер чиккә җиткән кысык күз карашлары буш һәм томанлы, кан тамырлары бүртеп торган куллары туктаусыз калтырый.

—Нинди митинг бу?—дип мөгердәде Зәйнәпыч.

—Сине суга батырырга хәл иттек!—дип кычкырды халык арасыннан берәү.

—Ничек батырырга, кайда?

—Аракыда.

—Аракыда булса, ярар,—дип канәгать җаваплады Буранбай, шуннан чак кына эндәшми торды да.—Аракыда мөмкин, мин риза,—дип өстәде.

Буранбайның әнисе, Хәкимова Зәйнәп, яшь чагында, күрәсең, мөлаем генә хатын булгандыр, тик хәзер, илле җиде яшендә, җитмеш яшьлек әби сыман күренә. Кара күзләре сак, куркып карый. Улы сыман ул да сәләмә киемдә, ситсы күлмәге күп юудан төссез чүпрәккә әйләнгән, башына унган, билгесез төскә кергән яулык ябынган. Төссезлеккә таушалган зәңгәрсу йон джемпер, колакларындагы эре сары пыяла алкалар гына җан биргәндәй. Хатын гәүдәгә бәләкәй—янында торган үсмер малайдан чак кына калкурак.

Зәйнәпнең дә, аның улы Буранбайның да алдагы көннәрдә юньле тормыш белән яшәмәячәге, яши алмаячагы күренеп тора иде.

— Зәйнәп,—дип мөрәҗәгать итте Шәрип.—Хәлне беләсең, өченче ел корылык. Табигатьтә шундый тәртип бар: яңгыр яусын өчен берәрсен суга батырырга кирәк. Шунда җыелган халык синең улыңны корбанга бирергә карар чыгарды. Ул бөтенләй файдасыз кеше, хәтта зыянлы, бушка азык черетүче паразит, ичмасам, үзенең үлеме белән җәмгыятькә файда китерсен. Буранбай, җәмгыять өчен суга батырга әзерсезме?

—Беләсеңме, кая кит!..—Буранбай сүгенде.

— Ничек инде батырырга?—дип аптырады Зәйнәп, улы иңенә төшкән җәзаның мәгънәсе аңа һаман барып җитми иде шикелле.—Минем улымны суга батырырга ниятлисезме?!

—Әйе, синең улыңны шул. Халык бер тавыштан кул күтәрде, значит, батырабыз!—диде элекке партком ышанычлы итеп.

— Ничек?.. Ул бит минем берд әнбер балам. Мин аны йөрәгем астында йөрттем, авыр таптым, ә сез суга батырырга җыенасыз. Юк, мин риза түгел!

— Әгәр быел яңгыр яумаса, киләсе ел бернәрсә дә үсми, значит, без һәммәбез дә ачтан кырылачакбыз. Дәүләттән ярдәм көтәсе юк, кул кушырып ятарга, элекке вакытлар үтте хәзер үзебез...

—Кырылсак кырылабыз, тик улымны бирмим!

—Зәйнәп, сугыш вакытында безнең әниләр, минем ризалыгым юк димәде. Әнә обелиск тора, анда йөздән артык фамилия язылган, алар барысы да сугыш яланнарында башларын салды, үзләрен без тере калсын өчен корбан итте,—диде Шәрип, парторг чагында сөйләгәнчә тамак төбе белән.

—Барыбер ризалыгым юк!

— Ә сез Буранбайның үзеннән сорагыз, ул үзе ризадыр, бәлки,—диде тракторчы Садыйков Шәфкать.—Әй, Буранбай, батырга телисеңме?

Буранбай бу эшне һаман чынга алмый иде шикелле, яки азагына кадәр төшенеп җитмидер. Алдындагы бер ноктага текәлгән дә тик тора аны махмыр бөгә, махмыр калтырата.

—Ул нинди балаң булсын инде? Пенсияңне эчеп бетереп тора, җитмәсә, тукмый,—дип хәбәрен янадан тезде Шәрип.—Ансыз, ичмасам кешечә яшәп калырсың. Ял итәрсең. Рәхәт яшәүнең ни икәнен белерсең.

—Ризалыгым юк!

—Ярый, алайса синең ризалыктан башка гына батырырбыз. Халык хәл итте инде. Бармаса, тотып бәйлибез дә, муенына таш асып, карьерга ташларбыз. Шулаймы, җәмәгать?

—Әйе, шулай!—дигән тавышлар ишетелде төркемнән.

Зәйнәп янә аптырап калды, бәләкәй йөзендәге җыерчыклары тартышты, тешсез авызы кыйшайды, иреннәре дерелләде. Ул зур кыенлык белән төкерерген йотты да, улына нәфрәтле карашын ташлап, кычкырып җибәрде:

—Батырыгыз!—шуннан баскан җирендә таптанып алды, кулларын селтәде.—Кеше түгел, хайван дип тә булмый аны. Хайваннан кешегә файда, ә бу армиядән кайтканнан бирле кул да кыбырдатмый. Канымны эчте. Тукмады, идәнгә сөйрәп төшереп, типкәләде. Карагыз, нинди көнгә калдым мин. Өйдәге бөтен нәрсәне сатып эчеп бетерде бит, хәшәрәт! Сыерны саттык—берүзем печән әзерли алмадым. Колхоз утын белән ярдәм итмәсә, без күптән бу җимерек өйдә туңып үләр идек. Озакламый ачлыктан аяк сузачакбыз. Батырыгыз, мин риза. Коткарыгыз мине бу паразиттан!

Зәйнәпнең сүзләреннән кешеләр аптырап калды, чөнки уй-ниятенең шулай кинәт кенә кирегә үзгәрүен һич көтмәгәннәр иде. Байтак кына тын торганнан соң элекке парторг Буранбайга эндәште:

—Күрәсеңме, хәтта үз әниең дә синнән баш тарта. Бар, үзеңне көч белән алып барып ыргытудан коткар безне. Яңгыр яуса, әйбәт итеп телгә алырбыз, рәхмәтләр укырбыз. Мондый үлем хайваннарча эчеп үлүгә караганда яхшырак бит.

—Баш төзәтергә табасызмы соң?—дип мөгердәде Зәйнәпыч.

—Табабыз. Күпме телисең, шул кадәр. Тик бат кына.

—Өч шешә... Минем үземне дә шундый тормыш ялыктырды.

Акча җыйдылар, кемдер магазиннан өч шешә аракы алып килде. Шуларның икесен Буранбай пычрак чалбарның кесәләренә тыкты, өченчесен тешләре белән ачты да, шешә авызыннан гөпелдәтеп эчә-эчә, өе ягына атлады. Ул кузгалгач, кешеләр дә таралыша башлады. Атлый-атлый батырга тиешле Буранбай турында сөйләштеләр. Берәүләр, күрегез дә торыгыз, алдаячак ул, батмаячак, зерә алып бирдек аракыларны, диде, икенчеләр, батачак, кайда барсын, ә Ваһапов Хан, өч шешәдән соң бер нәрсә белми йоклаячак, иртән килербез дә бәйләп карьерга алып барырбыз, диде.

Төнен кешеләр күк күкрәүгә, яшен яшьнәүгә, тәрәзә пыялаларына көлтә-көлтә яңгыр бәрүеннән уянды. «Аллага шөкер,—дип шыбырдашты алар.—Рәхмәт инде Буранбайга, тыңлады, яудырды бит!» Яшен зират эчендә үскән карагачның очын атып төшерде, подстанциянең трансформаторын яндырды, кайсы кешеләрнең кыекларыннан су акты, таудан ургылган ташкын тыкрыкның теге очында яшәгән Рамазанова Хәдичәнең ихатасын басты, базына төште.

Таң атуга яңгыр тынды, дөресрәге, ялкау, вак сибәләүгә күчте. Ә төш җитәр алдыннан, көн кабагы тамам ачылгач, кешеләр багорлар алып комлы карьерга китте—баткан кешене су төбеннән сөйрәп чыгарып, җирләргә кирәк иде. Әмма яр башында алар яңгыр суы белән тулы иске галошларга, бер-берсенең өстенә тәртипле итеп салынган төссез яулыкка, зәңгәрсу йон джемперга, эре сары пыяла алкаларга гына тап булды...

Ә Буранбай Зәйнәпович бу мәлдә, эчкән өч шешә аракысыннан соң өстенә аккан тамчыларга да уянмый, иреннәрен чәпелдәтә-чәпелдәтә исерек йокы белән йоклый иде.

♣



Сабир
Шәрипов

# КАРАК

ХИКӘЯ

Тын урамнан берәү атлый. Көн салкынчарак булса да ул яланбаш, йон беретын портфеленә кушып тоткан. Җиңелчә агарган калын гына чәчләрен, ара-тирә башын чайкаштырып, буш кулы белән унга-сунга сыпыргалап куя. Зәңгәрсу плащының изүләре ачык, чабуларын әрсез җил чая гына каккалый. Төсе-чыраена карап кырык тирәсен биреп була үзенә.

Район үзәге саналган, хәтта калача йорт-каралтысы хәтсез тоелган поселок урамында әле адәм заты сирәк очраштырса да, нигәдер ир, кемнәндер шүрләгәндәй, вакыт-вакыт туктап, тәбәнәгрәк итләч гәүдәсен өне өстенә калкынып баскан әрлән кебек җай гына борып, берчә узган, берчә барыр юлын айкап ала. Кунакка килгәнме? Командировкагамы? Тәүге тапкыр чит авылга ятсыныбрак керәсең шул.

Ангартмастан янәшәдәге таш йортның аргы кабыргасыннан нәрсәнедер дыңгылдатканчы тибеп җибәрделәр, тибелгән нәрсә яньчелгән тартма икән—юлаучыны шыелдык җиле белән сискәндереп, кызулыгын югалтты да җай гына тротуар читендәге янгыр күлләвегенә елышты.

Аңарчы тыкрык чатында пәйда булган елгыр малай, үткенчене өркетеп, өстенә үк ыргый язды.

—Һый-ый, шалапай!—Иркәйнең тавышыннан дертләү, шул ук вакытта тәкәбберлек, эрелек сыйфатлары чагылды. Малай беразга тагын нәрсәдер көткәндәй карап тора бирде, агай кеше инде аны күзгә дә элмәгәндәй ары узды. Малайның иреннәрен бөршәйтеп үзен үчекләп калуын күрмәде ул.

Баягы эре күзле янгыр нык сеңгәндерме, әллә электән бурсуы житкәндерме, такта тротуар ачык тыкылдамый.

Иртәләгән көз... Яфраклар сарыга сабышмас борын ук елак көннәр ешайды, аяз таңнарда кыраулы салкыннар тынны куыра.

Юлаучы ике катлы кунакханә ягына борылмады да. Шулай да авыз чите белән генә көлемсерәми булдыра алмады: кайчандыр шушы йортның шәп җиһазлы аулак бүлмәсендә үз тиңендәге, ягъни уртачарак түрә-кара белән типтергәннәрен хәтерләде. Әвеш-тәвештән кергән акчаларга. Иркенрәк иде шул элегрәк дөнья кадерен белгән елгыр бәндәләргә. Хәер, хәзер бигерәк тә...

---

Сабир ШӘРИПОВ (1948) — *төрле телләрдә чыккан дистәләгән проза китабы авторы. Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.*

Озынкүл тугайларыннан дымсу һава бөркелгән кебек. Инде такталы сукмак бетте, кырчынташлары таралып яткан киң, мәйдан сымагырак ачыклыкта күкрәге иркенәйгәндәй тоелды. Иркәй, портфелен куеп плащының төймәләрен чырт-чырт каптырды, билбавын җайлап буды, беретын рәтләп кийгәч, кулларын уды. Авылның бирге очында шулай да җанлырак икән. Еракта мылтык аткандай лау-лау эт өргәне ишетелә, кайдадыр көтү кайтканын көтеп бозау мөгри.

Кемдер алачыгында чаңкытып тимер чүки. Чаңк-чаңк... Ирексездән юлаучының күңеле «теге чак...», «теге чак...» дип дертләнгәндәй итте. Теге чакмы? Беренче килүе бораулыймы миен? Әллә соңгысымы? Соңгы тапкыр, калкулыктагы очтән икенче, а-анау өйгә, былтыр...

Куйчы, куй, искә төшермәвен хәерле. Кайчандыр сирәк-мирәк, егетләрчә җилкенеп барып керә иде алдында карт шомырт үскән иске, әмма ныклыгын югалтмаган җыйнак өйгә. Кызык, капка баганасына элек калайдан кисеп беркетелгән кызыл йолдыз торамы икән һаман?

* * *

Элеккеге сабакташын өч-дүрт ел элек уйламаганда очраткан иде. Сабакташы дип, ни бары тәүге курста бергә укыдылар вузда. Җәйге каникулдан соң кызый үз теләге белән укуын өзәргә мәҗбүр булды. Фронтовик атасы гүргә киткән, анасы түшәккә егылган...

Азак ятакта «кызып»-«кызып» диплом юган кичтә кемдер Озынкүл кызын телгә алды, «бичараның анасы да дөнья куйган бит,—дип кызганды.— Яшәве кыен булыр аңа, күңелгенәсе бигрәк йомшак»,—дип тә юраган иде өстәвенә. Менә шулай, еллар үткәч, сулар аккач, әлеге узамын—түрәкәй көтмәгәндә аны, ягъни элеккеге сабакташын, кышкы чилләдә Озынкүл универмагында очратты. Кыйгач кара кашлы, коңгырт күзле, аксыл йомры битле, ымсындыргыч иренле хатынкайны ничектер нык таныш, кайчандыр якын күргән кешегә охшатты.

Гади, әмма килешле киенгән хатын да үзенчә гаҗәпләнеп, таныр-танымас текәлде, әзгә генә йөзенә моңсу, сабыр елмаю ягылгандай булды. Хәерсез, исеме истә калмаган ләсә гәүдәгә юка гына монау хатынның.

—Саумы, Бәләкәч!

—Саумысыз, Озын абый...

Шул! Шул! Кайчандыр бергә агрономлыкка укыган сабакташы бит.

Армиядән кайткан егетебез ниститутта чакта ук үзеннән яшькә дә, буйга да кечерәк Озынкүл кызын шаяртып шулай сәламләгәне, ә җавапка «үзең озын булгач та», йә, «табылган озын абый...» дигәнерәк эчкерсез мыскыллау ишеткәне булды.

Кармак салырга да чамасы бар иде егетнең басынкы, итагатьле кызга. Тик нигәдер тартынды. Елмая төшкәннәргә сырпаланды шул.

—Нинди җилләр ташлады дисеңме?—күрешеп тормадылар, син дә мин сүз куерттылар.—Сез баерак бит, чәчүгә орлык теләнеп йөргән көн әле. Әй, бетмәс инде минем мәшәкать... Агропромның баш агроном камытын кигәнче, райкомда да йөгергәләп алдым әле бераз.

—И түрәлек бата шул Сезгә! Староста идегез бит әле группада. Партработник икәнегезне районыгыз гәзитеннән укып белгән идем әлегерәк.

Агроном аулак кибеттә гәпләшүдән үзенә җан рәхәтлеге, бераз шуклык өстәлүен сизеп, хәтта кайры тун төймәләрен ычкындырып ук җибәрде, кондыз бүреген кырынрак салды, «Бәләкәч»нең хәл-әхвәлләрен төпченебрәк белешергә, үзенекен күпертебрәк тасвирларга тырышты, «син»гә күчәргә кушты.

—Әй, Бәләкәч, Бәләкәч, укыганда бит мин, кайчан зурая инде бу, дип кызыга идем, валлаһи,—дигәч, тыелып калды, югыйсә, «хәзер син әнә нинди

симпатичный бичә» дип төчеләнмәкче иде. Сабакташының гаилә хәлләрен сорашырга да онытмады, тик икеле-микеле генә фикердә калды.

—Унмадым шул...

Укуын ташлап кайткач, сабакташы бераз почтада гомер уздырган, аннан китапханәгә күчкән, читтән торып техникум тәмамлаган. Бертуган энесен язын Армиягә озатмакчы...

Йомышы булмадымы, сатучыларның ләчтитеннән өректеме, хатынкай тышка ыңгайлады. Иркәй аны хәтсез генә озата барды.

Машинасы якында булмауга үкенеч белдерде. Әмма юлдашы моңа әллә ни әһәмият бирмәде. Хушлашып, Бәләкәч купшы, җыйнак кына ак пималарында кыланыбрак басып арытабан юргалады. Авыз-борыныннан тонык бу бөркетеп карап калды агроном. Икенче сәфәренә ул юк йомышны бар итеп чыкты, мәшәкатьләрен чәмләнеп кенә төгәлләде дә сабакташының өенә кайтыр юлын каравыллады. Тәрбияле агачлар уртасында икән китапханә. Яссы тагаракта вак кошлар чыркылдаша, сыерчык оясыннан озынча томшык елт-елт итеп кала. Чуак май урталары иде ул вакытта. Тегесе дә очрашуларына әлләни аптырамады. Сөйләштеләр, серләштеләр. Хатынкайның эчкече иреннән аерылып, тол яшәвен искәрткән иде инде агрономга Озынкүлдәге бер әшнәсе. «Яманаты таралмаган, дәртенә дәрман»,—дип бик мут кына күз дә кыскан иде. Юк, болай гына сорашам, дип котылмакчы иде дә: «Болаймы, түгелме, аның да бит бар жаны»,—дипмедер хихылдаган иде коллегасы.

—Ни бит әле, кунакханәне читтән киләчәк делегациягә бушаттыралар,—дип хәйләләде агроном.—Синдә генә берәр кич төнлимче. Ишек төбендә генә ятармын...

Ләм-мим. Бары тик елмаю. Рәнжүле елмаю.

—Адресың кирәк, энгердә чәйгә килермен, иптәш Бәләкәч.

—Кичме? Ярамый. Жиделәргә мөмкин. Очтан икенче өй.—Хатын ияге белән үзе яшәгән якка ымлады.—Шомыртлы...

Агроном әллә кисәтүне онытты, әллә ярамыйга карамады, хәленчә купшыланып, караңгы төшәр алдыннан гына алдындагы шомырт шау чәчкә аткан йортны тапты. Хуҗабикә аны көткәнгә охшый—пешеренгән, эре бизәкле юка күлмәк киеп алган. Кунак та буш килмәгән, кайдандыр тапкан тәм-томын,затлы шәрабын куйды.

Рәхәт иде икесенә дә. Кызмачалангач, Иркәй көлдергечләр ләпелдәп маташты. «Бер начальник секретаршасын алмаштырган. Жингәй абзыйдан сорый икән: «Йә, ничегрәк киенә яңа кыз?»—Жәһәт кенә киенә, маладис, димәсенме абзый».

—И ходай, хәзерге ир-атның уенда гелән бозыклык инде, кинода да шул, китапта да...

Тиздән солдат энекәшенең магнитофоны кабызылды, болар йомшак келәмдә биергә керештеләр. Кунак хуҗабикәнең биленнән кысты, нәзакатле хушбуй исенә исергәндәй, башын чайкап, колагына нидер шыбырдады... Тансык канмас мәхәббәт чишмәсенә чумгандай хис итте үзен Иркәй. Кара таңнан аны хәвеф катыш назлы тавыш уятты.

—Уян зинһар. Ходаем, уйламаганда баттым гөнаһка. Үлемнән оят көчле—кеше шәйләмәс борын китеп кал. Каенанам сизеп калса—бетте баш.

Хатынкай чынлап та шүрли иде элеккеге каенанасыннан. Ерак та яшәми бугай тегесе. Пешмәгән улын кабат әлеге йортка китереп кертер өчен әллә ничәмә кергән бу тупсадан. Килене жайга килми, улы Себер ягына олаккач, эзәрлекләргә, шымчыларга керешкән.

Хөсеттер инде, улым белән уңмаганны, башка ирдән дә уңмасын, диюедер.

—Тор, яме. Тамагыңа әзер.

Киерелеп сузылды да, кинәт кенә мут елмаеп Иркәй Хатынкайны жылы

кочагына алды. Кабат йомшак түшәккә аудылар, иркәләшкән-үбешкән булдылар.

—Бәләкәчем генә бит әле!

—Алтын зур булмый, диләр.

—Тәкъдим шундый: бүген эшенә барма да куй. Кич килгән идем, кич кайтырмын.

—Килешми, ничек аңлатыйм үзебезнен юбкалы газраилга?

—Ярый соң, китәм. Икенче юлы жилдертеп «Жигули»емда килермен. Ә служебныйны монда йөртү, син әйтмешли, килешмәс.

—Шулай кирәк, начальство булдым дигәч тә...

Түшәктән калкынган арада кунак каршы стенадагы куш портретның—хуҗабикәнең ата-анасы төшкән зурайтылган фотоның челтәр белән каплануын шәйләде.

Сынап карап тормагыз әле, оялам, дигәндер дә фотоны каплагандыр Бәләкәч. Шуны уйлап, сөяркәсенең әйткәннәрен аңламый калды, соңгы сүзләрен генә ишетте:

—Машинаң шәптер шәплеккә, тик монда дырылдата күрмә. Әгәр яманлык теләмәсәң, вообще кабат каңгыртма мине, яме. Ансат дисеңме әллә... яратмыйча. Кияүгә чыкмам дип нәзер дә әйтмәгәнмен әле. Соратканнар, димләгәннәр эт тубыгыннан.

—Уеннан уймак чыкканны хупламыйм мин. Холкым шулайрак. Ярату?.. Сине яратмыйм дигән кеше юк бит әле.

—Кыен миңа барыбер.

Кайда ул... Очраштылар.

Озынкүлгә тиклемге хәтсез генә араны Иркәйнең көненә ураган чаклары да булгалады. Тик килгән-киткәндә кеше күзенә чалынмаска—шомыртлы өйдә бу шарт катгый иде.

...Ямьле бер көнне Озынкүлнең аргы ярында кояшта кызындылар, сарык итеннән шашлык әзерләделәр. Табында Иркәй кызарып пешкән майлы итне биргәндә:

—Иң тәмлесе—сөяркәмә,—дип күнелчәкләнеп урысча ычкындырмасынмы. Үпкәләде, кылтымбикәләнеп торып ук китте гүзәл зат.

—Шушы этне адәмгә санаган мин исәр.—Чынлап ачуланды Бәләкәч. Бераз тынычлангач, йомшак кына итеп, мәкерле генә сорау чәпәде.

—Хатыныңны яратасыңмы соң?.. Яшерми генә әйт.

—Әллә инде... Юктыр. Монда ятмас идем ләсә. Аждаһа ул минем бичә! Харап рациональ дама!

—Уртак кыек астында яшисең икән, сатма хәләлеңнең гайбәтен.

—Ай усалсың! Хакны язган икән бер француз: бәләкәй хатыннардан сак булыгыз, дигәнме шунда,—көлемсерәгән булды чакырылмаган кунагы.

* * *

Ат күргән иде, аягы талды, дигән сымак, якыннан лыч су печән төялгән арба узгач, ул кинәт кенә үзендә арыганлык сизде. Картаямы? Иртәрәк әле. Бәлки, тән аруы түгелдер, рухый йончу бәласедер? Рас икән, менә баягы иләс-миләс хатирәләрнең дәвамы сәбәпче иде.

Чаңк!.. Чаңк!..

Ни гыйльлә бетмәс тимер чүкү ул? Ары барыргамы, әллә тәртәләрне кире борыргамы? Жиде үлчәп, бер кисер мәле житкәнен аңлап, Иркәй аскарак, күл ярынарак тартылды. Яшен аткан тирәккә бөршәеп кенә терәлде. Нигә моратына житәрәк кенә чыгымлады әле? Язгы тышаулыйдыр аякларын. Ирләргә—ирлек, хатыннарга—хурлык, дисәләр дә Озынкүл гүзәле белән гашыйк жепләре ныграк чәбәләнә төште.

Әйдәп-чакырып торган кебек тә Бәләкәчнең басынкы тавышы, читләткән—куган кебек тә.

—Кабат килмә, яме. Тагын килсәң, бала табам да куям. Курыкма, алимент түләтмәм. Кеше каршында роддомнан гына өйгә илтерсең... Йә алып аер, борынгыча...

Булды, мондыйрак тәкъдимнәр дә булды. «Бала» дигәч, «давай» дип сер бирмәскә дә маташып карады Иркәй. Ә соңгы тапкыр...

* * *

Әйе, көз иде, урак ахыры житкән аяз мәл иде. Иртәгә—авыл эшчәннәре бәйрәме көне дигән кичне кесәсенә мул гына премия салып кайткан иде баш агроном. Эшендә аны яманламадылар, тиздән агропромга баш булырын көткәннәр бар. Кызганыч, райдепутатлыкка үтмәде. Үзе ныкышмады, елгыррак, әрсезрәк тотыну фарыз булган.

Күл яклап кабыргага жил какты. Иркәй йомшак беретын батырыбрак киде. Сөяркәсе бүләк иткән иде бу беретны. Энемә янадан бәйләп куярмын, сиңа язган икән, туган көнең якынлаша шикелле, дигән иде. Килешми сиңа эшләпә, япон шпионына охшыйсың, дип тә көлгән иде, житмәсә (Шпиклар японда гына бардыр шул). Үз өендә Иркәй, базарда сатып алдым, дипме, ансат котылган иде.

Әйе шул, өенә байтак акча белән кайтты кайтуын, ә хатыны тырт та мырт. Әллә бер-бер... Озынкүлдәге каенанасы чокындымы, бетте башың. Килененә астыртын гына килеп йөрүен сизеп, исем-шәрифләреңең очына чыктымы, хәләленә шалтыратуы, йә берәрсе аша хат жибәрүе кыендыр шул әбекәйгә.

—Сөенче бичәкәй. Пыяла туй үткәрерлек премия чәпәгәннәр бит әле мина,—дигән булды хужа хатынының көйсезлеген сүрелдерү ниятеннән. Ә тегенәргә житә калды—бәйсез эттәй чөнкелди дә чөнкелди, еламсырап ала.

—Озынкүлдә туй үткәр, оятсыз. Шалкан кебек улың, алма кебек кыз үстереп айгырланып йөри берәү! Гарьлегеннән ят та үл! Пыяла туйга дип алган гәлсәр вазаңны атып бәрмәсәмме...

—Нигә бушка ләпелдисең, ә?—дип тә карады, эндәшми дә карады, инәлгән булып та кыланды.—Куйчы, ызгышмыйк юкка.

Аерым йокладылар. Иртәгәсен шимбә иде, соң гына торып берни булмагандай кумәкләшеп тамак туйдырдылар. Балаларының уен гаме белән тышка олагуы булды, янә буран купты. Ни хикмәттер—тиз үк басылды.

—Ярый, замана балаларын укытам дип болай да нервым какшаган. Теләсәң генә нишлә, кабат әйтмим. Китсәң кит—тотмыйм, калсаң кал—кумыйм. Бу өйдә кемнең баш, кемнең түш икәне электән билгесез. Барыбер дә хужабикә күбрәк өстен чыга. Зиннәтлерәк әйбер алганда да, анда-монда путевка сайлаганда да гәүдәгә иреннән калкуррак, тынкышрак хатыны, бәлки, шуңа ипкә килмидер, шайтан белсен.

Кичкә табан хужабикә кадимгечә йомыш кушты.

—Машинанны караштыр. Авылга барып әйләник әле.—Бу йомышка иреңң эче жылына төште: аләмчә генә эндәште, үпкәсен онытыргадыр чамасы. Алдына алганын өзми дә куймый ул—тыңламый кара.

Хатыны, балаларын чакырып, аны-моны кисәтеп, жыелышларга гына кия торган соргылт костюмын сайлап алды. Сагайтты бу шөкәтсез киеме ирен, мәгәр тынын чыгармады, хәтта кайсы авылга, кайсы туганнарына барырларын да белешмәде, ничегерәк киенергә дип тә киңәш сорамады. Жир читенә алып барып аудармыймы!

Менә поселок артта калды, ташны шыгыртадып машина кызу гына юргалады. Унга борылыргадыр, кайны-каенанасы яшәгән авылга, дип уйлап та өлгермәде, сул борылышка кул изәп, бичәсе анык кына фәрман бирде.

—Озынкүлгә безнең маршрут. Көндәшкәемне күреп, аңлашмыйча тынычлану юк безгә.

Бүртенде, кызарды ире, рулен ныграк кысты, газ өстәде. Көндәшкәем, дип мыскыллавы...

—Әйдә сон!—диде ир каты гына, хәтта ярсуы басылгандай тоелды.—Кеше көлдерәсен килә икән—мәйлен.

—Кем көлдерә бит.

Машина җилә, руль тотучының зиһененнән дә уйлар җилә. Нинди хәерсез көн... Барсаң да кыен, бармасаң да.

Хәер, элеккеге сабакташыма кереп чәй эчеп чыктым, гаепмени, дияр. Сабакташы белән мөнәсәбәтен ярый әле ачык авызланып берсенә дә сөйләмәде. Бүтән ир-ат сөяркәләре белән шапырынганда, аның да теле кычытып-кычытып куйгалый иде бәгъзе чак.

Монысы шәп. Бәй, кем күргән дә, кем тоткан аларны? Бәләкәч, ирең миндә кунгалый ул, дип акланып маташырмы ни газраил алдында? Юк, әлбәттә. Юк. Тотылмаган—бур түгел.

—Нигә ул тиклем куасың? Бәрдереп, йә аударып харап итәргә телисеңме?—бичәсе зәһәр елмайган булды.

—Шәп булыр иде дә...—Ире моны ачулы гына ычкындырды. Озак кына сүзсез бардылар. Һәр кем үзенчә уйларыннан уелды. Кинәт кенә Иркәй бер дусының сөйләгәннәрен хәтерләде. «Читтә уйнаштан малай үсә. Инде беренче класска йөри. Төнен барып кайттым, ләкин өйләренә керергә курыктым. Малайдан курыктым. Әллә ниләр әйтер сыман».

Гаҗәп, ә нигә ул курыкмый әле? Кичә шыр җибәрә язган иде... Шүрләрсең дә. Җаһил хәләленең тоташ галәмгә рисвай итәчәге көн кебек ачык. Анысына бик үк төкермәс тә иде, менә-менә югарырак дәрәҗәгә үрләргә торганда... Хәзерге түрә-карага күмәк адәм белән эшләве ансат түгел, мәгәр яши дә, эшли дә белер иде.

Бәләкәч өйдә булмаса гына ярар иде, дип теләгән иде дә, ул көткәнчә булмады: өйдә иде. Тәүдә хәтта ят хатынга әһәмият бирми, йөзен балкытып каршы алды. «Көндәшкәе» белән күрешере ике ятып бер төшенә дә кермәгәндер бахырның.

Чакырылмаган кунаклары да өенә әдәпле генә рәхим иттеләр.

Тик әйдәп торсалар да түргә узмадылар, эшләпәсе ишек төбендә серәеп калды, ә бөдрә башлы юлдашы якындагы диванга җәелеп утырды. Тынлык. Тынлык та җанга тияр икән. Ир түзмәде, машинасын караштырам, дигән сылтау табып, кире тышка шылды. Бераздан өйдә янаулы тавышлар яңгырады. Сыер дуласа аттан яман! Иркәй хәләл җефетен җилтерәтеп алып чыгар өчен, тәвәккәлләп кенә кире өйгә керде. Әмма җаны тораташтай катып калды. Бәләкәч бөршәеп кенә түр баштагы түгәрәк өстәлгә иелгән, ике кулы да битендә: гүя, битенә ләгънәт яумый, ә ачы пычрак сибелә. Ачырак сүз ишеткән саен куллары йөзен ныграк сыта, гүя, кайнарырак юынтык ишелә.

—Ярар, аңлаштык,—диде йомшарып, көндәшләрнең өлкәне. Шуннан завуч ханым кинәт кенә иренә эндәште.—Йә, хәзер синдә генә эш калды: кәнтәеннең артына тибәсең дә—гауга бетә, кабат син дә, мин дә бу өйгә юлны онытабыз.

Чәчләре үрә торды Иркәйнең, буй гынасы тагын да кыскаргандай, итләчлеге шиңгәндәй тоелды. Мәсхәрә!

—Җәһәт бул,—тизрәк үчен кандырырга тели иде, бугай, бу тавыш.

Иркәй берчә хәләленә, берчә сөяркәсенә бакты. Тәүгесе кансыз хөкемдардай ирәеп утыра, икенчесе бөтенләй каушаган, бөтенләй буынсыз калган. Бер мәлгә элеккеге сабакташларның карашлары очрашты: күпме әрнү, күпме рәнҗү, монсулык пәрдәсе каплаган яшькелт күзләрне!

—Житте, житте! Гаебе юк аның, әйдә кайтыйк...

—Өлгерербез!—Шулай диде дә катыны, әкрен генә калкынып, корбанына якынлашкан аучы кебек, Бәләкәчкә карап атлады.

—Торма катып, йә!

Көндәшенең ниятен анлаптырмы, анламыймы, бәлки йөрәге кузгалгандыр, хуҗабикә нидер кычкырырга маташты, тик тамагына тыгылган кузлы төер ирек бирмәде.

Менә ул куллары белән алмаш-тилмәш ишеккә ымлап, бер урында үрсәләнде, үчеккән бала төсле уң үкчәсе белән идәнне дөпелдәтте. Сөзешергә омтылган бәрән кылануын хәтерләтте бу.

—Алайса, үзем... Бия кешнәмәсә, айгыр тешләми—мә!..

Йә, Ходай, типте, типте ләсә укытучы китапханәченен кай җиренәдер, билдән түбән... Тайпылып та өлгерә алмады бичара,—егылды да куйды. Бары тик нәфрәттән бүртенгән битенә гәлсәр эз калдырып, ике бөртек ачы тамчы тәгәрәде.

Нигә тибелү иң гарьлекле җәза икән! Барлык халыкларда да.. Сукса, бәлки, бу тиклем газапланмас та иде. Тышта машина кузгалып киткәнен көтеп кенә торгандай, хуҗабикә чайкалып—үксеп диванга ауды.

* * *

Җан үртәгеч тимер чанкуы ишетелми инде. Юлаучы таныш йортка якынлашты. Карт шомыртның өстендә сирәк-мирәк корышкан җимешләр күренгәли. Баганадагы калай йолдыз мәрхәмәтсенми генә сәламләгән төсле. Әгәр аны Бәләкәч сыендырган хәлдә, йортка керү булып чыга түгелме? Йортка кергәнче утка кер... Тукта, үзе вузны бетереп, районга агрономлыкка җигелгәч, каенаналарында хәтсез генә яшәде. Димәк, утка кергән. Азак, ярый, казна кыегы астына сыендылар. Бу йорттан берәү киткән, димәк, уттан чыккан. Куй әле, ни пычагыма әйтемгә карап баш ватарга әле?

Борынгының боты сынган. Үз хатыны белән арытабан борчак пешмәсе көн кебек ачык... «Бу йортка син дә, мин дә юлны онытырбыз дигән иде лә, кая ул, тел очында гына.» Аз гына бәхәстә дә өзми дә куймый, йозгә бәреп өйдән куа. Монысы бер бәла әле. Түшәкләре бөтенләй суынды. Булмый, булмый арытабан яшәп. Әлегә ул кипкән алаша түгел...

Кемнән ким Бәләкәч? Нигә тәкъдим ясамаска. Фәрештәләр «амин» дисә...

Капка әкерен генә ачылды. Такта түшәлгән ихата уртасында какча гына берәү нидер әтмәлли. Шушы адәм булашкан икән бая тимер белән. Янында иннәренә шәл салган, башына купшы берет кигән хуҗабикә. Тәүдә чыраенда нур чаткылары чагылды. Шуннан күләгә ягылды.

—Карак! Карак йөри кеше таларга! Тибеп чыгарыйк артына.

Какча ир тәүдә аптырады, шуннан кинәт иелде дә, тәүдә өскә чөя биреп, кулына чүкеч сабын җайлап тотты. Остадыр, чүкеч сабы учына гүя үзеннән-үзе йомылды. Кем икән бу адәм? Армиядән кайткан туганымы? Элеккеге иреме, янасымы? Кемлегендә ни эше бар? Терәгедер, таянычыдыр, әнә туп-туры килеп ята бит. Бәреп екмас димә, эт оясында көчле. Юлаучы, сәрмәнеп кенә ачып, урыс капкасының бәләкәеннән аркасы белән урамга шылды. Миен буталчык уй бораулады. Нигә «карак» дип хурлады әле? «Эт» диеп кенә әйтсә... Йә өйбасар дисә...

Олы урамда баярак тартма тибеп дертләткән малай тагын очрады каршысына. Ни дә булса тибәргә яратылгандыр моның аягы. Зыңгырлатып консерва калаен бәләкәч туп урынына тибеп бара, җилкуар.

—Һәй—әй, шалапай, синең кебек чакта мин...

Ах, ах, үзенә күрә түгел икән лә Озынкүлнең әрсез малае:

—Үзеңне бел әле,—дип әрепләште дә кабаланып таш өй артына сыпыртты.



# Тамара Ганиева

## Минсез дөнья

Ташладың да тынычландыңмы соң,
Котылдымы җаның газаптан?
Кавышуның, хушлашуның аның
Кайтавазы үрти азактан.

Әле синең үксеп елаганда
Чәчләремә килер яшь сөрткең.
Яшеренәсең килгән чаклар булыр
Канатында ана бөркетнең.

Җир белән күк араларын иңләп
Дулауларым төшәр исеңә.
Учларыңнан эзләп исерерсең
Җаным белән тәнем исенә.

Ташладың да котылдыңмы инде?
И бәхетсез кешем, күр әнә,
Минсез дөньяң йоккә узалмаган
Түлсез хатын кебек сызлана.

***

Хушлашканда, юлың уңсын, дидем,
Әй укталдым караш җиткәнче:
Күктән өмет, миһербанлык катыш
Аяу көткән гүя, теләнче.

Икебезне бирәү иткән җирдән
Алып китә сине зәңгәр "ТУ".
Еламадым. Үрелеп сыгып элдем
Сытылырга торган болытны.

Тамара ГАНИЕВА — *шагыйрә, "Агыйдел" журналының шигърият бүлеге мөхәррире; "Аркаим", "Кызыл гөмбәләр" һ.б. китаплар авторы. Уфада яши.*

Көндез күктән инде өмет өздем,
Сер-тылсымы китте төннәрнең.
Чәчең тәме беләм яшең тәме
Сүрүендә кауршй мендәрнең.

## Малеевка шигыре

Татлы тоткынлыклар тәмам,
Хуш, урман кочаклары.
Кошларның тәрзә төбендә
Эч серен бушатканы.

Хушыгыз, уйчаннар иле,
Әйбәтләр оешмасы,
Хисләрнең ташып, шашынып,
Агарга тулышканы.

Каймак кебек татлы һава,
Сихәтең ни чамада?
Төннәрен төшләр дә тетри
Уфа дигән калада.

Хуш, Малеевка урманы,
Мин—яуга керер солдат.
...Бу ханым нәрсә сөйли дип,
Каеннар тора карап.

## Кырым гизәм

Чаң-чоң итеп чиркәү кыңгырау суга,
Мыштым ойый мәчет Кырымда.
Ишетелсә икән берәр татар сүзе
Элек гүләп торган урында...
Базарына төштем,
Сәүдә дисәң,
Җанын фида кылыр татарлар
Кайда булгандыр ул?
Мәйдан тулы
Бүтән телле алыпсатарлар.
Эшем кырам мин дә,
Кырым гизәм,
Чит кеше мин монда,
Чит илдән.
Юк, «кыпчагым, бул кунагым», диеп,
Йөгәнемнән алып үтенгән.
Яр читендә чиркәү кыңгырау кага,
Тау башында мәчет,
Юк азан.
Диңгез кыйммәт монда,
Кояш кыйммәт.
Милләт кайгылары—
Нык арзан...

***

Ява мәллә?
Сүндермәсме
Ут янган башкынамны.
Күзләрем күктә:
Яшенне
Чорнарга ашкынаммы?
Ява мәллә?
Дөбер-шатыр

Кемне күк камчылады?
Зурдан кубып шаулады да,
Яңгыры—тамчылады.
Аяусыз усал мәкердән
Көчләнгән сылу сыман,
Күктән кубып төшкән болыт
Үзәндә ята елап.

## Төн куены

Күксел тауга ара якынайгач
Җете кызыл булды ак кояш.
—Куеныма чум да,—диде кыя,—
Җангынаңны җылыт, карендәш!

Уйга калды Кояш. Һаваланып,
Кире үрли язды күкләргә.
—Таң атканчы гына,—диде күк тау,—
Сыенышып яллар итәргә.

Тау куены белән төн куены
Ике ялгызакны куш иткән,
Тәкәбберләр ничек кавышсын дип
Әйтүләре җирле буш икән.

Уйлама да икән, бу гомерләр
Табыштырмас диеп юк җирдән.
Ялгызлыктан өшеп кайчакта мин
Үз-үземнән учак тергезәм.

Кояш белән тауда эшләре юк,
Җир оеган, йоклый изерәп.
—Бүген төнлә көт,—дип пышылдаган
Берәүнең мин куркам килереннән.
...Килмәсеннән куркам бигерәк.

## Каравылчы

Юк, таң атмый әле...
Йокы качты.
Ни хикмәттер күзне шар ачты.
Әллә ни эш кырган кешедәй бер
Утырам шунда.
Төнге карачкы.

Сүндерегез эфир, Җиһан чыңын,
Килеп тулып минем зиһенгә,
Башкынамны шыплап зыңлата бит,
Таң атканчы чыда, түз генә.

Бер йокласым килә изрәп китеп,
Җир өстендә чакта, аң көе.
Өсләремә ишелеп төшмәс борын
Мәте катыш балчык өеме.

Беразга тик онытылсаң иде
Арыныр иде күңелең талудан.
Утырам шунда:
Гүя, Җир-Җиһанга
Каравылчы итеп куелган.



## Гөлнур Якупова

### Күгәрченем

Күгәрченем, утә көнең
Җим эзләп, гел чемченеп...
Очам дисәң, канатың бар,
Ник очмыйсың, мескенем?

Күрмәсәмче чүгән кебек
Соранып йөрүеңне,
Гыйшык көйләрен гөрелдәп,
Бас минем йөрәгемне!

Их, бу тамак, тәмугларга
Шул микәнни кертүе?
Югарыдан түбәнлеккә
Җиңелме күндерүе?

Күгәрченем, күкләреңнән
Ташландың нигә шулай?!
Аяк астындагы җимне
Табуы җиңел, кулай...

### Сүнгән учак

Уйсыз гына китеп барганда,
Туктап калдым, өем көл күреп:
Сүнгәнме ул тәмам, терелмәсме?—
Сынап кара аңа тын өреп.

Кем учагы, нинең көледер, ул
Килеп яткан минем юлыма—
Моңсуланды кинәт күңелем,
Көлне учлап алдым кулыма.

Агач көле,үлән көлеме,
Бәлки, гашыйк йөрәк көледер?
Шушы жансыз, салкын өемдә
Бер сөюнең соңгы көнедер?

Көлгә көлеп бага алмадым,
Аны кабат куйдым мин өеп.
Бәхетлеме булган ул учак,
Бәхетсезме,—киттем баш иеп...

---

Гөлнур ЯКУПОВА – *шагыйрә һәм прозаик, журналист. Уннан артык китап авторы. Җәлил Киекбаев исемендәге премия лауреаты. Уфада яши.*

## Юлаучы

Ишек тарттым—бикле.
Ачмадылар әллә?
Кем утыра икән,
Эчтән салып келә?

Ишек бикле.
Шикле.
Кем бар эчтә,
Ни бар:
Анда ялгыз берәү,
Әллә кунак-мазар?

...Син дә эчтән бикле.
Тыштан үзең алчак.
Таба алсам ачкыч,
Ачылырсың бер чак?

Юлаучымын.
Эчтә,
Серле дөньяда син—
Әллә калын урман,
Әллә киң даласың...

Син—биктә.
Сүз атам,—
Колагың тишектер?
Бәлки, нәкъ колагың
Мин ачар ишектер?

Баскынчы түгел мин—
Юлаучы.
Бәхетне юллаучы.
Мәхәббәт
Бар, диеп уйлаучы.

## Кәрлә сөю

Мин сине чамасыз яраттым!
Яраттым?
Тик миңа бул, диеп жан аттым.

...Теләдем иркеңне чикләргә,
Үземнең дөньямда бикләргә.

Калдыңдыр сизми дә, тиз генә
Кулыма төшердем тезгенне.

Чамасыз яраттым...
Ашкындым—
Ахырда мин сиңа баш булдым!

Тарайттым чикләрне—
Кечерәй!—
Мин сине читлеккә күчерәм.

Бәләкәй кәрләсең хәзер син,
Учыма йомсам да—әзерсең.

Теләсәм, сыярсың кесәмә,
Теләсәм, чыгарсың исемнән.

... Уф!!!
Нигә әйләндең кәрләгә,
Көнләшәм сөйгәне күркәмгә!

Файда юк дәгъвалар өюдән,
Бергәләп үтергән сөюдән...

Кәрләне соң инде әрләргә,
Кала тик сөюне җирләргә.

## Языклы язым

Миңа язсын өчен бу язың,
Кышны яз итәрлек җыр яздым.
Яшьлегеңә яшерен барып кердем—
Базмам дисәм, баздым.
Әллә аздым?

Капыл каушап калган карашыңны
Мин тәвәккәл иттем, наз иттем.

Тыным белән карны эреттем дә
Үз кышымны үзем яз иттем.

Базмам дисәм, баздым.
Әллә аздым...
Языкларым, беләм, ак кына:
Яланаяк кардан йөгердем дә
Умырзаяң булдым чак кына...



Фәрзәнә
Акбулатова

# АТАЙ ИКМӘГЕ

ХИКӘЯ

## 1

Быел яз иртә килде. Соңгы ике көн эчендә тау сыртындагы карлар эреп бетте. Урамнан шаулап гөрләвекләр акты. Тик өйләрнең салам кыеклары гына кардан әрчелгәч мескен кыяфәткә керде. Кайсы жире сыер тизәге белән сыланган, яртылаш жиргә сеңгән бу өйләр халыкның күргән нужасы турында әллә кайдан сөйләп торалар кебек.

Шулай да яз—яз инде. Авылда гадәттә булмаган жанлылык сизелә. Мидхәт белән Мотаһар да өйдә ятып түзә алмады. Әниләренең тыеп китүенә карамастан, күтәрмәгә чыгып утырдылар. Кыш буе өйдә ятып ялыккан тәннәрен язып өчен талны ат итеп яланаяк әле бу якка, әле теге якка чаптылар.

Өйнең кайчандыр киртәләнгән булуы турында анда-монда серәешкән казыклардан гына белергә мөмкин. Салкын кышта туңып үлмәс өчен, киртә-куралар күптән ягылып беткән шул. Нихәл итәсең, дүртенче ел барган сугыш үз авырлыгын халык жилкәсенә нык төшерде. Бу афәт басылса, барысы да рәтләнер иде дә...

Йорт хужасы Галләм абзый сугышның беренче көннәрендә үк хатынын, берсеннән-берсе бәләкәй ике улын калдырып фронтка китте. Аны озатканда кечкенә улы Мотаһар йөрми дә иде әле. Әтисен бөтенләй хәтерләмәгәнгә күрә: «Әтием болай идеме, тегеләй идеме?»—дип Маһикамал апаның да, Мидхәтнең дә тенкәсенә тиеп бетә. Ә соңыннан ишеткәннәрен үзе күргән төсле итеп сөйләп йөри. »Әти миңа зур булып үс дип әйткән иде, вәт»,—дип куя. Кайберәүләр жәллиләр, икенчеләре: «Ә син нәрсә дип жавап бирдең?»—дип сорыйлар. Мотаһар күзләрен зур ачып, тотлыга-тотлыга сөйләргә керешә: «Мин зур булам, дидем! Өй түшәменә тәрәлгәнче үсәм, дидем. Юк, менә хәзер үк тиям»,—дип стенага бәрелеп ала. Башын авырттырса акланып та куя: «Нык зур булсаң, нык бәреләсең дә куясың шул».

---

Фәрзәнә АКБУЛАТОВА—*прозаик, Башкортстан дәүләт телерадиокомпаниясендә эшли. Ш. Бабич исемендәге дәүләт яшьләр премиясе лауреаты. Башкортстан Республикасының атказанган матбугат һәм киң мәгълүмат хезмәткәре.*

Мидхәт әтисен томанлы гына булса да хәтерли. Шуңа күрә энесе сөйләгәннәргә төзәтмә кертеп тә җибәрә.

Менә шушы балалар сугышның дүртенче язын каршылыйлар. Мотаһар суыктан каз тәпие кебек кызарган аякларын уа-уа абыйсына эндәште:

—Абый, әйдә күтәрмәдә генә уйныйк!

—Чыкканга яңа гына, өшедең дәме?

—Аякларым туңды, әйдә инде!..

Мидхәт сукрана-сукрана өйгә табан китте:

—Пешмәгән булып чыктың бит, ә! Житмәсә, мин солдат булам, дип йөрисең әле.

Үзенең дә аяклары туңган, ләкин ул бит абый, һич кенә дә сер бирергә теләми. Мотаһарның бик тә солдат буласы килә, шуңа да ул җавапсыз калмый:

—Нишләп булалмый, ди?

—Була аласың инде,—дип ирештерде күтәрмәгә килеп утырган Мидхәт.—Йә, нәрсә уйныйк?

—Чәй эчкән булып, яме?

—Кызлар уены бит ул.

—Аһ-аһ, нигә, без дә чәй эчәбез бит.

Мидхәт, энесе белән сүз көрәштерүне файдасызга санап, кул гына селтәде: »Яса».

Мотаһар мыш-мыш килеп үзе җыйган чынаяк ярчыкларына «чәй» ясый башлады.

—Нигә сөт салмыйсың?

—Абый, әнием сыерны сатты бит, шуңа сөтсез генә эчерәм.

Мидхәт, әнисенең күзен үк сыерларын сатып җибәргәнен хәтерләп, көрсенеп куйды. Хәер, кыш чыгарырлык саламы булса, сатмас иде дә...

—Без монда юри генә чәй эчәбез. Шулай булгач, сөт тә бар, төшендеңме? Әнә, башмагыбыз сыер булган, дип уйныйк.

—Ярар,—дип Мотаһар баш какты да, балчык кисәкләре тезә башлады.—Ипи аша, абый, менә, әй күп алар...—Кинәт еламсырап, Мидхәткә төбәлде,—ачыктым, абый.

—Тукта, энем, уйнап бетик.

—Әй-й, мин башка уйнамыйм, ашыйсым килә... Эһң-эһ...—Мотаһарның күзеннән яшь бөртекләре тәгәрәде.

—Вәт сине, тукта инде! Үзе зур, үзе елый. Әнием кайтканны көтик. Хәзер ашап, кичен ач утырасың киләме?

—Минең монавы җирем авырта.—Мотаһар ашказан тәңгәленә күрсәтеп уфтанды.

Мидхәт аны тынычландырырга тырышты.

—Озакламый әти кайтыр. Әнием, ул кайтса, ипи дә, бәрәңге дә мул булыр, ди бит, шуны ишетмәдеңмени?

Мидхәт үзе дә шул көнне күз алдына китерергә маташты, чынлап та ипи, бәрәңге көн саен булырмы икән? Мотаһарның күзләрендә шатлык очкыннары күренде:

—Әтием тиздән ипи алып кайта, әйе бит?

—Әй исәрсең дә инде! Ул ничек сугыштан ипи алып кайтсын ди?

—Нигә? Ипи дә алып кайта ул,—Мотаһар абыйсын ышандырырга тырышты.—Әтием безнең гел ачыкканны белә дә инде... Абый, әйдә, мич эчен карыйк, бәрәңге онытылып калмадымы икән?

Мидхәт энесенең ниятен кире кагарга батырчылык итмәде. Менә

Мотаһар мич эченә кереп китте. Бераздан аның төшенке генә тавышы ишетелде:

—Юк...

Сүз юк, Мидхәт үзе дә бик ачыкты. Эчендә нәрсәдер чеметенеп-чеметенеп ала. Өйдә бәрәңге бар-барын, ләкин әнисе аларны исәпләп, көндәгесен көнгә бүлеп куйган. Сәке астындагы кичкә пешерергә дигәннәреннән икене генә алып... Юк, әнисе тукмар. Ул эштән арып кайта, әрләп тә, чабып та җибәргән чаклары була.

Мотаһар янә көйсезләнә башлады:

—Әнә, Хәдичә әбинен миченнән төтене чыга. Ашарга пешерәләрдер әле.

—Чү, дим бит. Мин дә ачыктым, ә бер дә еламыйм. Түз!

Шулай дисә дә Мидхәт үзе түзмәде, ике бөртек бәрәңгене учына кысты. Хәдичә әбидән пешертеп алыргамы әллә?

Түрбашта нәрсә беләндер булышып йөргән Хәдичә әби ишек тавышына әйләнеп карады.

—Кем икән дип торам, синмени, Мидхәт балам? Әйдә, уз.

—Юк, үтеп тормыйм. Шушы ике бәрәңгене пешереп кенә бир әле, әбекәй. Безнең мичкә ут ягылмаган.

—Бәрәңге, дисенме? Аһ-аһ, пешерермен, нигә пешерми ди! Менә үзем дә балаларга бирәр нәрсә әтмәлләп йөри идем,—диде Хәдичә әби оныклары ягына күрсәтеп.

Мидхәт тизрәк өйләренә табан йөгерде.

—Мотаһар, булды! Тиздән бәрәңге ашыйбыз.

Энесе шатлыгыннан сәкедә тәгәри башлады.

—Ура-ура!

—Әй, син, тукта әле. Ашавын ашарбыз, ә әнигә нәрсә диярбез? Вәт бит.

—У-у-у, безнең әле бәрәңге күп лә инде. Ашап та бетерә алмабыз әле, чын, кайчан әтием кайтканчы.

Мидхәт аның аңгыралыгына аптырап куйды. Әтисе кайтса, имеш, аның кайчан кайтыры билгесез шул. Әнисе генә тиздән кайтыр, ди, ә тизнең һаман тиз булганы юк.

Ниһаять, бәрәңге артыннан барыр вакыт җитте. Мидхәт күршеләренә дөбер-шатыр барып керде һәм сәке өстендә чыр-чу килеп елашып утырган балаларны күрде дә туктап калды.

—Әбекәй, мин бәрәңгегә кергән идем...

—Синме бу, балакаем? Нәрсә генә дип акланыйм икән соң, Ходай Тәгалә? Монавы кара йөзләр мин урамнан кергәнче бәрәңгене мичтән алып, кырып-себереп ашап беткәннәр дә куйганнар бит. Туктагыз дим, корыгырлар, тавышыгыз чыкмасын!

Мидхәтнең кинәт тез буыннары калтырады, ул, егылып китүеннән куркып, ишек янагына сөялде. Хәдичә әби һаман онықларын орышты:

—Мин юкта ризыкка тиеп кенә карагыз! Менә күрәсезме?—Ул кулындагы сыек чыбыкны селкеп алды.—Хәзерге шикелле генә итмәм мин сезне!

Балалар куркышып тагы да кычкырыбрак елый башладылар. Аларның тавышы Мидхәтне сискәндерде, башын түбән игән килеш малай чыгарга борылды.

—Балам, торып тор, риза итим,—кулына бер савыт катык тоткан Хәдичә әби аңа таба атлады.—Күптән катык күргәнегез юктыр. Ак белән тукланган кеше сәламәт була ул.

Мидхәт катыкны алырга да, алмаска да белмәде. Анның бу балалар ризыгы икәнен яхшы аңлый иде. Мотаһарны күз алдына китергәч, үзе дә сизмәстән савытка таба сузылды. Күз яшьләрен җиңе белән сөрткәч, Хәдичә әбинең ягымлы йөзенә карап, ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады.

—Зур рәхмәт, әбекәй...—Ул савытны эләктерде дә чыгып ычкынды.

Мотаһар абыйсы килеп керү белән аның кулына ябышты.

—Пештеме, абый, пештеме?

—Энем, Галияләр безнең бәрәңгене белмичә ашаганнар да куйганнар. Син аны әнигә әйтмәссең, яме. Ә Хәдичә әби безгә катык бирде.

Мотаһар ул сөйләгәнне әллә ишетте, әллә юк, ашыга-ашыга катыкны чөмерергә кереште. «Миңа да калдырмасмы икән?»—дип уйлады Мидхәт. Ач чакта икенче берәүнең ашаганын карап торудан да авыр нәрсә юктыр. Мидхәт газап чигә-чигә төкерекләрен эчкә йотты. «Ярар, мин түзәрмен. Әнием кайтырга да күп калмады инде»,—дип юатты ул үзен. Мотаһар катыкны эчеп бетергәч, буш савытның читен бармаклары белән сыпырып ялап куйды. Тагын әз генә булганда, их, юк шул...

Маһикамал апа эштән, гадәттәгечә, соң гына кайтты. Мотаһар әнисе керер-кермәстән аңа каршы йөгерде:

—Әни, без бәрәңге ашамадык, чын!

Мидхәт иренен авырттырганчы тешләде, ышан бу Мотаһарга, әйтми, имеш.

—Ашамадык, абый, әйе бит! Без аны, без аны...—ул абыйсының әйтмәскә кушуын хәтерләп шып туктады.

Маһикамал апа, болар нәрсә сөйли әле дигән шикелле, аптырап карап торды да сәке янына килеп, бәрәңгеләрен барлады.

—Икесе кая?

Мидхәт эндәшергә кыймады, бары тик Мотаһар гына әнисе янына килеп уралды:

—Без аны, без аны... Әти безгә тиздән бәрәңге, ипи алып кайта, әйе бит?

Маһикамал апа берчә янында сөйләнеп торган бәләкәченә, берчә күзләрен аска төбәгән зур улына карап уфтанды. Менә Мидхәт әкрен генә атлап әнисе янына килде һәм һаман башын түбән игән килеш:

—Без тимәс идек, әни... Без тимәс идек...- диде, аның тавышы калтыранды. Әнисе авыр эштән кытыршыланган сөялле кулларын улының иңенә салды.

—Беләм, тимәс идегез, балам. Их, бу сугыш...

Күңелсез тынлыкны бозып, Мотаһарның ачык тавышы яңгырады:

—Мин сугышны җиңәм, әни!

Җылына башлаган көннәр тагын суынды. Кар явып, җир өстен каплагач, яңадан кыш булды да куйды. Мидхәт белән Мотаһар өйдә генә утыралар. »Кар нигә җылы булмый икән, мин чыгар да йөгерер идем»,—дип пошынып ала Мотаһар. Ул үзе, әллә ашау ягы начар булгангамы, әллә салкын алдырдымы, еш кына авырый башлады, төннәрен туктаусыз ютәлләп чыга.

Маһикамал апа күзгә күренеп шиңгән бәләкәченә ничек ярдәм итәргә белми.

—Ах, сыерыбыз юк бит, ичмасам, балакайларым, болай ук бирешмәс идек,—дип зарлана ул.

—Сыерыбызны теге бабайлардан алыйк та кайтыйк,—дип үзенчә киңәш

бирә Мидхәт. Маһикамал апа күнелсез генә елмая:

—Ансат кына уйлыйсың...

—Их, тизрәк башмагыбыз зурайсын иде. Безнен дә Хәдичә әбиләрнеке кебек катыгыбыз булыр иде, әйе бит, әни? Әллә нигә мин дә, башмагыбыз да тизрәк үсмибез,—дип Мотаһар да сөйләнеп ала. Аның сүзләреннән соң Мидхәтнен йөрәге әрни.

Соңгы көннәрдә Мотаһар үтә ябыкты. Бүген дә хәле шәптән түгел, ахрысы, чыраен сытып, көч-хәл белән генә тын алып утыра. Ничек күңелен күтәрергә соң?

—Мотаһар, әйдә, күмер алыйк та, идәнгә рәсем төшерик.

Мотаһар башын чайкады:

—Әй-й-й, мин төшерә белмим.

—Белмәсәң, өйрәтәм. Кил, ат ясыйк. Менә, кара әле, ничек шәп чыга!— Мидхәт үзе төшергән рәсемгә сокланып карап торды. Мотаһар эндәшмәгәч, аның ягына борылды.—Кая, карыйм әле, син нәрсә төшердең?

Ул Мотаһар ясаган түгәрәкләрдән бернәрсә дә аңлый алмады.

—Болар нәрсә була соң ул?

—Аһ-аһ, бәрәңге икәне күренеп тора да инде! Монысы сиңа, монысы әниемә, ә монысы...

Мидхәт аны сак кына бүлдерде:

—Кара әле, энем, мин сиңа бәрәңге төшерергә кушмаган идем лә, әйдә аларны кояш итик.

—Юк, минем бәрәңге төшерәсем килә!—Мотаһар кызып-кызып яңадан түгәрәкләр сыза башлады. Инде Мидхәт ачуланды:

—Барыбер төшермисең! Нигә гел бәрәңге турында гына уйлыйсың? Ашарга кайдан алыйм мин сиңа?

Мидхәт энесенең бәрәңгеләрен сөртеп алды да агач төшерә башлады:

—Хәзер яз җитә бит, яфрак яра башлаган агачлар төшерик без.

Ул, энесенең бу тәкъдимгә ризамы-түгелме икәнен белер өчен, аның ягына борылып караганда, Мотаһар урындык астына керә язып нидер төшерә иде. Мидхәт әкрен генә энесе янына килеп басты. Тагын түгәрәкләр.

—Бәрәңгеме?

Мотаһар башын калкытты һәм төшергән рәсеменә бармагы белән төртә-төртә:

—Юк, болары көлчә. Көлчә, абый. Бу зурлары сиңа, әниемә, әтиемә, ә бу иң бәләкәче миңа,—диде, үзе аяныч елмаеп Мидхәткә карады. Әллә шул күзләрдән, әллә сүзләрдән тетрәнде Мидхәт, таш кебек катты да калды. Моны үзенчә аңлаган Мотаһар рәсемнәрен гәүдәсе белән каплады.

—Ипигә тимә, абый!..

Мидхәтнең бите буйлап күз яшьләре тәгәрәде.

## 2

Көннәр җылынды инде. Ләкин соңлап килгән яз Мидхәтләрнең өенә шатлык алып килмәде. Кечкенә Мотаһар менә ничә көн инде түшәктән тора алмый, ә көннәр җылынса, терелер төсле иде бит!

Тубыкларын кочаклаган Мидхәт тирән уйга баткан. Мотаһарның аратирә ыңгырашуы гына тынлыкны бозып, өйгә ниндидер хәсрәт өсти. Мидхәт энесе янына килде.

—Умачыңны эч инде, энем, ашау барда—яшәү бар, ди бит.

Мотаһар күзләрен йомган килеш әкрен генә башын чайкый. Мидхәт тубыкларын кочаклый да тагын уйга бата. Бөтен балалар урамда, ә аңа

энесен ташлап чыгып китәргә ярамый шул. Мотаһар тизрәк терелсә, алар да башкалар кебек юа, кузгалакка йөрерләр иде. Уйлары әнисенә барып тоташты. Мескен әнисе көне буе эштә, ә төнен Мотаһар янында була. Бу арада йончыды, берүк үзе авырып китмәсен. Малай энесенең тавышына сискәнде.

—Нәрсә диден, туганым?

—Кояшны күрәсем килә...

Мидхәт Мотаһарны күтәрде дә, анын җиңеллегенә аптырап китте: яткан мендәреннән дә авыр түгелдер, мөгаен. Ә кышын ул энесен чак-чак күтәрә торган иде...

Мидхәт аны болдырга алып чыккач, артына мендәр куеп рәтләп утыртты. Әллә кояш нык якты булгангамы, аның бите буйлап күз яшьләре тәгәрәде.

—Йә, энем, сиңа рәхәтме? Умачынны эчәсеңме?

—Эч, үзең эч...

—Син алай димә. Беләсеңме, бүген Галияләр юага китте. Сиңа да алып кайтабыз, диделәр. Әнием тагын да тәмлерәк итеп ашарга пешерер. Хәзер көннәр әйбәт, инде син терелерсең.

Ә сабыйның бите буйлап күз яшьләре акты да акты.

—Минем тереләсем килә, абый...

Ул әллә торырга теләде, кинәт калкына бирде дә мендәреннән шуып төште.

—Ай, Мотаһар, нишлисең?

Энесе эндәшмәде.

—Мотаһар, Мотаһар!

Ниндидер бәланен якынлашканын тойган Мидхәт энесен кертеп түшәккә салды да күршеләргә йөгерде.

—Әбекәй, Мотаһарга әллә нәрсә булды да куйды!—дип кычкырды ул күз яшьләренә төелә-төелә. Хәдичә әби Мотаһарны барып күргәч, Мидхәтне әнисе артыннан җибәрде.

—Һушын югалткан бит, балакаем, бар, тизрәк әниеңә хәбәр ит!

Кичен Мидхәткә күршеләрдә кунарга куштылар.

—Балам, бездә генә йокла. Мин әниең янында калам,—диде аңа Хәдичә әби. Малай башка вакыттагы шикелле киреләнеп тормады, энесе янына барып әкрен генә аның чәченнән сыйпады һәм кинәт борылып чыгып китте.

Төнлә ул төш күрде. Әтисе кайткан, имеш. Тик менә Мотаһар әллә кайда булган да куйган. Мидхәт аны эзләп әле бу, әле теге якка йөгерде. Күпмедер вакыт йөргәч, ерактა энесен күреп калды. Куып җиттем дигәндә генә, Мотаһар кошка әйләнеп очты да китте. Мидхәт аның артыннан йөгерә, кычкыра...

Аны Хәдичә әби уятты:

—Балам, икенче ягыңа әйләнеп ят, саташасың.

Мидхәт башта үзенең кайда ятканлыгын аңламады, исенә төшкәч, сикереп торып утырды.

—Юк, мин үзебезгә кайтам.

—Иртә әле, балам, таң да атмаган, ят-ят.

Ул соң гына уянды. Күзен ачканда Хәдичә әбинең оныклары чыр-чу килешәләр иде. Аларның иң зурысы Галия Мидхәтнең янына килде:

—Ә син беләсеңме, Мотаһар үлгән бит.

Мидхәтнең йөрәге жу итеп китте. Ул беразга тораташтай катты. Аннан, үзен-үзе белештермичә, Галиягә барып ябышты.

—Алдама-а!

Кызыкай күзләрен чылт-чылт йомды, калтыранды.

—Мин әбиләрнең сөйләшкәнен тынлап тордым, бәлки...

Мидхәт ишеккә ташланды. Ләкин ул тыштан бикле иде. Малай бар көченә ишекне этте.

—Ачыгыз! Ач!

Күпме кычкыргандыр ул, әмма беркем дә ярдәмгә килмәде. Өйдәге балалар да аңа кушылып елады. Берни күрми, берни ишетми, Мидхәт үкседе дә, үкседе. Күз яшьләре бетте, тавышы карлыкты, ә ул яшьсез-тавышсыз һаман елады. Ахырда өзек-өзек сулкылдап идәнгә йөзтүбән капланды. Һәм шул килеш йоклап китте.

—Балам, тор, энең белән хушлашып кал,—дип уятты аны Хәдичә әби.

Мидхәт аңламады, ничек хушлашырга? Әллә Мотаһарны берәр кайда алып китәләрме? Үлгәннәр белән ничек хушлашып булсын, алар ишетәләрмени? Димәк, Галия ялгыш аңлаган!

Бөтен күк йөзен каплап чәүкәләр оча. Мидхәт төшендә нинди кош күргәнен хәтерләргә тырышты. Нинди сон? Күгәрченме, тургаймы? Юк, ул Мотаһар иде бит! Мотаһар—кош?

Хәдичә әби аны житәкләп алды.

—Атла, балам.

Нигә соң бүген чәүкәләр бөтен күк йөзен каплаган? Ә кем әле чәүкәләр түбәннән оча, яңгыр ява, дип әйткән иде? Мотаһар беркөн көтеп-көтеп тә яңгыр яумагач, чәүкәләр алдакчы дигән иде...

—Әбекәй, ул йоклый гынадыр. Бәләкәйләр каты йоклый бит ул. Әбекәй, ул соңгы вакытта төннәрен дә йоклый алмый торган иде.

Әбинең эндәшмәве Мидхәтнең күңеленә шом салды. Мотаһар беркайчан да: «Чәүкәләр оча, бәлки яңгыр явыр!»—дип сөрән салмасмы?

—Юк!

Мидхәт бөтен гәүдәсе белән калтыранды. Хәдичә әбинең кулыннан ычкынып өйләренә таба йөгерде.

Ишегалдында ике-өч карт күренә. Мидхәт, болар мине тоткарлый күрмәсеннәр дигәндәй, дөбер-шатыр өйгә килеп керде. Эчтә әбиләрне күргәч, тагын тукталды. Нишлиләр алар монда? Әбиләр малайга кер дип тә, чык дип тә эндәшмәделәр. Мидхәт сак кына атлап сәкедә яткан энесе янына килеп басты. Ә Мотаһар күзләрен йомган килеш тып-тын ята. Тып-тын. Элекке кебек ыңгырашмый да, чыраен да сытмый. Күзләрен, тик менә күзләрен генә ачсачы...

—Мотаһар, энекәем, мине ишетәсеңме?

Энесе җавап бирмәде. Мидхәт яшь тулы күзләрен аннан озак ала алмый торды. Коточкыч дөреслеккә берничек тә ышанырга теләмәде. Һаман да Мотаһарның уянуын көтте.

—Мотаһар, син йоклыйсың гына, әйеме?

Ләкин аның соравы җавапсыз калды. Мидхәт әбиләр ягына борылды. Малайның ялварулы карашы әле бу, әле теге әбигә төбәлде. Кемдер сак кына аның иңбашына кагылды. Әнисе иде. Мидхәтнең күзеннән яшьләр тәгәрәде.

—Әни, нигә алай булды икән? Юк, ул барыбер үлмәгән!

Менә картлар кабыкка салынган кечкенә Мотаһарны алып чыгалар. Мидхәт әнисенең кулыннан ычкына да аларның артыннан йөгерә.

—Алып китмәгез! Алып китмәгез, бабайлар!—Үзен тыңламаганнарын күргәч, кычкырып еларга тотына.

—Тукта, бабай, тукта!

Мидхәтне тотып алалар, ул чәбәләнеп ычкынырга тырыша.

—Мотаһар! Энем!

Картлар артыннан йөгерә.

—Туктагыз! Карыйк, карыйк, үлмәгән бит ул! Нигә туктамыйсыз соң?

Бу аерылышуының мәңгелек икәненә ул берничек тә ышанырга теләмәде. Нәрсәгәдер әләгеп егылды. Торды да аксый-аксый зират ягына атлады...

***

—Улыкаем! Сугыш беткән!

Мидхәт башта бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенә алмый кебек, аңына барып җиткәч, шатлыгыннан кычкырып җибәрә дә әнисенең кочагына ташлана.

—Беткән? Ничек беткән? Инде сугыш булмыймы, әни?!

Маһикамал апа күз яшьләренә төелеп улын күкрәгенә кыса.

—Булмый!.. Җиңгәннәр! Нинди бәхет, балам!..—Шатлыгыннан исергән әнисенең тыны кысыла, ул әкрен генә чүгәләп төшә.

—Зиһенем таралды, Мидхәт. Бар, Хәдичә әбиеңнәргә йөгер. Сөенче... Сөенче ал... Әле берсе дә белми. Идарәгә яңа гына хәбәр иттеләр... Әле мин...

Мидхәт әнисенең әйтеп бетергәнен дә көтми урамга атыла...

—Кешеләр! Ишеттегезме!?

Шатлыклы хәбәр тиз тарала икән. Күз ачып йомганчы урам халык белән тулды да куйды. Кешеләр бер-берсен котлыйлар, елыйлар. Мидхәт тә башка балалар белән көне буе урамда чапты. Көтелгән бу куанычлы хәбәрне өйдән-өйгә йөреп, кат-кат сөенче алдылар.

Мидхәт кичен озак кына йоклый алмады. «Сугыш беткән»нең мәгънәсенә ныклап төшенергә тырышты. Башкача беркайчан да сугыш булмасмы? Үзен белә башлаганнан сугыш сүзенә күнеккән мескен бала сугыш дәвам итә дә итә, шулай булган һәм булачак, дип уйлый торган иде шул. Ахыр чиктә ул үзенә кычкырып сорау бирде:

—Хәзер бер фашист та калмадымы икән?

Көннәр үз җае белән үтә торды. Хәзер фронттан кайта башлаучылар күренде, тик Мидхәтнең әтисе нигәдер һаман кайтмады. Малай һәр көн әтисен көтә. Ә ул кайтмады да кайтмады. Инде Мидхәткә әтисенен хатындагы «тиздән кайтырмын» дигәне мәңге дәвам итәр дә, ә ул үзе беркайчан да кайтмас кебек тоела.

Соңгы вакытта ул Мотаһар энекәшен еш исенә төшерә башлады. Һәрнәрсә дә аны хәтерләтеп тора. Мидхәт энесе белән ничек уйнаганнары, сөйләшкәннәре турында әнисенә кат-кат сөйли торган булып китте. Мотаһарның каберенә барып үзенең яңалыкларын да сөйләп ала. Нишләптер, ана энесе тыңлап ятадыр кебек тоела иде.

Мидхәт көне буе балыкта йөреп эңгер төшкәч кенә кайтып инде. Әнисенең эштән кайтуына пешереп куярга дигән балыкларын тазартырга йөргәндә, ишек ачылган тавышка сискәнеп, башын калкытты һәм катып калды. Аның алдында солдат киемендә бер абзый басып тора иде. Мидхәт сикереп торырга итте—хәле җитмәде, кычкырырга теләде—тавышы чыкмады. Менә солдат аңа таба кулларын сузды.

—Улыкаем!

—Әти! Әти!

Күз ачып йомган арада Мидхәт күптән, бик күптән көткән әтисенең кочагында иде инде. Ата улын сөйде:

—Йә, елама инде, улым, без ирләр бит. Ничек зураеп киткәнсең!—Ул улының күзләренә карап торды да тагын кочаклады.

—Без сине шундый көттек. Көнен дә, төнен дә әнием юлдан күзен алмады. Ә мин... Мин кайта алмассың дип курыккан идем. Мотаһар да көтте... Әти, ул... ул...

—Улым, я...

—Әти, син иртәрәк кайтсаң, ул үлмәс иде...

Бу сүзләрне ишеткәч Галләм абзый тетрәнде. Күзләрен зур ачкан килеш улына карап катып калды.

—Нигә, улым, бу турыда бернәрсә дә язмадыгыз?!—дип сыкранып эндәште ата.

Мидхәт ни диярга дә белмәде. Әнисенең «әтиеннең кайгысын арттырмыйк, язмый торыйк» дигәнен әйтергәмени?

Улын кочаклаган килеш озак өнсез утырды Галләм абзый. Нәрсә турында уйлагандыр ул бу вакытта, кем белә...

Менә ул исән калган зур улына сагыш та, мәхәббәт тә чагылган күзләре белән тутырып карады һәм тагын да ныграк итеп кочаклады:

—Юк, яшәргә тиеш без!—Атаның күзе яшьле иде... Мидхәт аңа ныграк сыенды.

—Әти, инде беркая да китмисеңме?

—Юк, улым, сезгә кайттым. Тик нигәдер әнием һаман юк. Кайту хәбәрен инде житкергәннәрдер дим...

—Мин хәзер аның янына барып киләм, әти! Эшләре бетәргә тиеш.

Мидхәтнең әйтүе булды, ишектән Маһикамал апа күренде.

—Галләм!

Менә ул елый-елый газиз кешесенә ташланды.

—Йә хода! Күрер көннәрем бар икән!

Маһикамал апа озак тынычлана алмады, бәйләнешсез озак-озак сөйләнде:

—Килеп сөенчеләделәр. Чыгып йөгергәнемне дә белмим, Ходаем! Ах, Галләм! Галләм! Исән-сау!..

Галләм абзый аны кадерләп күкрәгенә кыскан килеш юатты:

—Йә инде, Маһикамал... Менә теремен. Хәзер елашырга түгел, шатланырга кирәк. Тынычлан, әнисе, йә...

Хатынының иңбашыннан тотып күзләренә карады да:

—Үзегезнең хәлләрегез ничек соң? Ничек көн иттегез, Маһикамал?—дип сорады.

—Илдә чыпчык үлми... Менә үзең күреп торасың.

—Жиңдек, Маһикамал! Жиңдек, улым!—Ир кадерле кешеләрен тагын кочаклады.—Мондый кайгы-хәсрәтне беркайчан да күрмәссез! Тик... Нигә алай булып куйды, Маһикамал?..

Хатыны, сүзнең бәләкәчләре—Мотаһар турында икәнен аңлап, күзләрен йомып пышылдады:

—Акылдан язарлык хәлләр... Кулымнан килсә, үз жанымны биргән булыр идем! Саклый алмадым бит!.. Көнен-төнен йөрәк әрни... Ниләр генә кылыйм соң!..

—Йөгерә-атлый кайтып киләм. Ә үзем зур улымны житәкләгәнмен, бәләкәчен жилкәмә утыртканмын... Челпәрәмә килде... Нигә соң хатка язмадың! Шушы минутка чаклы бернәрсә дә белмәдем бит мин...

—Чү-чү, Галләм... Сиңа ут эчендә болай да авыр иде. Житмәсә, сугыш бетеп килгән мәл. Әйләнеп кайта алмассың кебек тоелды. Шушы балаң хакына тере кайтуыңны теләдем. Әгәр дә бу кайгыны ишетсәң... Юк, юк...

Ир кеше нык була. Галләм абзый кебек ут-су кичкәннәре бигрәк тә үзләрен тиз кулга ала беләләр. Хәзер ул үзе хатынын тынычландырырга тырышты.

Тагын бер солдатның әйләнеп кайтканын ишеткән авыл халкы да җыела башлады. Алар үзләре белән йортка ниндидер күчелелек тә алып килде. Маһикамал апа бераз тынычланып, башкортның борынгыдан килгән йоласы буенча, кунаклар өчен чәй кайнатырга йөгерде.

Күз яшьләре дә кибеп өлгермәгән хатын бәхетле елмаеп авылдашларын табынга чакырды. Яше дә, карты да һаман килде. Аларны каршы алучы әтисеннән Мидхәт бер тотам да калмады. Чәй эчәргә утыргач, әнисенен: «Куй, балам, әтиенне йончытып бетермә, зурсың бит инде»,—диюенә карамастан, алдына менеп үк утырды.

Әтисе алып кайткан ипине табынга куйдылар. Мондый ипине Мидхәт гомерендә дә күргәне юк иде әле.

—Әти, нигә бу дүртпочмаклы? Әнием пешергән көлчәләр йә озынча, йә түгәрәк булалар,—дип гаҗәпләнеп карашын әтисенә төбәде. Үзе табындагыларның көлгәнен ишеткәч, оялып, шунда ук йөзен әтисенең күкрәгенә яшерде. Тере булса, энесе дә шулай иркәләнер идеме икән?.. Ул, оялганын да онытып, тиз генә башын калкытты:

—Әти, ә Мотаһар гел синең ипи алып кайтуыңны көтте. Бәләкәй булгач, аңламагач, ул сугыштан ипи дә алып кайталар, дип уйлый торган иде, әйе бит, әни?

Кешеләрнең йөзе уйчанланды. Маһикамал апа яулыгы белән күзен сөртте.

—Шулай булды, балам... Тик үзе генә...

Барысы да тын калды. Һәркем сугыш күрсәткән кайгы-газапларын ирексездән исенә төшерде. Бераздан кайгысын эченә яшергән Галләм абзыйның тавышы ишетелде:

—Мидхәт улым, иртәгә энең каберенә икмәк алып барырбыз. Ул шатланачак, чөнки әтисе сүзендә торды. Күрәсеңме, менә ул икмәк!

Малай әтисенең муенынннан кочаклап ала. Аның сөйлисе сүзләре бик күп җыелган, тик авылдашлары авыз ачарга ирек бирмиләр шул, төн булуга карамастан, һаман килүләрен дәвам итәләр. Юк, Мидхәт әлегә сөйләмичә түзәр, тик әтисе генә башкача беркая да китмәсен.

Ул оеп киткәнен сизми дә калды. Бераздан сискәнеп уянды һәм әтисенең алдында икәнен тойгач, тагын тынычланып йокыга талды. Кешеләрнең гүләвенә тагын бер тапкыр уянды һәм калкына биреп тирә-ягына карады, ашъяулык өстендәге икмәк телемнәрен күргәч, йокысы ачылып китте. Алар бит Мотаһар энесе өчен әзерләнгән, сагынып көткән әти икмәге...

—Әти, син беркайчан да, беркая да китмисеңме?

—Юк, улым, сезгә кайттым мин, мәңгегә!

Әтисенең тыныч, ягымлы тавышын ишеткәч, Мидхәт тагын йокыга тала. Кыска, ләкин михнәтле гомерендә иң татлы йокы иде бу.



Рәлис
Уразголов

## САНДЫК

ХИКӘЯ

—Апа, комганга жылы су салган идем, алып чык. Сездәге кебек, авылда хәҗәтханә өйдә түгел шул, и, Аллам, өшерсең инде,—дип өтәләнде Сәгыйдә.—Хәер, өйрәнерсең әле, озакка кайттым, дисең бит...

—Өшемәм, корыга кайгырма. Гомер буе комган тотмаганны, бүген генә абыстай булып булмас инде,—диде дә Гәшүрә, киез белән төпләнгән калын ишекне тышкы яктан япты. Чолан тупсасыннан таеп китмәс өчен көмеш саплы таягын чак кына алдан төшерде, аның артыннан аякларын шудырды.—Һай, шул кияү, гомер буе юньсез булды инде, кеше күтәрмәне шул кадәр биек ясыймы? Сәгыйдә ничек мантысын, какланган каз шикелле, арткан җире юк. Бу баскычтан көненә ничә тапкыр күтәрелә, төшә. Куй, бер юньсезгә чыкты бит. Анау нәрсәкәен дә өйдән әллә кайда итеп куйган, барып җитәр әмәл юк...

Атлаган саен Гәшүрәнең күзенә нидер чалына барды.

—Әстәги, күзгә төртелә,—дип, бакча киртәсенең бу ягына чыккан алмагач ботагын тиргәп алды.—Юньле кеше рәшәткәнең янына ук агач утыртамы? Шушы юлын әйтер идем, авылда да тротуар ясап була бит инде, ул, кеше көлдереп, кырчын таштан сукмак салган... Кит, әрәм итте гомерен Сәгыйдә. Гомере буе ир колы булды да, бала-чага нәҗесен тазартудан бушамады. Мал арасында йөрсә дә шул Сәгыйдә, өйдә дә шул Сәгыйдә. Заяга үтте гомере...

Гәшүрә йомышын йомышлаганда таягын тышкы якта калдырып керергә булган иде дә, кире уйлады. Кешегә ышанып буламы, алдылар киттеләр, дип уйлады ул, йөрерсең азак Садрый кияү ясап биргән кәкре тал чыбыгына таянып. Матурлап ясаса бер хәл әле ул, бар нәрсәсе чапмаган да юнмаган. Шушы убырныйны да кирпечтән салмаган, адәм көлдереп, мунча зурлык бураган да куйган. Йөгереп йөрергә җыена диярсең, эченә кергәч, тишеген таба алмый бер буласың.

---

Рәлис УРАЗГОЛОВ (1965) — *прозаик, ике китап авторы. "Башкортстан" газетасы редакциясендә эшли.*

Карчык таягын почмакка сөяде. Ишек келәсен элдерде. Такта ярыгыннан тышка күз салырга булган иде дә, алары шулкадәр нәзек, күрерлек өлеше каршыга өелгән тиреснең яртысын да күрсәтми. Бу хәл каты гына саруын кайнатты Гәшүрәнең. Ярый әле астарак ботак тишеген күреп калды. Иелеп, шунда күз салды: тирес башында чокынып, тибенеп йөргән тавыклардан, ара-тирә очып үткән тургайлардан башка җан иясе шәйләнми. Ул эчке якны карап чыкты, балчык белән күтәрелгән калын бүрәнәләр арасыннан чебен дә керерлек ярык тапмады. Садрый юкка гына шулкадәр туалет бураган дисенме, Сәгыйдә күрмәгәндә бер-бер этлек кыладыр әле, йә кереп эчепаладыр, карт шайтан, дип уйлады Гәшүрә.

Кирәкле җирдә әйләнгәләгәч, карчык итәген күтәрде дә күлмәгенең бил тәңгәлен капшады. Күнеленә олы бер куаныч табып, кабарып торган бөрмәләрен сыйпап-сыйпап алды.

—И-и, затлыкайларым, шунда гына ятыгыз, шунда гына. Иш янына куш сыя ул, арта торыгыз. Сез күбәйгән саен бөрмә бөгәрмен, шушы бөрмәләр бит ул минем сандык,—дип сөйләнә-сөйләнә, йомышына утырды. Тик кинәт биле тотты.—Ах-х, ү-үтерде...

Уф, аяксыз иткәне җитмәгән, шул хәзер билдән яздыра...

Шушы мәлдә Гәшүрәгә баягы ботак тишегеннән кемдер карап торгандай булып тоелды. Биле авыртуын да онытып, күлмәк бөрмәләрен сәрмәде. Һаман үзен кемдер күзәткәндәй; хәтта тегенең авыр карашын бар тәнендә тойды: әйтерсең, җилкәсенә ике ботлы гер асканнар—авырлыгы аяк табаннарын яндыра, чемердәтеп үткән тойгы чеметеп-чеметеп ала, калтырата. Ул башын селкеде. Бер карасаң, ботак тишеге көн яктылыгын эчкә төшерергә азаплангандай, икенче караганда тагын томалана. Тишек тагы ачылды. Карчык аның караңгылануын көтсә дә, бүтән ябылмады.

—Бетте, күрделәр!—диде Гәшүрә эчтән генә.—Харап кына булдым, яшерен сандыгымны күрделәр...—Тиздән аның башын тик бер уй чүкеде: кем булуы мөмкин?—Сәгыйдә дисәм... Тукта, бәлки, улдыр, апам нигә озаклады әле, дигәндер? Юк-к, булмас. Ә-ә...

Гәшүрә, ат башы чаклы алтын тапкандай, кычкырып ук җибәрде: «Садрый!» Әйе шул, нигә уеп куйган дисең ул тишекне, бигрәк сантыймын да инде, нишләп ботак тишеге булсын, махсус уелган булырга тиеш бу, дигән уйга килде хатын. Чынлап та, юкка гына мунча зурлык убырный бураган дисеңме ни? Ярамаганмы шунда. Әнә, кешеләрнеке алам-салам тактадан да ясалган бит әле, югычлык юкәсен сыдырган кабыктан көпләнгәннәре дә җитәрлек. Да-а, юкка бурамаган, бик зур хәйлә ята монда, хәйлә!

Тишек тагын капланды. Бу юлы хатын тышкы яктагының тын алышын да тоя инде. Карашы, инде Гәшүрә уйлаганча, Садрыйның карашы, алмаслык күләгә булып тагын тәненә ятты; тынын буды, саруын кайнатты, ярсытты, ыштанындагы бөрмәләрне тарткалагандай булды.

Гәшүрә почмакта сөялгән таягының очы белән келәне ачты да, бер аягының аксак икәнен дә онытып, тышка атылды.

—Әһә, эләктеңме азгын!—дип чырылдауга, таякның көмеш сабы һаваны ярып үтте һәм... убырный почмагына җилкәсен ышкыган бозауның башына килеп кунды. Ни булганын аңламаган бозау, ачы мөгрәп, авып китә язды. Тик, һушына килгәч, куркуыннан туры эчәгенә тыгылган нәрсәләрен бушатты да, ары чапты.

—Каһәр генә суккан... Шайтан. Мал хуҗасына охшый инде ул,—дигән өзек-өзек сукрану авазларын чыгарды, еш итеп тын алган арада Гәшүрә.

Тышка чыкканда ни булганын сиздермәскә тырышты Гәшүрә. Шулай да агарынган йөзеннән, кан сауган күз тамырчаларының кызаруыннан,

апасының буыла-буыла еш итеп тын алуыннан хафага калды Сәгыйдә. Бирешкән апам, олыгайган бит инде, дип уйлады ул.

—Бер-бер хәл булдымы әллә, апай?—дип сорады да фараз иткән сәбәпләрен үзе үк тезеп китте.—Авылда шул инде, урамга ук чыгып йөрергә кирәк. Әллә, дим, апа, бидрә-фәлән кертеп куяргамы? Ояты юк инде аның, Садретдин өйдә генә торган кеше түгел—тыштан керә белми, шунда нидер булса да шакылдап, чокынып йөри, мал җанлы кеше бит ул...

—Мал җанлы булганчы, лутчы сине уйласын иде. Шушы күтәрмәгә менә-менә хәл бетте,—диде дә Гәшүрә, диванга аркылы ауды.—Уф, һушын алыныр менеп җиткәнче. Берәр атна-ун көн торырмын дигән идем, булмас, ахры.

—Куйчы, апа, тор әле, күргәндәй дә, сөйләшкәндәй дә булмадык. Туган авыл да тартадыр, сирәк кенә кайткач, сагындырадыр да. Әти белән әнинең каберен барып күрербез, Коръән дә укытырбыз дигән идек,—дип үгетләргә керешә Сәгыйдә.

—Әстәги-әстәги, син дә мулла песие кебек, зират сөйлисең дә, Коръән сөйлисең. Садрый тәмам бозган сине.—Гәшүрә кесәсеннән кульяулыкка төрелгән даруын алып, бер төймәсен тел астына куйды.—Аннан тагы, дөньяда иң курыкканым шул зират та мәет...

—Нәрсәсеннән куркасың инде, апа, барыбыз да шунда барабыз. Борынгы юлчылар хәтта җәйләрен юлда куна калса, зиратка кереп йоклаганнар—тынычрак урынга.

Гәшүрә сикереп ук китте. Муен тәңгәлендәге кан тамырлары бүртте, кабакларын ертып, күз алмасы бит сөякләренә тиңләште, өстендә әллә күпме сырлар барлыкка килеп, танау тишекләре зурайды, чалшайган авызы тартылып бөреште. Гәүдәсен тагы сикертеп алды да диванның икенче ягына ук күчте.

—Кит, кит сөйләмә, үлгәч кайда куйсалар да барыбер түгелмени? Тавык сыман чүплеккә генә ташларлар иде дә, эт-фәлән тимәсен, карга чокымасын дип кенә күмәләр инде. Әстәги, шушы яшеңә җитеп, юк-бар сөйләп торасың.—Сәгыйдә эндәшмәгәч, Гәшүрә үзенең сүзе өскә чыгуын тойды, сөйләгән саен үз-үзенә ышана барды.—Әти-әнигә дә синең гарәп сүзләрең кирәкми, күптән сөякләре дә юктыр инде аларның...

Кеше үзгәрмәгәч үзгәрми икән, дип уйлады Сәгыйдә. Яше җитмештән узса да һич үзгәрмәгән апасы. Әнә бит, хәтта әтисе белән әнисе турында да... Аллам сакласын, уйлавы да куркыныч, тәүбә-тәүбә. Хәер...

Аталары Нәкыйулланы авылда Нәкый дип кенә йөртteләр. Олыгаеп гасырга якын гомер кичереп дөнья куйды. Авырып та йөрмәде. Тик җан бирер алдыннан атна-ун көн алда гына яшьлек, балалык еллары белән саташып алды. Кайдандыр йөгән табып алган, мәрхүмкәйнең, мөгаен ат караучы—конюхлардандыр инде, башкача кайдан булсын—ул чакта халыкка ат асрарга рөхсәт юк иде бит. Өстенә ап-ак күлмәген, кара чалбарын, өр-яңа сырмасын, аягына энәдән генә төшкән оекбашын, каз мае сөртеп ялтыраткан кәлүшәсен киеп ала да, йөгән авызлыгын зыңгылдатып, урам буйлап китә: «Минем атны күрмәдегезме, балалар? Калхуз дип апкиткәннәр иде, башына җиткәннәрдер инде. Тай-тулагы җәл түгел, туратым югалды менә. Күрмәдегезме, малайлар?»

Бала-чага да шук бит, олыны-олы дип белмиләр, мәрәкәләргә, нидән булса да кызык табарга гына торалар. «Күрдек, күрдек, кутырлыкка төшеп бара иде», диләр дә, кәҗәләнә-кәҗәләнә, юктан да хихылдашып, башлары тирәли бармакларын бораулап, маймылдай кыланып бабай артына төшәләр. Нәкый карт тау башына басып, кутырлык ягын айкый. Туры аты күренмәгәч, сабыйларча үчегеп, малай-шалайны куарга тотына: «Ристаннар,

иваннар, алдатып йөрисегез, чукынмышлар,—дип ачы тавышы белән берчә әрнешеп чыгара, берчә, сукранып, авыз эченнән мыгырдый:—Кеше атын югалткан, алар кеше кайгысыннан көлә...» Соңгы сүзләре белән ул кайткач карчыгы Хәсбиямалга да сукрана. «Карчык, туратым әллә кайда булды. Балалардан сораган идем, алар алдакчы булып чыкты, иванлашырга гына торалар»,—дип, озак кына үпкәләп йөри. Тик Хәсбиямалның: «Кайтыр турат, кайтыр бабакай, әйдә, чәй эчеп алыйк та, аз гына ятып тор. Син хәл алган арада мин карап әйләнермен»,—дип иркәләвенә генә тынычлана төшә. Йә булмаса: «Кайтмас инде ул, калхуз аны упалнамучка биргән, ди»,—дип, йөгәнне коча да, әбиенең итәгенә башын салып, сабыйларча елап җибәрә. Бу арада Сәгыйдәнең әнисе әтисенең чәчсез түбәсен сыйпый: «Кайгырма, карткаем, нахакка тартып алынган малларыбызга утырып, кылдан да нәзек тәмуг күперен чыгарбыз әле. Елын-елы корбан да салып киләбез, ахирәттә дә хайванкайлар җитәрлек. Фанилыкта, Аллага шөкер, балаларның сарае тулы мал-туар. Безнекен сыпырып алып, йорттан кусалар да, иншалла, җитәрлек. Ялкауның балалары да үзләреннән ерак китмәгән»,—дип туктаусыз тамакларга керешә.

Аталары түшәккә егылып та озак ятмады. Баш очына Газраил фәрештә якынлашкан саен аның аны, киресенчә, ачыла гына барды, әҗәле килеп җиткәнен дә аңлап ятты.

—Карчык, балаларны барсын да җый, кайтсыннар. Бәхилләшергә вакыт җиткәндер,—диде ул бер көнне, һәр сүзенә басым ясап.

Карт әйтмәсә дә Хәсбиямал читтәге бар балаларына, онык-онықчаларына хәбәр иттергән иде инде. Алтысының бишесе юлда булуын, тик Гәшүрә апасының гына кайта алмавы турында күңелсез хәбәр әйтте Сәгыйдә. «Әни, ул кайта алмый, шәмбе белән якшәмбе талчукта базар көне, сатуның самый төшемле чагы»,—диган иде дип, гарьлегеннән яшенә буылды. Гәшүрә апасы җибәргән конвертны әнисенә тоттырды. Хәсбиямал аны ачуга, егерме бишәр сумлык ике кәгазь акча һәм хат кисәге төште. «Әни, мине беләсең—мәеттән куркам. Әтине җирләр өчен илле (!) сум акча салам. Авырып, бар нәрсәсе астында булганчы, олы кешенең котылганы хәерле. Сиңа да авыр бит. Аңла, әни, мәеттән куркам»,—дип язылган иде анда.Хәсбиямал еламады. Аскы иреннәрен калган өч бөртек теше белән кысты да: «Ярар инде, бигрәк нечкә күңелле бит, әтисе күз алдында тере килеш калсын, дигәндер инде»,—диде. Әнисенең эчендә утлы күмер базласа да кешегә сиздермәгәнен яхшы аңлаган Сәгыйдә: «Үз намусында инде, әни, әти өчен кайгырган да җиткән, шуңа да борчылма. Бер бүген генә мени»,—дип юатырга кереште. Сәгыйдәнең «бер бүген генәмени» диюендә «картәтием белән картәниемне дә җирләргә кайтмады» мәгънәсе ята инде. Соңыннан, берничә елдан, шушы ук хәл әнисе мәрхүм булгач та кабатланды...

—Уф-ф, бу йөрәк, чукынгыры...

Сәгыйдә сискәнеп китте. Йөрәк тәңгәлен тоткан апасы калтыраган куллары белән кульяулыгыннан дару төймәләрен алырга азаплана.

—Һәй, уйланып китеп, карамый да торам, апа,—дип Сәгыйдә үзен тиргәп алды.—Кая, даруынны үзем алып бирим.

—Юк-ук, тыгылма кесәгә!—Гәшүрәнең күзләре акайды. Соңыннан, артыграк җибәрдем ахры дигәндәй, болай юхалады:—Үзем дә, үзем дә таба алам, юкка борчылма. Зират дисең дә хәбәр сатасың бит, әллә минем мәетләрдән курыкканны белеп юри сөйлисең?

— Нишләп юри сөйлим ди инде, апа, тик әти белән әнинең кайда ятканлыгын гына күрсәтермен дигән идем. Без дә шул тирәдә...

—Әнә, тагы башланды. Кайда күмсәләр дә барыбер түгелмени бер дөмеккәч?—Гәшүрә, авыр көрсенеп, тирән итеп тын алды.—Шулай да

үләсе килми бит әле минем, үләсе килми. Тазалык та бетте бетүен, шушы тәгәрмәчләрне генә кабып торам. Үлә-нитә калсам, Сәгыйдә, сина васыять итеп әйтәмен, теге ни, юып, чишендереп, ак простыняга төреп тормагыз, яме.

—...?

—Шул көе генә грубка салыгыз да—вәссәлам! Гомер буе Алласына да, мулласына да ышанмадым, үлгәч кенә килештереп ятасы юк әле. Шуннан тагы, тәнемә теләсә кемнең тотынганын теләмим...

Апасының юк-бар сөйләвеннән тәмам арыды Сәгыйдә, мунча ягасы барлыгы исенә төште.

—Ярый, апа, үләргә иртәрәк әле, ә мунчаны хәзер үк ягарга кирәк,—дигән булып, сүзне башкага борды.—Син чәй эчә тор, мин мичкә төртеп киләмен.

—Ни, синен һаман шул кара мунчамы, Сәгыйдә? Керсәм корымланыплар чыга торган гадәтем бар, кара булса ягып та торма, яме. Ы-ы... Кһы-м... Кайткач ваннада юынырмын әле, димәкчемен.

—Апа, авыл мунчасына җитә мени ул?—Сәгыйдә дәртләнеп сөйләп китте.—Садретдин тик тора торган кеше түгел, үзе кара мунча яраткач, анысын сипләп, ындыр артына утыртты, йорт алдына агын салды, аның хәл ала торган ягы да бар. Бала-чага кайтса, шунда пычтырдаша. Без үзебезнекенә—карага китәбез. Их, тын алулары икенче бит ул кара мунчада-а...

—Харап икән, харап! Карап торам да сина, Сәгыйдә, һич кенә үзгәрмәгәнсең: теленнән Садрыен төшми, һаман шул илгәзәк, беркатлысың. Гомерендә ир киеме юудан, бала-чаганың пычрагын тазартудан башканы белмәдең. Үзең өчен яшәмәдең, минем сүзне тотмадың, һай тотмадың. Гомер буе ир колы булдың. Кол инде, кол булмый, кем син?

Бу сүзләрне ишетмәмешкә салышты Сәгыйдә, мич өрлегеннән шырпы үрелеп алды да, чоланга чыкты. «Кара, дөрес әйткән борынгылар, алтыдагы алтмышта икән»,—дип уйлады ул.

Гәшүрә сеңлесенең мунча ягына юнәлүен тәрәзә аша озатып калды. Өстәл янына килеп, самавырга бармак чукларын тидереп алды. Кайнар.

—Һаман шул искелек калдыгына ябышып яталар, чыжлатып бер булалар. Самавыр чәе тәмле, имеш. Сылтау гына ул, сылтау. Садрый карун газын җәллидер әле, шуңа Сәгыйдәне этлиләр күмер сүндертеп. Шәһәрдә яшәп карасыннар, әнә, һәрнәрсәгә акча чыгарсалар белерләр иде. Монда ни, барсы да үзләренеке, яшиләр кулак кебек бушка ашап...

Гәшүрә килгәч үк үзе яткан диван тартмасына тыгып куйган сумкасын алды. Аннан ялтыр тышлы шоколадның берсен сүтеп, кәгазен кире салды.

Күчтәнәчкә әллә рәхмәт әйттеләр, әллә юк, дип уйлады ул, юк, әйтмәгәннәрдер. Өйгә кергән бала-чагага таратты да бирде «карамель» конфетларын Сәгыйдә. Әллә Гәшүрә бар авыл шпанасына алып килгән, ди? Бетмәс Садрыйның токымы. Пеләмән үгез шикелле, нәселе дә катлы-катлы чукынганның. Сәгыйдәдән сигезне таптырды, алары үсеп җитү белән үзләре тупылдата башлады—очына да чыгарлык түгел. Әнә бит, килога якын конфет «шап» итеп калды. Әллә үзенә чәй эчәргә дип алып килгән әле яраткан шоколадын, кимерер иде Садрыйның каткан писугын. Игелек күрсәтә торган нәсел түгел инде, түгел. Шул Сәгыйдәсе булмаса, кайтып та урамас иде. Олыгайган саен исән калган бердәнбер сеңлесенә тартып тора бит. Шулай да тиз туйдыра авылда, биздерә. Ни табалардыр инде шунда: көн дә иртән тор да мал тизәге тазарт, тор да сыер җилененә карап кат, юк, тормышның кадерен белмиләр монда,

гомерләрен әрәм итәләр. Хәер, калада яши аламыни алар? Анда бит кругом акча кирәк.

Уйлары акчага барып төртелгәч, Гәшүрә дертләп китте. Кайда куйды соң әле ул кайтырга дигәнен? Ә-ә... ы-ы... Әй, шулай бит әле, сумкасында ласа! Юлына да күп китә шул. Әле автобуска утырасың, әле «попутка»га. Күчтәнәче дә кирәк. Уйлап тапканнар бит теләсә нәрсәкәй, кунакка барсаң—күчтәнәч ал, имеш. Лутчы шуның хакын үзең ашасаң, атнага житәр. Безнең халык кына ыштансыз инде, әнә, монда килү өчен дә күпме кирәкте. Тә-әк... Килога якын кәнфит, ике кап һинд чәе, ике-өч төрле булка-а... Ә юлы, юлы!

Чолан ишеге ачылуын ишеткәч, Гәшүрә калган шоколадын тулысынча авызына капты. Чәйни алмый азаплануы гына житмәгән, артыннан уртлаган чәе аңкавына капланды. Чәчәде. Ирреклеген, теге шоколад кисәге идәнгә очты. Гәшүрәнең бар тәне калтырады. Менә-менә Садрый килеп керер дә: «Әһә, эләктеңме угры, үзең генә күшәп утырасыңмы?»—дияр төсле булды. «Тиз, бик җәһәт кенә эләктерергә дә, өйгә килеп үк кергәләгәнче, кесәгә тыгарга кирәк». Бу уй ми сырлары буйлап та йөгерергә өлгермәде, идәндә яткан соры «камыр»ны үрелеп алырга азапланган карчык утыргычы-ние белән тәгәрәп китте.

—Уф-ф... Ба-ба-шы-ы-ым...

—Менә, апа, ягып җибәрдем, ахшамнан соң мунчага да барырсың, Аллаһы боерса...—Сөйләнеп кереп килгән Сәгыйдә, кинәт дертләп китте.—А-а-па!!! Куй, шаяртмачы, апакаем, шаяртмачы...

Ләкин Гәшүрә шаяртмый иде. Сандык читенә терәлеп ук яткан башы астыннан идән буйлап кан йөгергән, ачык күзләре тоныкланып калган да җайлап кына яры белән каплана бара, алтын тешләрен кызартып, ачык авызы читеннән дә кан юллары сузылган; кысылган учының бармаклары арасыннан соры сыекча агып чыккан, икенче кулы эч тәңгәлен борып тоткан.

Сәгыйдә апасының башын кочты.

—Ташлама берүк, ташлама, яшик әле...—дип әйтте ул.—Әй, апа, нишләдең син мин чыккан арада, нишләде-ең? Әй, мин генә гаепле, мин генә, нишләп ташлап чыктым икән, Ходаем?

Сәгыйдә апасының маңгаеннан үпте, чәчен сыйпады. Шулчак, нигәдер, аңа әнисен кочкандай булып тоелды. Моннан унбиш еллар чамасы элек тә, авыру әнисе якты дөнья белән хушлашкач, ул нәкъ элеккечә елаган иде. Хәлсез Хәсбиямал карчык тәнендә калган көчен җыйды да, тартыла, сузыла биреп: «Бәхил бул, кызым. Барысы да җыелыр, тик... Гә-Гәшүрәм белән Рев-Ревлен гына килмәс-с. Бәхиллегемне җит-кер. Гә-Гәшүрәгә рәнҗемим»,—диде. Әнисенең «рәнҗемим» дигәнен төрлечә юрап була иде. Җирләшергә кайтмаганга да, башкача да...

Гәшүрә фатир кинәйтер булгач, әнисен бераз үзенә яшәргә алып торган иде. Шулай итмәсә, өстәмә бүлмә бирмиләр иде ул чакта. Кышын тышка чыгып йөрергә дә җинел булыр дип, әй, шатланып китте Хәсбиямал би! Китүен китте, тик ай да үтмәде, өлкән кызы аны кире кайтарды...

—Кайтам, дип, мыжып тик йөрде. Ревленга да дәрес әзерләргә ирек бирми,—диде ул. Үзе, чишенеп тә тормый, автобуска өлгерергә кирәк, дигән сылтау табып чыгып та китте.

Әнисендә нindидер үзгәреш барлыгын шунда ук сизде Сәгыйдә, тик башта ук ни икәнен аңлап җитмәде. Чишендереп, яңа киемнәрен алырга сандыгы янына китерим дисә... Коты алынды: Хәсбиямалның әлегә кадәр тасмалап, очына чулпы-тәнкәләр тагып үргән чәче юк иде! Үзе дә сизмәстән, ул әнисенең яулыгын сыпырып төшерде.

—Ә-ни...—диде дә, хәле бетеп, артына—сандык өстенә утырды.—Ни-ни бу-улды-ы?

Хәсбиямал елап җибәрде. Бәләкәч кенә калган ябык гәүдәсе дер калтыранды, үксегәндә сикереп-сикереп китте.

—Әрәм генә итте гомер буе үстергән толымымны, балам, әрәм итте. Төенчектә ята ул хәзер, төенчектә... Гәшүрә кисте, көн дә чәченне тарап торырга ни, диде дә кисте. Йә бетләрсен, сина монда еш юуынырга бушка килгән катык белән йомырка юк, диде... Үлгәч, түшемә салырга да калмады хәзер чәчем, балакаем, түшемә салырга да калмады. Рәнҗим мин ана, рәнҗим...

Сәгыйдә ул чакта әнисен юата алмады, күңеленә ятарлык сүз тапмады. Кадерле кешесенен елавын тәү тапкыр күрүе үзенә дә авыр иде. Ирексездән, яшенә буылды...

...Гәшүрәнең гәүдәсен өйнең түр ягына куйдылар. Табиб, бүлекчә инспекторы килеп карагач, тиешле кәгазьләр язып, култамгалар салдырдылар. Берничә сәгатьтән инде үз машинасында калага киткән Сәгыйдәнен улы Ильяс кайтып житте. Гәшүрәнең бердәнбере Ревленга әнисенең үлеме турында әйтергә барган иде ул.

—Ревлен абыйны офисында очраттым...

—Кайтмыйдыр!—дип бүлдерде улын Сәгыйдә.—Мәеттән курка, бигрәк нечкә күңелле бала шул. Күз алдында әнисенең тере килеш калганын телидер...

Сәгыйдә, елап җибәрүдән чак тыелып, аскы иренен тешләде дә, ул биргән кәгазь кисәген алып, кашыгаяк ягына чыкты. Калтыраган куллары белән зур конвертны ачты. Андагы кәгазьгә компьютерда шундый сүзләр басылган иде.

«Апа, мама билән прощаться итәргә кайта алмыйм. Улган кешедан куркам. Кумганда карагыз але, анын акчасы булырга тиеш, алтын айберлары да, разные бриллианты. Может быть они в одежде. Ос кондан кайтам, сезгә расходы на похороны туламын шунда. Авылда кумыгез, здесь сами знаете, похороны, поминка на то обходится. Постарайтесь бабушкалар кырында похоронить. Очень сожалею, но не могу приехать...»

—Елама, әни,—диде янына чыккан Ильяс.—Әбием өчен борчылганын житкән, һәркемнең үз намусында...

—Ә-ә... Әйе, улым, әйе. Ни, син хәзер ук төнәтергә карчыклар чакыр, Коръән чыгарга мулланы алып кил. Мөселманча җирләрбез. Үземә әзерләнгән кәфенлекләр дә бар,—диде дә Сәгыйдә, соңгы сүзләрен апасына төбәде:—Ачуланма, апа, васыятеңне тоталмыйм. Җәсәдеңне дә үзем юармын. Үзебезчә җирләтсәм, ичмасам, җанын бераз тынычлык табар...



Салават
Әбүзәр

## Гулливер

**Зурайганнан-зураям мин,**
**Буй җитмәслек олымын.**
**Йөзем белән ерып үтәм**
**Болытларның толымын.**

**Айга ялгыш башны бәреп**
**Куймыйм, диеп сакланам.**
**(Аны чарлап торалар бит—**
**Үткер хәтта балтадан).**

**Түбәндә—аяк астында**
**Җемелдәп яна утлар,**
**Һәм ары-бире үткәләп,**
**Йөриләр лилипутлар.**

**Ә колакны җилләр түгел,**
**Иркәли сөю җыры.**
**...Бүген ярым: "Сөям!"—диде,**
**Мин—сөю Гулливеры.**

***

**Күзләрең—зәм-зәм чишмәсе,**
**Сүзләрең—**
**җанга дәва.**
**Җир, гүя оҗмах бакчасы,**
**Мин—Адәм,**
**ә син—Хәүва.**

Салават ӘБҮЗӘР (1967)—*шагыйрь, "Җиремә җыр", "Ызгыш алмасы", "Тугызынчы дулкын" һ.б. китаплар авторы. "Башкортстан" газетасының әдәбият һәм мәдәният бүлеге мөдире.*

Җимешләрнең иң татлысын
Тыйгандыр, бәлки,
Алла.
Гөнаһыннан куркасым юк:
Сөюең миңа—
Алма.

Әгәр безнең керсез сөю
Гөнаһ икән,
кадерлем,
Синең белән тәмугка да
Сөрелергә
әзермен!..

## Дуэль

Синең белән мин—
дуэльдә.
Кашлар җәя,
Керфекләр—ук.
Бер угың да
читкә очмый,
Йөрәгемә тия
Тук-тук...

Күнекмәләр үтмәсәм дә
Мин үзем дә
Мәргәнмен бик!

Укларымны
йөрәгеңнең
Уртасына
Бәргәнмен бит.

Син дә, мин дә
өстен түгел,
Тик шунысы гына
ачык:
Икебез дә авачакбыз,
Авачакбыз...
Кочаклашып...

## Пират

Зәңгәр күзең—
зәңгәр диңгез...
Күңел кинәт
җилкенде.
Һәм ташландым
кочагыңа
Киереп сөю—
җилкәнне.

Тибрәтте ярсу
дулкының,
Шыгырдап торды
мачта.

Миңа берни
кирәк түгел
Синең киңлектән
башка.

Максатыма җитми
тынмам—
Ир-ат һәрчак
ир-ат ул!
Әгәр сөю диңгез
булса,
Диңгездәге—
пират ул...



# Гөлназ Котыева

## Әй, моңым...

**Актардым хәтерем битләрен,
Эзләдем югалган шул моңны,
Бер якта талпынды карашың,
Бер якта сагышым кул сузды.**

**Йөгерде каршыма дулкыннар,
Йөрәгең ни диеп сулкылдар?
Күзләрең ачармы киңлеген,
Киңлекнең Җиһанга тиңлеген?**

**Актардым хәтерем битләрен,
Гөлт итеп кабынгач ялкыннан.
Син мине ук диеп уйларсың,
Күңелем җәядәй тартылган.**

**Актардым хәтерем битләрен,
«Кайдасың?»—
Ымсынып үрелдем.
Гаҗизмен мин синең яклауга,
Әй, моңым. Көтмәстән сүрелдең...**

## Ымсыну

**И илаһи кодрәт,
Бүген таңнан
Баштанаяк нурга тиендем,—
Җаным чыга язып карап тордым
Уйнаганын ике тиеннең.**

Гөлназ КОТЫЕВА—*шагыйрә, Башкортстан республикасының Шәехзадә Бабич исемендәге дәүләт яшьләр премиясе лауреаты, филология фәннәре кандидаты. «Агыйдел» журналының җаваплы сәркатибе. Дүрт шигъри җыентык авторы.*

Ике нурның бергә кушылганын,
Базлаганын янып алтындай;
Йота язып озак карап тордым,
Сабыйларын уйнатырга чыккан
Дөньялары бөтен хатындай.

Ике тиен—
Ике төенчекме?
Ялт-йолт кына итте күз алдым,—
Бер-берсеннән узып уйнаганда
Ике сабый,
Ике шаян тиен,
Мин эндәшми генә түзалдым...

## Ничек?

Тышта—яңгыр...
Минең күңелгә дә
Шул салкын су үтә, үтә, үтә...
Хыялдан син нинди сарай салдың!
Иске-москы өйне сүтә-сүтә.

Кайда соң ул күңел ымсындырган
Тын рәхәтлек?
Юкка талпынуым...
Дөньяларның асты-өскә килде,
Яңгыр ява,
Юын, тирәк,
Юын.

Үзем дә бит синең хәлдә дә соң...
Юлларыма яңгыр чаршау корган.
Тагы ничек яхшы булырга, дип,
Тагы ничек матур булырга, дип,
Мин аптырап, менә, басып торам.

## Акыл

Җәй дә үтте...
Ераклаша чыңы
Юлга тупланышкан кошларның...
Кем соң белгән
Чыңрап сузгән мизгел
Өзелгән бер кылга охшарын?!

Кем соң белгән—
Үрмәкүчләр корган
Ауда җемелдәрен үткән көннәр?
Юк, чакырмас безне сандугач та,
Килер мизгел генә, бәлки, өнәр...
Җәйгә тартым гына гамәлләрне
Оныттырыр яфрак явымнары.
Һәр мизгелдән яратырга өйрән,
Дип шыбырдый, әнә, чаган тагы...

* * *

Бүген, беләм, бу калада син юк,—
Изри йортлар ап-ак томанда,
Мин бәхетле икән синең белән,
Синең барлыгыңны тойганда.

Бүген, беләм, бу калада син юк,—
Тәрәзләрнең сүрән балкышлары.
Якынайтып, берчә ерагайтып
Сынавыдыр, ахры, бу кышларның.

Беләм, бүген бу калада син юк,
Телсез сәгать кебек йөрешләрем.
Тик җил генә уйный урамнарда,
Җилләр аша кайтып килешләрем.

Юлларыннан язган караб кебек,
Кайда гына барма харап кебек,
Әчетелми калган шәраб кебек,
Тешсез тарак,
Суык барак кебек,
Йөрәгеннән язган карак кебек,
Алай дисәң,
Карлар ап-ак кебек...

Бүген бу калада, беләм, син юк...

## Чаган яфрагы

Нигә генә, нигә буташтырдың
Алтын көзне ап-ак кыш белән?
Бер мизгелдә көннәр чуалышкан,
Алтын көзгә ак тун юш килгән...
Ап-ак карга яфрак ятып елый,
Туфрагыннан мизгел аергач,
Җилләр аны төрле җиргә ташлар,
Туктар әле берәр, арыгач.
Ә Җир-Ана гамьсез каламы соң
Баласының шундый зарына?
Ипләп кенә, юаткандай итеп,
Ак тунынnan мизгел арына.
Тынычланып торыр әрсез җилләр,
Кышкы тынлык басар җир өстен,
Чаган ботагында тик бер яфрак
Хәтерләтеп торыр көз төсен.



Әмир Әминев

# ТАНКИСТ

ПОВЕСТЬ

—Илшатның иптәше машина алган, шуны юарга бардык,—диде кызы әтисенең сораулы карашына төртелеп. Туфлиләрен салып почмакка куйды да авыр сулап ишектән күренгән иренә борылмый гына:—Чәй куй, мин ваннага кереп чыгам,—дип өстәде.

Әти кеше кызының артыннан бераз карап торды да үзенең йоклап йөргән бүлмәсенә юнәлде, караватына утырды, киявенең туйган сыер кебек мышный-мышный кухняга үтүенә җаны көеп стенадагы сәгатькә күз салды—төнге бер. «Бу вакытта нинди чәй ди ул, иртәгә тора алмый ятачаклар бит, байтак утырганнар, ахры, икесе дә ару гына төшергән»,—дип уйлады.

Кызы Гөлсем, юынып чыккач озак мыштырдама дигәндәй, ирен ваннага этәреп җибәрде дә чәй әзерли башлады. Соң гына чәй эчәргә утырдылар. Карт, баш тартып караса да, бүлмәсеннән үгетләп чыгардылар барыбер.

—Әти, син хәзер бездә яшисең, моннан ары да яшәрсең, әйдә, авылдагы өйне сатыйк, ә? —Гөлсем көчләп елмайды, болай да кызыл йөзе аракыданмы, әллә юынуданмы тагы да кызара төшкән.—Әнә, Илшатның иптәшенең әле генә күтендә алмаш ыштаны да юк иде, бүген машина алды. Әнисен үзләренә китергәннәр дә авылдагы өйләрен сатканнар.

«Чираттагы һөҗүм башланды,—дип уйлады карт.—Һаман бер балык башы: бездә яшисең, дип кенә җибәрә. Көчләп дигәндәй алып килгәч, нишлисең, яшисең инде. Кәсепкә әйләндерделәр монда торуын. Нигә алай бугаздан алырга? Хәбәрне: «Сатырга уйламыйсыңмы, шулай итсәк ничек булыр икән?»—дигән рәвештәрәк алып барып була бит. Теләкләренә бер дә каршылыгы юк, тик кешечә, адәмчә сөйләшергә, аңлашырга кирәк ләсә. Кемнең дә күңеле бар...»

Ә кияве, хәйләкәр нәрсә, эндәшми, чәй уртлаган булып, ашъяулыкка коелган икмәк вагын әле бер якка, әле икенче якка тәгәрәтеп-шудырып, аска карап утыра. Хәбәргә кысылмый берәү, янәсе, ләкин ул читтән күзәтүче түгел, ә төп коткычы—кызы бит аның сүзен сөйли.

Әмир ӘМИНЕВ (1953) — *прозаик, башкорт һәм рус телләрендә чыккан бернича китап авторы. "Агыйдел" журналының баш мөхәррире, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

—Ничә тапкыр кабатларга: әле генә сатарга исәбем юк!—диде карт кызына карап.

—Нишләп? Сәбәбен әйт,—дип Гөлсем күтәргән чынаягын кире утыртты, ә кияве урындыгын олы тавыш чыгарып читкә шудырды да торып ук китте.

—Сезне ялкытсам, авылга кайтып торырмын, дим.

—Ничек инде «ялкытсам»? Моннан ары бездә яшәрсең дип сөйләштек ләсә. Бер өйрәнсәң, өй дә, авыл да искә төшми ул.

—Сиңа шулайдыр да, минем истән чыкмый. Барыбер шәһәргә берегеп китә алмамдыр. Тамыры ныгынып китсен өчен агачны да яшь чагында күчереп утырталар, олыгайгач тамыр ныгыта алмый. Соң. Минем дә шулай.

Кар эреп, үлән калыккач кузгалырмын, дим.

—Әти, нишләп син безгә ярдәм итәргә теләмисең ул, ә? Әллә мине үги итеп карыйсың?..

—Мин сиңа алай димәдем. Тирәнгә төшмик. Миңа син дә, абыйларың белән апаларың да бердәй кадерле. Бармакның кайсысын тешләсәң дә авырта. Шул якын булганың өчен былтыргы бәрәңге акчасын да, сыер акчасын да тоташ сиңа бирдем түгелме соң?—Кызының «үги итеп карыйсың» дигән сүзләре аның теңкәсенә тигән иде.—Ә син һаман риза түгел. Сыймыйм икән, алып барып ташлагыз. Мин сезгә көчләп килмәдем.

Ихтыярымнан тыш алып килдегез.

—Юкны сөйләмә, мин бит ул мәгънәдә түгел,—кызы башын чайкап кулларын күкрәгенә куйды.—Сыймасаң, китерер идекме? Зинһар өчен, ул уеңны ташла.

—Нигәдер, өйне бушату, аннан сатып җибәрү өчен алып килгәнсездер, дип уйлыйм шул. Кәефең ничек, өйрәндеңме, кыен түгелме, дип кызыксыну юк, бөтен хәбәрегез әлеге шул өй дә машина.

Гөлсем урыныннан калкынды, өстәлдәге савыт-сабаны шарт та шорт җыя башлады. Эшен бетергәч, бер сүз дә әйтми, әтисенә күтәрелеп тә карамый, бүлмәсенә кереп китте. Анда кызу-кызу мөңгерәшүләре, пышылдашулары байтак ишетелеп торды. Күбрәк кияве сөйләде, аның тавышы чыкты. Әти кеше аларның сүзен аңламады, хәер, аңларга, ишетергә теләге дә юк иде. Аларның картның кирелеге, янә ризалата алмаулары хакында сөйләшүләре болай да аңлашылып тора.

Тимергали карт урыныннан авыр кузгалып бүлмәсенә керде, озак йоклый алмый ятты, уйланды да уйланды...

Менә бер елдан күбрәк инде шәһәрдәге кызы белән киявендә яши Тимергали карт. Озак еллар янгын сүндерүче, ягъни пожарник булып эшләде, шул эшеннән пенсиягә чыкты. Янгын сүндергәнгә тиклем ат карады, каравылда торды, халыктан сөт, көл җыйды, аңа кадәр сугышта йөрде. Танкист иде. Авылда аңа үзеннән олылар гына исеме белән эндәште, ә яшьтәшләре «Танкист» диде, яшьрәкләр өчен ул—пожарник.

Карчыгы кинәт кенә вафат булып куйды. Җәйгә кереп кенә торган чак иде. Бер танда карчыгының җан атып кычкырганын ишетеп уянып китте, аш-су пешеренә торган яктан килә иде тавыш. Шуннан гөрс итеп нәрсәдер ауды, Тимергали, йә утыргычны аударды, йә дару эзләгәндә өстәл тартмасын нык ачып, идәнгә төшереп җибәрде, дип уйлады. Җәһәт кенә торып, шул якка йөгереп чыкты: карчыгы идәндә ята, авызында күбек, башын әле болай, әле тегеләй боргалый. Карт аны күтәреп диванга салды да фельдшерга чыгып йөгерде. Анысы килеп укол кадады. Уколдан соң карчыгы йоклап китте, әмма бер сәгатьтән соң исенә килә алмый үлде. Кан басымы югары, инсульт, диде фельдшер. Шуннан карчыгын җирләгәнгә ай да үтмәде, шушы Гөлсеме, төпчеге, кайткан саен үзләренә килеп яшәргә үгетли башлады

бит: «Ялгызына кыен, этләнмә, сине алып кайтып пропискага кертсәк, фронтовик дип безгә өч бүлмәле фатир бирүләре дә ихтимал...»

Тәүдә карт бөтенләй баш тартып караса да, кызының һөҗүме ярсурак була башлагач, уйлармын, диде. Анысын да Гөлсемне тынычландыру, вакытны сузу өчен генә әйткән иде дә, ахырда ризалык бирергә мәҗбүр булды. Кош-кортын бетерде, ике сарыгының берсен суйды, икенчесен сатты, сыерын күршеләре алды, бәрәңгесен Ырынбур ягыннан килеп җыеп йөргәннәргә төяп җибәрде һәм беркөнне ишеген бикләде дә кызы ялләп алып кайткан машинага утырып китте дә барды. Авыр тойгы белән китте.

Килгәннен икенче көнендә кызы белән кияве эшкә, оныклары мәктәпкә чыгып йөгергәч, кабаландым, ахры, быелгы елны, ичмасам, үткәрергә кирәк булган, дип уйлады. Тик соң иде инде, кышны кышламый кайта алмый ласа хәзер. Яшел үләнгә аяк басу белән кире юлланыр.

Әмма юлланмады. Кеше аптыратмыйм, дип уйлады. Хәзер менә шәһәрдә икенче көзен көзләве...

Җәй сузылдымы, әллә күз шулай килергә ашыкмадымы—көннәр октябрь урталарына кадәр коры торды да куйды. «Эх, шушы мәлдә авылда булсаң иде»,—дип пошынды Тимергали карт. Бәрәңгесен күчкә салыр, ихата-курасы тирәләрен караштырыр, кагар, ямаштырыр, бакчасына тирес түгәр; кош-кортыннан, мал-туарыннан бушамый йөрер иде. Мәшәкате күп булса да, авыл тормышы күңеленә якын барыбер дә. Анда син гел генә эш белән мәшгульсен. Ә монда...

Төшкә тиклем өйдә утыра Тимергали карт. Зарыгып, уйланып, бар тормышын башыннан үткәреп утыра. Оныклары мәктәптән кайткач, урамга чыга: өй тирәсендә, якын урамнарда йөри, базарга барып азык-төлекнең хакын белешә, йөгерешкән кешеләрне, бигрәк тә үзе кебек карт-корыны күзәтә. Әйе, кайда да тормыш, һәркемнең үз мәшәкате, үз йомышы: ашыга, йөгерә, этешә-төртешә транспортка утыра.. Бу шәһәр дигәннәре хас кырмыска иләве икән дә. Ана, авыл кешесенә болар барысы да кызык, мәрәкә.

Йортны сату мәсьәләсе беркөнне кич янә калкып чыкты—магазиннан күтәренеп кайтты да, Гөлсем бөтен ачуын, аруын шуңа ялгап, машина булса, шушылай ишәк кебек йөрмәс идем, дип тузды да китте. Бу юлы да әтисен үзен яратмауда, анларга теләмәүдә гаепләде, ул йортны ни хаҗәтемә черетеп утыртасын инде, дип битәрләде.

—Ничек сатыйм, мин бит аны үз кулларым белән салдым, әниен дә риза булмас иде... Мин үлгәнче утырсын, шуннан сатырсыз,—дип җаваплады карт.—Ул—минем тыл. Чигенү ихтималлыгын бервакытта да исеңнән чыгарма, ди торган иде командир.

—Нинди тыл, нинди командир тагы?

—Сугыштагы инде.

—Әллә саташасың? Ул исәр командирның өйгә ни кысылышы бар?

—Ә-ә-ә, алай димә, Гөлсем, командир бик тә акыллы кеше иде. Бервакытта да, башын югалтып, күрәләтә ут эченә кертмәде безне. Башта уйлады, алдагы хәрәкәтне безнеңгә салды, шуннан соң гына боерык бирде. Нәтиҗәдә, беттек, яндык дигән җирдән исән-имин чыга торган идек. Менә шул командир әйтә...

—Әти, гомер эчендә бер хәлемә кер, сатыйк өйне.

—Хәленә кергән чаклар булмады, дип уйлыйсыңмыни? Бу юлы да хәленә керсәм, мин тылсыз калам. Ә тылсыз калсам,эш харап, камап алачаксыз һәм тапап китәчәксез. Шуңа да плацдармны бирми торам әле. Мона тиклем машинасыз яшәгәнсез, моннан соң да яшәрсез.

—Ярый, хәзер нотык укый башларсың инде. Яшәү белән яшәүнең аермасы бар шул. Хәзер бит тормыш башка, сезнең заман үтте, безнең

заман килде. Машина—ул мәртәбә, абруй. Син шуны ничек аңламыйсың?— Гөлсем, башын ике кулы белән тотып, залдан кухняга чыгып китте.

Чираттагы артподготовка янә нәтиҗәсез тәмамланды: танкист соңгы плацдармын бу юлы да саклап кала алды. Тик озаккамы? Гөлсемнең һөҗүмнәре торган саен ярсурак, көчергәнешлерәк була бара, беркөнне килеп чигенергә туры килмәгәе...

Житте, болай да чуак көннәрне кирәгеннән артык бирдем, дигән кебек, табигать һава торышын кинәт үзгәртте—октябрьнең икенче яртысыннан яңгырлар башланды; салкынайтты, ачы җил исте, ара-тирә кар бөртекләре дә күренде. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, Гөлсем белән чираттагы әрепләшүдән соң үз-үзенә урын таба алмый урамга чыгып киткән иде— салкын тидереп кайтты карт. Кичкә табан температурасы күтәрелде, башы чатнап авыртты. Табиб чакыртканнар иде, үпкәсенә суык тигән, кичекмәстән дәваханәгә алып барыгыз, дип кәгазь язып бирде. Нишләсен, иртәгәсенә барып ятты инде. Житмештән узган иясе белән бергә картайган, таушалган үпкәне дәвалау ифрат озакка сузылды—дәваханәдә ике ай ятты да куйды. Мөлаем шәфкать туташлары, табиблар белән хушлашып, дәваханә ишеген тыштан япканда, шәһәр Яңа елга әзерләнә иде.

Кызы белән кияве болай ихлас каршылады, аның кайтуына оныклары да шат булды. Кичен картның яраткан ризыгын—пилмән пешерделәр, ярты ачтылар. Шулай да күз карашларында ниндидер серлелек галәмәте, шик тойды танкист; житмәсә, кияве элеккедән байтакка күбрәк сөйләнде, ныграк мышнады. Ихлас булырга тырышуларының сәбәбе картның дәваханәдән чыгуында түгел, икенчедә, әмма шушы икенченең сәбәбен Тимергали һич белә алмады. Сер Яңа ел алдыннан гына ачылды...

Яңа ел чыршысын, төрле төстә янган лампочкаларны, гирляндаларны күрергә дип бәләкәй генә онытгы белән урамга чыккан иде, авылдашы Мөхәрләм очрады. Ике кулына да сумка тоткан, карчыгы да күтәренгән. Исәнләштеләр, хәл-әхвәл сораштылар. Кайда юл тоттыгыз, дигәч, олы малай фатир алган, шуның өй туена китеп бару, диде Мөхәрләм. Тимергали карт үзенең дәваханәдә ятып чыгуын сөйләп алды. Ярый алайса, дип берберсенә исәнлек-саулык, Яңа ел теләкләрен әйтешеп һәркем үз юлы белән кузгалгач, карт сорап куйды бит:

—Әй, анда минем йорт нихәлдә, исән-имин генә утырамы?

—Нинди йорт?—дип аптырады Мөхәрләм, үзе бер карчыгына, бер танкистка карады.—Аны Гөлсемең белән киявең октябрь бәйрәме алдыннан гына, әйе шул, ноябрь башында, кайтып сатып китте бит.

—Ничек сатты?—Хәзер Тимергали карт аптырады, ялгыш ишетәмме әллә, дип авылдашына якынрак атлады.

—Нигә, белмисеңмени?

—Юк, беренчегә ишетүем, бүлнистә яттым, дим ләсә.

—Менә ничек, өеңне синең рөхсәттән башка саткан булып чыгалар инде, алайса.

—Кемгә бирделәр инде?

—Карамның Себердә эшләп йөргән уртанчы улы алды.

—Күпмегә сатканнарын белмисеңме?

—Кемдер, илле меңгә , дип әйтә иде, төгәл генә белмим.

—Соңгы плацдарм кулдан ычкынды, тылга керделәр, болай булгач,— диде танкист, байтак башын иеп эндәшми торганнан соң.—Хәзер тапап китәчәкләре көн кебек ачык.

—Нәрсә диден?—Авылдашы гаҗәпләнеп бер Тимергали картка, бер карчыгына карады.—Бәй, син ишетмәгәнсең дә икән... Өй тиклем өйне әтигә эндәшми саталардыр шул.

Мөхәрләм тагы әллә ниләр сөйләнде,тик танкист аны ишетмәде дә, күрмәде дә—контузиясе янарып, колаклары томаланды, күз алдында утялкын,шартлау пәйда булды, танклары дошман танкы белән бәрелеште... Анына килгәндә, авылдашлары янында юк, оныгы гына, картәти, картәти, кайтыйк, дип җиненнән тарткалый иде.

Чак кайтып ауды. Ярый кияве өйдә иде—«Ашыгыч ярдәм» чакырды. Картны алып киттеләр—бу юлы йөрәк. Сугыш тиклем сугышта суда батмый, утта янмый исән калган, әллә ничә тапкыр үлем белән күзгә-күз очрашкан йөрәк кызының хыянәтен күтәрә алмады. Дәваханәдә ана кан җибәрделәр, система куйдылар, таблеткалар ашаттылар, тыныч булырга, борчылмаска куштылар. Табиблар әйткәннәрнең барысын да үти ала карт, тик бер теләк-кинәшләрен генә—борчылмаска, уйланмаска дигәнен генә үти алмый. Булдыра алмый, хәленнән килми. Нишләсен, холык-фигыле шулай. Тәүге көннәрдә бик бетеренде, шулай да, кызы яки кияве килгәндә, өй турында сүз кузгатмаска көч тапты. Ул эндәшмәгәч, балалары да сүз башламады, һәм танкист үзен аяктан еккан вакыйга турында сирәгрәк исенә төшерергә, исән булыйм, терелеп чыгыйм, бер башка кайда да урын табылыр әле, дип уйларын читкә юнәлтергә тырышты. Ә ай ярым вакыт үткәч, дәваханәдән чыкканда, кызы белән кияве кылганга ачуы басылган иде диярлек.

Хәзер ул хәбәрләренә бик кысылмый, сүз кушсалар, «әйе», «юк»тан бетерә, үзегез карагыз, үзегез беләсез, дигәндәй, кулбашларын гына җыера,эндәшсәләр, ашарга чыга, чакырмасалар—юк, ята яки утыра шул бүлмәсендә. Бар игътибары оныклары Азат белән Русланда. Алар белән аралаша, уйный, урамда йөри. Гөлсем белән кияве анын кылыгын һич аңлый алмый, ә шулай да өен сатуны белгәнен чамалыйлар, тик кемнән, каян ишеткәнен белә алмыйлар. Ә беркөнне икенче класста укыган бәләкәй оныгы Руслан белән шашка уйнаганда, малай: «Картәти, син беләсенме, без машина алабыз»,—дип әйтеп салмасынмы! «Беләм, әниең белән әтиең минем өйне саткан, алсыннар әйдә»,—диде танкист. «Кайдан беләсең, әти үзе әйттеме?»—дип сорады оныгы. « Ишеттем»,—диде, әмма кемнән ишеткәнен әйтмәде. Хәер, малайга анысы мөһим дә түгел. Димәк, Мөхәрләмнең хәбәре дөрес, өен чынлап та сатканнар. Күңел өчен булса да, әти, саттык инде, үпкәләмә, дип тә әйтмиләр, ә, ичмасам. Ул бит әле исән, йөреп ята.

Беркөнне шулай урамда йөриләр иде, Руслан өзми дә куймый, әйдә, картәти, күрше урамда гына танк бар, шунда барыйк, дип кулыннан сөйрәп алып китте. Еракка бик үк йөрисе килмәсә дә, оныгының үтенечен екмады, аннан килеп, үзенә дә кызык булып китте—сугыштан соң беркайчан да танк күргәне булмады бит.

Киттеләр. Малай алдан йөгерә, картәтисе таягына таянып җайлап кына арттан бара. Менә берчак атлаган урамнары зур гына паркка килеп ялганды да, алда биек постаментка мендереп утыртылган Т-34 танкы шәйләнде. Әйе, чынлап та танк, шәһәр эчендә танк! Әлбәттә, әлеге ише танкларны картның телевизорда, киноларда күргәне бар, тик ул бит икенче, кайдадыр читтә, еракта, ә монда алдында тора!

Карт танк янына барып житте дә, туктап, ал яктан байтак карап торды, аннан кабырга ягына борылды. Борылды да башнясына ак буяу белән язылган «555» саннарын күреп аптырап китте—анын танкының номеры бит! Анын танкын мендереп куйганнар! Немецларның пушкаларын, пулеметларын тапаткан, пехотасын куган танкын. Ай, моның белән күргәннәре!

...1943 елның сентябре. Дала фронты гаскәрләре, кызу һөҗүм итеп,

Украинаның байтак шәһәр, авылларын азат итте һәм Днепрга якынлашты, илле чакрымлап кына ара калды. Дошманны арытабан эзәрлекләү өчен елгага житәргә, аны кичәргә кирәк, ә разведка мәгълүматларына караганда, каршы яр көчле ныгытылган.

Кременчуг янында Днепр аша салынган күпернең исән калганлыгы ачыкланды. Фашистлар, күрәсең, аңа үзләренең чигенүче частьлары көнбатыш ярга чыгып кала алсын өчен тимәгән. Полк командиры Тимергалиләрнең танк батальоны алдына шушы күперне алу һәм безнең төп көчләр килеп житкәнче аны саклау бурычын куйды. Бу тирәдә Днепр тирән, киң, кичәрлек түгел, шуңа безнең частьлар да күпер аша чыгарга тиеш. Бу мөһим заданиене үтәү өчен батальон командиры майор Тюрин унсигез танк сайлап алды. Шушы унсигез исәбенә Тимергалиләр экипажы да эләкте.

Иртәнге томан япмасы астында танк колоннасы чигенү аркасында хәлсезләндерелгән дошман оборонасы аша үтә башлады. Томан да, урынның чокыр-чакырлы, куаклы булуы да танкистларга унайлы иде. Бернича чакрым барганчы ул-бу булмады, бара торгач колонна башында килгән батальон командиры рация аша, алда берничә орудие расчеты күрәм, дип хәбәр итте һәм үзе үк атып берсенең көлен күккә очырды. Башкалар да берәр снаряд озатты—бер-бер артлы өч расчет юк ителде. Моннан ары качып-посып барып булмый, чөнки тавыш чыкты, шуңа да командир янә элемтәгә керең: «Алда—дошман танклары, колонна белән бармаска, сибелеп, ромбик рәвешен алырга!»—дигән боерык бирде.

Тимергали—төзәүче-водитель. Экипаж командиры кече лейтенант Иванов, Тюринның боерыгы үзләренә житкерелү белән, игътибарын бермә-бер арттырды. Прицел аша күреп тора: дошман танклары да телгә килде. Снарядлар алга, унга, сулга төшеп ярыла башлады, баш өстеннән дә очты. Ивановның комбаттан алган мәгълүматларына караганда, безнең бер танкның гусеницасына снаряд тигән, икенчесенең башнясы алып ыргыткан икән. Совет танкистлары каршы ут ачты, дошманга ныклап төзәргә бирмәс өчен әле бер якка, әле икенче якка тайпылып маневрлар ясады, куаклыкларны, чокыр-чакырны файдаланырга тырышты.

Көн үзәге житте, кояш төшкелеккә менде. Днепрның теге ягына чыгып өлгермәгән дошман белән алыша-алыша, батальон алга баруын дәвам итте. Немец танклары алар уйлаганнан күбрәк булып чыкты, шуңа да атыш ифрат каты барды. Дошман теше-тырнагы белән совет гаскәрләрен күпергә үткәрмәскә тырышса, Тюрин батальоны, аның каршылыгын сындырып, елгага омтылды.

Каршыларында пәйда булган төркемне туздырдык, дип уйлап, батальонның ике взводы калкулык артыннан ачык урынга килеп чыгуы булды, икенче төркем, икенче оборона сызыгы, аларга карата көчле ут ачты. Шундук дигәндәй, безнең ике танк дөрләп яна башлады, өченчесенең гусеницасы таралып төште. Тимергалиләр дә жавап уты ачты—нәтижәдә дошманның ике танкы өстендә ялкын уйнады.

Кинәт Иванов: «Артка, артка чигенергә!»—дигән боерык бирде. Туктадылар да арт белән чигенә башладылар. Нигә болай иттек соң әле, дип аптырап китеп барганда, еракта ата торган совет артиллериясе телгә килде һәм артларыннан куа төшкән дошман танкларын дөмбәсләргә тотынды. Тимергалиләр шунда гына моның хәйлә икәнен аңлады. Батальон чакрым чамасы барды да туктады.

Югалтулар зур: унсигез танкның сигезе генә калган иде. Тупландылар, бер-берсен барладылар, сак куйдылар, тамак ялгадылар, яралыларны карадылар; караңгы төшкәч, яу яланында утырып калган танкларны

тарттырып китереп ремонтладылар. Тылдан килгән өч машина боеприпас, ягулык, патроннар таратты, яралыларны төяп алып китте.

Йокы булмады диярлек—алмаш-тилмәш сакта торып чыктылар. Тан сызыла башлау белән, янә танкларга менеп утырдылар. Артиллерия уты байтак немец танкларын сафтан чыгарган: егермегә якынны санады Тимергали. Алай гына булмас, мөгаен, төнлә алар да тарттырып алып киткәннәрдер, монда ике гусеницасы да ычкынган, башнясы жимерелгәннәре генә калган.

Комбат дошман координатларын тылга хәбәр иткәндер—озакламый немец танкларын безнең штурмовиклар бомбага тотып үтте. Шуңа карамастан, дошманнын көче күп иде әле. Ә Тимергалиләр батальонында биш кенә танк торып калды. Шулар белән булса да һаман алга бардылар, елгага якынайдылар, хәзер сугышуга, дошманны кыруга караганда, күпергә житү һәм аны саклап алып калу мөһимрәк. Шуңа да, тайпылырга мөмкин урында тайпылып, мөмкин урында кача-посарак, биш танк алга хәрәкәт итте. Ә артларыннан, аларнын һөжүмен үстерә, фронтны киңәйтә барып, полкнын, дивизиянен бүтән подразделениеләре килә. Командирнын әйтүе буенча, килергә тиеш.

Күпергә житәрәк ике генә танк калды: батальон командиры Тюринныкы белән Тимергалиләрнеке. Майор машинасы алдан барды. Боеприпаслары юк хисабында, атмаска мөмкин булмаган чагында гына аталар. Егетләр Ивановтан вакыт-вакыт, күпергә еракмы әле, дип сорый. Экипаж командиры, озакламый житәбез, күпер аша теге якка танклар, машиналар чыкканын күрәм, солдатлар уза, ди, бинокле аша карап.

Килүен килеп життеләр, ә сугышнын ин катысы күпер өстендә булачак, чөнки дошман гаскәре бу якта байтак әле, немец бердәнбер чигенү юлын теше-тырнагы белән бирмәскә, чыккач, шартлатырга тырышачак.

Бераздан Иванов, аръякта орудиеләр кыбырдый башлады, безне каршыларга әзерләнәләр, диде. Каршы як ярга автомашина килеп туктады, аннан солдатлар сикерешеп төштеләр дә күпергә табан йөгерделәр. Шулчак күпер өстеннән янә безнең самолетлар очып үттеләр. Фашистлар ятарга мәжбүр булды. Аннан, калкынып, янә йөгерделәр.

—«Ландыш», «Ландыш», мин—«Сокол», күпергә карап ут ачаргамы?—дип сорый Иванов.

—Мин—«Ландыш», кирәкми,—дип жаваплый батальон командиры.—Үзем пулеметтан бәрәм.

Фашистлар күпер башына ук килеп житте. Тюрин танкыннан сибелгән ут күпергә менеп життем генә дигән немецларны чабылган үлән кебек кырды да куйды. Берсе дә качып котыла алмады. Бераздан дошман батареяләре телгә килде. Тимергалиләр тирәсенә снарядлар төшә башлады. Йә чак кына житми, йә чак кына унда, йә чак кына сулда ярыла... Киләсе снаряд мотлак өсләренә төшәчәк. Баш очыннан очты. Чираттагысы... Фашист снаряды шул тиклем нык бәрде—танк стенага төртелгәндәй туктап калды, хәтта экипажнын һәркайсысы, утырган урыннарыннан кубып, кабинанын алгы стенасына бәрелде. Иванов аңын югалтты, шлемы астыннан куе кан агып чыкты, механик-водитель Кондратьев кычкырды да танау-борынын тотты, Тимергалинең башы яраланды. Иванов аңына килеп, наушнигын рәтләде дә:

—«Ландыш», «Ландыш», мин—«Сокол», ишетәсенме?—дип батальон командирын элемтәгә чакырды.

—Мин—«Ландыш», ишетәм. Ни булды?

—Башняга снаряд тиде, мотор сүнде, экипажнын барысы да яраланды.

—«Сокол», бирешмә, пулемет, автоматларынны эшкә куш.

—Тыңлыйм!

Иванов шлемын салып, башын бәйләде, Тимергали белән икәүләп Кондратьевның ярасын бәйләделәр. Бинт житмәгәч, эчке күлмәкләрен ерттылар.

Дошманның кайдандыр пәйда булган зур гына төркеме боларның танкын камап ала башлагач, пулеметтан ут ачтылар. Берничә дошман солдаты ятып калды, калганнары калкулык артына чигенде.

—Двигательне кабызыйк,—диде Иванов.

Филиппов механик-водитель урынына утырды да моторны эшләтә башлады. Бераздан ул гүләргә тотынды, пошкырды, сүнде, аннан янә кабынып китте, һәм танк авыр итеп урыныннан кузгалды. Кызганычка каршы, озак бара алмадылар, фашист снаряды гусеницага килеп тиде, һәм машина янә туктады. Фашистлар, танкны эштән чыкканга исәпләп, атудан туктады, аның урынына бая калкулык артына качкан пехотачылар янә баш калкытты. Пулялары, кыек башына яуган эре яңгыр тамчылары сымак, броняны, башняны дөбердәтте.

—«Ландыш», «Ландыш», мин—«Сокол», ишетәсенме?

—Мин—«Ландыш». Ишетәм. Ни булды тагы?

—Гусеницага эләкте, гусеница өзелде. Уратып алган дошман белән алышам.

—Бирешмә, «Сокол». Безнекеләр озакламас, түз чак кына. Минем дә гусеница өзелде.

—Өч немец танкының теге ярдан күпергә кергәнен күрәм, атыйммы?

—Снарядың бармы соң?

—Ике бөртек.

—Ат!

Дошман танклары туктады, күзәтү-карау өчен туктадылар, ахры. Шуннан берсе күпер аша чыга башлады. Иванов егетләргә атарга кушты. Тимергали, кабаланмый гына төзәп, бер снаряд озатты. Тиде! Танк урынында зыр әйләнде дә, артыннан килгән ике танкның юлын буып, күпергә аркылы торды.

Моны карап-күзәтеп торган немец артиллеристлары көчле ут ачты. Танкны уратып тәмуг коены уйный дип торырсың! Әле алда, әле артта ярыла снарядлары. Исән гусеницаларына тиеп, анысы да шалтырап коелып төште. Шунысы: машиналары ал ягы белән күпергә карап туктаганлыктан, ата алалар, әмма боеприпаслары юк санында.

—Егетләр, бирешмәгез!— ди Иванов, иптәшләренең кәефен күтәрергә тырышып. Үзенең дә хәле мөшкел—башындагы чүпрәк аша һаман кан саркый.—Безнекеләр озакламый килеп житәр, түзик.

Чигенгән дошман янә калкынды да танкка якыная башлады. Совет сугышчыларының атмаганын шәйләп, кыюланып киттеләр. Ниятләре—экипажны тереләй кулга төшерү. Тимергали прицел аша аларның соры шинельләрен, каскаларын, хәтта ачулы йөзләрен дә күрә.

—Русиш, сдавайся!—дип кычкыра берсе, икенчесе танкка автомат прикладлы белән суга.

Танк эндәшми.

Рус телен ватып-бозып, янә кычкыралар:

—Берәр тере кеше бармы, булса чыгыгыз!

Танк җавап бирмәде. Немецлар үзара сөйләшә. Тимергали аларның хәбәреннән «штербен, штербен» дигәнен генә ачык ишетә, тик ул сүзнең мәгънәсен аңламый. Менә берсе танк өстенә менеп люкны ачарга тырышып карады, тик булдыра алмады—эчтән ныгыткан иделәр. Тегеләй-болай йөреп тукылдатты-тукылдатты да кире төште: танк, гүя, йомарланган керпе, җиңел генә кулга төшерерлек түгел. Озакламый ни сәбәптәндер

хәбәрләре тукталды, яннарына кемнендер килгәне беленде. Яна килгән немец, офицердыр ахры, карлыккан тавыш белән нидер сөйли башлады. Шуннан кумәкләп танкны уратып карарга керештеләр.

Бераздан Тимергали тын буарлык ачы ис килгәнен тойды:

—Төтен белән тончыктырырга булдылар,—диде Иванов.— Противогазларыгызны киегез!

Сәрмәнә-капшана, противогазларын эзләп таптылар.

Купмедер вакыттан сон учак сүнә башлады, сизелер-сизелмәс кенә саф һава өрде. Котылабыз, дип шатланган иделәр дә, немецлар утны көчәйтергә ниятләнеп, танкка тагын агач, такта кисәкләре ташырга тотынды. Донгырдатып, каяндыр бензин мичкәсе дә тәгәрәтеп китерделәр.

—Эй, русиш, чукынып калыгыз, сонгы сәгатегез килде, өтәбез!—дип кычкырдылар, янә рус телен вата-жимерә.

Шулчак Иванов:

—Самолет тавышы!—диде куанып.—Безнекеләр!

Күп тә үтмәде, жир селкетеп бомбалар ярыла башлады.

—Ур-ра, безнекеләр!—диде Иванов, малайларча куанып.Ул калкынды да колагын башня стенасына куйды.

Танк янында ыгы-зыгы, кыска-кыска сөйләшү, йөгерешү китте. Озакламый беркем дә калмады. Бомба ярылуы алга, яр башына, купер тирәсенә күчте.Тиздән үзебезнекеләр ягыннан танклар килгәне ишетелде. Гуләү якынайганнан якынайды, һәм бер машина алар янына туктады. Якында гына кемдер:

—Эй, тересезме?—дип кычкырды русчалап.

Көчергәнешлек үзенекен итте—берсенен дә аяк-куллары кыбырдамый, телләре әйләнми, барысы да алларына текәлеп катып калганнар.

—Командир, безнекеләр,—диде ахырда Тимергали.

—Ә, әйе, безнекеләр,—диде, ниһаять, Иванов, йокысыннан уянган кешедәй.

Тыштагылар танк өстенә менде, берәүсе үкчәсе белән төйде. Иванов, калкынып, люкны ачарга маташты, көчәнде-көчәнде дә, ача алмый, аска шуып төште. Аннан, үзенен көчсезлегеннән оялгандай, янадан этте—бу юлы ачты, ачты да күзләрен кысып тышка карады. Ә тышта—совет солдатлары, пехотачылар. Иванов, телсез калып, аларга карап торды, кабинадагылар төрткәли башлагач кына, өскә күтәрелде.

—Дивизия штабына хәбәр итегез: задание үтәлде—купер безнен кулда. Комбат Тюрин нихәлдә, белмисезме?

Башлар иелде, шлемнар салынды. Экипаж комбатнын һәлак булганын анлады.

Фронтнын алгы частьларына могжиза белән дигәндәй сакланып калган куперддән Днепр аша чыгарга, көнбатыш ярда ныгыган дошманны окопларыннан бәреп чыгарырга һәм һөжүмне арытабан җәелдерергә кирәк иде. Тик Тимергалиләргә, танкларын ташлап, пехотага ияреpгә туры килде, чөнки башнясы зарарланган, гусеницасы ычкынган машинаны ремонтларга вакытлары да, мөмкинлекләре дә юк.

Озакламый яраланып госпитальгә эләкте. Озак дәваланды. Танкка утырырга яраксыз дип табылгач, хужалык взводына беркеттеләр, һәм, сугыш беткәнче, ул гаскәр артыннан олау белән йөрде. Өч «биш» билгесе куярлык кыю сугышкан машинамны очратырмын дип өметләнеп йөрсә дә, очратырга насыйп булмады башкача...

—Улым, бу бит—минем танк!—диде Тимергали карт, хатирәләреннән тарткалап аерган оныгына карап.—Нишләп син мине монда элегрәк алып килмәден? Минем танк, минем өч бишем!

—Чын синекеме? Алдамыйсынмы? Вот здорово!

—Алдамыйм, нишләп алдыйм, ди? Мин аның белән Днепр ярына ук барып җиттем, фашистларның ут нокталарын, әллә күпме танкларын юк иттем,—картның күзләренә яшь тыгылды, ирённәре дерелдәде.

—Ә монда аны кем мендереп утырткан?

—Иванов, Кондратьев, Филиппов... Кайдалар икән, исәннәрме?

—Картәти, картәти, монда кем мендереп утырткан синең танкны?

—Бүген, ичмасам, берегезне күрәсе иде...

—Картәти, аны монда кем мендереп утырткан, дим.

—Әллә тагы. Шәһәрне сакларга утыртканнардыр инде. Сине, Азатны, әниең белән әтиеңне сакларга.

—Атамы?

—Юктыр. Ә кирәк булса—атар. Дошман ябырылса.

—Нинди дошман?

—Немец фашистлары кебек дошман.

—Алар тагын сугыш башлыймыни?

—Башлый калса, дим.

Оныгы, өйгә кайткач, без картәтинең танкын күрдек, аны парктагы постаментка мендереп куйганнар, дип яу салды. Тәүдә бу хәбәргә берсе дә игътибар итмәде, баланың чираттагы фантазиясе, дип кенә карадылар; Руслан янә кабатлагач, әтисе: «Ну, кайда инде ул танк?»—дигән булды, мыскыллы гына елмаеп. «Паркта, өйдән чыккач, шулай-шулай барасың,—дип аңлатты Руслан, кабалана-кабалана.—Картәти аның белән немецларга каршы сугышкан». «Картәтидән булыр ул, картәти—батыр кеше»,—диде әтисе, янә көлемсерәп. Әнисе: «Ярый, башны катырма, бар, дәресеңне әзерлә лутчы»,—дип улын катгый рәвештә тыйды да бүлмәдән куып чыгарды. Малай һаман, картәтинең танкы, барып күрегез, дип ныкышкач, әтисе, картның күңеле булсын диптер, ахрысы:

—Синең танкмы инде?—дип сорады.

—Минеке. 555 нче номерлы. Мин аның белән елга якын йөрдем, Днепрны кичәр алдыннан гына немец снаряды башняга тиде, ике гусеницаны өзде. Өзмәсә, арытабан да...

Киявенең күзләре шар булды. Малай, ярый, нәрсә күрә, нәрсә ишетә, шуны сөйли, ә бу карт ишәк, постаменттагы танкны «минеке» дип тора, акылыннан яздымы икән әллә, дип уйлаганы йөзенә чыккан иде.

—Нигә, фронтта 555 нче санлы танклар берәү генә булган дисеңмени?

—Безнең полкта берәү генә. Ә бу танкның минеке икәнен күңелем сизә.

—Хәтәр сизгер күңелле булып чыктың әле син, кайным. Кеше ышанмастай хәбәрне дөрес булса да сөйләмә, диләр. Үзең генә житмәгән, баланың башын да катырып йөрисең,—кияве, мышный-мышный, урыныннан торып китте.

—Сезгә бернәрсә дә исбат итеп булмас, ышанмасагыз ышанмагыз, ә ул —чынлап та минем танк!

—Ур-ра, здорово!—Кайсы арададыр бүлмәгә килеп кергән оныгы чәбәкәй итеп алды.

Кияве залдан кухняга үтте, барышлый уң кулының чук бармагын үзенең чигәсе тирәсендә бораулады: янәсе, карт тәмам исәрләнә башлады.

Танкын тапкан шушы көннән алып, Тимергали картның кәефе күтәрелде, дәваханәдән чыккандагы битарафлыгы, күңел төшенкелеге бетте. Юкса, тылны кабахәтләрчә басып алдылар, чигенергә урын калмады, плацдарм кулдан ычкынды, дип йөри иде бит. Плацдармы әле бар икән, димәк яшәүнең, алышуның әле мәгънәсе бар. Кызы белән киявенең аңа

ышанмавы—вак мәсьәлә, алар белән бервакытта да уртак тел табып яши алмады, таба да алмас. Яз житү белән кайтып, Карам малаеннан өен кире алыр. Бирми маташса, авыл советына,кирәк булса, район түрәсенә барыр, әмма кайтарып алмый туктамас. 555 нче санлы совет танкына каршы торырлык көч булмый торган иде, аның төзәүчесе дә алдына алган бурычын тормышка ашырмый тынычланмас.

Ә шулай да әлеге танкның чынлап та үзенеке икәнлеген ничек тә исбатларга иде. Байтак кына уйлап йөргәннән соң, танкист шундый карарга килде: шәһәрдә, мөгаен да, берәр хәрби часть бардыр, табып шулардан сорарга кирәк. Хәрби комиссариатка да барырга була. Аннан да жавап таба алмаса, Башкортстанның хәрби комиссариатына хат язарга мөмкин. Танк кибән эчендәге энә түгел, кайдан, кайсы частьтан китергәннәрен алар белми булмас.

Ниятен кызы белән киявенә белдергән иде, гажәпләнүләренең иге-чиге булмады, хәтта куркып киттеләр: «Кеше кангыртып йөрмә, алмашына башладыңмы әллә, нишләп синең танкың булсын ул»,—диделәр. Баланың да башын катырмавын үтенделәр. Үзең кебек тискәре, акылга бертөрле итүең бар, янәсе.

Чигәләре янып, йөрәге дарслап тибеп алып китте картның.

Китте-китте, озынга һәм тирәнгә китте сүзе. Бу юлы инде карт өен нигә алай сорамый сатулары хакында бәхәсләшмичә тыела алмады.

—Син больницада идең бит,—диде кызы, бик исе китми генә.

—Бәй мин әллә анда мәңгелеккә кергәнме?

—Тискәрелегеңә барып, саттырмас идең барыбер.

—Минем милек белән үзбелдегегезгә кыланырга сезнең ни хакыгыз бар? Син салганмы ул өйне, әллә берәр төрле ярдәм иттенме?

—Ярый, әти, әпәт нотык укый башларсың инде. Үткән эштән төш яхшы, аңа кире кайтмыйк.

—Бәй, нишләп кайтмый, ди? Син өйне сатуың турында миңа гына түгел, апа, абыйларыңа да әйтмәгәнсеңдер әле. Карап-тикшереп кайтыйк, дип барсалар? Ә анда чит кеше яшәп ята.Шул башбаштаклык булмыймыни? Әниең, дүрт бала арасыннан Гөлсеме иң жаһил, үзсүзле булып үсте, дип әйтә торган иде, чынлап та шулай икән.

—Анысын да ишеткәнем бар. Мине хәзер үзгәртә алмыйсың. Үзегез ише тәрбияләргә иде.

—Үкенечле, тәрбияләп булмады шул.

Шушы сөйләшүдән соң Тимергали карт кызы белән киявенә хәзер бик үк кирәкмәгәнлеген, фатирларында артык жаңга (аны прпискага кертеп, чынлап та өч бүлмәле фатир алдылар), дөресрәге артык тамакка әверелүен аңлады.

Шушыны төшенүдән соң, Тимергали картның янадан кәефе кырылды, өе исенә төште, бу туңбашларга бернәрсә дә аңлатып, бернәрсә дә исбат итеп булмастыр, ахры, дип йөрәге әрнеде.

Хәрби комиссариатта йомышын әйткәч, дежур лейтенант аны вертушка аша эчкә үткәрде дә 11 нче санлы ишеккә ымлады. Симез түгәрәк йөзендә күзе, танавы, авызы чак беленгән капитан танкистның хәбәрен тәүдә житди кыяфәттә тыңлады. Паспортын карады, кайсы фронтта сугышуын белеште, үзе картның жавапларын кәгазьгә терки барды. Тикшерергә, сорарга кирәк, диде. Кайдадыр шылтыратып, парктагы анау танкны кем мендереп куйды, кайдан китерделәр икән, дип белеште. Нәрсәгә кирәк ул сиңа, дип сораганнар иде, монда берәү килде дә,» минем танк» дип дәгъвалаша, диде, көлеп. Шуннан кайдадыр йөреп килде, янә шылтыратты. Шулай да тыштан эшем иясе күренгән бу капитан Тимергали картның соравына өметләнерлек

җавап таба алмады—ишек төбендәге вертушка сыман әйләнде-бөтеренде, әфайдасы нуль булды. Шуннан сәер генә елмаеп, күпме вакытымны алдыгыз, шуны белү сезгә шултиклем нык кирәкме инде, дигән сорау белән озатып калды.

Кияве ике иптәше белән Тольяттидан машина барып алды. Мөлкәтне кайсысынындыр буш торган гаражына куйгач, кичкә өйләренә килделәр. Бер-берсен бүлдерә-бүлдерә куанышып сөйләштеләр, лаякыл булганчы эчтеләр. Картның бүлмәсенә керүче дә булмады. Тавышка, битарафлыкка түзми, карт урамга чыгып китте.

Шушы көннән алып аңа игътибар бетте: кияве машинасы янында, оныклары—бигрәк тә олысы—әтисе эргәсендә, Гөлсем дә өйгә йокмый. Әүвәл, ичмасам, ашарга эндәшә торган иделәр, хәзер, чыкмыйрак утырса, «савыт-саба тавышын ишетмисеңмени, нигә чыкмыйсың, аерым чакыру кирәкме», дип җикерә. Картның янә кәефе кырыла. «Аягыңны сөртеп кермисең, киемнәреңне тәгаен урынга элмисең, тыштан кергәч, кулыңны юу юк» дигән сүзләр әйтелә. Өйләренә керәсе дә килми хәзер, әмма көндез өйдә утырырга, фатирны каравылларга кирәк, кеше-фәлән килүе дә бар; анысына түзә, ялгызына авыр түгел, иң мөһиме—битәрләүче кеше юк, ә менә кичләрен—башлана һәм йокларга ятканчы дәвам итә. Нахакка кыерсытуларына түзә алмый, ахырда шундый карарга килде: берәр төн кайтмый караганда ничек булыр икән? Бу карарга аны бер вакыйга этәрде, шушы вакыйга түземлек касәсен тутыручы соңгы тамчы булды.

Бер кичне Гөлсем тавыш куптарды: шушында гына илле сум акча салган идем, кемегез алды? Малайларның икесе дә бертавыштан, мин түгел, диде; кияве эре генә аңа калган көнем юк , дип җаваплады. Шулай булгач, акчаны кем алган булып чыга? Дөрес, Тимергали карт. Гөлсеме, әти, син генә алгансың, дип ачыктан-ачык әйтмәсә дә, бөтен йөреш-кыланышы, карашы шуны белгертеп тора иде. Әмма төбәп эндәшмәгәч, карт сүз башламады. «Кагылмаганмын бит акчасына, намусым таза, югыйсә, акланырга маташа, дип икеләнер», дип уйлады.

Кайда, Гөлсем эндәшми, азагына чыкмый кала торган кешеме—иртәгәсенә барыбер әйтте, күрмәденме, дип сорамады, ә шундук:

—Син генә алгансың,—диде.

—Күрмәдем дә, алмадым да. Эзләгәнегезне белдем, күргән яки алган булсам, әйтмәс идеммени? Шушында торып... Ай, авыр гаеп ташлыйсың, Гөлсем,—карт башын чайкады.

—Азат белән Руслан алмаган, ир—исключено. Мин алмадым, син генә каласың.

—Ә мин нишләп «исключено» түгел? Ышанычыгызны югалттыммыни тәмам? Малайларыңа ышанасың, иреңә ышанасың, ә миңа—юк.

Гөлсем эндәшмәде. Анын турсайган йөзендә итагать ишарәсе күренмәде.

Шул төн йоклады да, карт иртәгәсенә чыгып китте. Кайтмады да куйды. Җаны әрнеде ифрат. Үзәгенә, дөресрәге йөрәгенә төзәп атылган иде пуля сымак бу сүзләр. Тимергали өчен акча бервакытта да мал булмады, кызының фатирында торган көе ничек сорамый алырга мөмкин? Аңа акча нәрсәгә? Кинәт кенә кирәк булган сурәттә дә сорап алыр иде.

Магазиннарны, аннан базар карап йөрде, бернәрсә ала алмаса да, хаклар белән кызыксынды, чагыштырды, әйбернең, азык-төлекнең кыйммәтлегенә исе китте, шуннан вокзалга төште.

Җинел генә чыгып китсә дә, авыр булды олы кешегә вокзал сәкесендә көн үткәрүе. Кеше күп, тегеләй дә болай йөриләр, ятканнары хырылдый, бала-чага мыжый, шап та поп йөгерә. Тимергали карт бер эскәмияне үзенеке

иткән иде, озакламый өч ир килеп, аны яткан жиреннән калкытты. Кайда, черемгә китә алмады—тегеләр төне буе лыбырдап чыкты, әйтерсең, ун ел күрешмәгәннәр.

Өйдә беркем дә калмас вакытны чамалады да карт, иртәнчәгенә йончып кайтып керде, чәй кайнатып эчте, калган бәрәңгене жылытып ашады. Язу-мазар калдырмаганнармы, дип караштырган иде дә—табылмады, димәк, Гөлсем аны искә төшереп тә булышмаган. Картның болай да төшенке кәефе тагы да төшеп китте. Ул: «Әти, кайда йөрисең, нигә кайтмадың, куркып беттек, эзләдек»—дип кәгазь калдырыр яки эшенә бармый көтеп утырыр, дип өметләнгән була бит әле. Бөтенесе дә әүвәлгечә, бернәрсә дә үзгәрмәгән, үзгәрәчәк тә түгел. Берәр жирдә үлеп ятсаң да эзләмәячәкләр. Аһ, нигә генә китте икән авылыннан? Бу тиклем дә кимсетелерен белсә, һич кузгалмас иде.

Буыннары сызлап, аяклары авырайган иде, шуңа бүген беркайда да чыкмаска карар итте. Аннан килеп, шулай итеп йөрүе дә килешкән кылык түгел инде. Бала-чага кебек чык та кит, имеш.

Кызы ишекне үз ачкычы белән ачып керде дә, аяк киемен дә салып тормый, карт йоклап йөргән бүлмәнең ишеген этте.

—Әти, кайда йөрдең ул? Кичә нишләп кайтмадың?—Кызының яшьләре атылып килеп чыкты, күзләрен кул сыртлары белән сөртә-сөртә, Русланның караватына утырды.—Нигә шулай итәсең инде? Кайда йөрдең, кайда төн үткәрдең?

—Вокзалда,—дип җаваплады карт, озак кына көттереп.

—Вокзалда, ди, әстәгъфирулла. Анда нишләп барып чыктың?

Карт эндәшмәде. Аның бу турыда һич сөйләшәсе килми. Берәр нәрсә әйтсәң, янә сораулар явачак.

—Әти, давай, мондый спектакльләреңне ташла. Син олы кеше, олы була бел. Йортың, йоклап йөрер урының бар, ач утырмыйсың. Тагы нәрсә кирәк?—Кызы әтисенә текәлде. Елаулы-борчулы итеп, ул кадимге Гөлсемгә әверелде: кырлач танавы тагы да очлаебрак китте, юка иреннәре кымтылды.

—Эш бит, Гөлсем, урында, тамакта гына түгел, күңел дигән нәрсә дә бар. Ничек булсам да, мин сиңа әти бит әле. Машина алгач, кирәгем беттеме?

—Әти, монда машинаның ни кысылышы? Күреп торасың: иртүк чыгып йөгерәбез, арып-талып, кич кенә кайтабыз. Шулай булгач, кайда синең белән сөйләшеп утырырга вакыт?

—Махсус сөйләшеп утырырга кирәкми, кешечә мөнәсәбәт кенә кирәк. Сөйләшеп, хәл сорашып, киңәш итеп торсагыз—шул житкән.

—Ярый, шулай килешик: без сиңа, үзең әйтмешли, кешеләрчә мөнәсәбәт күрсәтербез, күрсәтергә тырышырбыз, ә син моннан ары өйдән чыгып китмә. Машина астына барып керсәң, югалсаң, җавап бир аннан.

—Гөлсем, миңа шартлар куйма, бала-чага түгелмен...

—Бала булмаганың өчен әйтәм дә инде. Аңларсың, дип.

Сүз шушында өзелде, өзелмәсә дә өзелмәс иде, олы малайлары Азат кайтып керде.

Азатка ундүрт яшь, сигезенче класста укый. Мәктәптән кайтып сумкасын ишек төбендә калдыра да, арлы-бирле капкалап, урам буена олага. Соң гына кайта, дәресләрен аннан-моннан караштыра да йоклап киткәнче—телевизор алдында. Бөтен караганы—сугыш, атыш, дөмбәсләшү. Йә акыртып-акыртып дөмбер музыка тыңлый. Гөлсем көн дә әрли аны, дәресеңне әзерлә, музыка тавышын кимет, әллә ишетмисеңме, ди. Кайда, колагына элми, житмәсә,

каршы әйтешә. Аптырый инде Тимергали бу кыргыйлыкка, кызының баласын тынлата алмавына исе китә. Ә бит малай үзсүзләнүе, кеше белән хисаплашмавы, нәрсә теләсә шуны эшләргә тырышуы белән Гөлсемгә тарткан.

Ә менә Руслан картәнисенә, ягъни Тимергалинең карчыгына, охшаган. Күнелчәк, кеше җанлы кеше иде карчыгы, үзенә авыр сүз әйтсәләр, нәрсә дип җавапларга белми, күзләрен шар ачып тик торыр иде, мәрхүмә. Йомышка килмәгән бәндә юк иде авылда, барысына да кирәген табып, юнңәтеп, тынычландырып чыгарыр иде. Әйе, рас, картәнисенә тарткан оныгы. Ипле, тәртипле, пычранып-боларып йөрмәс, укуы да бара: Гөлсем мәктәптәге ата-аналар җыелышыннан гел генә авызы колагына житеп кайта. Руслан картәтисен дә үз итте: мәктәптән кайту белән янына йөгереп керә, хәбәрен сөйли, Тик «озайтылган көн» дигән төркем ачылгач, шунда бирделәр дә баланы, өйгә йокмый хәзер. Шул ял көннәрендә генә иркенләп күрә оныгын, бергәләп урамга чыккалыйлар.

Ә менә Азаты төшкә тиклем укый да—төштән соң буш, күпчелек өйдә. Ләкин аның өйдәлегеннән Тимергали картка бер фәтвә дә юк. Зыяныннан башка...

Беркөнне Азат мәктәбеннән байтакка иртә кайтты. Озын итеп шылтыратуга карт ишекне ачты. Бу, картәтисе белән исәнләшү түгел, күтәрелеп тә карамый, сумкасын тупсада ук ташлап калдырып, залга үтте, магнитофонын кабызды. Шуннан башланды дөбер-шатыр акыруга, ыңгырашуга охшаган тавышлар! Тимергали карт бүлмә аша утырса да, колагын тондыра. Менә Азат, музыка тактына авыз эченнән көйли-көйли, кухняга керде, чәйнүген куйды.

«Ну, малай бигрәк шаша бу, котырган эт дип торырсың»,—дип уйлады карт, аптырап. Кәефе төште, бу кадәре даңгырдауга башы авыртырга тотынды. Шуннан түзмәде, тавышын бераз кимет әле, дип чыгып әйтте. Оныгы колагына да элмәде, берчә селкенгәләп, берчә артка каерылып, зал буйлап йөрде, гөрс итеп диванга барып ауды. Карт икенче тапкыр, улым, баш авырта ласа, җайрак куй, диде, залга чыгып. Малай аның ягына карамады да, киресенчә, тавышын тагы да көчәйтеп җибәрде.

Бу ни эш? Әле әнисеннән сүз ишет, әле тәртипсез малаеннан шундый кимсетелүгә дучар бул. Тыңлаган музыкасы да нинди бит әле! Русча түгел, башкортча түгел—әллә нинди чит телдәге даңгыр-доңгыр, акыру-бакыру. Картның ачуы тамагына тыгылды, мондый да адәмгә санамауга түзәргә мөмкин түгел, дип сикереп торды да залга атылып чыкты һәм магнитофонның шнурын өзә тартып алды.

—Ты что делаешь, а? Псих, что делаешь?— дип тамак төбе белән кычкырды оныгы, күзләрен алартып. Шуннан җилкенеп картәтисенең каршысына килеп басты.

—Баш авырта, дип әйттем бит, нигә туктатмыйсың?

—Обязательно шнур надо выдергивать? Больной что ли? Тогда иди в больницу.

—Яхшылап әйткәнне тыңламыйсың бит. Тавышын әкренәйтсәң ни була?

Калганын әйтеп тә өлгерә алмады, төртешү түгәрәгенә йөргән оныгының бәләкәй, әмма каты йодрыгы авызына килеп тә кунды. Билгеле, Тимергали карт моны көтмәгән иде, чайкалып китте, шулай да егылмады.

Карт кулын иренենә китерде бармаклары канга буялды—ирене эчке яклап ертылып киткән иде.

—Ах, бандит!—ул башка сүз әйтә алмады, җай гына атлап ванна бүлмәсенә барып, авызын салкын су белән юды, канын туктаткач, бүлмәсенә керде дә караватына сузылды.

«Бу ниткән эш, ә? Эт малай, фашист, тәмам бәйсезгә әйләнде бит. Монда килмәсә, белмәс тә иде—җәен авылга кайткан-киткән арада син дә мин сымак, әллә ни аптырарлык кылыклары күренми-сизелми торган иде. Эт үз өендә көчле шул. Ай, кайдан гына килде, кайдан гына килде! Шунда яшәп кенә ятса, аннан да акыллы кеше булмас иде».

Картның иреннәре сызлый, зәнки, юк, ирене түгел, йөрәге сызлый, йөрәге яна. Әйе, командиры дөрес әйткән, бөтен ситуациядә дә чигенү мөмкинлеге калдырырга кирәк, дип. Менә, иптәш командир, наводчигыңның бернинди дә чигенү мөмкинлеге калмады: тоткан плацдармын тәмам басып алдылар. Ә бит аның шөгыле төзәүче иде, әмма алдагы көннәрен төсмерли алмады.

Карт шешкән иренен кабат салкын суда тотты, Азат янына керде дә, озак итеп аңа карап торды, иң алама, үпкә сүзләре әйтергә теләгән иде дә, әйтмәде, әйтә алмады. Сүз, снаряд кебек, иң соңгы чиктә генә төзәп атылырга тиеш. Бүген малай аңлар хәлдә түгел, яшьрәк. Үсә килә төшенер, картәтисенә кул күтәргән өчен үкенер дә, бәлки.

Тимергали башын иеп, карашларын идәнгә кадаган оныгына карап торды-торды да жай гына әйләнеп чыгып китте. Әнисенең кирәккән-кирәкмәгән боларуына күнеккән малай картәтисенең эндәшмәвенә аптырап утырып калды.

Картның эләкләп йөрү гадәте юк—Азат белән булган вакыйганы кызына да, киявенә дә эндәшмәгән иде, тик ике көннән, кич, Гөлсем аның янына керде дә:

—Магнитофонның шнурын нигә йолкып алдың?—диде ачулы тонда— Ул сиңа комачаулый башладымы әллә?

—Ифрат шәп куя ласа тавышын, башка бәрә, түзми ике-өч тапкыр әйтеп карадым. Тыңламагач, алдым шул.

—Шуның белән булмасаң. Шәһәрдәге бала-чага шул инде: телевизор да магнитофон. Аларның башка ни эше бар? Нигә аңа тыгыласың? Олы була бел. Минем балаларга кагыласы булма! Ыштубы кыерсытма!

Әйтмәм, диган иде дә,минем балаларны кыерсытма, дигәч, жаны әрнеде һәм карт, нәрсә булса да булыр дип, дөресен әйтергә карар итте:

—Кем кемне кыерсыткандыр, башта шуны ачыкларга кирәк. Белсәң килсә, малаең мина сукты.

Гөлсем, гажәпләнеп, хәбәрен туктатты. Шулай дә әтисенә ышанмаганы күренеп тора иде. Азат ишек артында тыңлап торган, ахры, кинәт керде дә:

—Он врет!—дип сөрәнләде, тотлыга-тотлыга.—Все шнуры оборвал, магнитофон не работает.

Малае артыннан бүлмәгә жан-фәрман әтисе килеп керде, йөзе ачулы, яңак мускуллары уйный, йодрыгы төйнәлгән.

—Син, что позволяешь, а?—Киявенең ачуы чигенә чыкса яки эчсә, русчарак сөйләшү гадәте бар.—Балаларга кул күтәрә башладыңмы? Рукоприкладством занимаешься, да? Сездә нинди мәкаль бар әле? Эт симерсә, хужасын тешли, диме? Симердеңме? Малайларны обидага бирмәм, бел шуны!

—Кияү, мин сукмадым бит, ул сукты.

—Он врет, я не бил. Он оборвал провод. Магнитофон сейчас не работает.—Малай янә чабып чыкты, бармакларын картәтисенә төртте, янәсе, ул гына гаепле.

—Азат, сукмадым, дип әйтергә ничек оялмыйсың, ә? Иренне ярдың бит. Хәзер алдыйсың,—дип Тимергали карт малайның күзенә карады. Анысы карашын читкә алды.

—Ну, син инде бигрәк. Имгәтмәгән, зәгыйфьләндермәгән, аның сугуы инде...—Кияве мыскыллы гына көлде.

—Эш бит имгәтүдә түгел, дөресен әйтмәүдә, алдашуда. Мин, сукты, дип зарланмыйм. Аны сезгә бөтенләйгә әйтмәскә иде дә, үзегез кузгатканга гына.

—Ә ул шнурлар күпме тора беләсенме? Магнитофон? Әйбергә тигәнче, үзенә суксаң, лутчы булыр иде,—диде Гөлсем.

Тимергали аптырап, гаҗәп итеп баш чайкады. Ике көн элек булган вакыйганың шулай юнәлеш алуы аның өчен авыр да, сәер дә иде. Әйтерсең, пычрак су белән коендырдылар, ул, немец белән кыю сугышкан танкист, әллә күпме хәтәр янгыннарны сүндергән пожарник, шушы ундүрт яшьлек маңка малай алдында көчсез булып чыкты, үзенекен исбатлый алмады. Нинди кеше болар, нинди замана бу? Әллә шәһәрдәге бөтен халык шулай черек күңелле, алдакчымы? Акча, әйбер дип үлеп баралар бит. Бөтенләй икенче, моңача ул белмәгән-күрмәгән дөнья. Ят дөнья...

Шушы минуттан соң карт үзенең арытабан монда кала алмаячагын аңлады. Ул хәзер бу йортта—кирәкмәгән җан иясе, ул артык, ул барысына да комачаулый, аларга үзләренчә, үз кануннары буенча яшәргә ирек бирми.

Ул эчтән сыктап, гарьләнеп, йокысыз төн үткәрде. Иртәнчәк, кызы белән кияве—эшләренә, оныклары укуларына чыгып йөгергәч, кабаланмый гына чәй эчте, уйларын барлады. Шуннан тәвәккәлләде: китәргә! Киндер токчаена алмаш киемнәрен салды. Паспортын эзләп караган иде дә, тапмады. Гөлсем, пенсияңне үзем алырмын, йончып чиратта басып тормассың, дигәч, аңа биргән иде шул. Документы булмагач, хәзер үз акчасын үзе ала алмый йөрер инде. Шулай җаны көеп, әзрәк икеләнебрәк басып торды да, янә шкафка тыгылды: бер ордены, бер медале беркетелгән костюмын кисен әле, йә чыгарып ташларлар. Фатир ачкычларын суыткыч өстендә калдырып, ишекләрен шарт ябып, урамга чыкты Тимергали карт. Аны иртәнге салкын һава, аксыл томан, машина шавы, кешеләр йөгерешүе үз кочагына алды...

Картның яшәү мохите—хәзер урам. Ай-й, авыр аңа яңа тормышка өйрәнүе! Ни дисәң дә, сугышны, сугыштан соңгы авыр елларны хисапламаганда, көнитмеше әллә ни начар да булмады бит: ел әйләнәсенә сөт-катыктан, ит-майдан өзелмәде, бакчасында бәрәңгесе, җиләк-җимеше үсте. Ризык муллыгы, әлбәттә, таң сарысыннан торып, караңгы төшкәнче эшләү нәтиҗәсендә иде. Әмма Тимергали карт беркайчан да зарланмады, шулай кирәк, тормышта тир түкми булмый, дип эшләп тик йөрде. Дәүләткә дә, үзенә дә. Авылда бит ялкауга көн юк, анда, халык әйтмешли, эшләсәң генә тешлисең... Монда урам буенда авылдагыча өсте-өстенә өелеп яткан эш юк, әмма чослыгың, житезлегең барыбер кирәк! Бар эшең—йөрү, эзләнү. Бүренең тамагын аягы туйдыра, дигән сымак, Тимергали кебек берәдәкләрнең дә тамагын әнә шул аягы туйдыра. Әмма иң аянычлысы шул: ач һәм пычрак йөрүдән бигрәк шушы көнгә төшүдән кимсенә. Горурлыгы, нишләп мин бу көнгә тарыдым соң әле, мин—танкист, илне фашист итегеннән тапатмас өчен көрәшкән ләса дип күтәрелә дә чыга, күтәрелә дә чыга.

Ачыкты. Хәтта икешәр-өчәр көн авызына бер тәгам ризык эләкмәгән чаклары булды. Юкка чыгып киттем, тамагым ач утырмады, калганына ничек тә түзәр идем әле, дип үкенгән, кире кайтырга җыенып беткән мәлләре дә булмады түгел. Әмма Гөлсемнең, аннан да бигрәк киявенең сытык йөзен күз алдына китерә дә, кайту турындагы уйларын читкә куа. «Кайтмый хәлең юк, картлач, бездән башка борын төртер урының бармыни, һаман шул яратмаган киявең йортында торырга, шуның икмәген ашарга инде»,—дип мыскыллы көләчәк кияве. Кеткелдәп, мышный-мышный көләчәк. Анын шул кыяфәтен күрмәс, агулы сүзләрен ишетмәс өчен генә

дә әллә ниләр бирердәй булырсың. Иллә чыпчык үлми, әнә, алар сымаклар шәһәр тулы. Яшиләр бит. Көне бетмәсә, ул да яшәр.

Өйдән олагып чыгып киткәндә, март башлары гына иде. Хәзер көн сындыра башлады, язга тартты. Әмма төннәрен нык чатнама салкын, кайсы почмакка барып сыенырга белми берәдәк...

Беркөнне Үзәк базар тирәсендә йөри иде, үзе сымак сәләмә киемле, житкән чәчле, битен сакал-мыек баскан икәү туктатты. Чагыштырмача яшьләр, һәрхәлдә Тимергали карттан байтакка кечеләр.

—Син кем? Монда нишләп йөрисен?—диде берәүсе, катгый гына итеп. Тар кулбашына артмаклап ике чүпрәк токчай аскан, ябык гәүдәсе көянтәдәй алга бөгелгән. Кыяфәтләре изгелекле бәндәләргә охшамаган һич. Башкаларга да ул үзе шулай күренә микән? Аллам сакласын... Авылдан килгән берәрсе күреп калса—харап. Танкистны очраттым әле, кызы куандыр, урам буенда хәер сорашып йөри, ябыккан, беткән, кием генәсе, уф, дип кайтып сөйләр.

Тимергали карт бермәлгә югалып калды—күпме йөреп мондый сорау бирүчеләре юк иде әле. Аннан килеп, рус телен аңлавын аңлый, ә менә кайтарып жавап бирүе барыбер дә авыр. Шулай да, йөрим әле, ярамыймыни, дигәнрәкне аңлатты.

—Ярамый!—диде сорау биргәне.—Бу—безнен территория. Тагы күрсәк—үзенә үпкәлә. Белденме, татарин? Исәр башына салып куй: безнен территория, сиңа монда керергә рөхсәт юк!

Бу тирәдә йөрергә тыючылар кеше арасына кереп югалды. «Минем сымак хәерчеләр, ә ничегрәк сөйләшәләр, ә»,—дип уйлады Тимергали. Шулай да «безнең территория» дигәннәрен аңлап житмәде. Үзе сымак яшьләрдәге Захар исемле бер жирән урыс белән танышып алган иде анарчы, дөресрәге, уртак нужа таныштырган иде, шуннан сорады әлеге сүзнең мәгънәсен. Теге ни, байтактан бирле урам буенда көн иткән адәм, шулай аңлатты. Базар тирәсенә алар хужа, алар контрольдә тота була. Шәһәрне төрле төркемнәр үзара бүлешкән икән, алар бер-берсенең биләмәсенә керми,керә калса, чәкәлеш китә. «Тегеләрнең сине тукмап ташлаулары, хәтта үтерүләре дә ихтимал, саграк йөрергә кирәк»,—диде Захар.

Базарда халык күп, бигрәк тә шимбә, якшәмбе көннәрендә. Халык күп жирдә акча төшеп кала, су, сыра шешәләре жыела. Ашханә, кафе сымак жирләрдән дә тамак ялгарга табарга, һич югында капчык, яшник ташышып тиеннәр жыярга мөмкин. Шулай булгач, кемнең шушы «территория»не бирәсе, бүлешәсе килсен инде?!

Янә артка чигенде карт, янә бер позициясен бирде. Аны кысрыклау һаман дәвам итә, камап, почмакка кысрыклауларына да күп калмый. Ул чагында инде ике кулын да күтәреп бирелергә мәжбүр булачак.

Тормышның ул күзаллаганнан күпкә катлаулырак икәненә төшенә бара Тимергали карт. Моңа тиклем гәзиттән укып, телевизордан карап, кешедән ишетеп аның асылының өстен генә шәйләгән икән. Баксаң, тормышның зур өлеше безнең күздән читтә икән. Аның өсте һәм асты бар икән. Асны шунда яшәгәннәр генә күрә, өстәгеләр—иркен, бай яшәгәннәр—күрми, күрсә дә, күрмәмешкә салыша. Шушы ике катлылык (гамәлдә күп катлылык) торган саен ныграк аерымлана, аралары ерагая бара. Авылда бу юк сымак, һәрхәлдә ул киткәнче тоелмады, ә монда, шәһәрдә—адым саен.

Бер шулай трамвайга утырган иде. Этешмәде, төртешмәде, иң азаккы булып керде дә арткы тәрәзә янына сыенды. Чөнки күптән юынмаганлыктан үзеннән алама ис килгәнен дә, киеме таза түгеллеген дә белә, шуңа да кеше арасына тыгылмаска тырыша. Билет сатучы, олы гына яшьләрдәге хатын, аңа күпмедер вакыт текәлеп торды, шуннан эндәшми-нитми ары китте.

Тимергали карт сымаклардан сукыр тиен алсынмы? Ә янына килеп баскан бер маржа әле арты белән борылды, әле, кире әйләнеп, аңа йөзен җимереп карады. «Янында торганга канәгать түгел, әрләшергә сәбәп эзли»,—дип уйлады танкист һәм күз кырые белән генә тулы гәүдәле, битенә әллә күпме буяу яккан һавалы хатынны күзәтергә тотынды.

Тукталышка килеп җитәр алдыннан трамвай кинәтрәк туктаган иде, марҗаның иңгә куйган сумкасыннан карбызы тәгәрәп чыгып, Тимергалинең аяк очына килеп ятты. Хатын үзе дә чак егылмады: чайкалып китте дә бер кулын картның эченә терәргә мәҗбүр булды. Кулын кинәт кенә тартып алды, иелеп, карбызын тота алмый азапланды. Шуннан ачу белән картның аягын этте.

—Встал, не сдвинешь с места! Осел!

Тимергали аякларын күчереп баскан иде, карбыз ни, йомры нәрсә, тәгәрәп төшеп китте баскычлар буйлап. Баскычтан асфальтка сикерде һәм уртага ярылды куйды. Сылу марҗаның йөзе чалышайды, иреннәре калтыранды, шуннан усалланып йодрыклары белән танкистның йөзенә төртте. Сукмады—төртте.

—Бомж проклятый, татарва, свинья грязная!—дип ысылдады ул, әйтерсең дә, карбызы төшүгә Тимергали гаепле.

Вагондагыларның башлары болар ягына борылды.

—Шәһәрдә хәерче күбәйде, транспортка пычрак киемнәре белән керәләр,—диде берәү.

—Авылдан киләләр дә монда квартира, эш таләп итәләр. Үзебезгә җитмәгәнне аларга бирергә мәҗбүрбез,—дип элеп алды икенчесе.

—Башкорт, татардан көн юк. Кайда барма—шулар. Нык үрчеделәр,— шулай ярсыды өченчесе.

—Башкорт, татар сезгә комачаулыймыни? Шәһәр зур, һәркемгә дә урын җитәрлек. Хәзер бездә—суверенитет.

Бу ялгыз тавыш канәгатьсез күмәк тавышка күмелеп калды.

—Шул суверенитетыгыз белән тыгылып кына китмисез бит.

—Чечнядагы кебек, республикага гаскәр кертсәләр, белерсез әле суверенитетның нәрсә икәнен,—дип тамак ярды бер исерек урыс...

Үзе сатып алган йомры карбыз сымак йомры маржа кузгалган трамвайны кычкыра-кычкыра туктатып, ишекне ачтырды, төшеп барышлый йодрыгы белән Тимергали картка янә төртеп алды. Бу юлы—эченә. «Нинди җаһил нәрсә,—дип уйлады танкист.—Бернинди гаепсезгә бәйләнәче. Мондыйлар белән каберең якын булмасын, шунда да торып, нишләп минем яныма ятасың, тегендәрәк шуыш, дип әйтмәс димә. Дөньяга сыймый йөри, ай-һай».

Трамвайдагы шушы вакыйгадан соң үзе өчен бик мөһим нәтиҗә ясады Тимергали карт. Урыс башкортны да, татарны да яратмый икән ләбаса! Әнә ни диләр бит, безгә көн юк, кайда барма шулар, диләр. Димәк, урыска яшәргә комачаулыйбыз. Теге чак базарда туктаткан икәү дә «татарва» дип кенә җибәргән иде. Урыска бар мөселман да татар икән. Димәк, мин генә позицияне бирмим, безнең халык чигенә, димәк, барыбыз да позицияне бирәбез. Озакламый шулар алдында кул күтәрүебез дә ихтимал. Үз Ватаныбызда! Ул чагында бетте, хана.

Гөлсемнең үзен эзләячәген, милициягә дә хәбәр итәчәген чамалый иде Тимергали. Чынлап та беркөн кичке якка вокзалга килеп эзләп йөрде. Ерактан күрә-шәйли алмас иде карт, кинәт борылса, кызы янында ук тора! Карт җәһәт кенә кеше арасына кереп китте. Ә үзе сабыйдай, әһә, эзлисеңме, әтиең исенә төштеме, дип куанды. Куануы да күз яше аралаш иде. Шушы яшьтә үз баланнан яшеренеп кал инде... Ул, Тимергали Кылысбаев, элекке танкист, дошманны аяусыз тукмаган яугир, авыр сугыштан соң ярты

гасырдан артык гомер яшәгәч, кызыннан, оныкларыннан китеп урам гизә, сукбайга әйләнеп кайда җитте шунда йоклап йөри, нәрсә җитте шуның белән туклана. Ә бит үзе чыгып китте, ачыктан-ачык берсе дә кумады. Юкка гына авылыннан кузгалды. Кузгалмаса, мондый көнгә төшмәс иде...

Көннәр азрак сындырды. Кар муртайды, озакламый эри дә башлар. Парк яки сквер эскәмияләрендә йоклап булмый әлегә. Таң алдыннан нык суыта. Шуңа да Тимергали сымаклар вокзалга керергә тырыша. Тик анда да тынгылык юк—милиция куа. Элегрәк документ-фәлән сорамый, йөз-кыяфәтләренә, киемнәренә карап чыгаралар иде, хәзер һәрберсенең документын тикшерә башладылар. Булганнарына кагылмыйлар, әлбәттә, ә булмаганнарын машиналарга төяп алып китеп торалар.

Менә почмакта посып кына утырган Тимергали картка да чират җитте.

Яшь кенә сержант аны баштанаяк күздән үткәрде дә:

—Ваши документы?—диде.

—Үзем белән түгел, өйдә,—дип җаваплады танкист.

—Ансын отделениедә ачыкларбыз, әйдә, тор!—Сержант янындагы иптәшенә, курсант, ахры, ымлады.—Алып чык.

Курсант танкистның терсәгеннән тотты да, җилтерәтеп дигәндәй, вокзалдан алып чыкты, урамда торган «УАЗ»га төртеп кертте. «Яшь кенә булса да, ничегрәк эткәләргә өйрәнеп алган, олы кеше дип тә тормый»,—дип уйлады карт. Машинада аның сымак янә өч кеше бар иде.

Бүлекчәдә яшь кенә участковый, лейтенант, боларның дүртесен дә каршыдагы утыргычларга утыртты да һәркайсысына күзенең агы белән алмашлап карап чыкты, әйтерсең дә, бакчасына төшеп кыяр урлаган малайларны тоткан да аларга җәза бирергә җыенган усал хуҗа.

—Фамилиягез, исемегез?—Участковый, араларында иң олы булганлыктандыр, Тимергали картка ымлады.

Танкист үзенең исем-шәрифен әйтте.

—Берәр төрле документыгыз бармы?

—Монда юк, өйдә.

—Өй адресыгыз?

Әйтергәме-юкмы, дип бераз икеләнеп утырды карт. Әйтсә—хәбәр итәләр, әйтмәсә ябып куюлары бар. Шулай да әйтергә карар итте.

—Анда сездән башка тагын кемнәр яши?

—Кызым белән кияү.

—Телефоннары бармы?

—Юк.

Участковый Тимергали картның әйткәннәрен язды. Бүтән сорау биреп тормый, сержантны чакыртып, картны алып китәргә кушты. Ә сержант аны бәләкәй генә бер өстәлле, как сәкеле бер бүлмәгә бикләп куйды. Торарак танкистның теге өч «иптәше» дә монда керде.

Ничек, кайсы арада хәбәр иткәннәрдер иртүк Гөлсеме килде. Аптырады, «әстәгъфирулла» диде, бот чапты, кашларын чөеп, күзләрен түгәрәкләндерде.

—Әти, монда ничек килеп эләктең?—диде ул ачынып.

«Уйный, ай, уйный кеше алдында,—дип уйлады карт.—Шулай да артистлана белер икән! Кайдан өйрәнгән диген? Нәселдә юк андыйлар».

—Әти, мин сине әллә кайлардан, морглардан, больницалардан эзләп беттем. Нишләп шулай чыгып киттең инде? Ярамаган берәр төрле хәл кылдыңмы әллә?

Карт эндәшмәде. Кызын күрүе күңеленә нинди дә тынычлык китерсә дә, йөрәген йомшартмады. Үпкәсе бар шул Гөлсеменә, малаеның

кыерсытуыннан, иренең мыскыллавыннан саклый алмады әтисен. Сакларга теләмәде. Аларның кылыгында кызының турыдан-туры кысылышы юк, әлбәттә, берсенә танавына сук, икенчесенә көл, туры килгән, форсаты чыккан саен әче, чәнечкеле сүзләр әйтеп тор, дип этлеккә өйрәтмәгән, әмма үзенең битарафлыгы, игътибарсызлыгы, гел генә боерык тонында сөйләшүе, ордым-бәрдем мөнәсәбәте белән тегеләрне шул адымга барырга котыртты.

—Нишлим, алып кайтам дип сорыйммы?—дип янә аптыратты Гөлсеме.

—Сора,—диде карт битараф кына.

Кызы кайдадыр барып, бер милиционерны ияртеп килде. Аның янында сөйләшеп тормадылар, мәсьәләне тегендә үк хәл иткәннәрдер, күрәсең. Автобуска утырып, өйләренә кайтып җитсәләр дә карт подъездга кергән җирләреннән кире борылды. Пенсиясен сорамакчы иде дә, сорамады—бирәсе башы юк.

—Эти, тукта, кайда барасың?—дип эндәште кызы, әмма карт туктау түгел, артына әйләнеп тә карамады. Чөнки ул Гөлсем белән киявенең берничә көн генә ару булачакларын, аннан элекке хәлләренә кайтачакларын бик яхшы белә иде. Китеп барган көе генә башын чайкады да юлын дәвам итте. Байтак баргач, кызының:

—Аркылы, бу кадәре дә үзсүзле булыр икән, ә мин, исәр, алып чыгам бит әле,—дип ысылдаганын ишетте. Бу сүзләр үкчәсенә кадалган чыра сыман тәэсир итте. Әзрәк якын күрсә, куып җитәр, үгетләр иде, ә бу, җәһил нәрсә, ни дип кала...

Карт базарга каршы гына биш катлы йортның аскы катындагы бер оешманың (әле ул бикле) тупсасында утыра. Утыра һәм алдында кырмыска иләве кебек кайнашкан халыкны күзәтә.

Менә урта яшьләрдәге, иллене узгандыр, бер ир атлап килә. Чырае яшь күренсә дә, жилле итеп корсак үстереп алган, чалбарын шунын өстенә күтәреп, нәзек каеш белән буган. Өстендә—ак күлмәк, юан төенле галстук, әйбәт тукымадан тегелгән плащ. Башында—кара эшләпә, ике кулында да—авыр сумка. Яныннан, дөресрәге, чак кына алдарак, хатыны бара. Йөзе усал, иреннәре кымтаулы, нәзек гәүдәсен уклау йоткан кебек тотып атлый. Кулында кечкенә кара сумкасыннан башка әйбер юк, үзе әледән-әле, артыннан юргалаучы иренә борылып, канәгатьсезлек белдерә. Ирен тәмам буйсындырып алган икән, дигән нәтиҗә ясый танкист. Бүген, мөгаен, киләсе килмәгәндер бу ирнең, синең базарыңнан башка да эшем җитәрлек, дигәндер. Ә бу җәһилы, бармасаң, бернәрсә дә пешермим, бүгеннән алып үзең пешереп ашарсың, дип куркыткандыр. Нишләсен, берәр җиргә барырга җыенган җиреннән—ничек пөхтә итеп киенгән бит—бичәсенә ияреpгә мәҗбүр булгандыр...

Егерме яшьләрдәге егет бер чәчкә бәйләме алды да, ялт-йолт карана-карана, павильон алдына чыгып басты. Әле тегеләй үтә, әле болай—берәрсен көтәдер. Бот-балтырларын кысып торган чалбар кигән, чәчләре пумала кебек тузынкы. «Орчык бит әле хас та,—дип уйлый танкист,—бер дә житди егеткә охшамаган, безнең заманда яшьләр барыбер дә икенче иде. Юк, безнең танкка ярамас бу малай, немец күренү белән, коралын ташлап качар иде. Хәзерге яшьләр фашистка каршы барыр яшьләр түгел, сугыш бүген чыга калса, вич кырып салачак дошман бу манкалар армиясен».

Егет кинәт кенә урыныннан купты, колачын җәеп, кыска гына куртка, биек үкчәле туфли кигән, малайларча кыска чәчле кызга каршы чапты. Ә кыз һич ашыкмый, үз бәһасен белеп, җай гына атлый. Кочаклаштылар,

дөресрәге, егет ишарәте кочаклады, авызын ерып, чәчкәсен тоттырды, кызның биленнән алды да, тартып дигәндәй, трамвай тукталышына алып китте. Юк, мондыйлар белән Днепр өчен сугышып булмас иде, бигрәк сыек.

Үзе сымак олы гына кеше, әнә, чатанлап атлый—сугыш касафатыдыр... Янагын йон баскан, танавы бәрәңге кебек йомры һәм рәвешсез, кәпәч дигәне башында коймак сымак ләшпәеп төшкән. Кашлары чабатадай калын, иреннәре салынкы. «Авылдан,—дип фикер йөртте танкист,—аркасындагы рюкзагына караганда, үзе эшләгән берәр нәрсә сатарга килерә...»

Кеше тикшереп утыруы кинәт тукталды картның: кулбашына шапылдатып сукканга дертләп борылып караса, алдында теге чак «базар янында эзен булмасын, бу—безнең территория» дигән ике берәдәк басып тора.

—Без сине искәрттек, татарва, бу тирәдә йөрүенне оныт, дип, шулаймы?

Җавап бирү түгел, аңына килергә дә өлгермәде карт, тегеләр үзләре җаваплады:

—Искәрттек, ә син аңламагансың, һаман безнең биләмәгә керәсең.

—Кара, бу орден-медальләр тагып алган түгелме?—диде берсе мыскыллы гына елмаеп, аннан иелеп һәркайсысын тоткалап карады.—«Красной звезды», «За боевые заслуги», орден «Славы», юбилей медальләре. Боларны кайдан урладың?

—Урламадым, сугышта бирделәр.

—Алдашма, мондый наградалар алган кеше бомж булып йөрми ул.

Карт эндәшмәде. Фронтта танкист булуын, байтак алышларда катнашуын, Днепр өчен сугышта танклары ватылуын сөйләп утыра алмый бит инде бу йолкышларга. Барыбер ышанмаячаклар. Картның җавап бирмәвен егетләр орден, медальләрен чынлап та үзенеке түгел, кемнәндер урлаган итеп кабул итте шикелле.

Берсе Тимергали картның йөзенә китереп сукты, икенчесе биленә типте.

Карт йөзен каплап бөгәрләнде дә тупсадан җиргә тәгәрәде. Байтак ятты. Башын күтәргәндә, тегеләр янында юк иде. Вак-төяк киеме, унлап буш шешә, кружка салган чүпрәк токчае, иң начары—түшендәге орден-медальләре юк. Алып киткәннәр, кабахәтләр. Захар, тукмап, хәтта үтереп китүләре бар, саграк йөре, дип бик дөрес әйткән икән.

Шешә җыю—иң төп яшәү чыганакларының берсе. Халык, бигрәк тә яшьләр, сыра эчә, күп эчә; танау аслары да кипмәгән малай-шалай, хәтта кыз-кыркын урам буйлап сыра чөмереп йөри, шешәләрен тукталышларда, эскәмияләрдә калдыра, агач, куак төпләренә ыргытып китә, подъездларга ташлый. Тик, эчүчеләре сымак, җыючылары да күп шул аны. Тимергали карт сымак урамда көн итүчеләр генә түгел, әби-сәби, алай гына дисеңме, ару гына киенгән хатын-кыз, ир-ат та җыя. Кичләрен сумка, рюкзак тотып байтак кеше чыга шешәгә сунарга—танкист аларның чүп-чар савытларында казынганын, тукталышларда эзләнгәнен күреп йөри.

Әле чак «бомжить» итә башлаган мәлендә, ирексездән шундый хәлнең шаһиты булган иде ул. Егет корына кереп килгән берәү, өлкән класс укучысы яки студент-мазардыр, тукталыш эскәмиясендә, сыра чөмерә-чөмерә, гәзит укып утыра. Кулбашында—спорт сумкасы, кулында сигарет, кигән киеме дә күркәм генә. Тукталыш будкасына берәүләр керә, икенчеләр чыга, шулай да Тимергали өч кешенен—кулын кузгаткан саен чүпрәк сумкасындагы шешәләре шалтырап-шалтыраган әбинең, сәламә генә киенгән урта яшьләрдәге ирнең һәм бер егетнең, туктаган автобус, троллейбусларга бөтенләй игътибар итми, карашларын әлеге сыра эчкән

егеттән алмаганлыкларын шәйләде. Нигә бик еш күз салалар икән, дип карт бу өчәүнең шикле кылыгын тәүдә аңламый утырды әле, сыра кимегән саен кузгалышып-кузгалышып куйганнарыннан гына аларның әлеге шешәнең бушавын көткәнлекләренә төшенде. «Да, аны каравыллап утырган бер мин генә түгел икән»,—дип, эчтән генә көлеп тә куйды Тимергали. Ә вакыйга чынлап та көлкеле тәмамланды.

Студент бер-ике уртларлык сырасы калган шешәсен, башын артка ташлап, авызына каплавы булды, чүпрәк токчае шешә белән тулы әби урыныннан калкынды, аны күреп ир кеше торды, әмма аларның икесеннән дә егет житезрәк булып чыкты: ул, бу икәүдән ераграк утырса да, корбанына ташланган козгындай, бер-ике сикерүдә студент янына барып житте дә, тегенең эчеп бетерүен дә көтми, шешәсен кулыннан тартып алды. Тезе белән әбигә төртелде, анысы егылды, мескеннең кулыннан токчае ычкынып, шешәләре тәгәрәп китте, ә эчеп бетелмәгән сыра студентның чалбарына түгелде. Ул: «Что ты делаешь, сволочь?»—дип сикереп торган иде дә, үзеннән талап дигәндәй шешәсен тартып алган егетне куып житә алмасын аңлап, чалбарын сыпыра-сыпыра кире утырды.

Ул шешә галижәнапларын табулары, жыюлары, ай, жинел түгел. Башкалардан элегрәк өлгерим дисәң, иртүк чыгарга кирәк. Анда да йокысыз әби-сәби сыпырып чыккан була әле. Күпләр чүплектә, чүп савытларында казына. Тимергали карт та шунда чокынып караган иде дә, азак ваз кичте—халык аракы, шәраб шешәсен ыргытса да, сыраныкын бик ташлап бармый. Чөнки аракы шешәсе егерме тиен булса, сыраныкы—бер сум. Аннан килеп, яшник, чүп савыты эчендә казынырга жирәнә дә Тимергали карт. Шуңа Захар яшникләрне, чүп савытларын бутаган чакта, ул читтән генә карап тора. Соңыннан урыс, ну аксөяксең дә инде, дип көлә. Шешәнең иң күп табылган мәле—шәһәрдә берәр төрле чара үткәндә. Шәһәр көне, Яшьләр көне кебек һәм бүтән бәйрәмнәрдә, бигрәк тә кичен, яшь-жилкенчәк эркелешеп шәһәр үзәгенә агыла. Һәрбересенең кулында диярлек шешә. Эчеп беткәнен унлы-суллы ыргытып баралар. Артларыннан жыеп кына өлгер. Кулына тоттырып киткәннәре дә бар, шешә төбендә бер-ике йотым калдырганнары да очрый.

Йөри-йөри, Тимергалинең өйдән киеп чыккан киемгенәсе тузды, карайды, майланды. Алмашны күбрәк алырга башы житмәгән. Хәер, бар иде, теге ике бәндә сумкасы белән тартып алдылар бит. Аягындагы ботинкасы да актарылып бетеп бара. Ә башына кияргә бөтенләй онытып чыгып киткән кызулык белән, ярый әле Захар ләшпәеп беткән бер фуражка аламасы бирде. Берәр чүп-чар арасыннан тапкандыр инде. Өшетә, бигрәк тә иртәле-кичле. Андый чакта йөрергә, хәрәкәтләнергә тырыша, һәм «язгы көн яманында, карлы-бозлы яңгырда, нишләрмен икән соң?»—дигән уй миен бораударга керешә. Гөлсеме белән киявенә кире кайта алмый. «Килдеңме, барыбер шул яратмаган киявенә ишек кагасың инде»,—дигән мыскыллы елмаюны күргәнче, урамда йөрүе мең артык. Стәрледә яшәгән Әкълимәсенә барса, әлбәттә, Гөлсеме ише булмас, әмма борчыйсы килми—кияве аяк-кулын сындырып өендә ята. Ул кияве ару болай, сүзләре килешә иде. Төзелештә эшләгәндә, өченче каттан егылып төшеп казаланып куйды. Инвалидлык биргәннәр. Нил улының бичәсе алама. Кузгалма, үзебезнең авылда өй салыйк, дип күпме әйтте шул улына, бичә сүзеннән чыга алмый, чит якка ияреп китте барды. «Салпы килен» булып төште инде. Бәләкәй генә йортта бабасы, әбисе, өч бала белән көн итәләр бүгенге көндә.

Хәзер шунсына кайгыра Тимергали карт: Гөлсеме өйне шуларга сатса ни була инде? Жайлап түләрләр иде әле. Түләмәсәләр тагы. Нигез корымас иде ичмасам, карт үзе дә үз тупсасына иркенләп барып төшә алыр иде.

Төпчек улы Мәжит тә өметен акламады, армиядән кайтты да, классташ егетенә ияреп, Себергә чыгып олакты. Һаман кәләшсез. Сирәк кайта. Елына бер бирелә торган отпускасында гына. Ана да сыена алмый Тимергали карт—тулай торактамы, бәрактамы көн иткән кешегә ни йөзен белән барып керәсен?

Менә шулай балаларын, аларнын көнитмешен барлый танкист. Холыкфигыльләре үтә начардан булмаса да, ничектер язмышлары ул өмет иткәнчә яхшыдан булмады. Себер киткән Мәжитеннән башкалары институтка имтихан тотып караса да, Әкълимәсе генә керә алды, инженерлыкка укыды. Нилы—колхозда механизатор, Гөлсеме училище бетерде, сатучы.

Балалары бар да, башын төртер урыны юк Тимергали картнын. Аннан мескенләнеп йөрисе дә килми. Холкы кушмый, горурлыгыннан уза алмый. Танкист бит әле ул, немецны чүктергән кеше. Шул илбасарларга торган башы белән, яшәргә кертегез әле, дип ничек барып керсен? Ай, коргыры Гөлсем,нишләп кенә сатып җибәрде икән йортын? Болай йөрмәс, кайтыр да, моржасыннан төтен чыгарып яшәп ятар иде ләса.

Эче пошып, нишләргә дип өзгәләнгән мәлләрендә Тимергали танкы янына килә. Килә дә, каршысына басып, мышнак кияве әйтмешли, «тимер өеменә» карап тора. Юк, танк анын өчен бер дә тимер өеме түгел, ә балаларыннан да якын тере җан, гүя. Ул—танкистнын соңгы плацдармы. Гөлсеме белән кияве, фатирларыннан куып ук чыгармасалар да, аннан тәмам йөз бордылар. Үзе сымак ике йолкыш базар тирәсенә юллатмый, эзәрлекләп-эзәрлекли. Житмәсә, орден-медальләрен алып киттеләр. Транспортка утырырлык түгел, әрлиләр, куалар. Хәзер чынлап та бөтен юанычы булып шушы танкы калды. Ул аңа хәбәрен сөйли, сер уртаклаша. Шушы соңгы плацдармын да бирсә... калганын күз алдына китерергә дә курка танкист.

Көннәрдән беркөнне, шулай танкы алдында басып торганда, башына кинәт көтелмәгән уй килде: эченә кереп караганда ничек булыр икән? Әлбәттә, биектә утыра, дүрт метр гына бардыр, менүе бик җиңелдән булмас, шулай да... Шушы көннән башлап әлеге коткылы уй-теләк картны эзәрлекләп алды да китте. Нияте балаларчарак икәнен дә чамалый, егылып төшә калса, нык имгәнәчәген, хәтта үләчәген анлый, әмма танкы янына менмичә, анын эченә кереп карамыйча, йөрәге тынычлана алмас кебек.

Менәм дисән, баскычы кирәк әле. Аны такта-токтадан ясарга яки арканнан ишәргә була. Тактасын төзелеш тирәсендә табарга мөмкин, баумазарны магазин, киоск артыннан эзләр. Материал табуы кыен булмас: тик кайда ясар сон баскычны? Урыны, инструменты кирәк.

Күп уйланды, төрле планнар корды танкист шушы унайдан һәм дөнья хәлен белеп булмый, баскычны агачтан да ясарга, аркан да ишәргә кирәк булыр дигән карарга килде. Нәрсә очрата, ярардаен җыя башлады. Шешә җыю да, кешедән калганны ашау да, максат төсмерләнгәнгәмедер, аны элекке кебек тартындырмый башлады. Үзәк базарга барып чыгып, теге ике йолкыштан тагы бер тукмалуы да аны әлеге уеннан төнелдермәде, киресенчә, чәмләндереп кенә җибәрде—әүвәле, «мин дә алар кебек бомж инде» дип уйласа, хәзер үзен алардан югарырак итеп тоя иде.

Йортлар буйлап йөреп, бер биксез подвал тапты; шунда такта, агач кисәкләре җыйды, юлда очраган, күзенә салынган бау, шпагат-фәләнне токчаена салып йөрде; төзелеш барган җирдән кадак, чүкеч итәрлек торба кисәге, башка кирәк-ярак тапты. Атна ун көн дигәндә, аркан баскыч, янә өч көннән агач баскычы да әзер булды. Гомер буе авылда яшәгән кеше бит, кулы оста иде, ике баскыч та ярыйсы ук җыйнак, нык килеп чыкты. Агач

баскычын йөртүе уңайлы булсын өчен хәтта уртага бөкләрлек итеп ясады. Ә аркан баскычы токчаена да сыя. Ниһаять, беркөнне, дөресрәге төнне, Тимергали карт, аркан баскычны гына алып, подвалдан чыкты да танкына юнәлде. Урлаша белмәгән кеше ни, ифрат куркып атлады, сугышта дошман белән йөзгә-йөз очрашканда да шүрләмәгәнен... Максаты—постаментка бүген үк менү түгел, максаты—баскычның буе житәме-юкмы икәнен тикшерү. Төн уртасы булса да, кеше йөри, бигрәк тә яшьләр. Карт алардан йә парктагы агачлар ышыгына яшеренеп кала, йә тегеләрнең каршысына барып үтеп киткән кеше була. Танкы янына килеп житкәч, алан-ялан каранды да, жеп баскычны токчаеннан чыгарып, бер очын үргә ыргытып карады. Жеп нәрсәгәдер эләккән кебек булды, әмма тарткан иде, ычкынды. Икенчегә ташлады. Бу юлы эләкте шикелле, суырылып төшмәде, тик постаментның шоп-шома таш сыртына сылашып яткан арканга басып менүе мөмкин түгел иде. Стена белән баскыч арасында аралык булмагач ни, аягы белән бауга баса алмый да куя. Баскычны кире алырга булып аска тарткан иде, ычкындыра алмады, шуннан, кеше күрүеннән куркып, кулындагы очын да өскә ыргытырга мәжбүр булды.

Иртәгәсенә танкы янына бармады. Төшкә тиклем тынчу, әмма жылы подвалда утырды. Шуннан, чыгып, якын тирәдә генә йөреп әйләнде, бер сыраханәгә кереп, кемнәрдәндер калган сыра, кипкән балык койрыгы, икмәк сыныклары белән тамак ялгады да кире подвалына кайтты һәм шунда йокларга калды. Төшендә танклар күрде. Күп танклар. Батальон гына түгел, бер полк танклар. Тимергалиләрнеке дә бар. Алар чигенүче дошманны куып бара, имеш. Шунсы гажәп: һөжүм итеп барган танкларның барысының да башняларында—«555» саны...

Агач баскычны уртага бөкләп тотып алды да, икенче көнне янә танкына таба атлады Тимергали карт. Килде, алан-йолан каранды, тирә-як тәмам тынгач, постаментның тәбәнәгрәк арткы ягына баскычын терәде. Беренче аратасына басты, түзерме, сынмасмы яки шуып китмәсме дип селкетеп карады, шуннан сак кына икенчесенә басты һәм өскә үрмәли башлады. Кулы баскычның очына житкәч, аның кыскарак икәнен чамалады—бер ярты метр чамасы житми иде, каһәрен. Ярый, элекке көн ташлаган бау баскычка якын гына яткан. Шуны сәрмәп табып тотынды да, ябышып, өскә үрмәләде. Күтәрелеп баскан иде, йөзенә салкын жил, колагына парктагы каеннар шавы бәрелде, шомлы караңгылык өстенә жимерелеп төшеп килгәндәй тоелды. Ә күңеле шундый жиңеллек, шундый канәгатьлек белән тулды, әйтерсең дә, хәзер танкына кереп утыра да кузгалып китә.... Әлбәттә, бу—үзенең танкы. Мышнак кияве, юкны сөйләмә, кайдан синеке булсын, дисә дә, карт танкист тәненең бөтен күзәнәкләре белән сизә—үзенеке. Сәрмәнә-сәрмәнә гусеницага менде, башняга кулын салды, люкны тартып караган иде бикле. Уратып капшап чыкты, бер урыннан сварка белән ябыштырылуын аңлады. Монысын һич уйламаган иде, дөресрәге, шундый биектә утыргач, кем менсен, мөгаен да, ачыктыр, дип уйлаган иде... Болай гына көч житмәс, актарырга лом сымак нәрсә кирәк булыр.

Кирә алмаса да, шуны ачыклавы яхшы булды әле. Тимергали танкын сыйпап яратты. Броня шома, тигез, пуля, снаряд ярчыклары тигән жире сизелми дә диярлек—яхшы итеп буяганнар. Ягулык баклары юк, гусеницаны алдан да, арттан да тимер тростлар белән постаментка беркеткәннәр... Жиргә төшәргә дип агач баскычка аяк баскач, киләсе юлы тотынып менгәндә ышанычлырак булыр дип, арканын шул тимер тростка бәйләп куйды. Төшкәч, агач баскычын жәһәт кенә икегә бөкләп алып, подвалына ашыкты. Шөкер, күрүче булмады, бу баруы да уңышлы үтте.

Ломны иртәгәсенә үк тапты һәм төнен, аны тотып, янә танкына күтәрелде.

Люк башняга бер генә урыннан түгел, ике урыннан ябыштырылган икән. Шулай да аны актаруы кыен булмады—лом очын тыгып каерган иде, шарт итеп ачылды китте. Танавына тимер исе катыш бөркү һава бәрелде. Карт, башняның читләренә тотынып, аякларын эчкә төшерде. Табаннары төпкә терәлгәч, шырпы сызды—яктылык бирмәлгә генә тимер стеналарны күрсәтте дә шундук сүнде. Шулай да карт бөтен приборларны да алганнарын шәйләп өлгерде. Ә калганы элекке сымак, сугыштагы кебек, тик май, солярка исе генә юк, иптәшләре юк...

Танкист үзенең урынына утырды. Күпме хыялланды бит ул шушы минут хакында! Днепр өчен теге сугыштан соң югалткан иде танкын, хәзер килеп тапты. Моннан ары гел килеп йөрер, көн җылына төшкәч, шушында яшәргә дә күчәр. Рәхмәт инде бәләкәй оныгына, ул очраштырмаса, шушы шәһәрдә, хәтта күрше генә урамда торган танкын мәңге күрә алмас иде... Барыр җире юк, аны көтүче дә юк, аңа кайда йокласа да барыбер. Әллә хәзер үк төнне шушында уздырыргамы?

Танкист башнядан чыкты, постамент читенә басып, кече хаҗәтен башкарды, баскычын өскә тартып алып бөкләде дә танк астына тыкты. Шуннан башняга кире төшеп, сак кына люкны япты. Тынычланып бераз утыргач, гел аркасына артмаклап йөрткән чүпрәк токчаеннан мендәрен алып (аны да Захар табып биргән иде) баш астына салды, аяк киемнәрен чиште, олы бер кинәнеч белән сузылып ятты. Иптәшләре исенә төште, үе белән аларны үзләренең урыннарына утыртып чыкты: тышкы кыяфәте белән кабалануының ни икәне белмәгән, әмма барсына да өлгергән механик йөртүче Кондратьев, орчык Филиппов, үтә житди командир Иванов. Экипаж тәгәлләнде...

Танкист шул көннән, дөресрәге, шул төннән башлап үзенең танкында йоклап йөри башлады.Көннәре әүвәлгечә урам гизеп, шешә җыеп, ашханәләрдә кешедән калган белән тамак ялгап үтә,төнен, тирә-юньдә кеше аягы тынгач, танкына менә. Захар белән шәһәр читендәге чүплектә йөреп иске пальто ишарәте, җылы свитер, чагыштырмача яңа туфли тапты, юып, киптереп, шуларны танкына мендерде, ашханәдән стакан, тәлинкә, калак чәлдерде, танк төбенә зур кәгазь картон җәйде. Бер төнне яңа фатирын юарга Захарны чакырды. Булган гына акчаларын кушып, бер шешә аракы алдылар, шуны танк эчендә эчә-эчә, төне буе сөйләшеп чыктылар. Урыс, теле ачылып, ничек итеп бу көнгә төшүен, Тимергали үз язмышын сөйләде. Ул «Колой кантон»ны җырлады, урыс та көй сузды, шуннан икәүләшеп түгелеп-түгелеп елаштылар.

Танкына менеп-төшеп йөрүнең азагы булырын Тимергали карт аңлый иде. Барыбер берсе күрәчәк, әләкләячәк, андып торачак. Менә беркөнне, чынлап та, иртәнчәк (йоклап соңлабрак киткән) аягын җиргә терәве булды, янына ике милиционер килеп басты. Икесе дә яшь кенә сержантлар.

—Я, бабай, танк белән йөреп буламы?—дип елмайды берсе мыскыллы гына.

Карт эндәшмәде, баскычын алды да, бөкләп, китәргә чамалады.

—Тукта, китми тор, син бит общественный тәртипне боздың, аның өчен җавап бирергә туры килер.—Икенчесе татар егете булып чыкты. Ул картка үзенең артыннан иярергә ишарә ясады. Милиционерларның берсе алдан төште, икенчесе—арттан, Тимергали карт, уртага бөкләгән баскычын, чүпрәк токчаен тотып—уртадан. Килделәр, начальникларының бүлмәсенә керсәләр, теге вакыт вокзалдан тотып алып килгәндә сорау алган яшь лейтенант утыра. Ул чак лейтенант иде, хәзер—өлкән лейтенант.

—Иптәш өлкән лейтенант, бу карт Җину паркындагы танк өстенә менгән,

төшкән чагында эләктердек,—дип татар егете олы канәгатьлек белән рапорт бирде. Әйтерсең лә, дәүләт чиген бозган шпионны тоткан.

—Ну и ну! Могжиза тек могжиза. Страна чудес. Анда ничек менгән инде?

—Баскыч ярдәмендә.

Картны күрү белән танып алган өлкән лейтенант янындагы шкафтан калын кенәгә барып алды, аның исем-шәрифен, Гөлсемнең адресын тапты.

—Ә баскычны кайдан урладың?

—Урламадым, үзем ясадым.

—Теге вакыт тоткан җирдән чыгарган идем, нигә тагын урамда йөрисеңмени?—Өлкән лейтенантның тирән утыртылган күсе күзләре картка кадалды.—Тәмам бомжга әйләнгәнсең бит, иптәш фронтовик.

—Танкист мин!

—Танкист фронтовик булмыймыни? Танкист булгач, «глухо как в танке», дип тем более өйдә генә утырырга тиешсең. Кыяфәтеңә караганда, иптәш танкист, сиңа урам буенда да рәхәт түгел. Йә, бу юлы нишлибез? Мин бит общественный порядокны бозган өчен хөкемгә тарттыра алам. Ул—синең өчен генә танк, халык өчен һәйкәл, үткән сугыш истәлеге, немецларны җиңү символы. Сизәсеңме, нинди сәяси оттенок биреп була, ә!

—Барсы да сезнең кулда,—диде Тимергали битараф кына.

—Әлбәттә, минем кулда. Ә шулай да нәрсә дип менден анда, малайшалайдай булып?

—Ул—минем танк. Мин аның белән фашистка каршы сугыштым. Днепрны кичкәндә безне яндырдылар, танк шунда утырып калды, чөнки аны урынында гына ремонтларлык түгел иде... Соңыннан, ремонтлап, шушында китереп утырткаңнар. Тик кем утыртканын гына ачыклый алмадым.

Гаҗәп итте күсе күз, картның сүзләренә ышанмаганы күренеп тора иде.

—Именно синең танк икәнен кайдан беләсең, ничек таныдың соң?

—Номеры минеке, аннан күнелем сизә.

—Кызыңа шалтыратыйммы, әллә унбиш тәүлеккә ябып куйыйммы?

—Утыртсаң утырт, шалтыратма.

—Нишләп?

—Анда барыбер кайтасым юк.

—Ну, как знаешь. Менә кәгазь, ручка, бүтән анда менмим, и вопше, бүтән беркайчан да общественный порядокны бозмыйм, дип яз да кулыңны куй, числоны күрсәт.

—Башкортча язсам ярыймы?

—Русчаң хөртмени?—Өлкән лейтенант креслосында тураеп, сөякләрен шартлатканчы кулларын ике якка җәеп кирелде дә авызын зур ачып иснәде, шуннан йокылы тавыш белән:—Ярый, яз—диде канәгатьсез генә.—Дәүләт теле иттеләр дә,»русча белмим»гә сылтанып, башкорты башкортча, татары татарча язарга тырыша. Монда укый белгән кеше юк, русча кирәк дисән, алайса ни өчен башкорт телен дәүләт теле иттек, конституцион хокукны бозасыз, дип кенә җибәрәләр.—Монысын өлкән лейтенант әллә үзалдына сөйләнде, әллә аңа әйтте—Тимергали карт аңламады. Ни дип язарга белми озак хитланды танкист. Өлкән лейтенант янә бер-ике әйтеп кабаландыргач, шикәрдәй ап-ак кәгазь уртасына бер-берсенә ялганмаган, кәкре-бөкре эре хәрефләр белән өч сүз язды: «Башкача тәртип бозмам». Аска фамилиясен өстәде, числоны куйды.

Өлкән лейтенант кәгазьне алды да битараф кына күз йөгертте, шуннан: «Синнән нәрсә көтәсең инде»,—дигәндәй, кулын селтәде, кәгазьне калын

кенәгә арасына тыкты.

—Дүрт ягың кыйбла, тик бүтәнчә эләкмә, мин сине гел генә чыгарып утырмам,—диде усал итеп. Күсе күзләре картны, гүя, үтәли тишеп бораулады.—Төшенденме, танкист? Аннан, ул минем танк, дип саташма. Синеке түгел ул.

—Баскычны алырга ярыймы?

—Ярамый!—Өлкән лейтеннантның тавышында тимер зыны ишетелде.—Син әпәт менәргә чамалыйсынмы?

Карт җавап бирмәде. Борылды да авыр атлап ишеккә онгайлады. Үзе, котылдым шикелле, сонгы плацдарм әле исән калды, дип шатланды. Баскычы—ерунда, янадан эшләр дә алыр, монысы кыскарак та иде барыбер. Баскычын күргәч, шулай да җаны көйде: ничә көнлек хезмәте юкка чыкты хәерсез.

Көннәр тәмам язга авышты. Апрель туды. Кар башына житә торган әче жил исә.

Милициягә эләккәннән сон танкист атна чамасы подвалында кунып йөрде дә яна баскыч эшләргә булды. Кирәк тирәкне ега, ди. Бау, казакфәлән юллап, Үзәк базарга сугылды. Теләнчеләү, шешә карау теләге уенда да юк, бар теләге—баскыч юньнәтү.

Әмәлгә калгандай, каршында кинәт тагын теге ике йолкыш пәйда булды. Ике яктан кысрыклап, кеше бик йөрмәгән почмакка алып киттеләр. Карт: «Туктагыз, мин бит базар аша үтеп кенә барам», дип әйтеп-ялварып караса да, туктамадылар, сөйрәүләрен белделәр.

—Базар—безнең территория, нигә киләсең һаман, орденлы бомж?

Берсе эченә китереп сукты, икенчесе аягына типте. Авыртуга түзә алмый карт егылды. Тегеләр йөгерә-атлый качты. Тимергали карт байтак ятты да куйды кузгала алмый. Сызлану аралаш ул яныннан үткән кешеләрнен «алкаш», «бомж» дигәннәрен дә, «мескен, үлә бит» дип жәлләгәннәрен дә, «илне нинди чиккә китереп терәде бу житәкчеләр» дип төкеренгәннәрен дә ишетеп ятты. Жәлләсәләр дә, ачулансалар да, илне, ил житәкчеләрен сүксәләр дә аяк астында яткан карт берәдәкнең үз хәле—берәү дә ярдәм кулы сузмаячак. Бәвелә-чайкала калкынды да аксый-токсый атлап китте һәм подвалына көчкә барып ауды.

Ул, авыртынып-сызланып, берничә тәүлек ятты өенендә, кыты-мыты кимереп. Әзрәк хәл кергәндәй булгач, тагы баскыч әтмәлләргә тотынды. Урыс дусын ярдәмгә эндәште, икәүләп эшләделәр. Анысы танкистның шушы арада йончуын күреп бик пошынды. Эш беткәч, боек кына хушлаштылар, нидер сизенделәр...

Яңа баскыч әзер булгач, Тимергали карт подвалда булган бөтен киемсалымын төйнәде, ныклап күз бәйләнеп, урамда кеше өзелгәч, паркка табан атлады. Бу юлы бик өрекми атлады, тирә-ягына да каранмады. Тотып утыртып куйсалар да, әлеге ише тукмасалар да аңа барыбер хәзер. Эт көнендә яшәүдән арыды ул, бизде, гомумән, яшәүнең бер мәгънәсен дә күрми башлады, чөнки аның хәзер беркемгә дә кирәге юк: кызына да, җәмгыятькә дә...

Баскычын постаментка сөяде, зур гына төенчеген аркасына асты, кабаланмый гына менде (бу баскычын тап-таман гына итеп эшләгән икән). Люкны ачып эчкә төште, май шәмен кабызды, алып менгән кием-салымын таратып, кигәнен киде, кимәгәнен астына җәйде. Шуннан ятты. Ятуы булды—әллә көне буе авыртынып йөрүе, әллә аруы житкән иде—оеп та китте. Тагы төш күрде—анавы төшнен гыйбрәтле дәвамы. Ул йөгерә-чаба, әллә күпме танклар арасыннан үзенекен чак эзләп тапты. Иптәшләре дүрт күз белән аны көткән—ял вакыты беткән, кузгалырга боерык бирелгән.

Тимергали йөгереп килгән онгайга танкка сикереп менде. Игътибар итсә, танкларның номерлары төрлечә, аларныкы гына—«555»... Ә кияве, кияве генә дисең, хәрби комиссариаттагы капитан да, милиция өлкән лейтенанты да ышанмаган була, танкның үзенеке икәненә. Үзенеке, нәкъ үзенеке!..

Тимергали карт водитель урынына утырды. Машинаны кабызды. Гаҗәп, ул шундук дигәндәй кабынды. Бөтен приборлар да үз урынында һәм төгәл эшли. Двигательне бераз кыздыргач, иң түбән тизлеккә салып җай гына кузгатып карады, кузгалды, тик биек постаменттан машинаны ничек төшерергә соң? Җимертеп караганда? Һәм шулай итте дә Тимергали карт: танкны бер алга, бер артка биреп, тәүдә гусеницаны бәйләгән тростларны өздерде, аннан урынында гына бөтерелеп постаментны җимерергә тотынды. Бераздан таш, бетон ваклана, ватыла башлады, чит-читеннән зур гына берничә кисәк актарылып төште. Әйләндерә торгач, постамент тәмам какшады, нигезе җимерелеп җәелеп китте һәм танк әйләнгән көе таш, бетон өеме белән бергә җай гына аска шуарга тотынды. Тимергали икенче тизлеккә салды—танк алга ыргылды.

Карт иң беренче нәүбәттә кызы белән киявенә сугылырга булды. Йортлары янына барып, көбәкне аларның тәрәзәсенә терәп, радио аша: «Гөлсем, чык, бу—мин, әтиең»,—диде. Ярты минут та үтмәде кызы, аның артыннан мышнак кияве, Азат белән Руслан подъезд алдына чыгып та бастылар. «Әти, кайда йөрисең син?»—дип кычкырып җибәрде Гөлсем, еламсырап. «Ярар, артистланма!—диде Тимергали катгый гына.—Син минем өйне сатКансың икән. Кемнән сорадың?»—«Әти, гафу ит, мин....»—дип бутала кызы, ничек акланырга белми, яклау эзләп, кызы берчә иренә, берчә балаларына карый. Бәләкәй оныгы Руслан: «Әйттем мин сезгә, картәтинең танкы дип, ә сез ышанмадыгыз, әнә бит биш йөз илле биш саны!»—дип сөрәнли. Мышнак кияве аны үзенең артына яшерергә тырыша. Ә олы оныгы, Азат, гаепле төс белән читтәрәк тора һәм: «Картәти, сукканым өчен гафу ит, әнинең теге илле сум акчасын да мин алган идем, аның өчен дә гафу ит»,—ди елардай булып »Әти, әйдә керик өйгә»,—ди кызы, әмма Тимергали катгый баш тарта: «Юк инде, Гөлсем, әтиеңә мөнәсәбәтеңне күрсәттең, кермим, авылга кайтам, син саткан йортымны кире алырга кирәк»,—дип җаваплый. Танкын, урынында зыр әйләндереп, кирегә бора да хәрби комиссариатка юнәлә. Барып житкәч радиодан: «Унберенче кабинеттагы капитан хәзер үк монда чыксын!»—дип боера. Симез, йоп-йомры битендә күзе, танавы чак беленгән капитан пәйда була, әйтерсең Тимергалинең килүен көтеп кенә утырган. «Җиңү паркындагы танк чынлап та сезнеке икән. Гафу итегез, теге чак белми идем»,—ди капитан. Үзе бер честь бирә, бер кулын күтәрә. «Бу тыл комагын типкәләп китик, сугыштан качып утырып, ничек симергән»,—ди Кондратьев. «Яшәсен»,—дип җаваплый Тимергали һәм танкын кирегә бора. Юлда аны милиция бүлегенә тотып китергән ике яшь сержант очрый. Алар, таяктай катып, честь биреп торып кала. Бармак яный аларга танкист. Юл буе халык. Араларында милиция дә, хәрбиләр дә бар. Әмма аңа каршы чыгучы, туктарга кушучы юк, киресенчә, күпләр, теләктәшлек белдереп, кул болгый, көлә, шатлана. Кеше арасында Тимергали трамвайда карбызын баткан һәм ачуланып эченә төрткән чибәр хатынны, «шәһәрдә башкорт күбәйде» дип канәгатьсезлек белдергән ирне шәйли. Бер урам почмагында милиция өлкән лейтенанты честь биреп кала. Базар яныннан үткәндә аны берничә тапкыр тукмап, төенчек-токчайларын, орден-медальләрен тартып алган ике йолкыш тап була. Берсе җан-фәрман качарга тотына, икенчесе түш кесәсеннән Тимергалинең орден, медальләрен тартып чыгара. Туктый танкист һәм тегенең кулыннан наградаларын алып түшенә беркетә. Тимергали танкны авыл ягына бора. Тик иптәшләре туктата

да, юк, без синең белән бара алмыйбыз, кайтырга кирәк, дип төшеп кала. Танкист алар белән хушлаша. Ул ашыга, ана караңгы төшкәнче авылына кайтып житәргә кирәк. Шуңа да шәһәрне чыгу белән ул тизлекне күпкә арттыра. Ул юлда туры килгән авылларны урап уза, елгаларны кичә, тауларны үтә, куаклыклар, урманнар арасыннан юл яра һәм кояш баеганчы авылына барыбер дә кайтып житеп өлгерә.

Башнясына тиклем пычранган танкын капка алдына туктатты да, люкны ачып, байтактан бирле күрмәгән өенә, киртә-курасына карап торды. Болай бернәрсә дә үзгәрмәгән сымак. Ныклап кулы тияргә дә өлгермәгәндер Карам малаеның. Шуннан радиосын алды да: «Егет, чык әле, сүз бар»,—дип эндәште. Көттерми генә өйдән яшь ир килеп чыкты.

—Син нишләп минем өйдә торасың әле?—диде танкист катгый гына итеп.

—Нишләп дип, сатып алгач, торам инде.

—Аның бит хужасы мин!

—Гөлсем ападан, Тимергали бабай өен сатканны беләме, аның рөхсәте бармы, дип кабат-кабат сорадым...

—Гөлсемнең йортны сатарга хокугы юк иде. Ул сиңа миннән бернинди дә справка, ышаныч кәгазе алып килмәде. Шулай булгач, минем үз кулларым белән салып кергән йортымны кире алырга тулы хакым бар.

—Ә мин нишлим?

Егетнең тавышы көчсез генә чыкты, тирә-ягына карап, кемнәндер яклау эзләде.

—Ансын белмим. Әлегә әтиенә күч, аннан бирәр нәрсә уйларсың.

Тимергали, танк эченә төшеп, люкны шап иттереп япты да көбәкне өйгә төзәде—Карам малае тәүдә аның бу кылыгын аңламады, җыелып киткән кеше кычкырыша башлагач кына эшнең житди икәненә төшенде —калтыранып китте, нигәдер кулларын күтәрде, шуннан кинәт борылды да ишеккә ташланды. Күп тә үтми, аның булган бар мөлкәте чыгарылып бетеп, капка төбенә өелгән иде.

Тимергали танкын урынында гына йөз сиксән градуска борды да арты белән ихатага кертеп утыртты. Моторын сүндерде, чыкты, шлемын, комбинезонын салды, гимнастеркасындагы орден-медальләрен сыйпады. Кабаланмый гына төшеп, болдырына аяк басты, үз нигезен, үз тылын кайтарып ала алуына куанып, канәгать көрсенде дә: «Саумы, өем, мин кайттым! Моннан соң сине калдырып беркайда да китү юк»,—дип учы белән стенага сукты...

Чираттагы Жиңү бәйрәме алдыннан парктагы танкны буяу өчен ике кеше постаментка менде. Әлбәттә, агач баскыч ярдәмендә түгел, автокран мендерде. Шунда алар танк астында яткан баскычка, арканга игътибар итте. Аптыраштылар да, танк өстенә менеп, люкка күз салдылар. Гажәп, сварка белән ябыштырылган урыны актарылган! Буяучыларның берсе, куркып кына, люкны күтәрде, икенчесе үрелеп эчкә карады. Карады да, коты алынып, башын тартып алды. Бераздан икәүләп башларын тыктылар һәм шундый күренешкә шаһит кылдылар: эчтә куллары белән рычагларга нык ябышып, жансыз күзләрен туры, чал башын горур тотып бер карт утыра иде...

♣

# ХӘЗЕРГЕ ХИКӘЯ

*Инде хәбәр иткәнебезчә, редакциядә әдәби тәнкыйтьчеләр һәм язучылар катнашында «Хәзерге хикәя» дигән темага «түгәрәк өстәл» сөйләшүе булып узды. Сөйләшүгә юнәлеш бирү өчен түбәндәге сораулар куелган иде:*

***1. Хикәя жанрының соңгы еллардагы уңышлары нәрсәдә?***

***2. Соңгы еллар хикәяләренә нинди типик җитешсезлекләр хас?***

***3. Бу жанрны ничек үстереп була?***

*Түбәндә кайбер чыгыш ясаучыларның фикерләрен урнаштырабыз.*

**Рифат СВЕРИГИН:**

1. Безнең әдәбиятта хикәяләрнең, бигрәк тә хикәя-новеллаларның, матур үрнәкләре бар. Вакыт ягыннан алар күбрәк узып киткән егерменче гасырның төрле чорларына карыйлар. Заманында Шәриф Камал, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Аяз Гыйләҗев, Рафаил Төхфәтуллин, Мәгъсүм Хуҗин иҗат иткән хикәяләр әдәбиятыбызның алтын фондына гына түгел, күңел түрләребезгә, хәтерләребезгә дә кереп урнаштылар. Бу күркәм эшне лаеклы рәвештә дәвам иттерергә омтылучы талантлы хикәячеләребез бүген дә бар. Мәсәлән, Фәнис Яруллин, Айдар Хәлим, Радик Фәизов, Камил Кәримов, Нурислам Хәсәнов, Фәрит Яхин кебек әдипләр бер-берсен яисә башкаларны һич тә кабатламыйча, классик хикәя традицияләрен яисә казанышларын бүген дәвам иттерәләр, үстерәләр һәм хәтта үзләренчә камилләштерәләр дә.

Гадәттә чын хикәя-новелланың ачык беленеп торган төше, үзәге, «йөзем җимеше» була. Хикәяләрнең кайберләрендә бу үзәк әсәрнең тукымасына сеңә, шунда эреп, тарала. Кайчагында ул кабатланмас әдәби деталь рәвешендә тик бер мизгелдә генә күренеп ала һәм хикәя өстенә нур көлтәсе сибә—әсәрнең төп фикер-мәгънәсен көтелмәгәнчә, яңача ачып җибәрә—гүя эстетик энергия үзенең куәтле киеренкелеге-вольтажы белән синең зиһенеңә, акылыңа суга һәм син әле генә, хикәянең алдагы өлешендә укыганнарыңны да яңа яктылыкта, башкача аңлый башлыйсың. Мәсәлән, мондый алымның мисалларын Әхәт Гаффар хикәяләреннән табып була («Коелы өй», «Энә күзе» һ.б.лар).

Язучы Айдар Хәлим исә героеның һәм укучысының башыннан үткәннәренең хикмәтле, мәгънәле якларын таба, төрле халәт, мизгел, күренешләрне үз төсләре, тавышлары, моңы, яңгырашы, төсмерләре белән ала һәм аларны үзенчә яңарта, үзебезнең дә күңел хатирәләребезне, истәлекләребезне дә кузгатып, җитди һәм олы тормыш фәлсәфәсенә юл ачып җибәрә («Кыйбла», «Кылганнар чәчкә атканда», «Трофей ашъяулык» һ. б.)

Фәнис Яруллин, Радик Фәизов, Мансур Вәли-Баржылы, Фәрит Яхин кебек хикәячеләр үз әсәрләрендә тормыш вакыйгаларын һәм күренешләрен төгәл һәм эзлекле итеп сурәтләргә тырышсалар, Рифә Рахман, Рәмзия Габделхакова кебек әдибәләр үз күңелдәгеләрен укучыга гына түгел, геройларының, бигрәк тә героиняларының төп-төгәл рәвешләрендә үзләренә дә аңлашылып җитмәгән чуар психологик халәт айкалышларын, фәкать хатын-кыз логикасы аша гына хәл ителерлек сюжет мажараларын кызыклы хикәяләргә әверелдерәләр (соңгы автордан

кайбер мисаллар: «Бер микъдар былбыл», «Чәчәктә кайткан яз», «Судан тапкан йөземнәр», «Китмә!!!»).

Гомумән, хәзерге татар хикәяләренең диапазоны бик тар түгел. Эшләнешләре ягыннан караганда, аның бер тармагы гадәти новеллаларга тартым булса, икенчесе һәртөрле вак этюд- парчаларга, эчтәлеге-пафосы ягыннан лирик, юмористик язмаларга килеп тоташа. Икенчесенә аз гына тукталып үтик: Фәнзаман Баттал, Тәлгат Нәҗмиев, Алмаз Хәмзин кебекләр беркайчан да күләмле жанрларга үрелмәделәр, хәтта гадәти хикәя кысалары да аларга артык киң булып тоела. Әмма кечкенә, мобиль жанрларның да үз сыйфат югарылыгы, биеклекләре барлыгын истән чыгармыйк.

Фәнзаман Баттал, сарказм катнаш ирония тарафдары буларак, заманның көнкүреш хәлләрен бар ваклыкларына кадәр күрсәтә белсә, Алмаз Хәмзин төп игътибарны сәхнәгә чыгып сөйләрлек, хәтта жырларлык күренеш-монологларга юнәлдерә. Ә Тәлгат Нәҗмиев тормышта тик үзе күргән, үзе белгән конкрет кешеләрне генә, ул очракта да тик ил-күз каршында танылганнарын гына алып, шуларның биографияләрендәге көлкеле яисә аеруча истә калырдай вакыйгалар, фактлар тирәсендә миниатюр сюжетлар оештыра, оста юморист Тәлгат Нәҗмиевнең геройлары бу әсәрләрдә тормыштагы үз исемнәре, характер сыйфатлары, хәтта үз килеш-килбәтләре белән йөриләр, катнашалар, төрле көлкеле хәлләргә юлыгалар. Әмма автор шәхеснең абруена зыян китермичә генә көлә белә—бу хикәячекләр рәсем сәнгатендәгечә, шартларны да хәтерләтәләр—алар яшь кактус энәчекләредәй, аз гына чәнечкәндәй итсәләр дә, прототипларга яисә аларның якты истәлекләренә тап төшермиләр—киресенчә, бу аларны хөрмәт итүгә яисә яратып искә алуга тин.

2. Төп эшкә хикәянең табигатен, хасиятләрен аңлап житкермәү комачаулый—кайберәүләр теләсә нинди вакыйга да хикәягә нигез була ала, шул турыда ничек язсаң да, хикәя туа дип уйлыйлар, ахры. Шуңа күрә, кулына каләм алган һәркем, әгәр шигырь язмаса, хикәягә тотына. Менә шуңа күрә матбугатта хикәя исеме белән дөнья күргән язмалар бихисап, әмма чын хикәя дип саналырдайлары бик аз.

Моның шулай икәнлеген 2007, 2008 елларда журналда үткәрелгән хикәяләр конкурсы да раслады. Бер яктан, ул хикәяләренең саны күплеге белән шаккатырса (ялгышмасам, конкурска йөзләп хикәя килгән иде) икенчедән, жанрның гүзәл традицияләренә тугрылыкны саклаган хәлдә, аның яңа мөмкинлекләре турында сөйләрлек, яңа ачыш булырдайлары бик аз иде. Жанрның төп критерийларына жавап бирерлеклеген сайлап алу да, жинүчеләрне билгеләү эше дә шактый кыен булып чыкты.

Жанрның тәгаен чикләрен билгеләү, ачыклау да бүген кыенлаша бара—хикәябезнең ярлары картаеп, камыш басып, баткаклы сазлыкка әйләнеп баручы күл читләрен хәтерләтә. Ә элеккеләре дала уртасындагы түгәрәк көзгедәй ялтырап ята торган матур күлләр иде. Бүген исә, классикларыбыздагыча, айлар-еллар үтсә дә, исемен әйтүгә сюжеты-вакыйгалары, идеясе-барлыгы, геройлары жанлана, күз алдына китереп, искә төшерердәйләрен табуы жинел түгел.

3. Хикәя жанрының мөмкинлекләре гаять зур. Тик бу өлкәдә эшләүчеләребез моңарчы күргән-белгәннәре белән генә чикләнмичә, тормыш казанында ныграк кайнап, тема-сюжетларын да шуннан чумырып алсыннар иде.

О Генри, Эдгар По, Голсуорси, Сомерсет Моэм, А. П. Чехов, А. П. Платонов кебек дөнья классиклары тудырган хикәя, новеллаларның иң матур үрнәкләре белән якыннанрак танышып, шуларны үз әсәрләре белән янәшә куеп карарга гадәтләнсәләр дә бик әйбәт булыр иде.

**Халисә ШИРМӘН:**

Соңгы еллар татар прозасына без тәнкыйди карарга гадәтләнеп киләбез, хәтта прозаны сүгү модага кереп китте кебек. «Проза «телсез» калды, композиция матурлыгы югалды, унай геройлар күнел кайтаргыч» дип тәнкыйтьлибез. Уйлап караганда, «проза» төшенчәсе шулкадәр киң бит ул: монда никадәр төре булган роман жанры да, повесть-бәяннар да, хикәя-әдәби очерк-эссе-новеллалар да карый. Барысы да начар булып бетә алмый ич инде! Мина калса, хикәя жанры Әмирхан

Еники, Фатих Хөснииләр заманыннан ук үзенең бөтенлеген, матурлыгын саклап килгән жанр ул. Хикәя язуга авторлар да бик житди карыйлар, чөнки язманың һәр бите, һәр юлы укучының күз алдында; биредә, роман яисә повестьтагы кебек, «әсәремнең башында нәрсә яздым икән?» дип уйлап утырасы юк. Шаяртам, билгеле, шулай да жанрның кыскалыгы осталык таләп иткәне аңлашыла. Татар хикәясенең соңгы еллардагы уңышлары санның да, сыйфатның да артуы белән куандыра, минемчә. Талантлы хикәя осталары үсеп чыкты, яңа исемнәр барлыкка килде, китап киштәләре яңа хикәя китаплары белән баеды. Алар арасыннан аерым бер исемне атау кыен, чөнки бер авторның тел матурлыгы күңелгә хуш килсә, икенчесенең конфликт барлыкка китерү һәм чишү осталыгы, өченчесенең баш әйләндерерлек композицион төзелеш коруы гажәпкә калдыра... Үзем бик яратып укыган берничә авторны әйтеп үтәсем килә. Г. Гыйльмановны без зуррак жанр остасы буларак кабул итәргә өйрәнгәнбез, тик аның хикәяләре дә («Ана сүзе», «Әрем исе», «Күңел күзең күрәме?», «Гомер эзләү» һ. б.) һәр яктан күңелне кузгатырлык. Рәмзия Габделхакова хикәяләре көчле лиризм белән сугарылганнар. Бер караганда, тормышта һәркөн кабатлана торган гади ситуацияләр, тик шулар арасына Рәмзия ханымның гына күзенә күренгән бик нечкә төсмерләр килеп керә дә, күңелне чеметеп ала... Камил Кәримовның әле жинелчә юмор белән сугарылган, әле йөрәкне сыздырырлык моңсулык өртелгән хикәяләре хәтергә уелып кала. Ә менә «Сары йортлар сере» белән татар прозасына бәреп кергән Марат Кәбировны мин «виртуаль язучы» дияр идем. Бүгенге яшьләрне китап укытып карале син! Кем әйтмешли, тау Мөхәммәд янына килергә теләмәсә, Мөхәммәд тау янына барыр ди. Бөтендөнья интернет челтәре аша ниндидер бер итальян яки бразилияле белән «Unrea Tournament» уены уйнап яткан татар малае Марат Кәбиров сайтына элэгә һәм «maratkabirov. com»да эленгән романнарның исемнәреннән генә дә («Параллель дөнья», «Чиксез табут», «Хөрмәтле мәет әфәнде», «Бердәнбер һәм кабатланмас», «Убырлар уянган чакта») башы әйләнеп китә! Болар барысы да татар телендә ич! Рей Бредбэриларың бер якта торсын! Укыган өчен акча түлисе бар анысы, шулай да, нихәл итәсең, «нык үскән капитализм» заманында яшибез бит... Рухи ризыкны бушка бирмиләр... Романнарына караганда, Марат Кәбировның хикәяләре миңа күбрәк ошый. Проблеманы куя белү, чишә белү, психологизм, конфликт барлыкка китерә белү осталыгы белән ошыйлар.

2. Безнең дөнья ихтыяж кануннары буенча яши, моны хәтта коммунизм классиклары да кире кага алмадылар. Ихтыяж—без яшәгән заманның да төп кагыйдәләренең берсе. Ихтыяж булса, әсәрләр укыла, ихтыяж булмаса—укылмый. Ә ихтыяжны булдыру өчен һаман да шул заманнан артта калмаска кирәк. Хәзерге заман кешеләрен нәрсә кызыксындыра? Нәрсә турында укырга телиләр алар? Дөнья халыклары «Код да Винчи»ны укыйлар икән, димәк, татар халкының да шуны алыштыра алырдай әсәре булырга тиеш. Марат Кәбиров, бу яктан караганда, яңа тип язучы буларак, жилнең каян искәнен яхшы чамалый. Әдәбият—хис дөньясы. Көчләп яраттырып булмаган кебек, укырга теләмәгән китабын кешедән көчләп укытып булмый. Темаларның саегуы да, бәлки, шуңа бәйледер. Безгә үзгәртеп кору чоры алып килгән рухи ярлылыктан чыгу өчен әле тагы күп еллар кирәк булыр...

Прозаның, димәк, хикәянең дә төп кимчелеге итеп, тел ярлылыгын күрсәтәләр, хәзерге проза әсәрләре сөйләп бирүгә корылган, диләр. Анысы шулай, ләкин хикәянең нәрсә икәнен аңлаткан әдәби сүзлекләрнең барысында да хикәя «сөйләп бирүгә корылган кече эпик жанр» дип күрсәтелә! Димәк, телибезме, теләмибезме, сөйләп бирергә туры килә. Ә. Еники, Ф. Хөсни хикәяләре дә сөйләп бирүгә корылганнар. Тик тел аерыла шул. Марат Кәбировның хикәясендә өч сүздән торган жөмләләр саны егермегә житсә, Ә. Еникинең хәтта саф диалогка корылган «Яшьлек хатасы» хикәясендә дә уннан артмый. Мин Марат Кәбиров хикәяләренең теле ярлы дип әйтергә теләмим, киресенчә, урыны-урыны белән ул искиткеч сурәтләү осталыгы күрсәтә. Аның хикәяләренең теле сюжетка, ягъни автор барлыкка китергән вәзгыятьнең киеренкелегенә бәйле. Гомумән, теләсә кайсы әсәрнең тел төзелеше сюжетка тыгыз бәйләнә. Шулай да матур әдәбият теленең югары формасы (классик татар әдәби теле) бетүгә таба баруы һәркемгә билгеле, минемчә. Дөньяда хөкем

иткән прагматиклык әдәбиятка, сәнгатькә көчә. Бәлки, бу вакытлы күренештер. Бәлки, йөз-ике йөз елдан соң әдәбият-сәнгать үзенен тәхетенә янадан утырыр. Тарихта Янарыш чоры (Ренессанс) булган бит!

Прагматиклык язучынын тормышына да тамыр җәйде. Урта яшьләрдәге профессиональ язучыларыбыз (ягъни, өйдә утырып, бары иҗат эше белән генә шөгыльләнә торган язучы) юк икәне беркемгә дә сер түгел. Мондый хезмәт белән гаиләне туендырып булмый. Димәк, эш эзләргә туры килә. Гадәттә күпчелек язучыларыбыз—журналистлар, редакция хезмәткәрләре. Газета-журнал өчен языла торган мәкаләләрнен теле матур әдәбият әсәрләре теленнән аерылырга тиеш, әлбәттә, ләкин аларны бер үк кеше яза бит! Шул рәвешле, публицистика жанры матур әдәбиятка үтеп керә һәм тел фәкыйрьлеген китереп чыгара...

3. Яшьләрне укытырга, өйрәтергә кирәк, минемчә. Тукай әйтмешли, «Картаеп каткач буыннар, эш белү унайсыз ул.» Хәзерге язучылар үзләренә тин алмаш әзерләү турында уйланырга тиеш. Кызыклы әнгәмәләр, дәресләр, кичәләр оештыру мөмкин ич! Безнен яшьләр үзләре башлап йөриләр, аларны бары кузгатып җибәрергә генә кирәк! Секциянен күптән түгел булып узган бер утырышында классикларыбызнын тавышы-кинәшләре язылган тасманы бергәләшеп тынладык. Күнелләргә искиткеч тәэсир итә! Язучылар берлегенен яшьләр катнашында үтә торган утырышларында шундый язмаларны тынлау гадәткә керсә яхшы булыр иде.

Әлбәттә, кызыксындыру чаралары да булырга тиеш. Русларда әдәби иҗат кешеләренә генә бирелә торган уналты премия бар, кайберләренен күләме өч миллилион ярым сумга житә диләр. Бездә дә премияләр аз түгел, тик алар аерым номинацияләрне күздә тотып бирелсә (әйтик, ин матур телле яисә ин кызыклы композицияле әсәр), файдалырак булыр иде, минемчә.

Әйтергә теләгән сонгы сүзем шул: хикәя жанрын үстерүнен ин кулай юлы—язарга, язарга һәм язарга!

**Рафаэль МОСТАФИН:**

Хикәя жанры сонгы елларда кризис кичерә. Ә. Еники, Ф. Хәсни, Р. Төхфәтуллин хикәяләреннән сон жанрнын саегуы аеруча нык күзгә ташлана. Әлбәттә, хикәяләр бөтенләй юк түгел, алар әледән-әле басылып тора. Араларында матур-матур хикәяләр дә очрый. Әмма тулаем алганда аларнын дәрәҗәсе шактый төште.

Сонгы берничә елда басылган хикәяләр арасында Мәгъсүм Хужин хикәяләре аерылып тора. Аларда тормыш дөреслеге бар. Алар телнен байлыгын, эчке бер мон булуы белән күнелне җәлеп итәләр. Менә, әйтик, «Казан утлары»нын 2008 елгы 5 нче санында басылган «Ипи. Колын. Без» хикәясе. Монда мин искиткеч тирән мәгънә күрәм. Автор гади авыл малае язмышы аша илебездә барган социаль үзгәрешләрне бик оста итеп тасвирлый. Без гаепсезгә кулга алуларны, халыкнын жиргә мәхәббәтен, телен, милли үзенчәлекләрен югалтуны күрәбез. Анын сәбәпләре турында уйланабыз. Болар барысы да бик тәэсирле итеп күрсәтелгән.

Сонгы елларда «Казан утлары»нда басылган хикәяләр арасында Вакыйф Нуриевнен «Кара бишмәт» хикәясе дә бик матур тәэсир калдырды. Бу хикәядә лирик жылылык, эчке бер мон бар. Хәер, бу хикәя турында Нәкыя ханым Гыйлажева матбугатта язып чыкты инде. Мин анын фикерләре белән тулысынча килешәм.

Журналда даими басыла башлаган «Тормыш язган хикәяләр» дә игътибарны җәлеп итә. Аеруча мина охшаганнар арасында—Нәүфәл Хәмидуллиннын «Кабер казучылар»ы. Монда тормыш чынбарлыгы да, ачы ирония, сарказм да бар.

Үз юлын Тәлгать Нәҗмиев тә тапкан. Ул бик кыска формада тормыш үзе тудырган мәзәкләр турында яза. Бер караганда, бу язмаларнын эчтәлеге сай, мәгънәсе юк кебек тоелуы мөмкин. Әмма аларны укыганда ихтыярсыздан елмаясын. Һәрхәлдә, аларны укуы күнелле.

**Рифә РАХМАН:**

«Казан утлары» журналы сонгы елларда сан ягыннан кискен артып киткән хикәя жанры хакында «түгәрәк өстәл»не бик вакытлы оештырды. Әлеге үзгәрешләр форманын арифметик артуы гына булып калмады, сыйфат ягыннан да күзәтелде.

Хикәя—милли тел матурлыгын сакларга, аеруча ачык күрсәтергә ярдәм итүче жанр дип саныйм. Бәхетебезгә, хәзергә заманыбызның сөйләмебезгә салган зыяны анда азрак чагылыш таба, шуңа да карамастан прозабызда барган телгә бәйле кайбер артка чигенешләр аерым авторлар иҗатында ачык күренә.

Хәзер хикәя язучылар зур бер авырлык алдында торып калды. Татар кешесе шәһәргә күчеп бетеп барган шартларда аның теле рус алынмалары белән кирәгеннән артык чуарланды, хәтта ки гомер бакый авылда яшәгән агай һәм апалар, әби-бабайлар арасында да чиста сөйләм гадәттән тыш бер күренешкә әйләнде. Алай гына түгел, үз сөйләмнәрен русча-татарча җөмләләрне аралаштырып төзегән авыл балалары барлыкка килде. Бу инде—телгә яраклаштырылмаган алынмаларның артуыннан да куркынычрак бер хәлдер. Яшьләрнең сөйләме ярлыланды, тар даирәнекенә (сленгка) әйләнде. Әлеге сөйләмне ничек хикәядә бирергә? Мин еш кына югалып калам һәм шунлыктан балачактан күреп үскән хәлләрне тасвирлауны хуп күрәм.

Икенчедән,татар гаиләсе, татар тирәлеге чуарланды. Катнаш гаиләләр тормышын ничек чагылдырырга? Рус-татар мохитен, ике милли тел сөйләмен кертеп, ничек тудырырга? Роман-повестьларда бу җиңелрәк. Шигырь һәм хикәя кебек нәзберек һәм кече күләмле жанр формалары алынма сүзләрне, бигрәк тә килделе-киттеле геройлар диалогын бик авырдан кабул итә. «Милли үзаңны чагылдыру да формалаштыруда, реаль тормышны чагылдырган әсәрләр генә булыша» дигән караш тарафдарларына менә миндәйләргә нишләргә? Үз принципларына каршы барып, җитмешенче елларга исән-имин килеп җиткән, бик нык камилләшкән, әмма үзгәртеп кору чорында чынбарлыкта яшәүдән туктаган тел белән язаргамы, заманчасына күчәргәме, әллә инде алтын урталыкны табаргамы? Сөйләмнең герой характерын чагылдыруын күздә тотсак, бик кыен очрак килеп туа. Болай да прозабызда дүрт сыйныф белемле геройлар, кеше үтерүчеләр галимнәр теле белән сөйләшә, аларча фикер йөртә яисә кирәгеннән артык төчеләнә. Әгәр дә инде тискәре» үзгәрешләргә юл биреп, заман теле белән иҗат итәргә тотынсаң, берничә елдан синең әлегә татарча дөрес сөйләшкән, телен яраткан укучың да «чирмешчә» сөйләшә башлар һәм әдәбиятыбыздан бөтенләй үк баш тартыр.

Темага бәйле проблемалар да бар. Бүгенге көндә татар хикәясенә шәһәр тормышын чагылдыру житми дибез икән, аның бер сәбәбе әлеге дә баягы тел проблемасына барып тоташа. Шәһәрдә яшәүче татарга авылның үткәне турында язуыбыз, бер яктан, яхшы да. Милли хисне тәрбияләрлек материал житәрлек һәм нәкъ менә шул җирлектә күп тә ул. Икенче яктан, без шәһәр тормышыннан шул хисне үтерерлек күренешләрне табып алып кире кагарга бурычлы, замананың кеше рухына зыян салырлык якларын бүгенге укучыга ничектер ачарга тиеш.

Шул ук вакытта шәһәр чынбарлыгын тасвирламауның башка сәбәбе дә бар. Кешеләрнең тормышы анда яшәгән тораклары кебек үк шактый охшаш. Аның хәтта вәхешлеге белән имәндергән, көн дә кич «Эфир» программасы күрсәткән күренешләре дә бер-берсенә тартым. Күп ишеткән саен күнел ката бара, ә менә авылның кечерәк кенә вакыйгасы да уйга сала. Авылда тугангамы, анда кайткач, яшәү һәм үлем, узган һәм киләчәк, ата-баба, милләт турында күбрәк уйланасың, аның суларын эчеп сафланасың, яшәүгә өмет аласың, әмма тагын авыл тарлыгыннан шәһәргә качасың. Язучының, ул иҗат иткән геройның шушы ике арада бәргәләнүләре хикәя формасында да чагылыш таба башлады. Без кайчандыр авылдан шәһәргә күчкәндә урталыкта торган каһарманнарны бөтен нечкәлекләре белән бирсәк, аның социаль статусын үзгәртүен уңай дип карасак, хәзер бу мәсьәләне бөтенләй башкача чишәбез.

Әдәбиятка яшьләр килә башлады. Аларда да шәһәр балалары тормышы тасвирлана, әмма берьяклы, сюжетлар гади, ярлы һәм охшаш. Бу да алар яшәгән шартлар белән аңлатыла. Тора-бара, тәҗрибә туплагач, яшьләребез бу киртәне узар дип уйлыйм. Әлеге яшьләр, башкалардан ишеткән вакыйганы тасвирлагыз әле, дигәндә, шактый кызыклы гына әсәрләр язалар. Димәк, бүген әдәбиятка килүче яшьләр киләчәктә хикәя жанрын лаеклы дәвам итәрләр дигән өмет бар, чөнки каләмнәре йөгерек һәм көчле.

Моннан тыш шул да сөендерә: әдәби мәйданга ныклап аяк басып килүче яшь

буыннын ясалма сюжетлы әсәрләрендә дә әдәби эзләнү омтылышы чагыла, ә менә инде әдәбиятка ия кайбер ир язучыларыбызнын хикәяләре, реалистик әдәбият булырга дәгъва белдерсәләр дә, хыял җимеше яисә артык нык үзгәртелгән тормыш вакыйгасы сыман. Мине, мәсәлән, андый әсәрләр җәлеп итми.

Җәлеп итү дигәннән, хикәя, гомумән алганда, сиксәненче еллардагы биеклегеннән нык күтәрелде, әмма истә калырлык әсәрләр бармак белән санарлык кына. Барлык матбугат органнары да хикәя конкурслары уздырды, яратып укыган әсәрләр дә бар иде кебек, нәрсә хакында иде алар—әйтә алмыйм. Ин кызыгы шул: минем күзлектән караганда, конкурсларда катнашырлык түгел кебек әсәрләрнен эчтәлекләре дә истә калган.

Мине сөендергән күренешләрнен берсе хатын-кыз хикәясенен, повесть һәм романнардан аермалы буларак, укучы тарафыннан ир-атларныкына караганда җылырак кабул ителүе. Үзем, мәсәлән, Р. Мулланурова, Ф. Җамалетдинова, А. Әхмәтгалиеваның әсәрләрен бик рәхәтләнеп укыйм. Хатын-кызларыбыз кешеара мөнәсәбәтләрне тирәнрәк һәм нечкәрәк ачалар, милли әхлак, гаилә турында уйландырырлык әсәрләр язалар. Әлбәттә, җитешсезлекләр хатын-кызлар прозасына да хас. Яшь тәнкыйтьчеләр белән анализ ясау, мәсәлән, конкурсларда гел урыннар алып килүенә карамастан, Рәмзия Габделхакованын кайбер хикәяләрендә сюжет логикасы аксаганы, мотивлаштыру җитмәүне күрсәтте. Анын каравы ул кулланган тормыш материалы шактый бай, уку өчен кызыклы. Әсәрләре теле һәм идея эчтәлеге белән авторның кайда яшәгәнлеген, кайсы социаль төркемгә хас фикерләвен ачык күрсәтеп тора.

Ир-атларның кызыклы, актуаль проблемалы, оста тел белән язылган публицистик язмаларына, күләмле әсәрләренә бихисап мисаллар китерә алам, «кайсы ир-ат прозаикнын кайсы хикәясе бик ошады» дигән сорауга кистереп кенә җавап бирү кыен. Кайбер ир-атларыбызнын прозасында күнелгә ятмаган әйберләр күбрәк. Ясалма сюжетлардан тыш, тел ясалмалыгы... Тагын бер нәрсәне әйтми калдыра алмыйм. Ир-атларыбыз иҗат иткән хатын-кызлар еш гаҗәпкә калдыра, бу бит күлмәк кигән ир кеше: ул ирләрчә уйлый, ирләрнен безне ярым-йорты аңлауларын чагылдыра, дисен. Шул ук вакытта алар прозасы милләтне яшәтүне, милли үзанны уятуны максат итеп язган әсәрләргә бай. Бу очракта А. Хәлим, З. Зәйнуллиннар прозасын күздә тотам.

Кыскасы, без гаиләдәге кебек, хикәя авторлары буларак та, бер-беребезне тулыландырабыз. Бу чыгышны йомгаклап, тагын шуны әйтәсе килә: сан һәм сыйфат үзгәрешләре кичергән хикәянең әдәби классика киштәсендә урын алырлык әсәрләр сыйфатына ешрак ирешүен телим. Хикәягә нибары шул җитми. Әмма хикәя үсе бар һәм булачагына шик юк. Классик хикәяләр сандыгыбыз тагын да баер әле дигән өметем дә көчле.

**Флюра НИЗАМОВА:**

Хикәя яза белүчеләргә сокланам да, көнләшәм дә. Чөнки хикәя, сиземләвемчә, повесть яки романга караганда да авыррак жанр, аны чын оста гына яза ала. Хәер, әлегә оста прозаик дип аталмаган язучылар арасында да менә дигән хикәячеләр очрап куя. Күрәсен, бу—талант эше, Ходай Тәгалә бүләгедер инде. Менә, мисалга, заманында, моннан егерме еллар элек, филология факультетларына аяк та басып карамаган Зөлфәт Хәкимҗанов әдәбиятка бер кочак сатирик хикәяләре аша килеп керде. Кем өйрәткән аны язарга? Ә бит Зөлфәтнен хикәяләрен газета-журналлардан эзләп табып, кырылып укыдылар! Күп хикәяләрен артистлар үз репертуарына алды, сәхнәләрдән сөйләп йөрделәр. Дөрес, хәзер Зөлфәт Хәким инде хикәяләр язмый, ахры, ул эрерәк жанрларга—романга, драматургиягә күчте...

***

Гаҗәп хәл: бүген хикәя жанрында хатын-кыз авторлар алга чыкты. Гөлчәчәк Галиева, Нәҗибә Сафина бу жанрда уңышлы эшлиләр. Бүген ике хикәячене аерып атап үтәсем килә: болар—Рәмзия Габделхакова һәм Фирүзә Җамалетдинова. Икесенен дә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан проза җыентыклары

бар, китапларында төп урынны хикәяләр алып тора. Һәм ике ханымның да хикәяләре бер сулышта укыла. Гәрчә бу ике язучының стиле, аһәңе бер-берсеннән нык аерыла.

Фирүзә Жамалетдинова—иң элек шагыйрә, берничә уңышлы шигъри җыентык авторы. Шуңадыр да, хикәяләре дә пафослырак, шигърирәк тел белән язылган. Әйтик, менә Фирүзәнең «Таш чыгаручы», «Эш тәме» хикәяләрен алыйк. Икесе дә эштән тәм табып яшәүче, кешеләргә шатлык китереп яшәүче картлар турында. Берсе өлгергәннәрен генә сайлап, су төбеннән таш чыгара. Шул ташларны ватып, мунча ташына тилмергән кешеләргә бик аз гына хакка сатып бирә. Ана алмашка яшьлегеп Себер ягында, шахтада эшләп үткәргән ир кайта. Картның да, ирнең дә хикәядә исемнәре юк. Һәм моның әлләни әһәмияте дә юк: автор аларны ниндидер фәлсәфи биеклеккә күтәрә, карт белән ир—игелекле эшнең дәвамчыл булырга тиешле икәнен күрсәтүче символлар гына кебек. Бу үзе үк шигырьгә, поэмага хас гомумиләштерү алымы. Икенче хикәясендә дә—«Эш тәме»ндә Фирүзә Жамалетдинова үзенә кушылмаган, артык эш эшләп үзенә рәхәт табучы урам себерүче агайны сурәтли. Бу юлы агайның исеме бар—Галимулла. Хәер, аңа исем бирмәсә дә, хикәянең бер чите дә кителмәячәк: бу юлы да язучының геройлары—балаларга бозлавык өстендә комнан кар бөртекләре ясаучы, чүп савытларына төрле сурәтләр төшерүче агай белән бер юлдан йөрүче түрә, вахтер егет, урам себерүченең эшенә бәя биреп торучы карчыклар, матурлыкка сокланучы балалар—исемсезләр. Бер хикәя канвасына (тукымасына) җыелып, алар, бергәләшеп, урам себерүченең хезмәтен ниндидер кул җитмәс югарылыкка күтәрәләр. Бусы да шигърият хасияте. Арада бер хикәя, «Васыять» исемлесе бүтәннәреннән аерылып тора. Татар авылына сугыштан иренә ияреп кайткан Мария хакында гынамы бу хикәя? Кыска, җыйнак тел белән язылган әлеге әсәрендә язучы Мария—Мәрьямнең, татар хатынына әверелеп беткән хәлендә дә, идән астына төшеп, үз диненә хас йолалар белән яшәвен сурәтли дә, аны табигый үлеменә китереп җиткерә. Баксаң, Мария үзен күрше авылдагы урыс-чуаш зиратында җирләргә дип васыять әйткән икән. Әгәр хикәя шуның белән тәмамланса, әллә ни сискәндермәс тә иде. Гаҗәп түгел—христиан хатыны ич аның Мәрьяме. Юк шул, болай гына бетми әле. Күрше авылга Мария—Мәрьямне илтеп, җирләр кайтып килүчеләрнең машинасына буранлы юлда егет белән кыз очрап утыра.

«—Син Гарифулла малае, әйеме?—диде картларның берсе.

—Әйе.

—Кыз кемнеке?

—Анысы килен була инде,—диде егет.—Исеме—Мария. Кайткач, никахка керерсез.—Егет кош тоткандай елмайды...»

Һичбер төрле үгет-нәсихәтсез генә, татар авылының фаҗигасен ача да бирә язучы.

***

Әнә шулай... Нәкъ шушы тәмамы өчен язылган бу хикәя... Кыскасы, шигырьләрдән прозага күчеп, Фирүзә Жамалетдинова үзенчәлекле яңа хикәяче барлыгын исбат итте...

***

Рәмзия Габделхакованың «Көмеш төн»ын сатып алырга мине бу авторның элегрәк газетадан укыган бер хикәясе этәрде. «Кәлүшле кыз» исемле хикәя иде ул. Шундук истә калды, авторның исем-фамилиясен хәтер сандыгына салдырып куйды. Һәм менә Рәмзия ханымның ике ел элек чыккан китабын йотылып укып чыктым. Бусы—бөтенләй бүтән стильдә язучы автор. Кырыс-җыйнак хикәяләү, сукмак-тыкрыкларга кереп буталып йөрмичә генә, сурәтләнәсе хәл-вакыйганы, тәлинкәгә салып дигәндәй, укучы алдына китереп куя ул. Хикәяләвендә һичнинди купшылык, бизәкләр юк—һәммәсе гап-гади, тормыштагыча чып-чын. Бик табигый диалоглар, тел төгәллеге һәм сюжет аныклыгы хас Рәмзия ханымга. Ә төп үзенчәлеге—һәр хикәя ахырында автор үз героена тиешле җәзасын йә рәхмәтен бирә. Хәтта тормышта еш кына алай булып чыкмаса да, әлеге хикәяләрне укыгач, гаделлекнең барыбер

җинәсенә ышанычын арта. Кырыс, әмма оптимистик рухтагы проза бу. Мисаллар да китерим. Габделхакованың «Соңгы һөҗүм» хикәясендә изгелеккә салынган булып, Марсель исемле адәм актыгы ялгыз картның пенсиясен, җыйган соңгы акчаларын «савып» алып китә. Икенче бер ялгыз картның да шундый ук бәлагә тарыганлыгын очраклы рәвештә ишетеп, бабай теге «изге зат»ның инде икенче кешене үз кармагына эләктергәнен аңлый. Һәм аферист егетне дә, аның әшнәләрен дә хәйлә белән үз өендә бикләп алып, яндырып үтерә. Билгеле инде, әлеге гамәленнән әсәренеп тетрәнүдән, үзе дә җан бирә. Чөнки, гадел булса да, кеше үтерү гамәле янә үз җәзасын алмый кала алмый—авторның мантыйгы дөрес. Кеше ышанмаслык хәлме? Әйе, әмма хикәядә бу хәл ышандыра да, шатландыра да.

Рәмзиянең кайбер хикәяләренә мистика да хас. Ләкин бу һич кенә дә үзмаксат түгел, ә фикер-идеяне җиткерер өчен сайланган алым гына. «Караңгылык эчендә» исемле хикәясе—шундыйлардан. Караңгы салкын төндә, барасы авылына барып җитә алмыйча, салам эскертендә куныл калгач, журналистка төнне үзе кебек үк җылы эзләп эскерт эченә кергән ике кыз белән сөйләшеп үткәрергә насыйп була. Ә иртәнчәк кызлар юкка чыга. Журналист, хат буенча теге авылга барып җиткәч, үзе мактап язарга тиешле колхоз рәисен эзләп таба. Әле шушы авылдан тагын бер хат буенча килгән ул, берничә ай элек үк институтка керергә дип чыгып киткән ике кыз югалган.

Эскерткә килеп төртелүгә, рәис машинасына ут каба. Журналист күз алдында, кулларын чәбәкли-чәбәкли, ак бөркәнчекле ике кыз бии, ә машинада янган рәиснең кара шәүләсе иләмсез булып күккә күтәрелә дә, соңыннан җиргә инә. Эскерт урынында җәй көне үк югалган ике кызның мәете табыла. Менә шулай җәзалый язучы җан кыючы залим рәисне...

Рәмзия ханымның бик тә реалистик, шул ук вакытта психологик яктан бик төгәл хикәяләре күп. «Әниле йортта», «Берни дә булмады», «Кояш чәчәге», «Өченче бала», «Кәлүшле кыз»—шундыйлардан. Ә «Көмеш тун», «Авыру», «Теләк»—болары беркадәр О. Генри новеллаларын хәтерләтәләр. Кыскасы, Рәмзия Габделхакова укучыны бер «эләктереп» алса, үзеннән бер дә ычкындырмый торган автор, чын хикәяче. Татар әдәбиятын мондый язучысы пәйда булу белән котларга була!

**Гөлнара МАНСУРОВА:**

1. «Яңа дәвер кешесе» бәйгесенә тәкъдим ителгән хикәяләрне укып чыккач, авторлар геройлары, вакыйгалары, сурәтләү чаралары белән татар прозасындагы хикәя язу традициясеннән читләшергә тырышалар, яңача уйларга омтылалар дигән фикер кала.

Хикәяләүне төрле персонажлар алып баруы күзәтелә. Мәсәлән, М. Хуҗинның «Ипи. Колын. Без» әсәрендә (хикәя исеме үк Ф. Кафка иҗатын искә төшерергә мәҗбүр итә) вакыйгалар автор үзе һәм геройлары тарафыннан бәян ителә. А. Әхмәтгалиеваның «Өзелгән гөл» хикәясендә дә вакыйгаларга өч герой карашы сурәтләнә. Шулай итеп, аларның бер сызыктан үсүе-үзгәрүе генә түгел, ә тукталып шәрехләнүе дә күрсәтелә. Укучы хәлне төрле яктан карый ала.

XX йөз башы татар прозасында киң кулланылышта йөргән интертекстуальлек (Г. Рәхим, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан) бүгенге хикәядә дә бар. Р. Рахманның «Сөннәтче әби», А. Юнысованың «Мадам Бовари» әсәрләренең исемендә үк текстара аралашу күренә, хикәяләрдә безгә яхшы таныш булган әсәрләрнең эчтәлеге, идеяләре хәзерге заман ноктасыннан бәяләнә. Мәсәлән, Р. Рахманның хикәясендә Г. Исхакый тарафыннан билгеләнгән кыйммәтләренең югалмавы, киресенчә, дәвам итүе ассызыклана. А. Юнысова чит ил яшәешендә актуаль мәсьәләләрне милли җирлеккә утырта, аларны һәр халык өчен әһәмияткә ия проблема дәрәҗәсенә күтәрә.

Ә. Гаффарның «Коелы өй» әсәре бер вакыйганы тәэсирле сурәтләү һәм хатирәнең чиратлашып баруына корыла. Тасвирлар көтелмәгәнрәк тоелса да, шаккатырулар белән мавыгу сизелә («Минем йөгем пөхтә—чагыштырырга яраса, әз-мәз көмәнле бер-бер хатын-кызның әлегә сизелер-сизелмәс, бүлтәйгән кием-салымына тартым...»). Шул ук вакытта нәкъ менә хәзерге мизгелне геройларның

кыска репликалары һәм пейзаж сурәтләре аша торгызу XX гасыр башындагы татар әдәбиятында чагылыш тапкан абстрактлылыкка омтылуны хәтерләтә.

Шагыйрь-шагыйрәләр хикәяләре хиснең хөкем итүе белән аерылып тора (Э. Шәрифуллина. «Уяну», Х. Ширмән. «Мәхәббәтнең соңгы көне», Р. Рахман. «Сөннәтче әби» һ. б.) Хис, идеяне житкерү өчен авторлар төрле алымнардан оста файдалана: җыр, шигырь, төсләр, төш, монолог, диалог. Соңгысына аерым тукталыйк. Бу алым бөтен хикәяләрдә диярлек сәхнә диалогы ролендә килә, ягъни хикәягә башка әдәби төр үзенчәлекләре үтеп керә. Хисләрнең әйтелгән сүзләрдән күпкә тирәнрәк икәнлеге шул рәвештә күрсәтелә. Белүебезчә, әлеге алымны (аның иҗади исеме «айсберг») Э. Хемингуэй үз хикәяләрендә тәкъдим итә. М. Хуҗин, Р. Зәйдулла әсәрләрендә бу аеруча сизелә.

Язучылар хикәядә сурәтләү чараларының төрле мөмкинлекләрен отышлы куллана. Мәсәлән, М. Әмирханның «Убыр уты» хикәясендәге диалектизмнар шундый тансык кабул ителә ки, геройларны хәтта күргән кебек тоела башлый. Мифологик катламга ишарә төсендә төп герой исемнәрен пәйгамбәр исемнәре белән кисештерүе шәйләнә. (И. Сиражи. «Күкләр никахы»).

Хәзерге заман хикәяләрендә үз асылыңны югалтмау, йола-гадәтләрне хәтердә саклау идеяләрен авторлар авыл агайларыннан әйттерәләр, укучы белән ачыктан-ачык сөйләшәләр (М. Хуҗин. «Ипи. Колын. Без», М. Хәбибуллин. «Өч көнлек көтүче»).

2. Соңгы елларда басылган хикәяләрдә, ни хикмәт, бер үк житешсезлекләр дә күзгә ташлана.

Жанрга кагылышлы кимчелекләр үзләрен нык сиздерә. Хикәянең төп асылы—киеренке бер вакыйганы алып, шуның тәэсирендә геройның үсеш-үзгәрешен күрсәтү. Безнең хикәяләрдә бу кызык чагылыш таба: киеренке ситуация итеп хәзерге мизгел алына, ләкин төп вакыйгалар ретроспекциядә бирелә, ягъни үткән тормыш сурәтләнә, хикәя хәтта бүлекләргә таркатыла (М. Әмирхан. «Убыр уты», Р. Зәйдулла. «Кыз-хатын», Ф. Яхин. «Чишелмәс төен», А. Юнысова. «Мадам Бовари», А. Әхмәтгалиева. «Өзелгән гөл» һ. б.) вакыйгаларны мондый рәвештә тәкъдим итү повесть жанрына күбрәк туры килә.

Хикәя жанрының иң мөһим таләпләренең берсе—вакыйгада төп герой һәм бер-ике ярдәмче герой катнаша. Бәйге хикәяләрендә исә геройлар никтер чамасыз кертелә, хикәя бу кадәр персонажны үзендә сыйдыра алмый. Ярдәмчеләр төп геройны төрле яктан ачуга хезмәт итә, тик бу очракта күп персонаж аркасында ул төссезләнә генә. Әсәрдә башлам, аның ахыргы өлеше, исеме ул—көчле позиция; гадәттә аларда образлар тыгызлап бирелә, укучыга идеяне табу өчен юллар күрсәтелә. Хикәядә һәр сүз—шундый сукмактагы бер адым. Әмма күп әсәрләрдә мондый образ тыгызлыгы хикәя башында гына очрый, соңыннан ул юкка чыга, яңадан әсәр ахырында гына калка. Һичшиксез, каймалап алу алымы үзен билгеле бер вакытта аклый, ләкин ул ясалма булырга тиеш түгел.

Образлылык, сурәтләү алымнары хикәяләрдә төрле дәрәҗәдә килә, әмма бер психологик алым һәр хикәядә диярлек кабатлана: ул—монолог. Дөресрәге, хикәяләү беренче зат тарафыннан алып барыла. Авторлар персонаж хисен үзеннән әйттерәләр. Минемчә бу—бары тик заман ялкаулыгы. Тәэсирле психологик портрет яисә пейзаж уйлап торганчы, геройларны сөйләтү күпкә җиңелрәк бит: хикәя үзенчәлекле төзелә, герой күңелен ачып сала, шул җитмәгәнме, янәсе. Шунда классик әдипләребезнең хикәяләре, алардагы психологик портретлар искәрмәстән искә төшә, сагындырып куя, үзеннән-үзе кул мәктәп дәреслегенә сузыла.

3. «Казан утлары» оештырган хикәяләр бәйгесе «Яңа дәвер кешесе» дип аталган иде. Авторлар алдына тәгаенләнгән бурыч куелды, алар яңа дәвер кешесен табарга тиеш. Бер яктан, максат билгеләү хикәя кысаларында хәзерге заманны бәяләргә ярдәм итсә, икенче яктан, язучының иҗатын, күзаллау офыгын чикли кебек. Бәйгегә тәкъдим ителгән күп кенә әсәрләрдә дәвер героен эзләү, чын мәгънәсендә, үзмаксатка әйләнә һәм хәзерге заманда үз урынын тапмаган (А. Юнысова. «Мадам Бовари», Х. Ширмән. «'Мәхәббәтнең соңгы көне»), югалган (Ф. Яхин. «Чишелмәс төен»), тормышыннан ваз кичкән (Ф. Гайнуллин. «Күчтәнәч») яисә тормыш төбенә

тәгәрәгән герой (И. Сиражи. «Күкләр никахы», К. Кәримов. «Сунар вакыты», Р. Зәйдулла. «Кыз-хатын») тәкъдим ителә.

Шул ук вакытта язучылар өмете булган, аякларында нык басып торган ир-ат (М. Хужин. «Ипи. Колын. Без», М. Хәбибуллин. «Өч күлмәк көтүче», Ә. Гаффар. «Коелы өй») һәм борынгы йолаларны, өй учагын саклаучы, гүзәллек иясе хатын-кыз геройлары (Э. Шәрифуллина. «Уяну», А. Әхмәтгалиева. «Өзелгән гөл», Р. Рахман. «Сөннәтче әби», М. Әмирханов. «Убыр уты» һ. б.) да укучыга бүләк итә. Татар хикәясен үстерү юлында төп геройны дөрес табып, аны тиешенчә сурәтләү мәслихәт.

XX гасыр башында чагылыш тапкан интертекстуальлек хәзерге татар хикәясендә дә күренә. Язучыларыбызның чит ил, рус һәм милли әдәбияттан үрнәк алулары унай күренеш. Шулай да ияреп язу белән мавыкмыйча, дөнья әдәбиятына бирердәй яңалык сорала.

Күп кенә хикәяләрдә сурәтләү материалы итеп тормыш ваклыклары алына. Мондый вакыйгалардан еш файдалану әдәбиятны бер дә бизәми. «Кичке хәбәрләр»дән дә күреп булган мәгълүматны сәнгать әсәрендә уку нык ялыктыра.

Татар әдәбиятында житди хикәяләр өстенлек итә, юмор, сатира бик аз. Әсәрне жанландырып жибәргән бу алымнарны язучылар никтер онытып тора. Сурәтләү чараларын алдан уйлап кую мөмкин түгел, ләкин әсәр эчтәлеген барлаганда, формасына игътибарны күбрәк бирү кирәк, мөгаен.

Бүгенге көндә язучыларны актив эшчәнлеккә акчалы бәйгеләр аша гына тартып була, күрәсең, башка юллары хәзерге заманда юк. Хикәя торышын бер жайга салдык кебек, шул унайдан әдәби төрләрнең башка жанрларын да үстерү өчен шундый бәйгене көтеп калабыз.

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, жинел таныдырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар жибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

## ЭШ КҮРСӘТКӘН ИРНЕ ИЛ ОНЫТМАС!

Узган елның 7 ноябрендә Төркиянең Истанбул шәһәре Мәдәният сараенда күренекле тарихчы-галим Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановка Ислам конференциясе оешмасы каршындагы Ислам тарихын, сәнгатен һәм мәдәниятен өйрәнүче халыкара тикшерү үзәгенең махсус бүләге тапшырылды. Бу бүләк Ислам цивилизациясен өйрәнү өлкәсендә атаклы хезмәтләр өчен генә бирелә.



М. Г. Госманов—Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстан Фәннәр академиясен нигезләүчеләрнең берсе һәм аның хакыйкый әгъзасы, хәзерге вакытта академиянең президент киңәшчесе, Татарстан республикасы Милли китапханәсенең фәнни консультанты... Хәер, галимнең барлык вазифа һәм титулларын санап чыгу өчен дә күп урын кирәк булыр иде.

Ә шулай да бу мәртәбәле бүләккә ни өчен лаек ул? Җиде томнан торган «Татар тарихы» исемле фундаменталь хезмәтнең баш мөхәррире булган өченме? Әллә инде югарыда атап үтелгән халыкара оешма тарафыннан әзерләнгән «Татар тарихы һәм цивилизациясе» исемле энциклопедик хезмәтне оештыручыларның берсе булгангамы? Кытай Халык Республикасының Голҗа шәһәрендә туып-үскән М. Госмановка бу мәртәбәле дәрәҗәләргә ирешү, әлбәттә, җиңел генә бирелмәгәндер.

1955 елда СССРга күчеп кайткач, ул Казанга килә һәм Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала. Университетны тәмамлагач, М. Госманов шунда ук СССР тарихы кафедрасында калдырыла, 1964-1967 елларда аспирантурада укып, 1968 елда XVII-XVIII йөз татар тарихи чыганакларын тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. 1967 елдан башлап ул университетның СССР тарихы кафедрасында укытучылык эшчәнлеген башлап җибәрә. 1981 елда «XIV-XVI йөзләрдәге Җүчи Олысының ярлыкаш актлары» дигән темага докторлык диссертациясе яклап доктор һәм соңрак профессор дәрәҗәсен ала, 1982 елдан совет чорына кадәрге СССР тарихы кафедрасы, ә 1989 елда яңа ачылган татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетында үзе оештырган татар халкы тарихы кафедрасын җитәкли. Бер үк вакытта ул 1988 елда кафедра каршында фәнни-тикшеренү археографик лабораториясенә дә нигез сала, 1985-1991 елларда Казан дәүләт университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры һәм ректор вазифасын башкаручы булып та эшли.

М. Госмановның укытучылык эшчәнлеге, традицион дисциплиналардан лекцияләр курсы уку белән беррәттән, Идел-Урал буе халыклары тарихы

чыганакчылыгы, иске татар палеографиясе кебек яна курслар барлыкка китерү белән бергә үрелеп бара. 1968 елдан алып 1985 елга кадәр ул Татарстан тарихы буенча специализациянен (жирле тарих буенча махсус белем алучы төркемнен) житәкчесе дә була.

М. Госмановнын фәнни-тикшеренү өлкәсендәге төп юнәлеше—Идел-Урал буе төрки халыкларынын тарихы һәм мәдәниятенә караган XIII-XX йөз башы төрки язма чыганакларны өйрәнү. Татарстан һәм Россия Федерациясенен төрле өлкәләрендә сибелеп яшәүче татар халкы арасында татар, гарәп, фарсы телләрендә ижат ителгән, күчерелгән язма ядкарьләрне жыю һәм тикшерү буенча оештырылган археографик экспедицияләр бу өлкәдә аерым урын тота.

1963 елда анын идеясе һәм инициативасы белән университетта археографик экспедиция оештырыла. Моны исә Казан ориенталистика мәктәбенен көнчыгыш кульязма ядкарьләрен жыю һәм өйрәнү өлкәсендәге элеккеге традицияләрен мәгьлүм дәрәжәдә тергезү дип тә бәяләргә кирәк.

Элеккеге биш автономияле республика һәм унбиш өлкәдәге татарлар яшәгән 900гә якын авылны тикшерү нәтижәсендә 9 меннән артык кульязма һәм мен ярымга якын иске басма китаплар жыела. Экспедицияләрнен уңышлы эшләве Казан дәүләт университеты Фәнни китапханәсенен кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенен көнчыгыш кульязмалар фондын ике тапкыр диярлек баетырга мөмкинлек бирде. Археографик экспедиция үз эшчәнлеген хәзергә кадәр дәвам иттерә һәм милләттәшләребез яшәгән төбәкләрдән ел саен йөзләгән кульязма истәлекләр алып кайта.

Галимнен халык арасындагы кульязма ядкарьләрне жыю һәм өйрәнү процессын яктырткан «Каурый каләм эзеннән. Археограф язмалары» исемле хезмәте Казанда 1984, 1994 елларда ике тапкыр нәшер ителеп, үзәк һәм жирле матбугатта югары бәя алды. Элеккеге СССРнын төрле шәһәрләрендәге (Казан, Алма-Ата, Баку, Ереван, Киев, Мәскәү, Санкт-Петербург, Оренбург, Симферополь, Ташкент, Томск, Уфа һ. б.) архивларда һәм фәнни китапханәләрдә татар халкы тарихы һәм әдәбиятына караган язма истәлекләрне ачыклау һәм фәнни хәрәкәткә кертеп жибәрү буенча да М. Госманов тарафыннан ифрат зур эш башкарылды. Шундый истәлекләр нигезендә анын тарафыннан Идел-Урал буе төрки халыклары тарихы чыганакчылыгына багышланган «XVII-XVIII йөз татар тарихи чыганаклары» *(Казан, 1972)* һәм «Жүчи Олысынын ярлыкаш актлары» *(Казан, 1979)* исемле фундаменталь хезмәтләре дөнья күрде. Тикшеренүләрнен бай чыганаклар жирлегенә нигезләнүе һәм аларны өйрәнү нигезендә ясалган нәтижәләрнен ышанычлылыгы Казан, Мәскәү, Баку, Тбилиси, Будапешт, Әнкара һәм башка шәһәрләрдә дөнья күргән рецензияләрдә, ягъни халыкара фәнни жәмәгатьчелектә унай янгыраш тапты.

Археографик экспедицияләрдә, архив һәм китапханәләрдә табылган кульязмалар һәм 1917 елга кадәр дөнья күргән басмалар нигезендә М. Госманов тарафыннан XIX йөз татар әдәбияты классиклары Габделжаббар Кандалый, Мифтахетдин Акмуллаларнын әдәби мираслары тикшерелеп, төп оригиналдагыча бастырып чыгарылды. Ул китапларда классик әдипләребезнен тәфсилле тәржемәи хәлләре белән бергә аларнын әдәбиятыбыз тарихында һәм, гомумән, ижтимагый тормышыбызда тоткан урыннарын билгеләү һәм кабатланмас әдәби ижатларынын үзенчәлекләрен, әһәмиятен яктырткан монографик пландагы күләмле мәкалә-тикшеренүләре дә урын алган.

Ул, шулай ук, XIII йөз болгар-татар шагыйре һәм фикер иясе Кол Гали, татар халык дастаны «Идегәй» һәм XVIII-XIX йөз мәгърифәтче шагыйре

Габдрәхим Утыз-Имәни басмаларының текстологик һәм фәнни мөхәррире дә булды.

Галим җитәкчелегендә XVIII йөздә халык азатлыгы хәрәкәте тарихын өйрәнүгә мәгълүм өлеш керткән җыентык: 1773—1775 еллардагы Крестьяннар сугышына караган татар документлары җыентыгы төзелә һәм бастырылып чыгарыла. Баш күтәрүчеләр лагереннан чыккан һәм моңа кадәр аз өйрәнелгән 188 документ гарәп хәрефләре белән төп нөсхәдә һәм русчага тәрҗемә итеп бастырылды. Нәтиҗәдә, Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы тарихына караган беренче кульязма чыганакларның кыйммәтле комплексы фәнни хәрәкәткә кертелде.

М. Госманов аз өйрәнелгән тарихи чыганаклар нигезендә XIX—XX йөз башы күренекле татар мәгърифәтче галимнәре Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, Р. Фәхреддиннәрнең эшчәнлеген һәм мирасын яңача өйрәнеп җәмәгатьчелеккә тәкъдим итте.

Фәнне пропагандалап яисә киң җәмәгатьчелек игътибарын тарих фәненең хәл ителмәгән мәсьәләләренә юнәлтеп, М. Госманов вакытлы матбугат битләрендә фәнни-популяр һәм публицистик чыгышлар ясауга да зур игътибар бирә. Шундый характердагы басмаларның сайланма бер өлеше «Үткәннән—киләчәккә» *(Казан, 1990)* исемле җыентыкта дөнья күрде.

Татарстан Фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы, профессор һәм язучы М. Госманов тарафыннан барлыгы 470тән артык фәнни хезмәт, шул исәптән 11 монография һәм җыентык бастырылган. Галимнең күп кенә мәкаләләре Алмания, АКШ, Төркия, Франция, Тайвань, Көньяк Корея һәм башка илләрдә нәшер ителүче фәнни журнал һәм җыентыкларда басылган. АКШ һәм Маҗарстан галимнәре белән берлектә Берлин һәм Сегедта татарча тарихи чыганаклар буенча ике китабы дөнья күрде. Моннан тыш 40тан артык китап, тикшеренү галимнең мөхәррирлегендә һәм эшкәртүендә дөнья күрде.

Педагог-галим буларак М. Госманов фәнни алмаш әзерләү өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. Аның гыйльми җитәкчелегендә 20дән артык аспирант кандидатлык һәм ике шәкерте докторлык диссертациясе яклады.

М. Госманов даими рәвештә бөтенроссия һәм халыкара фәнни конференция һәм симпозиумнарда катнаша һәм киң фәнни җәмәгатьчелекне халкыбызның тарихы, мәдәнияте белән таныштыруга зур өлеш кертә.

Казан дәүләт университетының проректоры булып эшләгән дәвердә М. Госманов төрле яңа бүлекләр—язма чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару буенча фәнни-тикшеренү үткәрүче археографик лаборатория, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты (һәм андагы берничә тарихи-филологик кафедра), шулай ук экология факультетын оештыруда актив катнашты. Аның ярдәме белән Казан дәүләт университеты һәм берничә чит ил университеты арасында элемтә урнаштырылды (Венгрия, Алмания, Кытай, Төркия).

М. Госманов Россия Фәннәр академиясенең археографик комиссиясе (1969 елдан), «Казан утлары», «Мәгариф», «Фәнни Татарстан» журналлары редколлегияләре әгъзасы булып торды яки тора. Ул—тарих һәм филология фәннәреннән докторлык дәрәҗәсе бирү буенча гыйльми советлар әгъзасы да.

Татарстан Фәннәр академиясен нигезләүчеләр арасында да без М. Госманов исемен очратабыз. Ул көнчыгышны өйрәнүчеләрнең XXXV Халыкара конгрессын (Будапешт, 1997) оештыру комитеты составында да нәтиҗәле эш алып барды. 1997 елның октябрь аенда Россиянең Көнчыгышны өйрәнүчеләр съезды аны ике елга Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнүчеләр җәмгыятенең президенты итеп сайлады.

Татарстанның атказанган фән эшлеклесе М. Госманов республикабызның иҗтимагый-мәдәни тормышында да актив катнаша. 1989 елдан алып ул татар телен һәм мәдәниятен үстерүгә өлеш кертүче «Җыен» фондының рәисе булып тора. Аның җитәкчелегендә һәм шул фондның ярдәме белән М. Худяков, К. Фукс, И. Гаспралы, Г. Газиз, Г. Рәхим, Рәмиевләр, Һ. Атласи, Г. Сәгъди һ.б.ларның халкыбыз тарихын яктырткан, әмма элек «онытттырылган» хезмәтләре янадан дөнья күрде.

Башкалабыз Казанга 1000 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек буенча республика комиссиясе әгъзасы сыйфатында М. Госманов 1998-2000 елларда Җүчи Олысы тарихы, Урта Иделнең тарихи географиясе һәм безнең төбәктә шәһәрләр барлыкка килүе һәм үсешенә багышланган өч халыкара конференцияне оештыруда һәм фәнни яктан җитәкчелек итүдә, шулай ук федераль программа кысаларында үткәрелә торган «Бөек Идел юлы» халыкара фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашты.

Хәзерге вакытта М. Госманов язма чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару өлкәсендә интенсив тикшеренү һәм оештыру эшләре белән мәшгуль. Бу эшкә татар халкы тарихы һәм мәдәнияте кафедрасы хезмәткәрләре, шулай ук студент яшьләр дә җәлеп ителә. Соңгы елларда галим 1917 елга кадәр Россия империясендәге һәм чит илләрдәге татар диаспоралары тарихын өйрәнүгә дә зур игътибар бирә.

Сүзебезне Истанбулдагы тантанадан башлаган идек. Әйе, күренекле галим чит илләрдә еш була, язмыш аны дөньяның төрле кыйтгаларындагы егермеләп илгә алып бара. Монда шунсын басым ясап әйтергә кирәк: бу сәфәр-командировкаларның абсолют күпчелеге теге яки бу илдәге архитектура истәлекләрен тамаша кылу, кибет-базарларда йөрү, яисә ял йортында истирахәт чигү белән бәйләнмәгән. Аның сәфәре тарихыбызны барлау, эшлекле хезмәттәшлек урнаштыру кебек максатларга буйсындырылган. Мисал өчен, күптөрле сәфәрләрнең берсенә генә тукталып узыйк.

1990 елның 5-10 сентябрендә Төркиянең башкаласы Әнкарада Төрек тарих корымы (җәмгыяте) тарафыннан оештырылган XI халыкара тарих конгрессы булды. Дистәләгән илләрдән килгән берничә йөз галим катнашкан бу конгресста М. Госманов доклад белән чыгыш ясый. Әнкарада булган вакытта ул Төркиядә яшәүче якташларыбыз профессор Әхмәт Тимер (хәзер инде гүр иясе), доктор Надир Дәүләт, инженер һәм җәмәгать эшлеклесе Мәхмүт Таһир, Фазыл Агиш һәм башкалар белән очраша. Күренекле татар галиме, җәмәгать эшлеклесе Садри Максудиның кызы, Төркиянең Италиядәге элеккеге илчесе Адилә ханым Айда әтисенә Гаяз Исхакый тарафыннан язылган хатларның күчермәләрен М. Госманов аша Казанга юллый. М. Таһир Казан университеты Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә Төркиядә 11 ел дәвамында нәшер ителгән «Казан» журналының тулы төпләмәләрен, узган гасырның егерменче елларында Харбинда татар телендә чыккан «Ерак Шәрык» журналының дистәләгән нөсхәләрен һәм күренекле татар галиме Р. Фәхреддиннең 20-30 елларда Финляндия татарларына язган биш хатының төп нөсхәләрен бүләк итте. Бу сәфәр вакытында М. Госманов Казан университеты белән Истанбул, Мәрмәрә, Әнкара университетлары арасында хезмәттәшлек урнаштыру турында сөйләшүләр дә алып бара. Менә болар—бер сәфәр вакытында эшләнгән эшләр. Киләчәктә дә әнә шундый уңышлы сәфәрләр телик аңа!

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,**
**Җәүдәт МИҢНУЛЛИН.**

Миркасыйм
Госманов

# БИРЕЛМИЧӘ КАЛГАН СОРАУЛАР

**Сорауларны Чыңгыз Айтматовка бирергә уйлаган идем...**

Язманың башында ук мәшһүр язучының исемен күрүгә кайбер укучыда: «Әһә, «Мин һәм Айтматов» кыйссасы башлана икән!»—ише ирониялe уйның тууы ихтимал.

Ләкин ашыкмыйк. Минем ният чак кына икенчерәк. Хәтта монда, истәлектә, «Айтматов һәм мин» дигән вариант та чамалы гына урын алачак. Мине, асылда, бирелми калган, мәгәр күптән күнелдә йөргән, аны гел «кытыклап» тора торган берничә сорау уйландыра. Дөресрәге, шул сорауларны тудырган сәбәпләр, аларның табигате, нәтиҗәләре кызыксындыра. Хәтта бүген дә, Чыңгыз Айтматов үзе «әйләнеп кайтмаска» киткәч, ягъни якты дөньядагы җисмани гомеренә чик куелгач та.



Әйе, ниятемнең асылы икенчерәк һәм ул бик гади, бер үк вакытта катлаулы да. Сүз, беренчедән, Чыңгыз Айтматов тарафыннан, үзе русча язучы буларак киң танылгач, «асылга кайтып» дигәндәй, кыргызча язылган, миңа өлешчә генә таныш булса да, үземә гаҗәп дәрәҗәдә ошаган, ләкин кырыс һәм сәер язмышка тарып, автор үзе исән чакта тулысынча басылмыйча калган бер әсәр хакында булыр.

Икенчедән, язучының бәгъзе сәер гамәлләре, ягъни үзенең чыгышына—«кемлегенә» карата «серле» мөнәсәбәте, шулай ук бездәге кайбер дәгъвалар, мәгънәсез сузып тартулар хакында да сүз булыр.

Мәсьәлә ачыграк, аңлаешлырак булсын өчен мин ана кинрәк, беркадәре әтрафлырак итеп тукталырмын. Форсаттан файдаланып, Чыңгызның иҗаты, эшчәнлеге, исеме тирәсендә барган кайбер ыгы-зыгылар, мәрхүмнең шәхси язмышындагы, минемчә, бер аңлаешсызрак мәсьәлә хакында да үземнең кайбер уй-фаразларымны әйтермен.

Ниһаять, Чыңгыз Айтматов белән булган, очраклы дип әйтерлек рәвештә генә килеп чыккан кыска очрашулар вә сөйләшүләрнең, керәле-чыгалы дәрәҗәдәге «хезмәттәшлекнең» үземә ясаган гыйбрәтле тәэсирен дә бераз яктыртырга тырышырмын.

* * *

1972 елның җәе, дөресрәге, август ахырлары иде. Чираттагы археографик экспедициядән кайтып ялга чыккач, Идел буендагы Зеленый Бор дигән җирдә такта-фанердан әвәләнгән, гадәти эт оясыннан дүрт-биш мәртәбә генә зуррак булган бер казна алачыгында хозур итеп «корсак сыйпап» яткан көннәр. Уйламаган, көтмәгән җирдән язучылар оешмасының машинасы килде. Дөресрәге, ашыгыч рәвештә Казанга чакырган язу килде. Киттем, әлбәттә. Шул ук машинада. Ни өчен чакыруларын белмәгән дә килеш.

Уйланып барам. Моннан берничә ай элек, фатир мәсьәләсен беркадәре яхшыртып булмасмы дип, идарә башлыгы Зәки Нури янына кергән идем. Ул сүзне кыска һәм кырыс тотты: «Үзебезнең мондагы егетләрнең дә мәсьәләләре хәл ителмәгән әле. Эшчеләр сыйныфыннан әдәбиятка килгән шагыйрьләр дә общежитиедә интегәләр...» Шул рәвешчә барсы да аңлашылган иде. Шулай да чакыру әлеге сөйләшүне искә төшерде. Әллә?..

Зәки агай һәрвакыттагыча якты чырай белән каршы алды, чакыртуның сәбәпләрен дә шунда ук ачып салды:

—Тиздән безгә Чыңгыз Айтматов җитәкчелегендә кыргыз язучылары киләчәк. Шуларны әйбәт публикацияләр белән каршыларга кирәк. «Кыргыз хикәяләре» дигән, син үзең дә катнашкан хикәяләр тәрҗемәсе җыентык булып чыгып ята инде. Хәзер бүгенге кыргыз әдәбияты, бигрәк тә Чыңгыз Айтматов иҗаты турында яңа мәкаләләр кирәк. Ике мәкалә булсын. Айтматовтан, өзекләр рәвешендә булса да, яңа тәрҗемә эшлисе иде. Без бу эшләрне сиңа йөкләргә булдык. Кара аны, Чыңгызга багышланган мәкаләнең авторлы мәкалә булуы хакында беренче секретарь үзе күрсәтмә бирде. Димәк, җаваплы эш бу!—дип, идарә җитәкчесе миңа ике-өч кыргызча яңа китап белән «Ала Тоо» дигән журналның берничә санын да тоттырды.

Шулай итеп, көтмәгәндә ялым тәмамланып, кызу эш тә башланып китте. Тиздән кунакларның да башланачагын исәпкә алып, көнне төнгә, төнне көнгә ялгап дигәндәй эшләргә туры килде. Тиз арада шактый нәрсәләрне майтарып ташладым. Югарыда телгә алынган җыентыкта басылып яткан биш тәрҗемәгә өстәп тагын дүрт язучының, бер шагыйрьнең әсәрләреннән тәрҗемәләр ясалып, вакытында ук «Социалистик Татарстан» һәм «Татарстан яшьләре» гәзитләренә бирелде.

Ике мәкалә дә өлгерде. Аларның берсе, Айтматовка багышланган «авторлысы», кыргызлар Казанга иртәгә-берсекөнгә килә дигән көнне үк басылып чыкты *(10.09.72)*. «Яшәргән халыкның ялкынлы әдәбияты» дип аталган гомуми рухтагысы да шул ук «Социалистик Татарстан»да ике көннән соң, ягъни делегация килгән көнне дөнья күрде.

Ч.Айтматовтан яңа тәрҗемә өчен «Ала Тоо» (Алатау) журналында зур гына бер бүлеге басылган, «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» дип исемләнгән тарихи эчтәлекле әсәре сайланды. Аннан шактый күләмле өзек берничә көн дәвамында басылды *(«Социалистик Татарстан», 10-15.09.72)*. Бер парчасы яшьләр гәзитендә бирелде.

Шулай итеп, бер кичкенә мажараны исәпләмәгәндә, эшләр шактый кызу һәм шома барды.

Мажара исә әлеге «авторлы» мәкалә кисәге, дөресрәге, Чыңгыздан эшләнгән тәрҗемәгә бирелгән махсус кереш язма белән килеп чыккан иде.

9 сентябрь көнне гәзит корректурасын укыр өчен редакциягә килдем. Иң элек тәрҗемәне карап чыктым. Бер-ике хәреф хатасы гына табылды. Ниһаять, бер баганага сыеп беткән әлеге «кереш»кә, янәсе «авторлы мәкалә»гә күз салдым. Аның ахырына җитүгә, такыр башымдагы чәч төпчекләре дә үрә тордылар: язманың өч-дүрт җөмләдән гыйбарәт, мәгәр мәгънә ягыннан әһәмиятле булган йомгак өлеше бөтенләй юкка чыккан!

Гаҗәпләнүемә каршы, бүлек мөдире мәрхүм Рәшит Гарипов тыныч кына:

—Әйе шул,—диде,—без аны үзебез төшердек, колонка баганасына сыймаган иде.

Мин, әлбәттә, фикер тәгаллеге өчен ул җөмләләрне кайтару кирәклеген әйттем. Бүлек мөдире үз фикерендә калды. Мин дә үз сүземдә тордым. Дәвамы басылачак тәрҗемәдән соңгы бер абзацны киләсе санга күчерү, шул рәвешчә корректураны артык үзгәртеп тормау мөмкинлеген әйттем. Рәшит исә әлеге кыскартуның баш редактор тарафыннан раслануын тукый башлады. «Алайса,—дидем,—минем фамилиямне дә алып ташлагыз, алмасагыз—кул куймыйм!» Аптыраган Рәшит ишеккә ташланды. Бераздан баш редактор урынбасары Гарәф ага Шәрәфетдинев күренде. Мине сабыр гына тыңлагач, ул тыныч кыяфәт белән:

—Ике-өч җөмлә өчен генә сүз куертып тормыйк инде, егетем,—диде.—Чыңгыз Айтматов хакында кичтеке мәкалә генә түгел, бәлки зур роман, монография язарга кирәк. Ә гәзит мәкаләсе бит...

Минем җен ачуларым чыкты:

—Карагыз әле, абзый кеше,—дидем кырыс рәвештә,—бер кечкенә генә мәкаләне җүнләп баса алмаган килеш монография дип авыз чайкап тормыйк әле... Ярар, сезнеңчә булсын, тик минем фамилиямне алып ташлагыз һәм вәссәлам!

Гараф агай: «Юк инде, алай мөмкин түгел!»—диде дә, бүлмәдән чыгып ук китте. Бер-ике минуттан кире әйләнеп керде. Күрәсең, коридорда бераз тынычлана төшкән ул:

—Ярар, сезнеңчә булсын, төзәтербез, кулыгызны куегыз да кайтып китегез,—диде.

—Юк!—дидем мин катгый рәвештә.—Яңа гранканы күрмичә кул куймаячакмын.

Сәгать ярымнан артык вакыт узгач, төзәтелгән яңа гранка да килеп җитте.

Ләкин әлеге ике-өч җөмлә хакындагы бәхәс икенче көнне дә дәвам итте. Дөресрәге, Ирек мәйданында, өлкә комитеты тарафыннан килүче баш редактор Шәмси Хамматов очрады. Мине күрүгә ул:

—Нигә кичә газета бастыруны ике сәгатькә тоткарладыгыз?! Безнең производствода һәр минуты исәпле... Икенче алай эшләмәгез,—дип, сүзен әйтеп тә бетермичә, китеп барды.

Икенче «алай эшләргә» туры килмәде, әлбәттә. Чөнки моннан соң редакциягә тәкъдим ителгән материалларымның берәр җирен кыскартырга, төзәтергә кирәк тапсалар, үзем белән махсус килешеп гамәл кыла башладылар. Әмма Шәмси агай, нәшрият коридорында очраткан чакта, мине күрмәмешкә салынып, читкә карап узып китүчән булды. Ә Гараф агай Шәрәфетдинев исә, киресенчә, туктап кул биреп исәнләшә, хәтта хәл-әхвәл дә сораша торган булды. Нәшрият директоры эшенә күчкәч тә шул гадәтен ташламады ул, бәлки тагын да якыная төште.

Төп сюжеттан болай читкәрәк тайпылып, үз «җинүем», кайберәүләр әйтүенчә, «киреләнүем» хакында тәфсилләбрәк сөйләвем очраклы түгел. Бәлки әлеге әкәмәт вәзгыятьнең гыйбрәтләре дә бар иде. Беренчедән, редакциядә, хәтта башкаларында да, минем хакта «авыр холыклы автор» дигән фикер таралып өлгерде. Икенчедән, иң мөһиме, беренче секретарьның «авторлы мәкалә» булсын дигән бер сүзенең шул кадәр ыгы-зыгы тудыруы, редакция хезмәткәрләренең әлеге әмер-фәрманга мөкиббән китеп буйсынулары, чарасыз калулары гаҗәп дәрәҗәдә гыйбрәтле иде минем өчен.

* * *

Кыргыз язучыларын Ульяновта каршылап, Казанга алып кайтыр өчен махсус самолетта Ренат Харисны җибәрәләр. Ул Казанда «кыргыз материаллары» басылып өлгергән гәзитләрне дә алып китә. Юлда Чыңгыз Айтматов шулар белән таныша. Ренат әйтүенчә, үзе турында чыккан язмадан вә «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» әсәреннән тәрҗемәнең басыла башлавыннан канәгать була.

Казанда кыргыз язучылары делегациясе икегә бүленде. Дөресрәге, Чыңгызны төп төркемнән аерып алып, берүзен генә башка кунакханәдә асрап, махсус кунак иттеләр. Кайда, ничек сыйлауларын һәм кемнәрнең бу эшне башкаруларын мин белмәдем, әлбәттә. Чөнки төркемнең зур өлешен язучылар идарәсе Әлмәт-Чаллы якларына озаткан иде. Кушулары буенча мин дә шуларга ияреп йөрдем.

Болай бергә күченеп, бергә кунып йөрүләр дәвамында делегация әгъзаларының шактые белән якыннанрак аралашырга, сөйләшергә, табигый ки, аларның үзара фикер алышуларын да ишетәләргә туры килде. Нәтиҗәдә кыргыз әдипләренең берберсе белән якын-ераклыкларын, кайберләренең Ч.Айтматовка карата үзенчәлекле мөнәсәбәтләрен, хәтта аны яратып бетермәүләрен, көнләшүләрен дә шайләргә мөмкинлек туды. Чыңгызның махсус илтифат үзәгендә булуы беркемгә дә ошамый иде. «Монда кыргыз язучысы дип бары урысча язучы Айтматовны гына беләләр икән...», яки: «Без Татарстанга килмәдек, бәлки Россиягә, Мәскәүнең үзенә барасы делегация булабыз»,—ише төртмәле фикерләрне дә кат-кат ишетергә туры килде. Татар-кыргыз мәдәни мөнәсәбәтләре хакында сүз чыккач: «Элек дәреслекләрне, китапларыбызны Казанда бастырырга мәҗбүр идек, хәзер үзебездә бастырабыз,

сезгә ялынудан котылдык инде!»—дип тә ярып салган иде берсе. Һәрхәлдә, жае чыккан саен Кыргызстанның союздаш республика булуын, аның автономиядән күпкә өстен икәнлеген искә төшерергә тырышучылар да бар иде.

Дөрес, мондыйрак фикер йөртүчеләрнең күпчелеген яшь һәм урта буын вәкилләре, ягъни «чын советча» тәрбия алып үскән, элекке чорларның тарихыннан хәбәрсезрәк, күбрәк русча иркен сөйләшүчеләр тәшкил итә иде. Делегация составындагы иң олы яшьтәге бер шәхес кенә, тәгаен әйткәндә, шагыйрь Куанычбәк Маликов, киресенчә, тирәнрәк тамырларга карап фикер йөртә иде. Аның «Дуслык» һәм «Үзем татар булмасам да...» дигән шигырьләре шуна шаһит. Соңгысыннан өзекләр китерик:

*Мин татар түгелмен; яшь чакта*
*Тордым мин татарның йортында.*
*Әниләр чәй куеп каршыма*
*Татытты икмәген, тозын да (...)*

*Татарның мәктәбен күрдем мин,*
*Ишеген киң ачып кердем мин,—*
*Габдулла, Галимҗан булдылар*
*Һәрвакыт мендәрем урнында!*

*Мин татар түгелмен—кыргызмын.*
*Татардан сабаклар укыдым,*
*Остазлар каршында баш иеп,*
*Шәкертлек дәверен уздым мин (...)*

*Мин татар түгелмен—кыргызмын;*
*Тик күрдем туганлык татардан:*
*Тукай һәм Галимҗан моңнары*
*Килде бит кыргызга Казаннан (...)*

Без шулай Чаллы-Әлмәтләрдә кунак булып, «фикер алышып, үзара аңлашып» йөргән көннәрнең берсендә Чыңгыз Айтматов Казанда, аның өчен махсус оештырылган пресс-конференциядә матбугат вәкилләре белән очрашкан икән. Әйтүләренә караганда, үз чыгышында ул XX гасыр башы татар «әдәби фикеренең» (Чыңгыз бу очракта нәкъ шундый гомумиләштерүче олы төшенчә куллана) бөтен төрки дөнья масштабында зур казанышларга ирешүен, башка кардәш әдәбиятлар өчен үрнәк булуын билгеләгән. Кыргыз язучылары делегациясен Казанда зурлап каршы алулары, үз иҗатына Татарстанда даими игътибар итүләре өчен рәхмәтләр әйтә. Сүз уңаеннан ул «востоковед-тюрколог Усманов мәкаләләренә», ул башкарган тәрҗемәләргә карата да жылы мөнәсәбәт белдерә. (Минем шәхесемә адресланган билгеләмәләрнең самолетта килгән чакта Чыңгызга Ренат Харистан күчкән булуы бәхәссез, чөнки моңарчы аның минем кәсеп-һөнәрем, белгечлегем хакында белүе мөмкин түгел иде.)

Айтматовның минем хактагы әлеге сүзләре аерым кешеләрдә болар арасында дустанә мөнәсәбәт бар икән ише фикер тудырган булса кирәк. Кайберәүләр мине күргәч: «Сине Чыңгыз дустың бик мактады», яисә: «Чыңгыз белән дус икәнсең бит!»—кебегрәк сүзләр әйтеп каршылау очраклары булды. Хәтта бер яшь журналист шул хакта интервью алу теләген дә белдергән иде. Мин, әлбәттә, бернинди дуслык-фәлән юк, дип, андый әңгәмәдән баш тарттым. Беренче мәртәбә очрашканда нибары биш-ун минут кына сөйләшкән булсак, икенче мәртәбә Айтматовны шушы көннәрдә, ягъни 1972 елның сентябрендә генә Казанда күргән һәм егерме-утыз минут чамасы гына аулакта әңгәмәләшеп алган идек.

Очрашу аның теләге белән ул чактагы шәһәр китапханәсендә (хәзерге Милли китапханә бинасында) барган экскурсия вакытында булды. Икәү генә калгач, Чыңгыз иң элек үзенең рәхмәт сүзләрен кабатлады, Казанда күрсәтелгән сый-хөрмәтләрдән, татарча кунакчыллыктан гаять канәгать икәнлеген белдерде. Сүз җаен китереп, ул

Татарстанда, аның автоном республика булуына карамастан, халык хуҗалыгының гаҗәеп көчле, мәдәни һәм әдәби тормышның да шактый югары дәрәҗәләргә ирешкәнлеген билгеләп үтте. Аның татарларга, Татарстанга карата мөнәсәбәте вә мәгълүматы, элеккеләренә караганда, бу 1972 елда, шактый үзгәргән иде. Монда килер алдыннан мәсьәләне өйрәнгән икән, дип уйлап куйдым.

Шул рәвешчә, делегация сәфәренә бәйле гомум сүзләрдән соң, Чыңгыз үзен кызыксындырган төп мәсьәләгә күчте: «Тарихчы, тюрколог буларак турысын гына әйтегез әле, «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» романы хакында чын фикерегез, аның тематикасына, шул теманың яктыртылуына карата мөнәсәбәтегез ничек?»—дип сорады. Үзе миңа, өмет һәм шикләнү аша «белгеч» хөкемен көткән сыман, төбәлеп карый башлады. Аның нәрсәдәндер шөбһәләнүе, икеләнүе дә сизелеп тора иде. Мин иң элек әсәрнең үземә гаять дәрәҗәдә ошавын, аны яратып тәрҗемә итүемне, хәтта вакыт-вакыт текстка, андагы сурәтләү чараларына соклануымны да әйттем. Әсәрнең тематикасына килгәндә, мин калмак, ягъни җонгар-уйрат яуларының казакъларга, казакъ ханлыклары белән бәклекләренә нинди бәла-казалар китергәнен бераз белүемне, әмма кыргызларның да ул гарасатларга дучар булуыннан монарчы бихәбәр икәнлегемне әйттем. Нәкъ шул төштә Чыңгыз урысчалап: «Еще как!»—дип куйды. (Без монарчы, беренче кат очрашкандагы кебек, үзенчәлекле рәвештә сөйләшә идек: ул кыргызча сөйли, ә мин—казакъча. Бу ике телнең сөйләмә рәвешләре татар-башкорт телләренә караганда да якынрак, бары язма рәвешләре, имла үзенчәлекләре ягыннан бер-берсеннән аерылалар.) Аннары язучы бераз икеләнгән төсле утырды да, бу теманың аны уйландырган, борчыган яклары булуын да әйтте. Мәсәлән, бүгенге укучы аны кабул итә, аңлый алырмы, өстәвенә моннан 250 еллар элек булып узган вакыйгаларны тасвирлаганда әсәргә модернизация, ягъни «янарту» элементлары кереп китмәсме. «Шуның өчен тюрколог тарихчының фикерен сорап утырам да»,—диде ул, максатын ачыклап. Миңа калса, дидем, әсәрнең проблемасын кабул итә алу-итмәү мәсьәләсе һәр укучының үз мөмкинлекләренә бәйле. Ә модернизация мәсьәләсенә килгәндә, текстның миңа таныш өлешендә андый күренешләр очрамады. Бу тематика белән кыргызлар гына түгел, минемчә, башка халык вәкилләре дә кызыксынырлар, дидем.

—Әсәрне тулысынча тәрҗемә итәргә алыныр идегезме?—диде ул әкрен генә.

—Әйе,—дидем мин икеләнмичә,—кулымда тулы текст кына булсын!

Шуны ишетүгә Чыңгыз, сүз беткәнгә ишарә иткәндәй, ике учы белән өстәлгә шап иттереп сукты да, аягүрә басты:

—Ярар,—диде көр тавышы белән,—мин сезгә кулъязмасын ук җибәрермен. Тагын бераз гына кайбер өлешләрен янадан карап чыгармын да, сезгә җибәрермен,—диде һәм өстәп куйды,—тәрҗемәнең кыргызчадан татарчага эшләнүен теләр идем...

Чыңгыз Айтматов белән икенче мәртәбә очрашкан вакыттагы кыскача сөйләшү менә шулай тәмамланган иде һәм ул, әйткәнемчә, беренче очрашудагы аңлашудан нык аермалы булды. Шуна күрә анысы хакында да берничә сүз әйтергә кирәктер.

* * *

Чыңгыз Айтматов белән беренче тапкыр очрашуым моннан, 1972 елдан, унбер ел элек булган, очрашуга исә аның иҗаты белән танышу этәргән иде.

1961 елның май ае ахырларында факультетыбыз (химик корпус) почмагына каршы киосктан, кызыксыз лекцияләр вакытында караштыргалап утырырга дип, «Огонек» китапханәсе»ндә чыккан кечкенә форматлы, бәясе тиеннәр генә тора торган дүрт-биш брошюра сатып алган идем. Нәкъ бер сумга (киоскычы хатынның кайтарырга вак акча юк дип зарлануы истә калган).

Брошюраларның берсе, тышлыгына автор рәсеме куелып, «Джамиля» дип аталганы игътибарымны җәлеп итте. Чыңгыз Айтматов дигән яшь кеше язган икән аны. Титул битендә әсәрнең автор тәрҗемәсендә басылуы күрсәтелгән. Әгәр билгеле язучының мәгълүм әсәре булса, аны берәр Мәскәү яһүденең тәрҗемәсендә генә басарлар иде, шулай да аның «Огонек» китапханәсе» сериясенә эләгүе очраклы түгелдер дигән каршылыклы уйлар белән китапчыкны актаргалый, аннары җентекләп укый да башладым. Башладым да, туктый алмадым. Соңгы битен япканда



*СССР язучыларының VIII съездында. Уртада–Чыңгыз Айтматов. Сулдан уңга: Рәдиф Гаташ, Туфан Миңнуллин, Миркасыйм Госманов, Разил Вәлиев. Мәскәүнең Съездлар сарае,1986 ел.*

җәйге якты таң беленеп килә иде инде. Күнелдә дә әллә нинди яктылык, җылылык хисләре. Шул ук вакытта тоташ моң да сарып алган аны...

Мәхәббәт турында монарчы нинди генә матур әсәрләр язылмаган да, ниндиләре укылмаган, күнелдән кичерелмәгән! Ләкин монысыннан аерата бер нечкәлек, олы хислелек, бер үк вакытта әйтеп бетергесез гади гүзәллек, җылылык бөркелеп тора. Мондый сыйфатлар, бәлки, хикәяченен—үсмер баланың табигый ихласлыгыннан, мәхәббәт дигән катлаулы күренешкә карата нарасыйларча пакь мөнәсәбәтеннән киләдер?.. Бер якта сөелүгә, хәтта гап-гади игътибарга да сусаган Җәмилә белән Даниярның яшьни-яшьни күк күкрәп янгыр яуган чактагы кайнар кавышулары. Шунда ук үзенең дә Җәмиләне үлеп яратуын беренче мәртәбә тойган, аңлаган үсмер Сәетнең самими, кайнар күз яшьләре...

Нәшриятка бер килгәндә, фикерен белеп карыйм әле дип, әдәби әсәрләрне күп укуы белән аерылып тора торган Кыям Миңлебаевка бирдем әлеге «Җәмилә»не. Икенче очрашуда ул, китапчыкны үземә кайтарып: «Шәп нәрсә икән бу, зәвыгың өчен рәхмәт! Әйдә, тәрҗемәсен эшлә, безнен редакциядән бастырып чыгарырбыз!»—диде. Мин мондый ук реакция булыр дип уйламаган идем. Икеләнеп торуымны күргәч, Кыям агай, гадәттәгечә кеткелдәп көлеп куйды, аннары: «Тәрҗемәне исә кыргызчадан эшләргә кирәк. Оригиналның исе, ароматы, сүз тәме төгәлрәк саклансын. Әчке рецензияләр язганда үзеннең казакъчаны, кыргызчаны белүеңне күрсәттең инде. Ике дә уйлап торма, әйдә, кыргызча оригиналын тап та, эшкә башла!»—диде боерган төсле.

Кыям Миңлебаев биргән идея тора-бара үземне дә биләп алды. Җәйге каникулда әти-әниләр янына, Талды-Курган якларына кайткач, өйдә артык юанмыйча, Алматыга киттем, анда Кыргызстанның башкаласы Фрунзеда яшәүче ерак туганнарыбыз Мәсгуд абзый Халидовларның (тарихчы, этнограф Корбангали Халидинең оныгы) адресын табып, шул якка ук юл тоттым.

Икенче көнне ул чакта әллә ни зур булмаган, мәгәр яшеллеге, төзеклеге ягыннан үземдә әйбәт тәэсир калдырган Фрунзе шәһәренең китап кибетләрен айкап чыктым. Тик бер җирдә дә Айтматов әсәрләренең кыргызчасы табылмады. Күптән сатылып бетте, диделәр. Ниһаять, башыма бер кыю фикер килде. Әгәр Язучылар союзына

барсам, яки Айтматовның үзен табып очрашсам, аның үзеннән үк алырга мөмкиндер «Җәмилә»нең кыргызчасын? Һәм киттем адреслар бюросын эзләп. Адрес табылды. Фатиры да әллә ни еракта түгел икән. Ишекне ул үзе ачты. Казаннан икәнемне, аны күрергә теләвемне әйткәч, икеләнеп кенә эчкә дәште. Эш бүлмәсендә бер гадәти генә язу өстәле, бер китап шкафы һәм ике-өч урындык кына. Аның каруы өстәл өсте тулы кәгазь, язылганнары да, язылмаганнары да.

Эшеннән бүлүем сизелеп тора. Әллә ни теләмичә генә Казан хәлләре, андагы язучылар хакында сорашкан булды. Күренекле әдипләрдән кемнәр барлыгы хакында сүз чыккач, мин Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмовларны атаган булдым. Әллә ни реакция күрсәтмәде. Соңгы елларда нинди яңа әсәрләр язылуы хакында да сорашты. Казанышларның берсе мисалында мин «Мәңгелек кеше» романын атадым. «Нәрсә, «җүләр кеше» дигән мәгънәдәме?»—дип гаҗәпләнде ул. Мин китерелгән мисалның уңышсыз булуын аңладым: ул «мәңге» сүзен кыргыз һәм казакълардагы, гомумән, Урта Азия төркиләрендәге «бәңге» (тиле-миле, әфьюнче, наркоман) белән бутаган булып чыкты. Русча аңлатырга туры килде. Гомумән, хуҗа кешенең татар дөньясы, татар әдәбияты хакында әллә ни белмәве, хәтта кызыксынмавы да сизелеп тора иде. Бер язучының, бер шәхеснең дә исемен атамады. Бәлки, атарга да теләмәгәндер...

Дүрт-биш минут шулай сүрән генә сөйләшеп утыргач, мин үз максатыма күчтем. Әгәр автор каршы булмаса, аның «Җәмилә»сен татарчага тәрҗемә итәргә исәп, ләкин тәрҗемәне русчадан түгел, бәлки кыргызча оригиналдан эшлисе иде, шулай иткәндә тугандаш телдә язылган әсәрнең сыйфаты тәрҗемәдә тулырак чагылыш табар иде, дидем. Чыңгыз монысы белән килеште һәм: «Казакъчагыз әйбәт икән, кыргызчаны да аңларсыз инде»,—дип куйды. Тик «Җәмилә»нең кыргызча оригиналын китап кибетләрендә таба алмавымны әйткәч, ул җәһәт кенә китап шкафы ягына бер карап алды да: «Кыргызчасы үземдә дә сакланмаган шул,—диде.—Кыргыз телендәге китапларны күбрәк районнарга җибәреп саттыралар. Шәһәрдә бит руслар яки русча сөйләшүче кыргызлар тора... «Җәмилә» дип сорасагыз, кибетләрдә белмәүләре дә ихтимал. Кыргыз телендә әсәр дә, китап та «Обон» дип атала. Аны бары ауыл кибетләреннән генә таба алырсыз инде...»

Җыеп әйткәндә, Айтматов үз әсәренең татарчага тәрҗемә ителүе белән әллә ни кызыксынмады, шулай ук ул «кыргызча белмәгән» әллә нинди бер студент кисәгенең андый эшне башкарып чыгуына да ышанмады. «Казакъчагыз әйбәт» дию дә шуңа ишарә булды кебек.

Артык утырудан мәгънә калмады.

Визит, шулай итеп, мин көткән нәтиҗәне бирмичә, күңелсез тәмамланды.

Дөрес, бер файдасы да булды аның: әсәрнең кыргызча исемен ачыкладым. Бер китап кибетенә кереп, олырак яшьтәге сатучы ападан «Обон» дип сорашкач, ул тагын бер серне ачты:

—«Обон» бездә күптән сатылып бетте инде. Үзе дә аз килгән иде. Ә сез, беләсезме, шәһәр читендәге гел урыслар гына яши торган бистәгә барыгыз, анда ул әле сатылып бетмәгәндер,—диде һәм бистәнең адресын, автобус номерын да әйтте.

Ярты сәгатьтән тиешле кибеткә барып җиттем. Мин эзләгән повестьтан тыш тагын кечкенә күләмле дүрт хикәяне дә эченә алган һәм «Обон» (моң, көй мәгънәсендә) дип исемләнгән, 1959 елда ук басылып чыккан 192 битле җыентык та табылды!

* * *

Шул ук көнне Фрунзедан кайтып та киттем. Кайтуга ук тәрҗемәгә тотындым. Дөресрәге, иң элек әсәрнең кыргызча оригиналын төгәл укып чыктым. Баштагы биш-ун бите авыррак укылды. Хәзерге кыргызча язуның имласы ярыйсы гына үзенчәлекле, башка төрки телләрнекеннән, җөмләдән гап-гади сүзләрнең казакъча язылышыннан да үзгәрәк икән. Әсәрнең теле дә мин элек татарча тәрҗемәсен чагыштырып рецензияләгән кыргызча әкиятләр теленнән сүз байлыгы, җөмлә катлаулыгы, сурәтләү чараларының камиллеге җәһәтеннән шактый аерылып тора иде. Шулай да тора-бара күнектем, тизрәк, төгәлрәк аңлый башладым. Татарчадан

тыш казакъча, үзбәкчә һәм уйгырча телләр, аларның сүз байлыклары белән таныш булу аркасында «Обон»да мин анламаган бер генә сүз дә, бер генә җөмлә дә калмады.

Күпчелек язма төрки телләр арасындагы эчке бәйләнешләрнең бер үзенчәлеге менә шуннан—берсендә очраган «ят» сүзләрнең мәгънәләре икенчесеннән табылу хикмәтеннән гыйбарәт икән. Шуна күрә дә элекке гарәпчә язудагы китаплар,—кайларда гына язылып, басылса да,—күпчелек төркиләр өчен якын вә аңлаешлы, хәтта уртак булган. Шуна күрә дә татарча газет-журналларны элек үзбәкләр дә, казакълар да, уйгырлар да иркен укыганнар, аңлаганнар, үзләре дә Казанда, Ырымбурда мәкаләләрен бастырганнар. Совет чорында көчле-көчле ике мәртәбә язу алмаштыру бер яңайдан менә шул якынлыкны какшату, тамыр берлеген имгәтү максатына да хезмәт иткәндер, бәлкем ?

Мондый нәтиҗәгә мин, әлбәттә, үз акылым белән генә килмәгән идем. Тел белеме буенча лекцияләре вакытында укытучыларымнан Үзбәк ага Байчура, кыеклатып кына дигәндәй, берничә кат мона ишарәләр ясаган иде, (бу хакта үз урынында да әйтермен әле).

Мәсьәләнең шушы яклары хакында уйлаган чакта мин Чыңгыз Айтматовның үз әсәрен татарчага тәрҗемә итүгә карата салкын, битараф караштa булуын да искә төшергәләдем. Кардәш халыкларның элекке чор әдипләре өчен хас булмаган салкын мөнәсәбәт иде бу. Күрәсең, яна совет чорының тәрбиясе тәэсиредер инде. Кардәшлек, якынлык хисләренең зәгыйфьләнә, сүрелә баруының да чагылышыдыр. Башка бер очрак булса, авторның мөнәсәбәтен исәпкә алып, тәрҗемә эшеннән баш та тартырга мөмкин иде. Киткән ди исем! Ләкин мин киресенчә үҗәтләнеп тәрҗемәгә тотындым. Чөнки мин бер авторга хезмәт күрсәтү ниятеннән түгел, бәлки гүзәллеге, камиллеге ягыннан әйбәт, үземә чын-чынлап ошаган әсәрне үз ана телемдә дә яңгырату теләгеннән чыгып бу эшкә тотынган идем.

Шунысы да тәэсир итми калмагандыр: киләчәктә нindirәк белгечлек алырга дип уйлана да башлаган чорым иде. Бәлки тәрҗемәчелек эшенә өйрәнүне дә күз уңында тотканмындыр. Ихтимал...

Җыеп кына әйткәндә, каникулның зур өлеше кыргызча текстны татарчалатып утыру белән узды. Казанга кайтуга ук тәрҗемәнең беренче вариантын машинкага бирдем. Дания Шәрәфиева (журналист Исмәгыйль Шәрәфинең әнисе) һәрвакыттагыча тиз генә акка чыгарып бирде аны.

Кыям Миңлебаев кулъязманың ике-өч битен караштырды да:

—Телен бераз шомартасы бар икән әле,—диде.—Менә сиңа бер журнал, анда Луи Арагонның «Җәмилә» хакындагы мәкаләсе бар. Ул да нәкъ безнеңчә уйлаган икән,—дип, Кыям гадәтенчә кеткелдәп куйды.

Мәкаләне укып чыгуга,—исеме ни тора: «Самая прекрасная на свете повесть о любви»—күңел сизгән сыман, кирәге булыр әле дип, аннан машинка күчермәсен эшләтеп алдым.

Бер очраганда Рәшат абый Гайнанов минем җәен «нәрсәләр кырып йөрүем» белән кызыксынды. «Җәмилә»не ул да укыган икән. Тәрҗемәдән «Азат хатын» журналында да берәр өзек бастыру мөмкинлеген әйтте. Китердем кулъязманы. Тик икенче очрашуда баш редакторның әсәрне бик үк ошатып бетермәве беленде. Сәбәбен сорагач: «Ире фронттагы яшь хатынның икенче берәү белән азынуын аклау килеп чыкмасмы?»—дигән икән.

Соңра беленгәнчә, әсәргә карата әлеге дәгъва элегрәк әйтелгән тәнкыйтьләрнең бергә-бер кабатлануы гына булган икән. Автор үз повестеның кыргызчасын журналга тәкъдим иткәч, Фрунзедагы кайбер дәрәҗәле әдипләр, редакторлар аны: «Ничек инде, сугышта кан коеп, ватанны саклап яткан геройның хатыны ирена эшләгән хыянәтне шулай җыр итеп мактарга? Кайда монда социалистик реализм? Кайда монда патриотлык?!!»—дип, авторны каты тәнкыйтькә тоталар. Шуннан соң Ч.Айтматов «Обон»нан «Җәмилә» ясап, аны Мәскәү журналына бирә. Бары шуннан соң гына, имеш, әсәрнең кыргызча варианты дөнья күрә...

Форсаттан файдаланып, тагын бер мәсьәләгә кагылып узам. Әгәр «Обон»ның кыргызчасы советча консерватив көчләр тарафыннан кире кагылмаган, яшь авторга

юл ачылган булса, иманым камил, Ч.Айтматов үз әсәрен русчага күчереп тормаган, аннан соң да тулаем диярлек русча язып китмәгән булыр иде. Димәк, Чыңгызның рус телле язучыга әверелә язуына—ул кыргызча язудан да бөтенләй тукталмый—патриотизм сөреме белән артык ысланган, соцреализм догмасына чумып баткан кайбер кыргыз әдипләренең үзләре үк өлеш керткән булып чыга. (Хәер, мондый күренешнең кайбер мисаллары бездә дә булды бугай...) Ләкин, башка кайбер рус телле «милли» язучылардан үзгә буларак, Чыңгыз Айтматов бервакытта да үзенең кыргызлыгына хыянәт кылмады, бәлки гел аның кайгысы белән янып яшәде, соңгы сулышына хәтле үз халкына хезмәт итте.

Рәшат абый баш редактор сүзләрен кабатлауга ук мин портфелемнән, алдан әзерләнеп куюыма сөенеп, Луи Арагон мәкаләсенең күчермәсен бирдем. Рәшат абый, аны, күз йөртеп алуга, балаларча сөенеп, баш редактор янына кереп китте...

Шулай итеп, уйламаган җирдән «Җәмилә»нең бер өзеге «Жыр» дигән исем белән «Азат хатын» журналында да басылды (1961, №8). Әлбәттә, икенче мәртәбә янгыраган большевистик догманы атаклы язучы, күренекле француз коммунисты Луи Арагонның абруйлы сүзләре бәреп еккан иде. Кем әйтмешли, чөйне чөй белән...

Икенче елны «Җәмилә» повесте Татарстан китап нәшриятында аерым китап рәвешендә дөнья күрде. 1965 елда ул Ч.Айтматовның башка повестьлары белән бергә икенче мәртәбә дә басылды.

Әйтүләренә, бәя бирүләренә караганда «Җәмилә»нең тәрҗемәсе уңышлы гына чыккан икән. Мона, ихтимал, тел чараларының үзенчәлеге, тәрҗемәсез дә аңлашыла торган кыргызча (гомум төркичә) сүзләрдән, гыйбарәләрдән мул файдалану да сәбәп булгандыр. Һәрхәлдә, профессор Хатип ага Госман да үзенең СССР Язучылар союзына мине тәкъдим иткән язмасында тәрҗемәнең сыйфатын махсус билгеләгән иде (Казан утлары, 1970, №4, 185 б.)

Китап чыккач, табигый ки, үз әсәрем басылган төсле сөенеп, дус-ишләргә аның нөсхәләрен өләшеп йөрдем. Журналист Кояш Тимбикова белән ире Рейнга да бер нөсхәсен язып бирдем. Кояш ханым яздырмыйча да китапның бер данәсен сорап алды: «Авторга җибәреп, сөенчесен алырбыз, син җибәрмә, үзеңнән сәлам дә әйтербез!» —диде. Шуңа күрә мин Чыңгызга хат язып та, китабын җибәреп тә тормадым. Болай «саранлануның» икенче бер сәбәбе дә булган иде: узган елгы очрашуда аның ерак Казаннан үзе өчен файдалы идеяне күтәреп махсус килгән кеше белән җүнләп сөйләшмәве, теләктәшлек күрсәтмәве онытылмаган иде әле.

...1972 елда исә, югарыда махсус әйтелгәнчә, аның татар культурасын белүе, татар әдәби фикеренең гомум әһәмиятен аңлавы бөтенләй башка югарылыкта иде. Шуңа күрә үзенең кыргызча язылган «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» исемле яна әсәренең беренче тәрҗемәсен тулы килеш татарча күрергә теләве дә аңлаешлы.

Тик ул үз вәгъдәсендә тора алмады: кульязмасын җибәрмәде. Аның язмышы хакында сорашып язган хатка да җавап булмады. Соңрак беленгәнчә, җавапны бирә алмаган икән шул.

Шуңа күрә мәсьәлә мине тагын да ныграк кызыксындырды...

* * *

Сүз җае чыккач, тагын бер четерекле мәсьәләгә махсус тукталуны, алгарак узып дигәндәй, соңрак билгеле булган кайбер мәгълүматларны әйтүне дә кирәк табам.

Чыңгыз Айтматовның бер-бер артлы яна әсәрләре, мәсәлән, «Беренче мөгаллим», «Гүзәлем Әсәл», «Ак пароход», «Хуш, Гөлсары» повестьлары, «Гасырдан да озынрак бер көн» романы һ.б. чыгып, язучының дан-шөһрәте киң таралган чорда аның анасы татар хатын-кызы булуы хакында сүзләр ишетелгәли башлады. (Мин үзем дә аның анасы татар кызы, хәтта аерган беренче хатыны да, имеш, әлеге кавем кешесе булуын—дөрестерме, юкмы монысы—шулай сонлап кына ишеткән идем.) Безнең кайберләребез дөньякүләм мәшһүрлек казана башлаган зур язучыны шул яктан да үзебезгә якын итәргә теләде, дөресрәге, тырышты. Гәрчә анасының кем, кайсы милләттән булуы хакында Айтматовның үзе озак вакытлар бер сүз әйтмәсә дә.

Үз вакытында әлеге хәбәрләргә шикләнеп караган бер каләмдәшем әйткәнчә,

Ч.Айтматовның әдәби әсәрләрендә бер жирдә дә татар кешесе күренми, хәтта татар дигән сүз дә телгә алынмый. Гәрчә кечкенә генә Кыргызстанда 70-80 меңләп татар яшәп, (совет чорында 30 мең дип ялганласалар да!), алардан меңнәрчә кеше мәктәп-мәгариф, фән-гыйлем, хужалык-икътисад, матбугат һәм сәнгать өлкәләрендә тырышып эшләсә дә. Бигрәк тә яңа мәктәпләр ачылуда, беренче спектакльләр куелуда эш башында күп очракта татарлар торса да... Язучы боларны күрмәгәнме, белмәгәнме, әллә икърар итәргә теләмәгәнме?..

Озак вакыт ачылып житмәгән мондый «серне» сәбәпләрен төрлечә аңлатучылар булгалады, билгеле. Шуңа күрә бу четерекле теманың соңгы көннәрдә, язучы вафатыннан соң, тагын да ешрак күтәрелүен, төрле дәгъвалар, ялган версияләр туа башлавын истә тотып, ана бераз киңрәк тукталуны кирәк табам.

Заманында Урта Азия өлкәләре, Казакъстан һәм беркадәре Кавказ төркиләре кешеләренең, бигрәк тә аларның өстенгерәк, хәллерәк, укымышлырак катламнары вәкилләренең чагыштырмача аграк тәнле һәм чак кына түгәрәгрәк, ачыграк күзле, ягъни укый-яза да белгән татар кызларына теләбрәк өйләнүләре мәгълүм факт. Андый гадәт шагыйрь Сибгат Хәким «Кызлар сездә кияүдә» дип, гомумиләштереп жырлаганча, киң таралган, үзенә күрә модага әверелә язган күренеш иде. Мондый процессның гел киңәя баруына Идел-Урал якларындагы колониаль изү тудырган авыр тормыштан, жирсезлектән, махсус оештырылган ачлыктан, колхоз крепостнойлыгыннан кача алган, качып котылган татарларның ул тарафларга күпләп күченүләренең дә өстәмә сәбәп булуы бәхәссез, әлбәттә.

Шул рәвешчә күпләп барлыкка килгән катнаш никахта торучылар һәм шулардан туучылар элегрәк үзләренең тормыш чынбарлыгын яшермиләр, бәлки балаларын тәрбияләүдә, укытуда шундый үзенчәлекләреннән файдаланырга тырышалар иде. XX гасырның башы һәм беренче яртысына хас күренеш иде бу. Әмма шул ук гасырның икенче яртысында, элеккесеннән үзгә буларак, әле генә билгеләнгән тормыш вә чыгыш үзенчәлекләре хакында әйтмәү, хәтта мөмкин булган кадәр аларны яшерү тенденцияләре дә барлыкка килгән иде. Мондый омтылышларның объектив сәбәпләре бар иде, әлбәттә. Беренчедән, ул яклардагы төркиләрдә милли аң чарланып, оешкан яңа милли менталитет көчәя башлый.

Икенчедән, СССР дигән «иң гадел, интернациональ» дәүләттә халыкларны, милләтләрне өч-дүрт төргә, ягъни сортларга бүлү, «союздашларына» караганда «автономлыларына» урынны түбәнрәк жирдән бирү, ягъни аларга өстән торып карау гадәткә әйләнеп житкән иде. Шул рәвешчә үз ата-аналарыннан берсен икенче-өченче «сортлы» халыктан итеп күрергә, күрсәтергә кем теләсен?!.

Өченче сәбәп исә сәясәттән, ягъни «илбасар, явыз татар-монголлар» хакындагы тамырдан нахак, өстәвенә ярымрасачыл уйдырмаларның (әйтерсең лә руслар үзләре башкаларны яуламаган, жинмәгән, таламаган, измәгән!) даими рәвештә тукланып, мәктәп яшеннән үк дәреслекләр аша аңга сеңдерелә килүеннән, ВКП(б) үзәк комитетының 1944 елгы мәгълүм карарыннан соң шул тенденциянең «тарихи дәреслек» кыяфәтендә тоталь идеологиягә әверелүеннән гыйбарәт иде. (Татар балаларының тарих дәресләреннән соң өйләренә елап кайтулары, татарлыктан качарга тырышулары мәгълүм күренеш.)

Игътибар итегез, күренекле казакъ жырчысы Бибигөл ханым Түләгәнова ата-анасының икесе дә татар булуын соңгы елларда, үзе Казанга килгәч кенә икърар итә алды. Аңарчы бу хакта ачык әйтергә юл куелмаган икән... Мөслим Магомаевның әбисе татар хатыны икәнлеге дә соң гына әйтелде... Мондый фактларны дисталәп, хәтта йөзәрләп-йөзәрләп санарга мөмкин. Үзебездә дә андыйлар житәрлек...

Урта Азия республикаларында татар кешеләренең министр, мөдир, директор, баш редактор ише эшләрдән читкәрәк тибәрелүләре, идарә-оешмаларда беренче дәрәжәле урыннарда утыручы татарларны системалы рәвештә «милли кадрлар» белән алмаштыру процессы 60-70 елларда киң колач жәйгән иде. Милли аң оешып, милли азатлык омтылышлары көчәю шартлары өчен табигый күренеш бу. Моны дөрес аңларга кирәк. Гомумән, СССРда татарларның, Татарстанның «автономлы урынына» төртә-төртә күрсәтеп тору да, әгәр табеевларча икейөзләнмәсәк, әзлекле кагыйдәгә әверелеп беткән иде. Мәсәлән, Үзбәкстан әдипләрен, сәнгатькәрләрен

Татарстанга чакыру теләгән Каракалпак автономиясе вәкилләрен кабул итү белән «канәгатьләндерү», Чүпрәле районы кадәрле генә Ломжа воеводствосы белән бөтен Татарстан республикасы арасында хезмәттәшлек оештыру һ.б. фактлар—мондый мисалларны дистәләп-дистәләп китерергә мөмкин...

Ләкин мин бу мәсьәләдә үзенең мөстәкыйль фәлсәфәсе, төрле мәдәниятләргә, диннәргә карата да үз фикере, гадел карашы булган, ичмасам, шуңа омтылган Чыңгыз Айтматовның татарларга булган мөнәсәбәте мондый түбән дәрәҗәле сәяси аң (дөресрәге, аңсызлык) тәэсиреннән килеп чыккандыр дип, берьяклы рәвештә уйламыйм. Һич тә! Гәрчә шундыйрак сүзләрне ишеткәләгән булсам да. Чынлыкта Чыңгыз үзе анасының кайсы халык кызы булуы хакында озак вакытлар бернәрсә дә җүнләп әйтмәде. Сораган очракта да бары 80-90 еллардан башлап кына, кыскача икърар итү белән чикләнде. Моның, минемчә, утә дә шәхси, күңелнең төбендә үк урнашкан шактый катлаулы сәбәпләре булганга охшый.

Чыңгызның зур дәрәҗәле партия эшләрендә торган атасы Түрәкол Айтматов тоталь репрессия корбаны сыйфатында 1938 елда үлемгә хөкем ителә. Түбән хезмәт хакына эшләргә мәҗбүр булган анасы Нәгыймә өчен «халык дошманы» хатыны халәтендә, табигый ки, үз җанын асрау, эш урынын саклау да, һичшиксез, зур проблемага әверелә. Шуңа күрә тугыз-ун яшьләрендә әтисез калган дүрт баланың берсе үсмер Чыңгызга авыл жирендә яшәүче әбисендә, атасының әнисе кулында да тәрбияләнергә туры килә.

Түрәкол кулга алынгач килеп чыккан матди, «юридик» (бигрәк тә, психологик!) начар үзгәрешләргә төрле сәяси басымнар нәтиҗәсендә туа торган башка әхлакый сәбәпләрнең дә өстәлгән булуы ихтимал. Ягъни 1937-1938 елларда, аннан соң да тоталь рәвештә хөкем сөргән намуссызлык, вәхшилектән дә түбән, җан ияләреннән бары кешеләргә генә хас кабахәтлек чорында туганны туганга, баланы атага, хатынны иргә каршы файдалану фактларының гаҗәп киң таралган булуын да онытмыйк...

Шул рәвешчә, ауыл (аил!) шартларында, ягъни кыргыз табигате кочагында кыргыз чынбарлыгын, кыргыз дөньясын, аның кабатланмас бай рухи байлыгын, Манас дастанын якыннан, тирәннән белеп үскән үсмер бала ир-егет булып җитлегә. Бу елларда аңар анасының кавеме хакында уйлану мөмкин, хәтта хаҗәт булды микән? Димәк, аның кыргыз кешеләренә һәм самими, һәм гадел, һәм гаять олы ихтирамы, мәхәббәте менә шундый шартларда шытып, борнап чыккан, гөрләп үскән, ныгыган сыйфат-аң иде.

Язучының кыргыз кешеләрен, аларның һәм гади, һәм катлаулы эчке дөньяларын искитәрлек бер гади осталык ярдәмендә яктырткан әсәрләре дөньяга гаҗәеп сәләтле сүз остасы килүен күрсәткән, өстәвенә җир йөзендә КЫРГЫЗ дигән бер аерым вә гаять үзенчәлекле халык барлыгын да калку итеп күрсәткән, танытакан иде. Әгәр казакъларны башка халыкларга беренче мәртәбә яхшылап таныту Мохтар Әүэзовның «Абай» романы аша булган булса, кыргыз халкының истә калырлык образы Чыңгыз Айтматов иҗатында гәүдәләнгән иде.

Адәм баласы дигән гаҗәеп катлаулы, каршылыклы, бер үк вакытта искитәрлек дәрәҗәдә гап-гади җан иясенең табигатен, асылын, бетмәс-төкәнмәс мәшәкатен, котылгысыз фаҗигасен аңлар, ачар, аңлатыр өчен ул, Айтматов, тормыш дигән «нәрсә»гә кыргызча кешнәгән, кыргызча үкереп, кыргызча улаган җан-җанвар—атлар, дөяләр, бүреләр язмышы, аларның күзләре, хисләре, күз яшьләре, үлемнәре аша да карый алуга ирешә. Бу исә табигать балалары булган кыргызлар хәятын шул табигать, җан-җанварлар, җир-үсемлекләр, ягъни бөтен яратылыш белән берлектә карарга, аңларга ярдәм итте. Шуңа күрә тормыш гаҗәеп табигыйлектә яктыртылды...

Бары диннәр табигате, диннәр фәлсәфәсе, аларның кешелеккә тәэсире, кешеләр тормышындагы урыны хакында уйланганда («Плаха», «Когда падают горы» һ.б.) ул кыргыз чынбарлыгына сыя алмады—киңрәк дөньяга чыкты... Шул рәвешчә бер ил, бер халык язмышы кысаларыннан галәми дип әйтерлек киңлекләргә омтылды. Һәм әлеге киңлек-биеклекләргә үз халкын да чыгарды, күтәрә алды. Тормышка, гомер дигән хикмәткә фәлсәфи мөнәсәбәте аны «адәм баласы дигән җан иясенең яшәеше үзе үк бер фаҗигадер!» дигән мәгънәдәге кабул ителмәслек дәрәҗәдә ачы, мәгәр

котылгысыз катгый хакыйкатьне (Улоф Пальменың үлеме хакындагы язмасында) әйтә алу югарылыгына күтәрде...

Менә шундый зур, хәтта глобаль дип әйтерлек проблемалар белән шөгыльләнгән, мавыккан, шуларга җавап эзләгән язучы үз тәрҗемәи хәлендәге кайбер, бәлкем үзе уйлаганча, «вак-төяк» булган мәсьәләләргә кагылмагандыр. Ихтимал, беркадәре серлелеге, анлаешсызлыгы булган бала-ана мөнәсәбәтләренә кагылуны кирәк тапмагандыр.

Ләкин соңгы вакытларда, әйткәнемчә, язучының вафатыннан соң, әлеге мәсьәлә ясалма рәвештә куертыла башлады. Мәкаләләрдә, аерым язмаларда, мәсәлән, язучының әсәрләре хакында төпле, җылы берәр сүз әйтү, аннан калган күпкырлы, бай әдәби мирасның гомум кыйммәтен, әһәмиятен билгеләү, күрсәтү урынына аның анасының «туган төбәген», ягъни ватанын Кукмара яклары, хәтта Бөребаштан бүленеп чыккан Мәчкәрә авылы дип, ярты дөреслеккә ярты ялганны кушып раслауларны алыйк. Чынлыкта анасы Нәгыймә монда түгел,—тегендә, ягъни Каракул шәһәрендә туган. (Тик, бездә кат-кат язылганча, «кара күл»—бәрән тиресе түгел! «Елгалы үзән» мәгънәсендәге борынгы төркичә киң әйтелешле «къол» (къоол) сүзе башка топонимнарда да очрый: Нарынкоол, Кинкоол һ.б.; мондагы «кара» сүзенең борынгылыкта зур, олы дигән мәгънәсе дә булган...) Шулай ук бабалары дип исәпләнгән кешеләрнең Үтәмешевләр дигән фамилияле булуыннан чыгып, «нәсел башы» дип игълан кылынган әллә нинди билгесез Үтәмешне Сөембикә ханбикәнең улы дип уйлау да тома наданлык галәмәте. Ике яшендә әсир ителеп Мәскәүгә озатылган, анда чукындырылган, бала килеш үк үлеп киткән, сөякләре хәзер Мәскәү Кремлендә ята торган Үтәмешгәрәйнең, «никахтан тыш туган баласының нәселеннән булырга тиеш» дип тузга язмаганча көчәнү дә шыр мәгънәсезлек ул. «Нәселнең» мөселман булып калуы шулай фаразларга куша. Ә инде ундүрт-унбиш яшьлек Үтәмеш—Александр Мәскәүләрдән Бөребаш-Кукмара якларына «командировкаларга» килеп, «никахтан тыш» шаярган очракта, әлеге Үтәмешевләр, иң кимендә, керәшеннәр, дөресрәге, урыслашкан Александровлар булырга тиеш иде.

Кыскасы, белмәгән нәрсәң турында «уйламыйча сөйләсәң», кем әйтмешли, «авырмыйча үлерсең...»

Казанда сафсаталар сату җитмәгәндәй, Бишкәкләргә барып, «нәсел тамыры» хакында уйдырмалар таратып йөрү исә ахыр чиктә татарны көлкегә калдыруга кайтып кала.

Шул ук вакытта миндә икенче бер сорау да бар: ни өчен Чыңгыз Айтматовның үзе исән чакта аның шактый күпсанлы татар туганнары—арада фән докторлары да бар икән—мәшһүр язучыны эзләп табып, аның белән танышмаганнар, кунакка чакырып хөрмәт күрсәтмәгәннәр?.. Әллә үлгән кешенең «иясез калган» шөһрәте кирәкме аларга?!.

Бу мәсьәлә бездәге икенче бер әкәмәт күренешне дә искә төшерә. Татар тарихын бик борынгы, ун-унбиш мең еллык итеп (ачыклап куям: гомумән тарихны түгел, бәлки этнос тарихын, ягъни үзебезнең милли тарихыбызны) күрсәтергә теләүче кайбер авторлар да бик «кыю» эш итәләр. Алар, мәсәлән, «үз бабаларыбыз» ихтималында туры нәселләре төгәл билгесез скиф-сарматларга, яшәгән җирләре дә нәмәгълүм, шөбһәле әллә нинди биармиларга яки шумерларга, алар гына җитмәгәндәй, этрусскларга, алардан да узып атлантидалыларга, хәтта океаннар аша гизеп, Америка кызылтәнлеләренә кадәр барып җитәләр. Варислары бүгенгә кадәр билгеле, сакланган халыкларның берсенә дә кагылмыйлар. Гәрчә андыйлар белән якынлык күбрәк булса да. Андый омтылышлы авторларга, күрәсең, туры нәселләре калмаган, дөресрәге, танылмаслык дәрәҗәдә нык үзгәрү нәтиҗәсендә варислары «юкка чыккан» дип исәпләнгән борынгы «бөек» халыкларның «күләгәләренә» барып ышыклану җайлырактыр ул. Беренчедән, башка мираска сузылган кулга сугып җибәрүче булмас, ягъни хәвефсез; икенчедән, «менә мин нинди бай, зур тарихыбызны» ачам дип күкрәк сугарга да мөмкинлекләр туа...

Халкыбыз тарихын икенчерәк юллар белән ясалма рәвештә зурайтырга, киңәйтеп күрсәтергә омтылучылар да булгалады. Мәсәлән, ерак Испаниядәге

Бильбао топонимын (шәһәр исемен) татарның гадәти каеш кушагына, яисә чүпрәк билбавына нисбәт итеп, шул рәвешчә: «Менә без нинди зур, киң таралган халык, хәтта испан җирләренә дә җиткәнбез!»—дип, үз сүзләренә үзе ышанмаса да, мишәр әйтмешли, халык башына «ком төяүче» спекулянтларыбыз да булмады түгел. Бильбаодагы баскляр да синең татарча сөйләп, татарча язганнарыңны белеп тормыйлар бит—теләсәң нәрсә сөйлә!..

Шулай, Чыңгыз Айтматов та «әйләнеп кайтмаячак юлга» киткәч, аның шан-шәрәфе, даны тирәсендә «җылынырга», бер уңайдан милләтне дә бераз «җылытып алырга», янәсе, милли патриотлык галәмәте күрсәтергә теләүчеләр, омтылучылар пәйда булды соңгы вакытта. Шәҗәрә дигән булып, юк-бар уйдырмалар тарату, яисә «соңгы сәфәренең Татарстанга, аерым алганда Кукмарага ясалуының (дөреслектә, ясалмыйча калуының!—М.Г.) тирән бер мәгънәсе бар. «Чыңгыз Айтматов безнеке дә ул. Хәер, моның шулай икәнлеге күптән билгеле иде»,—дип раслау шуны күрсәтә. Ә мондый сузып тартулар, минемчә, зур абруй алдында, үзе киткәч, кача-поса гына, түбәнсеңү катыш, бер үк вакытта «менә без нинди!»—дип, «күләгәрәк» җирдә күкрәк сугып, үзең генә ишетерлек итеп шапырынудан башка бер нәрсә дә бирә алмый.

Бу мәсьәләдә кырыслык күрсәтүем һич тә очраклы түгел. Мәсәлән, төрки-татар тамырлы йөзләгән урыс фамилияләрен саный-саный, «менә без нинди бөек милләт!» дип шапырынулар, хәтта чит илләргә барып шул темага лекцияләр укып йөрүләр дә «сынык-санак» белән туенуга күнеккән әлеге мескенлек, коллык психологиябезнең чагылышы гына. Халкының бер өлеше үз җирлегеннән аерылуы өчен мактанырга түгел, бәлки, иң киме, уйланып гыйбрәт алырга, нилектән шулай килеп чыгуның сәбәпләрен ачыкларга, белергә кирәк. Ни сәбәптән башкаларга «донорга» әверелүеңне белү, аңлау гаделрәк һәм файдалырак та булыр иде.

Чыңгыз Айтматовны якын итү, аның белән горурлану мәсьәләсенә килсәк, мондый теләк-омтылышларга мин дә каршы түгел. Тик андый горурлану примитив «кабиләчелеккә», эгоистик һәм перспективасыз тар милләтчелеккә кайтып калмасын иде. Әгәр олуг әдип тудырган шедевр әсәрләрнең, ул күтәргән мөһим фикерләрнең әһәмияте, кыйммәте хакында сөйләп, шундый бөек зат белән замандаш булуыбыз өчен горурлансак, ниһаять, аның әсәрләрен пропагандалау белән шөгыльләнсәк (бик күп кеше аларны хәзер җүнләп белми дә бит!), мондый омтылышка кем каршы килсен?! Әгәр иҗатка карата шундый мөнәсәбәткә сәләтле булсак, 400 елдан артык колониаль изелү төпкелендә тапталган, вакланган психологиябез дә бераз сәламәтләнә төшәр, юк-бар белән канәгатьләнеп алданудан арына башлар иде. Ә инде адым саен диярлек «анасы татар булган» дип су туглаулар, шуннан чыгып «ул безнеке дә» дип нигезсез дәгъва кылулар, «ярымтатар Айтматов кыргызны бөтен дөньяга танытты» ише ялган раслаулар татарны вак-төяк «тәтиләр» белән генә юатудан, димәк, иҗтимагый аң җәһәтеннән тынычландыру һәм йоклатудан башка берни дә түгел. Җыеп әйткәндә, Ч.Айтматовның үз ихтыярын да хөрмәт итик—ул үзен бары тик кыргыз гына дип исәпләгән,—кыеклатып булса да икенче бер кардәш халыкларны кимсетүгә китерә торган түбәнлеккә төшмәсәк икән!

* * *

Чыңгыз Айтматов белән мөгамәләдә ул исән, кодрәтле чагында ук хакыйкатькә төртеп күрсәткәндәй гамәл итүче кеше дә булган икән. Бер генә мисал китерәм. Туфан Миңнуллин көлә-көлә миңа сөйләгән иде: «СССР Югары Советы депутаты булып йөргән чакларда, очраган саен, мин аңар татарчалап: «Исәнмесез, Чыңгыз абзый!»—дип кычкырып эндәшә торган идем. Башта ул мондый мөрәҗәгатьтән сәерсенеп, бик үк кабул итмичәрәк карап, җавап бирми иде. Тик мин барыбер шулай сәламләүне дәвам иттем. Тора-бара ул күнегә төште шикелле, кул биреп күрешә, хәтта сөйләшә, хәл-әхвәл дә сораша башлады».

Кыргызчага да туры килә торган киң аңлаешлы гомум төрки «ага-агай»дан саф татарча «абзый»га күчү-күнегүнең татарларга карата якынлык хисе барлыкка килүгә беркадәр тәэсир ясаган булуы, минемчә, бәхәссез. Чөнки сиңа карата даими рәвештә хөрмәт күрсәткән кешенең үзенә генә түгел, бәлки аның милләтенә карата да синдә яхшырак мөнәсәбәт барлыкка килә. Бу—мәсьәләнең бер ягы. Икенчедән, кешеләр

гадәттә олыгая барган, үзләренен киләчәге, ягъни гомер чикләре хакында уйлый башлаган саен (ә бу котылгысыз тәрәккыять) узганы, чыгышы, туган-тумачалары, нәсел тамырлары хакында да уйланучан, эзләнүчән булалар. «Нәсел агачы» дигән шәҗәрәләрне, кагыйдә буларак, олы яшьтәге кешеләр, картлар төзиләр, шуларны үз балаларына васыять итеп калдырырга тырышалар.

Һәрхәлдә Ч.Айтматовнын татарларга карата үзгәрүе шундый төрле сәбәпләр аркасында әкрен, бик әкренлек белән, чамалап кына үсә барган булуы миндә шик тудырмый.

1972 елда Казанга килгән чакта, югарыда бер әйтелгәнчә, анын татарлар, безнен әдәбият хакындагы мәгълүматлы булуы, кызыксынуы 1961 ел белән чагыштырганда беркадәре үзгәргән, кинәйгән булса, гасыр ахырына таба әлеге үзгәреш тагын да үсә төшкәнгә охшый.

СССР язучыларынын 1986 елда узган VIII съездында Ч.Айтматов татар язучыларынын бер төркеме белән беркадәре сөйләшкән, бергә-бергә рәсемгә дә төшкән иде. 2000 елда исә ул, Улжас (Олжас) Сөләйманов белән бергә, махсус рәвештә Казанга да килеп, Татарстан язучылары белән кинрәк аралашу юлын эзләде.

Дөрес, бу 2000 елгы сәфәрнен сәбәбе анасы ватанын эзләү, яисә барлау түгел иде асылда. СССР таркалып, мөстәкыйль дәүләтләргә әверелгән элекке төрки республикаларнын язучылары белән рус әдипләре арасындагы элекке тыгыз бәйләнешләр зәгыйфьләнгәч, күпчелек әсәрләре русча язылган, шулай басылган Айтматов һәм Сөләймановларише рус телле «милли» язучыларга Русия эчендәге аерым төбәкләр, бигрәк тә тугандаш халыклар белән элемтә булдыру, аны саклау, ныгыту һичшиксез кирәк вә мөһим иде. Икенчедән, Татарстаннын Русиянен эчендә кала биргән килеш тә «мөстәкыйльлек алуы» (һич югы игълан итүе), рухи-мәдәни яктан тернәкләнә баруы, шушы юнәлештәге тәҗрибәсе дә алар өчен кызыклы булып тоелгандыр.

Гомумән, Чынгыз Айтматовнын сонгы еллардагы иҗтимагый, сәяси активлыгы, Төркия, Казакъстан, Кыргызстан һәм башка җирләрдә оештырылган күпсанлы халыкара форумнарга актив катнашуы, күп очракта лидерлык итүе, «Ауразия—диалог» җәмгыятенен эшчәнлегендә дә үз урынын табуы игътибарга аерата лаек. Ул төрки халыкларнын уяну, күтәрелү, кумәкләшү хәрәкәтләренә ихлас теләктәш була башлады. Димәк, сонгы елларда Татарстанга тартылуынын, мондагы тормыш, үзгәрешләр белән кызыксынуынын сәяси, социаль-иҗтимагый сәбәпләре дә бар икән. Шунадыр, күрәсен, бу 2000 елгы сәфәрендә Чынгыз «ана ватаны» мәсьәләсендә үзен битараф диярлек дәрәҗәдә тыйнак тота. Шул вакыттагы Язучылар берлегенен башлыгы Фоат Галимуллин «никтер» дип гаҗәпләнеп әйткәнчә, Сабантуйларда йөргән Айтматов «бер тапкыр да бу төбәкләрнен кадерле әнисенен ватаны икәнлеге хакында искә төшермәгән» (бу өзектәге «кадерле» төшенчәсенен кемнен сүзе булуы да уйландыра).

Татарстанда аны асылда иҗтимагый, мәдәни, рухи мәсьәләләр кызыксындырган.

Язучылар берлегендә оештырылган очрашуга мин дә чакырылган идем. Сүз, нигездә, әдәбият, иҗат мәсьәләләре тирәсендә барды. Чынгыз үзенен сорауларын мина төбәлеп биргәләде. Мин исә хәлләребез хакында анлы рәвештә унай һәм шомарак итеп җавап бирергә тырыштым. Авызын тулы кан булса да, ятлар алдында төкермә, дигән хикмәтле мәкаль бар бит. Ниһаять, аларнын үз хәлләре дә хәл икәнлеген истә тоттым. Бигрәк тә совет чорында яшьли даими депутатлык дәрәҗәләре, бер-бер артлы яуган зур премияләр, орденнар белән дәүләт тарафыннан кирәгеннән артык иркәләнеп «тешсезләндерелгән», шуна күрә хөкем сөргән гарип системаны тәнкыйтьли алмаган әдипләрдән гаҗәеп зур талантка ия булган Айтматовнын хәле аерата четерекле, иҗади позициясе дә беркадәре каршылыклы иде. Ләкин язылмыйча калган «әсәрләр» өчен тәнкыйть куертып тормыйк: язылып басылганнары да дөньякүләм әһәмиятле, гомумкешелек дәрәҗәсендә кыйммәткә ия.

Милли ан үсә барган, милли азатлык хәрәкәте гел көчәйгән чорда элекке

республикаларда рус телле «милли» язучыларның хәлләре икеләтә шәптән түгел иде. Дөрес, андый «рус телледәрне» элек тә «чукып торганнар», хезмәтләрен, эшчәнлекләрен дә күрмәмешкә салышканнар. Моның кайбер мисалларын мин Ч.Айтматовка карата 1972 елда ук күргән, башка үрнәкләрен соңрак үзебездә дә күзәткән идем. Бер мәлне мәрхүм Гариф Ахунов ачынып әйткәнчә, Фрунзеда Ч.Айтматовның кыргыз киносын булдыру юлындагы тырышлыгының кадерен белмиләр... Шуңа күрә Чыңгызның да, Улжасның да үзгәртеп кору башлануга ук үз ихтыярлары белән «шәрәфле сөрген» язмышын сайлап, ерак илләргә илче булып китүләре бәхет ташуның нәтиҗәсе түгел иде, әлбәттә.

Очрашу тәмамлангач, анда катнашучылардан Ркаил Зәйдулла минем «шома» җаваплардан ачы итеп көлеп куйды: «Нәкъ совет чорындагыча җавап бирдегез!» Әйе, дидем мин, без барыбыз да, кызганыч ки, шуннан чыккан...

2000 елгы очрашуның шулай формаль рәвештә баруы һәм анда кайбер «артык» күз-колакларның да катнашуы аркасында мин Чыңгызга үземне 28 ел дәвамында кызыксындырган, һич тә онытылмаган, ягъни «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» әсәренең язмышы хакындагы соравымны бирә алмыйча калдым. Ул сорау аның үзе өчен дә күңелсез икәнлеген сизүем дә сәбәп булгандыр, бәлкем. Шулай да өметемне өзмәдем, янә бер җае килеп чыгар, тагын очрашырбыз әле дип уйладым (Рафаэль Хәкимевнең миңа берничә кат әйтүенә караганда, Ч.Айтматов һәрвакыт Казанга килү чарасын эзләп торган икән).

Ниһаять, тагын сигез елдан соң, 2008 елда, Чыңгызга шул сорауны бирү мөмкинлеге туа язган иде...

* * *

2008 елның май ае урталарында Чыңгыз Айтматовның Казанга килүе турында хәбәрләр таралды. Казан ягының аны зурлап каршы алуы мәгълүм булды. Язучының 80 еллыгына аның тормыш юлына, иҗатына багышланган «Гасырдан да озынрак көн» исемле кинофильм төшерергә җыенулары хакында да беленде. Шул эш процессында, ниһаять, Кукмара районына анасының ата-бабалары чыккан авылга бару планлаштырганлыгы да ишетелде. (Тик тормышка ашмый калган бу «сәфәрнең» кем идеясе икәнлеге мәгълүм булмаган иде.)

Олуг кунакның көен көйләү, аны сыйлау эшләренә билгеләнгән кешеләрнең берсе, күптәнге танышым, үзе миңа мөрәҗәгать итте. «Әгәр теләгегез булса, сезне һәм тагын бер-ике кешене Чыңгыз Айтматов белән очраштыра алам. Берәр сәгатькә. Әйтик, көндезге чәй, аш вакытында. Янығызда кемнәр буласын гына беләсе иде»,—дип, Рәшит әфәнде Фәсхетдинев ихтимал очрашуның вакытын да билгеләгән иде—иртәгә яки берсекөнгә.

Мин, һичшиксез теләгем барлыгын әйтеп, Разил Вәлиев белән Туфан Миңнуллинның исемнәрен атадым. Шул хакта аларның берсенә шалтыраттым да бугай. Ниятем, әлбәттә, форсаттан файдаланып Чыңгызга әлеге күңелемнән гел китмәгән сорауны, дөресрәге, еллар узу дәвамында аның, сораунының, үзгәргән вариантын бирү иде. Бу юлы инде, дидем үз-үземә, кыюсызланып, тартынып тормаячакмын!

Әлеге хәбәрне алган шул көнне дә, икенче көннең беренче яртысында да 1972 елны тәрҗемә ителгән, 1978 елда, Чыңгыз Айтматовка 50 яшь тулу уңае белән «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» әсәренең тагын бер кат эшкәртелеп, тулырак рәвештә «Казан утлары» журналында басылган бүлеге белән янадан «саташтым». (Журналның шул елгы 12нче санын Фрунзега юбилей бәйрәменә чакырылган Гариф Ахунов алып киткән иде.)

Әйе, минем өчен саташырлык дәрәҗәдә тәэсирле булган иде әлеге тарихи роман! Тарихи роман дигәч, форсаттан файдаланып, тагын бер мәсьәләгә кыскача тукталуны кирәк табам.

Мин үзем, гомумән, тарихи повесть-роман дигән нәрсәләрне укый алмыйм. Бигрәк тә якынрак чор вакыйгаларына багышланганнарын. Чөнки, тарихны беркадәр өйрәнгән кеше буларак, «алай булмавын», иң мөһиме, «була алмавын» белгәнгә күрә, андый әсәрләрнең биш-ун битен укуга ихласым кайта. Ләкин

кинрәк җәмәгатьчелектә, бигрәк тә яшьләрдә тарихка карата кызыксыну тудырыр өчен андый әсәрләрнең дә кирәклеген аңлап, мин матбугатта аларга каршы махсус чыгышлар да ясамадым. Яшьрәк чакта үзем дә Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур»ы белән «Сызгыра торган уклар»ын, аларның бездәге мөһим әдәби экспериментлардан икәнлеген белгәнгә, мәсьәләнең шул ягын да аңларга теләп укыган идем. (Чын тарихи роман жанрының бездә, Мәхмүт Галәү әсәрләрен исәпкә алмаганда, монархчы, совет чынбарлыгында, җүнләп үсә алмавын, Н.Фәттах иҗатында исә шул процесска яңа рух өрелүен онытмыйк.)

Чыңгызның «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» дигән әсәрен мин, чынын әйткәндә, аның иҗатыннан берәр яңа тәрҗемә кирәк булганга актара башлап, аннары йотлыгып укып чыккан һәм яратып тәрҗемә иткән идем. Кыргызча язылган әсәрнең теленә, әдәби сыйфатына сокланган хәлдә. Дөрес, әсәр фабуласының, тасвирланган вакыйгаларның минем өчен яңалыгы да килеп чыкты. Шунысын да кыскача яктыртып узыйм.

...Кайчандыр дөньяны дер селкетеп алган монгол яуларыннан соң, Чыңгызхан, аның угыллары, оныклары оештырган суперимперия таркалып, тагын өч-дүрт гасыр үткәч, көнбатыш монгол кабиләләренең икенче бер күтәрелеше барлыкка килә. XVI йөздә Үзәк Азиянең бер өлешендә хәрәкәт башында монгол телле җонгар-уйрат кабиләләре торган, табигате буенча шактый сугышчан Җонгар (яки Уйрат) ханлыгы оеша. Хәзерге Кытай Төркестанының төньяк-көнбатышындагы Шенҗаң (Синьцзян) регионының төньяк төбәген, Алтай-Тянь-Шань тауларыннан, Монголиянең бер өлешен эченә алган бу зур гына дәүләт XVII йөздә шактый кодрәтле хәрби көчләрнең берсенә әверелә.

XVII гасыр башында шул дәүләт эчендәге кабиләләр арасында көчле ызгышлар туа. Аларның үзара ызгышта җиңелгән, төркиләр тарафыннан «калмак» дип аталган бер өлеше көнбатышка таба күченергә мәҗбүр була.

Әмма бу хәрәкәт гадәти генә күченү булмыйча, юлда очраган башка илләрне, халыкларны яулап пыр туздырган, җәберләгән, талаган әзлекле яу чабуга әверелә. Хәрәкәт, дөресрәге, яу чабулар, иң элек казакъ ханлыклары һәм бәклекләре өстенә ишелеп төшкән авыр бәла-казаларга әйләнә. Кинәт ябырылган яудан тулысынча җиңелгән, туздырылган, таланган кайбер казакъ бәклекләренең кешеләре, бөтенләй кырылып бетүдән куркып, малсыз-атсыз килеш җәяүләп качарга мәҗбүр булалар. Хәлсезләнүдән башка бара алмаган карт-коры, бала-чагалар юл читләрендә ятып кала. Бу качуның «Ак табан чобырынды» дигән (яланаяк каңгыру мәгънәсендәрәк) үз исеме дә бар. Фаҗига хакында риваятьләр, тарихи җырлар киң мәгълүм казакъларда.

Шул рәвешчә үзләренә юл ачкан монголлар, ягъни «калмаклар» утыз-кырык үгез җигелгән галәмәт зур арбаларында, унга-сулга канлы кылыч селтәгән сугышчан җайдаклары белән көнбатышка ургылалар һәм Русиянең көньяк-көнчыгыш чикләренә—Түбән Идел буйларына ук килеп чыгалар.

Әстерхан татарларына, нугайларга, Кырым ханлыгына һәм тынгысыз Кавказ халыкларына каршы көрәштә сугышчан кавемнән файдалану ниятеннән чыгып, патша хөкүмәте, калмак тайчалары (бәкләре) белән махсус килешеп, аларга шул төбәкләрдә (Түбән Идел буенда) тукталу, төпләнеп калу мөмкинлеген тудыра. Хәзер безгә яхшы таныш калмыклар Идел буена менә шулай килеп чыккан калмакларның нәселеннән гыйбарәт (димәк, калмык дигән исем элекке төркичә «калмак» этнонимының варианты гына).

Казакъ-калмак бәрелешләре һәм гыйльми әдәбияттагы аларга бәйле сирәк-мирәк фикерләр, бәхәсләр хакында мин 1972 елда ук, Айтматов әсәрен укыганга кадәр дә беркадәре белә идем. Әмма канлы калмак яуларының кыргызларга да кагылган булуы ул вакытта минем өчен беркадәре яңалык булды.

«Әйләнеп кошлар кайтканчы...» дип мәгънәле рәвештә аталган роман, исеменнән һәм басылган өлешендәге эчтәлектән күренгәнчә, Эссекүлдә (Ыссыккөл) кышлаган кошлар язын китеп, көзен тагын кыш уздырырга шул җылы күлгә әйләнеп кайтканчыга кадәрге вакыт аралыгында калмаклар белән булган кискен бәрелешләргә багышлана. Басылып чыккан, ягъни мин тәрҗемә иткән текст,

димәк, шундый катлаулы вакыйгаларны яктыртырга тиеш эпик рухлы зур әсәрнең беренче, ягъни башлангыч өлеше иде. Шуңа күрә анда төп сүз илбасарларга каршы яуга чыгарга әзерләнү хакында. Сугышка дип атка атланган ир-егетләр арасында Манас дастанын өйрәнә башлап, кабилә-ыруда зур өметләр тудырган Сәнербай угылы Куйчыман да бар...

Текстның тел-стиленнән, гомум рухыннан, мәгънәви ишарәләреннән күренгәнчә, шул дүрт-биш ай вакыт эчендә Эссекүл буе тирәләрендә яшәгән кыргызларның тормышында кискен үзгәрешләр, зур кыенлыклар булырга тиеш...

Ләкин нинди конкрет вакыйгалар булып, нинди ситуацияләр туар, кереш өлештә исемнәре аталган, җиңел штрихлар ярдәмендә Айтматовча истә калырлык образлары тудырылган персонажларга тагын кемнәр кушылыр да, кайсысынын язмышы ничек очланыр? Сугыш мәйданында бәрелешләр нинди нәтиҗә белән тәмамланыр? Гаҗәеп бер йомшаклык, ягымлылык, хәтта үзенчә җылылык белән башланган кыштан соң нинди яз, нинди җәй килер? Ничек килер? Кемгә килер? Ишкәк ишкән сыман салкын һаваны ера-ера еракка киткән казлар, үрдәкләр ничегрәк кайтырлар?..

Укыйсы, укыйсы иде әсәрнең калган төп өлешен. Шул теләктән чыгып мин 1972 елда Чыңгыз Айтматовка аны тәрҗемә итәчәгемне икеләнмичә әйткән идем. Әйе, әсәрнең эчтәлегеннән, анда тасвирланган вакыйгаларның тарихилыгыннан бигрәк (анысы да, әйткәнемчә, кызыклы гына), мине бигрәк тә романның язылу үзенчәлеге, искитәрлек матур теле, сурәтләү чаралары, көтелмәгән яктан табылган хикәяләү алымнары, җыеп әйткәндә, үзенә генә хас әдәби сыйфатлары кызыксындырган иде. Һәм кызыксындыра да.

* * *

...Романның беренче, ягъни башлангыч өлеше кыргызча, аннары татарча тәрҗемәдә чыккач, әллә ни күп тә узмыйча, шул ук текстның автор үзе әзерләгән русча варианты «Плач перелетной птицы» дигән исем белән «Литературная газета»да басылган иде. Димәк, дидем мин, Ч.Айтматов яңа әсәрен бөтенсоюз матбугатында да игълан иткәч, аны тәмам эшләп, эшкәртеп бетергән икән. Димәк, тиздән, вәгъдәсенә муафикъ рәвештә, аның тулы текстын Казанга җибәрергә тиеш. Һәм көтә башладым.

Тик, әйткәнемчә, килмәде... Тиздән гаҗәпләнүләремә тиешле җавап та табылды. Мәскәүдә очраткан таныш казакъ язучыларыннан берсе түбәндәгечәрәк итеп серне ачты. Имештер, әсәрнең әлеге русча варианты чыккач, калмыкларның мәшһүр шагыйре Давыт Күгелтинов—шул чордагы абруйлы дүрт-биш милли әдипнең берсе,—Чыңгыз Айтматовка махсус мөрәҗәгать итеп, «Плач»ның тулы текстын бастырмауны үтенгән. Болай да депортация афәтен баштан кичергән, яртылаш кырылып беткән, тәмам имгәнеп калган мескен халыкка, аның бабаларына карата яңадан нәфрәт тудырырлык әсәр язудан сиңа ни файда? Әллә ансыз да әсәрләрең азмы, дөньякүләм казанган шан-шөһрәтең, абруй-даның җитмиме?!—дип, чал сакаллы йөзен күз яшьләре белән юа-юа елаган, үксегән, имеш...

Күңеле йомшарган Чыңгыз Айтматов, башка халыкларга зарар китерү нияте уенда да булмаган олуг әдип, имештер, «Әйләнеп кошлар кайтканчы...»ны бастырмаска вәгъдә иткән...

Бу сүзләрнең кайсы өлеше хак, нindиләре әдәби фараз икәнлеген ачык әйтә алмыйм, билгеле. Әмма шундый ук мәгънәдәге сүзләрне башка ике-өч кешедән дә ишетергә туры килде.

Чыңгызның иҗатына багышланган язмаларда, аның белән булган күпсанлы әңгәмәләрдә дә әлеге әсәрнең телгә алынуын күрмәдем. Бәлки миңа гына очрамагандыр...

Әле генә тасвирланган тарих, кайсы яктан килеп карасаң да, тирән вә гыйбрәтле мәгънәгә ия. Тарихи дөреслеккә каршы килеп булса да, күз яшьләрен түгә-түгә үз кавеменең мәнфәгатьләрен яклауга ирешә алган Давыт Күгелтиновның гамәлләре, һичшиксез, ихтирамга, соклануга лаек. Сирәк ир-агалары гына андый кискен адымга бара ала, унай нәтиҗәләргә ирешә.

Икенче бер кавемнең тирән фаҗигасен, моң-зарын аңлап, аның үтенечен кабул

итүе белән Чыңгыз Айтматов та чын олы җанлылык, чын кешелеклелек үрнәген күрсәткән ир-егет булып калды. Дөреслекне яклыйм дип шәррән ярып әйтергә ярамаган дөреслекләр дә бар. Мәсәлән, әҗәл түшәгендә ятучыга әйтелә торган юату сүзләре. Тәгәл бер халыкка карата начар мөнәсәбәт, нәфрәт тудырырга сәләтле дөреслекнең дә бердәнбер хакыйкать сыйфатында әйтелмәве хәерлерәк. Мисал кирәк булса, «монгол-татар яулары» хакындагы берьяклы тоталь хөкемнең нәтиҗәләре хакында төптәнрәк уйлану да җитеп торыр. Бигрәк тә Русия кебек сәер илдә...

Мәсьәләнең менә шундый үзенчәлегеннән чыгып, минем 2008 елда Чыңгыз Айтматовка бирәсе, бары аулакта гына бирәсе сорауларымның эчтәлеге, максаты да, элеккеләреннән аермалы буларак, шактый башкача яңгырарга тиеш иде...

Рәшит әфәнде Фәсхетдинов Чыңгыз Айтматов белән очрашу ихтималы барлыгы хакында әйткәч, мин, әлбәттә, утыз елдан артык күңелне кытыклаган сорауны бирергә җыенган идем. Тик беркадәр үзгәргән вариантын биргән булыр идем. Иң элек соравым шулайрак яңгырар иде: Күгелтиновка биргән вәгъдәгез вакытлымы, гомерлек идеме, әллә мәңгелекме?..

Әгәр Чыңгыз ачылып җавап бирә калса, роман текстының язмышы хакында да белергә теләр идем—оригиналы сакланганмы, русча варианты тәгәл эшләнгәнме?..

Әмма ләкин язмыш бу юлы да саран, кырыс, хәтта мәрхәмәтсез булып чыкты. Рәшит әфәнде икенче көнне төшкә кадәр шалтыратмады. Төштән соң исә Казан кирмәнендә йөргән чакта Чыңгыз Айтматовка «йөрәк өянәге» булуы, аны шунда ук хастаханәгә илтеп салулары турында хәбәр таралды.

Ике-өч көннән өянәкнең бөердә икәнлеге беленә һәм әдипне Алманиягә алып китәләр...

Нюрнберг шәһәренең махсус хастаханәсендә дәваланып яткан Айтматов, кризис уза төшкәч, хәл белергә баручыларга хастаханәдән чыккач Казанга кайтачагын әйткәнлеге дә ишетелде. Кайбер татар журналистлары Кукмара ягына барырга теләгәнлеген дә өстәп куйган иде.

Ләкин хастаханәдән чыгарга да, Казанга әйләнеп кайтырга да насыйп булмаган икән Чыңгызга...

Минем утыз елдан артык күңелдә асраган соравымны, шулай итеп, эчтәлеге үзгәргән хәлдә дә, аңар бирергә насыйп булмаган икән... Хәзер инде ул гыйльми трактатка әверелә язган бу сәер истәлегемнең туууына сәбәп хәлендә, үзенә җавап булмаячагын белгән килеш, төпсез бушлыкка карап яңгырап торыр...

Азмы-күпме дәрәҗәдә дөрес җавапны, бәлкем, бездән соңгы буынның вәкилләре генә белә алыр.

Нинди васыять калдырганлыгы, аның ничек үтәләчәге дә билгеле түгел бит. «Үлгәннәрнең сүзен тереләр тыңламас», дигән борынгы бер хикмәтле төрки мәкаль бар...

Чыңгыз Айтматовның гомум иҗатына, бу гаҗәеп якты, чын ихлас иҗатның тулаем әһәмиятенә, гомумкешелек дәрәҗәсендәге кыймметенә, шулай ук язучының тормыш юлына, тәрҗемәи хәлендәге кайбер үзенчәлекләргә килсәк, югарыда китерелгән мәгълүматларга, әйтелгән фикерләргә таянып, мин үзем өчен—әйе, үзем өчен—түбәндәге нәтиҗәләрне чыгардым: бөек язучы Чыңгыз Түрәкол угылы Айтматов үзен катгый рәвештә кыргыз кешесе һәм кыргыз әдибе итеп тойган, инанган, шул иманда торып иҗат иткән, ахыргача шулай калган бербөтен—бүленмәс шәхес; шундый иман ныклыгы, ихласлыгы аны гомумкешелек югарылыгына күтәргән; әгәр аның олы иҗатын хөрмәт итүебез ихлас булса, аның кемлек хакындагы ихтыярын да берсүзсез танырга, кабул кылырга тиешбез; шулай гына ул барыбыз өчен дә уртак була ала.

*Наратлы—Казан*
*2008—2009*

Марсель
Әхмәтҗанов

# НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ ТУРЫНДА ХАТИРӘЛӘРЕМ

*Нәкый ага белән якыннан таныша башлавым 1967 елның 22 декабрендә Казан университетында уздырылган очрашу кичәсеннән башланып, бөек язучы һәм галимебез гомеренең соңгы елларынача барды.*

*Мин аның белән очрашуларның һәркайсын диярлек озакка калдырмый кәгазьгә терки бара идем. Алар соңгы вакытта Н. Исәнбәт исталегенә, аның каләм мирасына күләгә төшерергә маташучыларга һәм аның 35 томлык әсәрләр җыелмасы чыгуны өзгән кешеләргә бер рәнҗү булып та барып ирешсен иде.*

### Беренче мәртәбә танышуым

1967 ел. Мин бу чакта Казан университетының тарих бүлегендә кичен укып йөрим. Лекцияләр дүртенче каттагы аудиторияләрдә уза иде. Лобачевский урамындагы бу бинаның калган өч катында химия факультеты иде, һәм ул шул бинада калды да.

22 декабрьдә кич укырга килгәч, бер игъланга күзем төште. Анда бүген кич 7дә атаклы язучы Нәкый Исәнбәт белән очрашу буласы әйтелгән иде. Лекциябез сәгать 7дә башланганга, мин бик кызыксынсам да күрсәтелгән вакытта очрашуга керә алмадым. Минем бәхеттән, лекторыбыз лекциясен алданрак төгәлләде тагын.

100нче аудиториягә киттем. Ләкин очрашуны бүтән урынга күчергәннәр икән. Татар теле кафедрасы алдында бер төркем студентлар күреп, шунда килдем. Студентлар арасында Арча районы Иске Өҗем авылыннан танышым Равилне күреп, аның белән сөйләшеп алдым. Очрашуга университетның һәм педагогия институтының татар теле бүлеге студентлары килгән икән, тәнәфескә чыкканнар. Бер заман каршыдагы ишектән Нәкый ага белән берничә университет укытучысы килеп чыкты. Мин фәкать әдәбиятчы Ибраһим Нуруллинны, безгә лекцияләр укыган Индус Таһировны гына таныдым. Студентлар бар да ашыгып аудиториягә кереп тулдылар. Равил мине алдагы урынга чакырып утыртты.

Нәкый ага ак күлмәктән, галстуктан, карангырак төстәге костюмнан иде. Өстәл артында бик җанлы утыра, кысыграк күзләре белән бик тере карый, йөзе алсуланган, тавышын күтәрми, салмак кына сөйли, бик килешле сөйләшә. Ул аудиториягә карап: «Сез миңа сораулар бирегез, миннән белергә теләгәннәрегезне белеп калыгыз»,— дип, сүзен башлап җибәрде, аны бик бирелеп тыңлыйлар иде. Тыңлаучыларны ул көлдереп тә ала, сүзен берничә темага бүлеп алып барган кебек тәэсир калдырды.

—Мин кечкенә чакта К. Насыйриларның, Тукайларның, Гафуриларның әсәрләрен һәм шул елларда чыккан газет-журналларны укып бара идем,—диде Нәкый ага.—Мин, 11 яшьтә шагыйрь идем. Безнең заманда 12 яшьтә шагыйрь булу соңга калу иде инде ул.

Малаязда, бала чагында ук, ул газет-журналларга шигырьләрен җибәреп бастыра

торган булган. Һәм «Нәкый әфәнде, быел да безнең журналга (яки гәҗиткә) язып торыгыз инде» дигән үтенеч хатлары алган. Ә мин, 15 яшьлек малай, башка балалар белән бергә ат-ат уйнап йөри идем,—диде Нәкый ага.—Уйнап туйгач, өйгә кереп әче катык белән бәрәңгене корсакка тутыргач, бер шигырь язмый булдыра алмый идем. Минем күп шигырь-поэмаларым ул вакытта «Аң» кебек алдынгы журналларда басыла иде. Шагыйрьлек ул тумыштан була, Мусалар, Такташлар 11 яшьтә шагыйрь булганнар». Нәкый ага 11 яшьтә чакта ук шул чордагы татар сатирик журналлары йогынтысында кулдан язып журналлар чыгарган, шунда өч исемдә аларны атап та күрсәтте.

Берсенен исеме «Күсәк» булган. Шәһәр халкының коралы чүкеч булса, авылның коралы Күсәк, дип тә өстәде ул. Журналдагы бер рәсемдә бер яшь егет күсәк тотып басып тора иде, рәсем янында авылны наданлыгыннан шушы күсәк белән тукмап уятырга кирәк дип язылган шигырь дә булган. Нәкый ага: «Бу хулиганнар күсәге түгел инде, мәгърифәткә өндәүче «күсәк»,— диде. Ул әлеге журналларның кайберләре әле дә булса үзендә саклануын әйтте. «Шагыйрь булу өчен котыртып торучы кеше кирәк ул. Минем бер укучым, җингәм бар иде. Мин язып бетергән әйберләремне аңа күрсәтә идем. Ул, аларны укыгач, эче катып көлә торган иде». «Бездән шулай иртә, 11 яшьтә шагыйрь булырга, күрәсең, заман үзе таләп иткән. Революциядән соң (1905 елгы), кадрларга ихтыяҗ зур булган. Без, шуңа җавап рәвешендә, тиз житешкәнбез.



*Уңнан сулга: балетмейстер Гай Таһиров, хатыны актриса Галимә Ибраһимова, Нәкый Исәнбәт, хатыны Нәҗибә апа. «Васильево» санаториендә. 1981 ел.*

Бүгенге көндә татар язучылары бик аз. Исәпләүләрем буенча, 1913 елда гына да татар матбугатында язышкан 400 шагыйрь бар иде. Революциягә кадәр татар әдәбияты Русиядә, рус әдәбиятыннан кала, зурлыгы буенча икенче урында иде, яисә украин әдәбияты белән рәттән тора иде. Аварлар кебек берничә меңле милләтләрнең 40-50 язучысы бар, ә 4 миллионнан артык татар халкына 100 язучы булу бик аз, бу хәл мине бик борчый. Безнең язучылар грузин һәм әрмән язучыларыннан да күбрәк булырга тиеш, чөнки сан буенча алар бездән аз бит. Сез яшьләр яңа кадрларны эзләп табарга, аларны үстерергә тиеш. Дөрес, безнең язучылар сыйфат ягыннан хәзер яхшырак язалар, ләкин алар аз.

Революциягә кадәр татар кызларыннан язучылар аз иде—Гыйффәт туташ, Маһруй Мозаффария, Хәбирә Насыйрия, Хәбибҗамал Акчурина һ.б. Алар көчле шигырьләр, хикәяләр яздылар. Мәсәлән, Гыйффәт туташның «Мин яшь әле...» дип башланган шигыре бик күңелдә калган. Бу шигырьдә дәрт, сафлык, хезмәткә, көрәшкә әзерлек нинди матур әйтелгән... Мин Октябрь революциясе булгач әдәбиятка бик күп хатын-кызлар килер инде дип өмет иткән идем, кызганычка каршы, алай булмады. Аларны тормыш мәшәкате бастымы, безнең ирләр эгоизмы киртә булып тордымы, ачык әйтә алмыйм. Татар хатыны әйбәт ул, түзем, сабыр. Аңа башка милләт вәкилләре дә өйләнәләр, яраталар аны. Без аның сабырлыгыннан артык файдаланмыйбызмы

соң? Хатын-кыз хисчәнрәк, тирәнрәк анлый бит ул, алардан менә дигән язучылар чыгар иде татар әдәбиятына. Урыс әдәбиятында алай түгел, анда атаклы язучылар, лауреатлар бик күп, ярты урыс әдәбиятын инде хатын-кызлар иҗат итә, бездә дә шул булсын иде, моны булдыруда сез эшли аласыз, яшьләр.

Бездә яшь язучылар Марстан тәлинкәгә утырып төшкән кешеләргә ошыйлар. Татар халкының инде революциягә кадәр үк зур әдәбияты булган. Аңа Горькийлар, Веселовскийлар һ.б. зур бәя биргәннәр. Татарлар арасында инде XIX гасырда мәдрәсә бетергән, ә аннан соң урыс мәктәпләренә кереп укыган алдынгы кешеләр булган. «Хөсәения», «Галия», «Мөхәммәдия» һ.б. зур мәктәп-мәдрәсәләр бар иде, XIX гасырда ук инде татар университеты ачарга талпынулар булган. Татар культурасы коры җирдә генә кинәт үсеп китмәгән, ерак традицияләр нигезендә үскән. Бездә борынгы әдәбият, культура калмаган, аны Иван Грозный җимереп бетергән, татар культурасы удмурт, чуаш, чирмеш культуралары дәрәҗәсендә генә үскән, диючеләр бар. Хәзерге тарихчылар да татар халкының культура дәрәҗәсе турында урыс фәнендәге чыганакларга карап кына фикер йөртәләр, ә аларны бит фанатик христиан монахлары язган. Алыйк Иван Грозный походын, бу бит тәре походы. Иван Грозный иң элек Казан каршына сал белән агызып китерелгән бүрәнәләрдән чиркәү сала. Аннан ике бистә арасына кабыктан палатка корып, шунда бертуктамый чукынып яткан. Казанны алгач, 6 яшьтән 60 яшькә кадәрге барлык кешеләрне суйдырып бетергән. Казанга татарлар соңыннан гына җыелганнар. Монда күп нәрсә юкка чыккан: йортлар, сарайлар, мәчетләр, мәдрәсәләр, китапханәләр фанатик урыс монахлары тарафыннан яндырылган. Алар үзләренең елъязмаларына да татарларны начар яктан, карага буяп язганнар. Болгар, Алтын Урда заманнарында татар халкының зур культурасы булган. Ул культура үзе башка культуралар үсешенә тәэсир иткән. Бүгенге көндә татар культурасына урыс культурасы тәэсире ничек булса, ул чорда татар культурасы урыс культурасына шундый йогынты ясаган. Алыйк мисаллар: чуен. Чуенны Болгар шәһәрендә XIII гасыр ахыры, XIV гасырның беренче яртысында—Европадан ике гасыр элек коя башлаганнар. Ул болгар-татарлардан исеме белән бергә урысларга кергән. Мишәрләр әйтә ди: «Бу татарлар бер дә дөрес сөйләшмиләр, чулканы оек дип әйтәләр»,—дип. Без көлүен көләбез дә, мишәрнең сүзендә хаклык бар икән, «чулка» сүзе үзе «чолгау» дигән сүздән килеп чыккан икән. Башка төрки халыклардан әзәрбайҗаннарда, казакъларда да оекны «чүел» дип әйтәләр икән. Татар теленнән урыс теленә бик күп атамалар кергән. Мәсәлән, тулуп, кафтан, кушак, колпак, дюрбень, халат, башлык, бурка (бөркәнчек), чекмень һ.б. Бу татар культурасының йогынтысы хәзерге көнгә кадәр бер дә өйрәнелмәгән әле. Моны интернационализм ныгуның ерак чыганаклары дип карарга мөмкин. Сез бу өлкәдә зур эшләр башкара аласыз»,—дип Нәкый ага елмаеп студентларга карап куйды.

Бераз уйланып, пауза ясап, «арыттыммы?»,—дип күзләрен кыскалап алды да, «Юк!»—дигәнне ишеткәч, янадан сүзгә кереште:

—Татар халкының культура мирасын ныклап өйрәнү тиеш. Мин үзем быел эш белән Ленинградта булдым. Шунда Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәнең кульъязмалар бүлегенә кереп утырдым. Монда 3 меңнән артык борынгы татар кульъязмасы саклана. Алар өйрәнелмәгән. Мин кереп утыргач, әһә, бер татар абый да кереп утырды әле, диделәр. Гомумән, Ленинградта татар әдәбияты истәлекләре күп, алар үзләренең өйрәнүчеләрен көтеп яталар. Бер заман мин утырган җиргә 20ләп үзбәк килеп керде, алар китаплар алдылар да, татар китаплары буенча өйрәнә башладылар. Үзбәкләрнең, казакъларның, төрекмәннәрнең культура истәлекләре сакланып калмаган, алар үзләренең узганнарын татар әдәбияты аша өйрәнәләр һәм шуңа ябышып яталар.

Татар әдәбияты бик зур булган ул. Аның хәзерге көнгә хәтле истәлекләрен җыеп бетерә алганнары юк. Аларны берәмтекләп җыярга кирәк. Әби-бабайларның җаеннан торып сөйләшсәң, алар бернәрсәләрен дә җәлләмиләр. Сез менә яшь, экспедицияләргә чыгасыз, ул эшләрне сез башкара аласыз бит. Мин карт инде, мин чыгып йөри алмыйм, мин чыксам, әллә нәрсәләрен таба алыр идем дип ышанам.

Кульъязмалар саклану ягыннан Казан университеты китапханәсе СССРда иң

зурлардан, анда 13 меннән артык татар кульязмасы саклана. Аларны өйрәнү өчен гарәп язуын, гарәп-фарсы телләрен белергә кирәк. Бу хәзинәләргә ачкыч шунда. Аны сезгә университетта бирәләр. Шуны файдалана белергә кирәк. Мин вакытым сыйдырганда кергәләп чыгам анда. Ленинградта мин авырдым, мина анын һавасы ярамады. Бер кульязма китап алган идем, дин китабы диеп язган тышына. Укып карагач, алай ук түгел икән, анда урта гасырларда татар кешеләре урыслар белән эш иткәндә үзләрен ничек тотарга тиешлек кагыйдәләре язылган булып чыкты.

Алдым тагын «Бәхтиярнамә» дигән XV гасыр китабын. Бездә урта гасырларда шигырьләр, поэмалар гына язылган дип уйлыйлар, ә бу исә чәчмә әсәр, роман булып чыкты. Ул урта гасырлардан калган рыцарьлык романынын матур бер мисалы булып тора. Болгар-Казан чорыннан безгә әдәбият үрнәкләре калмаган диләр. Бар ул, эзләргә генә кирәк.

Нәкый ага бер Америка язучысы хикәясен мисалга алып сөйләп китте. Хикәядә карабларнын ярга бара алмаулары бәян ителә. Ана дошманнар туплардан аталар. Карабтагы халык сусызлыктан бик интегә. Йөри торгач, бер урында—дингез эчендә туктыйлар. Дингез суы тәмсез, эчәргә ярамый. Кешеләр аптырап, янып үлү дәрәҗәсенә житәләр һәм капитаннан: «Нишлик?»—дип сорыйлар. Капитан: «Торган жирегездән сосыгыз!»—ди. Карабтагы кешеләр аны анламыйлар. Капитан берничә мәртәбә шул сүз белән жавап бирә. Аптыраган кешеләр чиләк төшереп дингез суын алалар, алсалар, эчәргә яраклы төче су була. Караб туктаган урын зур бер елга тамагы икән. Елга суы берничә чакрымнар дингез эченнән ага икән. Идел елгасы да Каспий дингезе эченә 80-100 чакрым кереп ага. Менә мин әдәби ядкарьләр юк диючеләргә дә торган жирегездән сосыгыз дияр идем.

Бер мәлне минем кулыма бер борынгы кульязма китап керде. Ул бик иске иде. Аны бала чагымда укыганымны исемә төшердем. Кәефем яхшырак булса, йоклар алдыннан кулыма берәр китап алып ята торган идем. Менә шундый бер кичтә мин теге китап белән танышып чыктым. Бу бик кызыклы әкият китабы иде. Исеме «Женстанга сәяхәт».Язылу вакыты һәм язылган урыны күрсәтелмәгән. Мин аны тел жәһәтеннән тикшерә башладым һәм анда борынгы «болгар» телендәге «әжен? нөжүн?» (бу сүз хәтеремдә дөрес янгырашта калмаган—М.Ә.),—хәзерге телебездә «дөнья» дигән мәгънәгә туры килгән сүз таптым. Димәк, бу безгә гарәп дине килеп кергәнче, исламгача әдәбият үрнәге булып тора. Анда төрле мажаралы илләргә йөриләр, бер тауга менәләр, анда бөтен дөньяны күрсәтә торган прибор табалар (безнеңчә, спутник-телевизор). Күрәсен, шул чорларда ук инде бөек ачышлар турында хыялланганнар... Ә теге «Бәхтиярнамә» китабынын мин, көнчыгышны өйрәнүчеләр каталогыннан карап, XV гасырдан калган ядкарь икәнлеген белдем. Менә шулай «торган жирегездән сосыгыз!»—дип, «Аларны өйрәнү сезнен бурыч»,—дип, Нәкый ага туктап калды.

Аннары янә: «Сез мина үзегезне кызыксындырган сорауларны бирегез, белеп калыгыз»,— дип өстәп куйды.

—Менә мин шундый эзләнүләр нәтижәсендә Мөхәммәдъярнын «Нуры содур» поэмасын таптым. Аны Казанда таптым. Ул поэма Казанда язылган булган, ләкин Иван Грозный заманында аннан алып чыгылган (бәлкем, тагы да бардыр әле шундый әсәрләр). Ык елгасы тирәсендә күчерелеп, яңадан Казанга кайткан. Аны ничек табуым турында мин 1941 елны «Совет әдәбияты» журналында (№ 4) язып чыккан идем. («Мөхәммәдъяр Мәхмүд углы әсәрләренең табылу тарихы бик кыска: 1940 елнын жәендә Казан базарында иске-москы кәгазьләр, китаплар актарганымда, шулар арасыннан сайлап алынган кульязмаларнын бер өлеше анын әсәрләре булып чыкты»,—Нәкый ага журналда шулай дип язган.—Ред.) Минем кульязмаларны күргәч, син бай икән диләр. Мин аларны халык арасыннан жыйдым. Халыкта алар хәзер дә бар.

Мине кызыксындырган нәрсә тагын халык ижаты, тел. Мин бала чагымнан ук Каюм Насыйри сүзлекләрен күреп, үзебезнең якнын (Малаяз авылы) сүзләрен жыя башладым. Жырлар, мәкальләр, табышмаклар—барсын да жыйдым. Минем хәзер төзелеп беткән зур «Татар теленең сүзлеге» бар һәм мин шулай ук хәзер дә

басылмаган «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзедем. Аларны бастырырга теләсәм дә, басмыйлар, кәгазь юк, план, дип, төрле сәбәпләр табалар. Сүзләр, мәкальләр бик зур түземлелек сорый торган вак эш. Безнең халыкта андый түземлелек билгесе юк. Мондый сыйфат немецта гына бар. XIX гасырда немец галиме Радлов эшләре моңа мисал булып тора. Ул кышкы Себер салкыннарыннан курыкмыйча, чанага утырып иң ерак төрки халыкларга, кабиләләргә барып житә, аларны өйрәнә, халык иҗаты материалларын җыя, сүзлек төзи. Аның сүзлеге бүгенге көндә дә әһәмияткә ия. Без аннан аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәсен беләбез.

Мина да мондый зур түземлелек әниемнән күчкән. Ул авыру иде. Җәй көне ишек алдына чыгып, төрле догалар укып йөрер иде. Каз мамыгы очып барса, аны тотып алып, биленә кыстырып куя һәм шулай итеп көзгә кадәр бер мендәрлек мамык җыя иде.

Менә мин дә шулай бөртекләп 50мең чамасы халык мәкален җыеп бастырып чыгардым. Хәзер 5 меңнән артык табышмакны эченә алган җыентык төзеп ятам. Ул басарга әзер диярлек инде. Миндә шулай ук җыр-бәет һ.б. буенча материаллар бик күп, ләкин мин аларны эшкәртеп тәртипкә салырга өлгерә алмыйм. Мин аларны бала чактан ук әби-бабайлардан сорашып җыя торган идем. Менә күптән түгел генә «Татар мифлары» дигән хезмәтемне «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басарга бирдем. Редакторлар аны ничек итеп басарлар инде, өзгәләп бетермәсләрме?!.

Алыгыз грек мифларын. Аларга бөтен дөнья соклана. Ә алар бит халык иҗатына нигезләнеп язылганнар. Халык иҗатын белми торып оста язучы булып булмый.

Шуннан соң Нәкый ага сораулар көтеп тынып калды.

Профессор Ибраһим Нуруллин: «Нәкый ага, драматургиягез турында да сөйләмәссезме?»—дигәч, Нәкый ага сүзен халык иҗатына бәйләп түбәндәгечә башлап китте:

—Менә күпләр татар халык җырын башы бер төрле, ахыры икенче төрле булган бернәрсә дип карыйлар. Хәтта Тукай да шундый караштa булган. Бервакыт мин җырлар дәфтәрен актарганда (мин яшь кызларның җыр-истәлек дәфтәрләрен җыя идем, кайсыларын алам да бирмим, алар соңыннан кияүгә чыккач, кирәкми дип үзләре дә бирәләр иде). Шунда бер җырга күзем төште.

*Аклы ситсы куймәгемнең*
*табалмадым ишләрен.*
*Гомрем буйларына, Рәйхан,*
*онталмасам нишләрем.*

Тукта, мин әйтәм, бу бит алай түгел (теге фикер кебек), монда бик тыгыз бәйләнеш бар. Аклык—сафлык билгесе. Димәк егет, шундый саф сөйгәнен аклы ситсыга охшата, аны үз гаебе белән ташлый, аннан үкенеп эзли, ләкин соң була. Ул сөйгәнен таба алмый. Бу драма бит—җырның дәвамы драма булган. Менә шуннан соң мин «Рәйхан»ны яздым.

Мин беренче драмамны бала чакта, 13 яшьләрдә яздым.

Мине авылның берничә җилкуар шәкерте акча урларга котырттылар. Мин акча урладым, тотылдым, әти моның кемнәр эше икәнен белде... Кирәкле кешеләр җәзасын алдылар. Бу вакыйганы мин сәхнә әсәре итеп өч пәрдәдә яздым. Ул миндә сакланмаган. Бала чакта язган икенче, өченче әсәрләрем әле дә үземдә сакланалар.

Гражданнар сугышы елларында авылларда әледән-әле театрлар, концертлар куела иде. Репертуар юк иде. Авыл яшьләре минем язганны белеп, мина киләләр, ашыгыч булганга, мин бик тиз, өч көн дигәндә сәхнә әсәре язып бирә идем. Аны сәхнәдә суфлерлар ярдәмендә куялар иде. Мин сатирик планда язарга ярата идем. 30нчы елларда минем «Культур Шәңгәрәй» һәм «Портфель» комедияләрем зур шау-шуларга сәбәп булдылар.

«Культур Шәңгәрәй» Мәскәүдәге урыс театры каршындагы татар труппасы тарафыннан куелды. Тамашачылар төркемнәргә бүленеп, капма-каршы яклар

барлыкка килде. Монда пролеткультчылардан көлеп язылган иде (комедиядә). Шәнгәрәй мәчетләрдә концерт куя, хатыннар барлык кешенеке дә дип бөтен кешенең ачуын китерә торган хәлләр ясый. Бу пьеса өчен мине бик сүктеләр.

Совет Гогольләре кирәк диләр, әллә Тукай дөрес әйткән микән дип тә уйлап куям. «Гоголь иң элек бөтен кешене карага буйый да, аннары алардан үзе көлә»,—дип.

Шуннан соң Уфада минем «Портфель» дигән комедиям куелды. Монда бар да бер начальниктан, аның портфеленнән куркалар. Үзе югында портфелен ачып карасалар, анда мунча киемнәре, наган һәм кишер генә күрәләр. Комедияне караган кайберәүләр «Егетләр, бу совет портфеленнән көлү бит!»—диде. Уфадагы шул чор матбугатын ачып карасагыз, минем анда—Уфада яшәрлегемне калдырмаганнар иде.

Шушы хәлләрдән соң мине, «жидегәнче» дип гаепләп, төрмәгә дә ябып куйдылар. Мин анда бик күп акыл җыйдым. Димәк, болай ярамый, «Гогольләр» кирәген кирәк тә, тик аларны яратмыйлар икән, бүтән болай язмыйм дигән нәтиҗәгә килдем һәм икенче төрлерәк яза башладым. Шуннан соң, менә син хәзер әйбәт язасың инде, диделәр. Мин ул чакта пьесаларны бик тиз яза идем. «Зифа»ны Кавказга ялга киткән көнне яза башладым, ялдан кайтканда драма әзер иде инде.

Мин драманың иң элек соңгы пәрдәсен язам, шуннан соң бөтен агымны шуна юнәлдерәм. Дөрес, соңгы пәрдә соңыннан барыбер үзгәртелә, ләкин болай язу отышлы була.

Тарихи драмаларны—«Вахитов», «Муса Җәлил», «Идегәй»не мин озак яздым. Аларны язуы читен. Анда тарихи дөреслекне сакларга да кирәк, үз сүзеңне әйтергә дә кирәк. Мин аларны кабат-кабат эшлим. «Муса Җәлил» трагедиясенең вариантлары, эшләре үзе бер китап, шуннан да артып китте...

Бу истәлек тулы түгел, чөнки минә ашыгыч рәвештә очрашудан китәргә туры килде.

Соңыннан, Нәкый агага аның «университет лекциясе» турында сөйләгәч, ул миңа: «Бу очрашу өчен мине органнарга чакырып бик интектерделәр»,—дип әйтеп куйды.

**1975 ел, 27 июнь, Казан.**

Бауман урамындагы китап кибетенең букинистика бүлегендә Альберт Фәтхи һәм Әбрар Кәримуллиннар белән очрашырга туры килде. Китап кибетенең Альберт белән җәйге археографик экспедиция планнары турында сөйләшеп алдык, аңа үземнең Арча район газетасында басылган «Арча ягының борынгы тарихы» исемле мәкаләмне дә күрсәттем. Шул вакыт кибетнең татар китаплары бүлеген карап йөреп, безнең янга Нәкый ага Исәнбәт килеп туктады. Кулында берничә яңа китап та бар иде. Ул безнең белән хәл-әхвәлләр сорашып, сөйләшеп алды. Шуннан соң Альберт һәм Әбрар Кәримуллин китеп бардылар, без Нәкый ага белән сәяси китаплар бүлегенә кердек. Мин аңа яңарак кына басылган, Татарстанга багышланган «Социальное и национальное» исемле, статистик-социологик эчтәлекле китапны күрсәттем, кыйммәтле мәгълүматларга бай, дидем. Нәкый ага ул китапны сатып алды. Шуннан соң без аның белән кибеттән чыгып, Бауман урамының сул ягы буйлап Куйбышев (хәзерге Тукай) мәйданына таба киттек. Мин аның китапларын күтәреп бардым. Урамның «Татар ашлары йорты» турысына килеп җиткәч, безгә әдәбият галиме Хәсән Хәйри очрады. Юри генә бераз сөйләшеп торгач, киттек. Бераз баргач, ул миңа: «Бу кеше безнең шикелле партиясезләрне бик җәберләде»,—дип әйтеп куйды. Юлда минем диссертация эшем һәм археографик экспедицияләргә йөрүем турында кызыксынып сорашты. Аңа мин, «Вузовец» кинотеатры янына җиткәч, укып торырга дип Арча район газетасының минем мәкаләм басылган саннарын биреп тордым. Бер өч көннән кереп чыгармын әле, дип, Нәкый аганы таксига утыртып өенә озатып калдым.

## 1975 ел, 30 июнь.

Нәкый аганың Товарищеская урамындагы фатирына килдем. Мин кергәндә ул ял итә иде. Хатыны—Нәҗибә апа каршы алды, хәзер торыр инде ул, китми тор,—дип,—Нәкый ага, сезгә кунак бар,—дип, аңа киенергә булышты. Нәкый ага белән исәнләшеп, зур залга кердек. Аның өстендә халат иде. Бүлмәгә кергәч, утырдык. Нәкый ага миңа моннан берничә ел элек тел, фольклор, йола материаллары язылган дәфтәремне кайтарып бирде. Аны мин узган очрашуда сораган идем, табып куйган икән. Минем газетадагы «Арча ягы тарихыннан» дигән мәкаләне укый алмадым диде. Шуннан соң мин аңа мәкаләне кычкырып укып чыктым, ул бик игътибар белән тыңлап утырды. Укып бетергәч: «Бик әйбәт булган, мондый мәкаләләрне күбрәк язарга кирәк, яңа материалларың да бар, искеләрен дә берләштергәнсең»,—дип, уңай бәя бирде. Шуннан соң ул миңа Түбән Оры һәм Олы Мәңгәр авылларында кулъязмалар табылу ихтималы зур булу турында сөйләде.

Мин аңа бер кулъязма битендә укыган

*«Карагайлы кара урман,*
*Үтәр көнем булырмы?!—...»*

дигән шигырьне сөйләдем. Ул бик җанланып тыңлады һәм, кара әле, Әхмәтҗанов, син аны миңа алып кил әле, минем дә шундыйрак әйбер бар иде,—дип куйды. Мин, ярар, дип вәгъдә бирдем. Тагын бераз сөйләшеп утырдык. Бу истәлек әлеге очрашудан соң берничә айлар үткәч кенә язылды, күп сүзләр онытылган иде инде.

Н. Исәнбәт белән Һади Такташ Донбасстан йөреп кайтканда, Галимҗан Ибраһимов безгә Казанда көн күрсәтмәс инде дип фикер алышканнар. Шуннан соң Нәкый ага туп-туры Уфага китеп барган.

(Бу сүзләрнең нигезендә Нәкый аганың Г. Ибраһимовның 1920-1921 елларда «Алмачуар» хикәясенә карата язылган усал телле бәяләмәсе яткан булса кирәк— М.Ә.).

## 1976 ел, 8 июль.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының текстологлар бүлмәсе. Нәкый ага кичке бишләрдә килеп, Рашат Гайнанов белән сөйләшеп утырган. Кичке алтыларда киткән, Рашат абый миңа моны үзе сөйләде.

Нәкый Исәнбәт ага Г. Тукайның яңа басмасының икенче томын алган булган, III, IV томнар кайчан чыгар икән дип кызыксынган. Томнарга карата үзенең фикерләрен әйткән, кайчан яклыйсың инде диссертацияңне дип тә сораган.

## Күп еллар элек сөйләгәннәрдән

—50нче елларда минем драма әсәрләре җыентыгым басылырга әзерләнгән иде. Ул басылды да, ләкин чыгарылмады. Шуннан соң мине гаепләү башланды. Үги улым Булат Гыйззәтуллин Мәскәүгә барырга киңәш итте. Ул вакытта астма белән авырый идем. Көчкә генә, хәлсез хәлемдә Мәскәүгә поездга утыртып җибәрделәр.

Анда йөргәч, мине тыңладылар, бар, бабай, борчылма, кайт, дип җибәрделәр. Бу хәл 1952 елда булды.

Кайткач, берникадәр вакыттан соң мине Зиннәт Моратов үзенә чакыртты. Кердем, диванга утыртты, яныма килеп әйбәт кенә сөйләште. Минем гаебем юк, мин инженер кеше, менә «ике лауреат» язып биргәч, ышанмый хәлем булмады, диде. Шикаять язучылар мине «Миркәй белән Айсылу» драмасында Мәрҗани исемен телгә алган өчен гаепләп язганнар икән. Моратов, сиңа күрсәтергә ярамаса да күрсәтәм дип, аларның әләкләрен дә күрсәтте.

Бу истәлек күп вакытлар узгач, 1977 елда язылды. Шунлыктан кайбер әһәмиятле сүзләр онытылып та калгандыр инде.

## 1982 ел, 23 сентябрь

Эштән кайтышлый Нәкый аганың фатирына бардым. Ишекне Нәҗибә апа ачты. Нәкый ага егылып кабыргаларын авырттырган икән, авырып торса да, ачык чырай белән өстәл янына килеп утырды.

Ана Тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советы карары белән чыгарылган «Урта гасыр татар әдәбияты тарихыннан» исемле, яна гына басылган фәнни җыентыкны бүләк иттем. Ул аны сөенеп кабул итеп алды. Үзе турында истәлекләр сөйләп китте.

1918 елда Уфада наданлыкны бетерү буенча укытучылар курслары ачылгач, Нәкый ага шунда укырга килә. Анын торагы Фатыйма Шакулованыкы белән янәшә була. Нәкый ага аларга кереп йөргән. Бу ханым бик күпне белүче, укымышлы хатын була. Ул татарларга карата Русиядә үткәрелгән сәясәтне бик дөрес анлап, үз заманынын күпләр белмәгән мәгълүматларын белгән. Бертапкыр С. Күкляшев турында да сөйләп китә һәм, менә анын сүзлеге, мин аны сезгә бүләк итә алам дип, «Диване хикәяте татар» хрестоматиясенә төзелгән сүзлекне Нәкый агага биргән. (Ул сүзлек әле дә миндә саклана, диде Нәкый ага). Шул вакыт Шакуловларга шигырь укый-укый бер карт килеп керә. Язучы һәм фабрикант Йосыф Дебердиев була бу. Сез нинди шигырь укыйсыз?—дип сорагач, «Сөбател-гажизин»нән, ди. Суфый Аллаһияр—ул искиткеч зур шагыйрь, оста шагыйрь,—ди. Мин аптырап, сез фабрикант, ничек инде суфый шагыйрь белән мавыгасыз?—дидем. Ул, бу китап бик күпләргә дөньяны танырга ярдәм итә,—ди.—Минем фабриканы алдылар, алсыннар, менә идарә итеп карасыннар анын белән,—ди. Фабриканы мин аны хәзер янасын эшли алам, аны алганга кайгырмыйм, әнә Суфый Аллаһияр кайгырмаска кушкан,—дип, анын китабыннан күп-күп өзекләр китереп сөйләп китте. Бу акыллы һәм культуралы кеше иде. Безнен искедән килгән зыялы нәселдән. Заманында Петр I татарнын интеллигенция катлавын, аны оештырып, культурасын тоткан мирзаларын юк итү сәясәте уздырган, аларны чукындырган, ә Дебердиевләр чукынмаганнар...

## 1983 ел, 30 декабрь

Бу көннәрдә Һади Такташнын III томы басылып чыккан иде. Мин ул томны Нәкый агага тапшырып кайтырга җыендым. Кичке сәгать 5ләрдә трамвай белән юлга чыктым. Иптәшлек урамына җиттем, Исәнбәтләр фатирынын ишегендәге кынгырауга бастым. Озак кына көтәргә туры килеп, инде китәргә җыенгач, баскычтан Нәҗибә апанын менеп килгәнен күрдем. Анын күнеле күтәренке, ниндидер көй көйләп, җинелчә басып менеп җитте. Исәнләштек. Озак көттегезме?—ди, календарьлар җибәрдем әле бер унны, ди. Ташкенттагы Мөгаззәмә апага (галим Җәвад Алмазнын бертуган апасы) да татар календаре җибәргән.

Өйгә кердек. Мин тиз генә йомышымны бетереп китмәкче идем дә, чишенегез дигәч, чишенмичә булмады инде. Чишенеп, Нәкый аганын эш бүлмәсенә үттем. Мин кергәндә ул, башына салам эшләпә киеп, эшләп утыра иде. Шатланып күреште. Татар теленен сүзлеге өстендә эшлим әле, диде.

Нәкый ага бу III томны алган икән инде. «Мин аны карандаш тотып, укып чыктым әле»,—диде. Мин инде корректурадан хаталар калып, Нәкый ага шулар турында әйтергә телидер, ахры, дип уйладым. Ул исә: «Юк, мин анын тормышы белән танышып чыктым. Бик авыр шартларда, ярдәм күрми яшәгән икән, анын шул шартларда иҗат итә алуына да исен китәр,—диде.—Том яхшы чыккан,—диде.—Андагы бер хатны нигә «Газыйм .... ка» гына дип яздыгыз, мин анын Газыйм Касыймов икәнлеген чамаладым инде, ул бер «левак» иде, минa да күп зыяны тиде анын Уфада чакта»,—диде. Мин үземчә генә акландым. Ул кешенен гражданский реабилитациягә генә эләгүен әйттем. Мәсьәлә аннан тыш редакторларга да бәйле бит, дип әйттем. Чөнки мондый бер очракнын Фатих Әмирхан томнарын әзерләгәндә булганын хәтердән чыгармадым.

Нәкый ага Такташ турында үзендәге материаллар нигезендә бер истәлек язарга җыенганлыгын да әйтте. Мәскәүдә булганда без Такташ белән бик дусланып киткән идек, диде ул. Оренбургта вакытта Такташнын «Төркестан сәхраларында» дигән

шигыре басылгач, Нәкый ага аны газетадан кисеп алып, җыеп куйган һәм үзе белән йөрткән. Такташка, мин синең шигырьләреңне укып һәм җыйнап барам, дип әйттем, диде. Мәскәүдә үзенең җыйганнарын Такташка күрсәткәч, шагыйрьнең моңа бик күнеле булган. Соңгы мәртәбә Такташны Казанда, шагыйрь үләр алдыннан, «Киләчәккә хатлар»ны язган чагында күргән. Ул үлгән чагында минем «җидегәнче» дигән даным чыккан иде, иптәшләргә күләгәм төшмәсен дип мин ул вакытта алар белән аралашмадым, читтән әйләнеп үттем, ул вакытта минем тормышым да бик авыр булды шул, дип сөйләде Нәкый ага. Такташ турындагы истәлеген ничектер яза алмады ул *(«Мирас» журналында чыкты. 2004,№2,3.ред.).*

Институт тормышы белән гел кызыксынып торды Нәкый ага. Миндә Мифтахетдин Акмулланың кайбер билгесез әсәрләре булырга тиеш, аларны эшләргә вакыт җитми дигәне дә истә. Мин, Институтта Акмуллага бәйле бер җыентык чыгасы бар шикелле, дигәч, бу сүзгә каршы берни дә әйтмәде үзе. «Кыйссаи Йосыф»ның язмышы аны бик кызыксындырды. Тиражга бирелгән инде дигән хәбәргә бик шатланды. Колгалинең 800 еллыгын Мәскәүдә, Колонналы залда үткәрү кирәк иде дип офтанды.

Нәҗибә апа шул әңгәмә барышында Нәкый агага бер стакан үлән суы китереп эчерде һәм соңрак табын янына чакырды. Шунда Нәкый ага, миңа бик күнелле булды әле, бүген минем туган көнем дә иде, диде, без аш бүлмәсенә үттек. Уңышларыбыз, югалтуларыбыз турында сөйләшеп утырдык. Нәкый ага композитор Латыйф Хәмиди һәм урта гасыр фарсы әдәбияты белгече Габдрахман Таһиржановларның вафатын ишетмәгән булган икән, бик офтанды. Габдрахман Таһиржанов Казанга соңгы килүендә (1983нең 11 октябре) Нәкый абыйларда булып, ялгыш эшләпәсен алыштырып киткән икән. Нәкый ага аның турында, бу—кətелмәгән югалту, зур галим иде, дип көрсенде. Ул «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томы кайчан чыгар икән дип, шулай ук Галимҗан Ибраһимов әсәрләре чыкмауга (6-9 томнар нәшер ителү берничә елга тоткарланып торды) борчылды. Исән чакта күреп каламмы-юкмы инде дип сөйли иде. Аннан соң ул, XVII гасырның беренче яртысында татар әдәбияты тарихында нинди яңалыклар бар, бу дәвер бик буш бит, заманында мин бу дәвер белән кызыксынып эзләнгән идем, дип әйтеп куйды.

Мин Нәкый агага Фатих Әмирханның Сәхибгәрәй Сәетгалиев һәм Борһан Мансуров хакындагы фикерләрен әйткәч, алар шул бик «левак» кешеләр иде дип әйтте. Борһан Мансуров аеруча тупас җанлы, мин белмәгән нәрсә дөрес түгел дигән фикер белән яшәүче булган икән.

## 1992 ел, 17 сентябрь

Бүген Нәкый ага Исәнбәт белән бөтенләйгә саубуллашу көне. Аның җәсәден Камал театры фойесына куйдылар. Күп халык аңа соңгы ихтирамын күрсәтү өчен килгән иде. Мин дә табут янында шәрәфле каравылда тордым. Аннан соң аның җәсәден җеназа укыту өчен Ш. Мәрҗани мәчетенә алып киттеләр.

Көн кояшлы, тыныч, җылылык 18 градус булыр. Халык күп, күмүгә катнашучылар өч автобуска утырып Яңа Бистә зиратына барды. Нәкый ага беренче хатыны Гөлсем апа янына күмелде...

**Редакциядән:**

***Әдәбият галиме, археограф, текстолог, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗановка 70 яшь тулды. Марсель Ибраһим улы—татар әдәбияты тарихына, текстологиягә һәм шәҗәрәләргә караган егермедән артык китап, йөзләрчә мәкалә авторы. Бу күренекле мирасчыбыз 1972 елдан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли, 1985 елдан ул институтның кулъязмалар, фәнни һәм архив бүлеге мөдире.***

# БАБАМ ВАСЫЯТЕ

Еш кына бездән, дөресрәге, хәрби-патриотик теманы яктыртырга яратучылардан: «Ни өчен сез сугышта үлгән кешеләр турында күбрәк язасыз?»—дип сорыйлар. Бу сорауга күренекле әдип—батырларыбызның якты исемнәрен, кылган каһарманлыкларын мәңгеләштерүдә биниһая зур эшләр башкарган Шамил ага Рәкыйповның «Аяз күктә карлыгачлар» дигән әдәби-документаль китабындагы (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982) гыйбрәтле сүзләр белән җавап бирәсем килә:

«...Үлгәннәр истәлеге тереләр өчен кирәк,—ди китап геройларының берсе, Алтын Йолдыз кавалеры, республикабызның Балык Бистәсе районында туган Александр Меркушев.—Тереләрнең җаны тыныч түгел. Дөнья тыныч түгел. Үлгәннәр турында даими сөйләргә кирәк. Вакытсыз үлгәннәр турында... Алар онытылмаска тиеш. Алар хакы изге...» (220нче бит).



Фронтовик-геройның менә шушы сүзләре тирәнтен уйланырга мәҗбүр итә. Әлеге сүзләр сугыш китергән дәһшәтне, явызлык-рәхимсезлекләрне үз җилкәләрендә нык татыган һәм фашизм дигән кара көчне җинеп чыккан Солдатларның, Ватан-ана сакчыларының алмашка килүче яшь буынга үтенечләре дә... Шуна күрә бүгенге язмамда да мин Туган ил иминлеге өчен утка кереп, гомерләрен биргән каһарманнарның тагын берсе турында сөйләргә һәм күнелемдә туган кайбер уй-фикерләрем белән уртаклашырга телим.

...Мамадыш районының Алан эшчеләр бистәсендәге буш нигезләрнең берсе каршында, тирән уйларга чумып басып торам. Мондый буш нигезләрне һәр авылда күпләп очратырга мөмкин. Һәркайсының—үз тарихы, үз моңы... Менә бу нигезнең дә үткәне гыйбрәтле. Заманында бирелә өч сугыш ветераны саналган бабам Ибраһим белән әбием Хәбибҗамал гомер кичерәләр иде. Куе урман эчендә, яшел чирәмле тау битендәге түгәрәк аланлыкка урнашкан әлеге «оҗмах оясы»на без—аларның нәкъ бер дистә оныклары!—өч чакрым ераклыктагы Арташ авылыннан еш менеп йөри идек. Бабай белән әбигә кышлык утын-печән әзерләүдә, бакча-кура эшләрендә, су китерүдә, мал-туар караyда, көчебездән килгәнчә, теләп-яратып булыша идек. Өлкәннәрнең май кояшыдай балкыган рәхмәтле якты йөзләрен, кыстый-кыстый чәй эчертүләрен һич онытасыбыз юк...

Бабам белән әбием әлеге төбәкнең бик хөрмәтле кешеләре иде. Гомерләре буе (аларның беренчесе—90 яшькә, икенчесе 80 яшькә кадәр яшәде), күпләрне сокландырып, тату-матур тордылар. Тик түгәрәк бәхетләренең бер чите китек иде шул: берләнбер уллары Миннегаян сугыштан әйләнеп кайтмаган. Һәр көнне бабам белән әбием, аның яу кырыннан җибәргән беренче һәм соңгы фоторәсеменә карап, уллары белән исән кешедәй итеп сөйләшәләр, күнелләрендәге шатлыкларын да, борчуларын да уртаклашалар иде.

Аларның үз тормышлары белән икесе ике җирдә яшәүче кызлары—әниебез Гөлзәйнәп, апабыз Бибимәгъшия дә, очрашканда, бертуганнары Миннегаян абыйны чиксез сагынып-юксынып телгә алалар, аның турында сөйләгәндә яулык читләре белән яшьле күзләрен еш-еш сөртәләр иде. Шуна күрәдерме, Ватан сакчысы булган Миннегаян абыебызның якты истәлеге балачактан ук безнең күнелләргә тирәнтен уелып калды. Без аны әкиятләрдә сөйләнелә торган өч башлы аждаһаны җиңгән

пәһлеван батыр итеп күзаллый идек, аның белән ихлас күнелдән горурлана идек.

Сөйләүләренә караганда, чыннан да, яшьтән үк батыр йөрәкле, тәвәккәл, үтә булдыклы кеше булган ул безнең Миннегаян абый. Баштарак колхозда, аннары беренче бишьеллыкларның удар төзелешләрендә эшләгән—мактаулы исеме телдән төшмәгән.

1941 елның мартыннан ул Кызыл Армия сафларында хезмәт итә башлый. Фашист-илбасарларның безнең илгә каршы сугыш башлауларын да шунда ишетә.

Миннегаян абый, танкка каршы ата торган артиллерия полкы составында, Мәскәүдән Көнчыгыш Пруссиягә кадәр данлы сугышчан озын юл үтә, рядовойдан орудие командиры дәрәҗәсенә күтәрелә, хөкүмәтебез бүләкләренә лаек була. «Дошманны эзәрлекләп, көне-төне алга барабыз, хәзер дошманны үз җирләрендә тукмыйбыз инде, тиздән туган нигезгә кайтыр вакытлар да җитә—көтегез!»—дип яза Миннегаян абый 1945 елның гыйнварында бабайларга язган хатында. Әмма аңа бәхетле Җиңү көннәрен күрергә насыйп булмаган икән—сугыш бетәргә берничә ай калганда гына аңардан хатлар килү өзелә. Озак та үтми, ул хезмәт иткән частьтан бабайлар йортына: «Сезнең улыгыз—гвардия өлкән сержанты Гаян Ибраһимов социалистик Ватан өчен көрәштә, хәрби антына соңгы сулышынача тугры булып, батырларча һәлак булды»,—дигән хәбәр килеп төшә...

Ышанмыйлар карт белән карчык улларының үлгәнлегенә. Җиңү таңы атып, кайтасы фронтовиклар кайтып беткәч тә, бабай белән әби улларының әйләнеп кайтасына өметләнделәр. Бәлкем, исәндер, кайда да булса тоткарланадыр дип, һаман могҗиза көтеп яшәделәр. Әнә бит, кияүләре—Кызыл Йолдыз ордены кавалеры Әхмәтсафа солдатның да үлгәнлеге турында ике мәртәбә кара хәбәр килгән иде... Берзаман, тере килеш, үзе кайтып төште! Авыр яраланып, контузия алып, ике күзе дә сукыраю, ишетә дә, сөйләшә дә алмау сәбәпле, госпитальләрдә озак дәваланган икән... Азмыни андый язмышлар?!

Еллар үтә торды. Әмма бабам белән әбием күңел күкләрендәге Өмет Кояшын һаман сүндермәделәр. Һәм көннәрнең берендә аларны тирәнтен дулкынландырган бер вакыйга булып алды...

...Ул көн—1966 елның кояшлы феврале—бүгенгедәй хәтеремдә. Түбән Ушмы урта мәктәбендә (Мамадыш районы) уку атнасын тәмамлап, Аланга—бабайларга булышка, дип менгәч, алар йортына почтальон абзый чит почерклы хат китерде. Үзләре хәзерге язуны рәтләп таный белмәгәнлектән, бабам белән әбием ул хатны миннән укыттылар (соңыннан эзтабарлык эше белән тирәнтен кызыксынуыма сәбәпче булган әлеге хатны бүгенге көндә дә үземдә кадерләп саклыйм һәм биредә аны тулы килеш китерүне кирәк дип саныйм).

«Исәнмесез, кадерле иптәш Ибраһимов Гаян! Исәнмесез, гвардияче батырның туганнары!—диелгән иде хатта.—Сезгә Мәскәү өлкәсенең Шахов районына кергән Никола-Дуниловский сигезьеллык мәктәбенең кызыл эзтабарлары зур үтенеч белән мөрәҗәгать итәләр. Безнең VII класс укучылары элекке 16нчы армиянең танкка каршы ата торган 1нче гвардияче артиллерия полкы сугышчыларын эзләү белән шөгыльләнделәр. Бу унайдан без СССР Оборона министрлыгы Үзәк архивы белән дә элемтәгә кердек. Архив мәгълүматларына караганда, 1нче гвардияче артиллерия полкы составында кызылармеец Ибраһимов Гаян да булган. Ул үзе 1921 елгы, 3нче батареяның 1нче взводында орудие расчеты номеры... Иптәш Ибраһимов 1942 елның февралендә безнең төбәкне дошманнан азат итүдә каһарманнарча сугышкан... Бәлкем, бу хатны гвардияче батыр үзе алып укыр һәм безгә шул утлы-давыллы елларга кагылышлы истәлекләрен язып җибәрер, хәзерге көндәге тормышы турында да мәгълүматлар бирер... Сездән түземсезлек белән җавап көтәбез!»

Хаттагы әлеге юллар бабам белән әбиемне чиксез дулкынландырды. Бүтән вакытларда сабырларның да сабыры булган Ибраһим бабамның да сугышта кылыч белән телгәләнгән бит алмалары буйлап бөрчек-бөрчек яшьләр тәгәрәде.

—Кара син аларны, эзтабарларны әйтәм, рәхмәтләр төшсен инде үзләренә, нинди игелекле, кирәкле эшкә тотынганнар! Сугыштан соң ничәмә-ничә еллар узса да, безнең улыбызны да онытмаганнар!—диде карт солдат, яу кырында гарипләнгән уң кулы белән әлеге хикмәтле хатны йомшак кына сыйпап. Аннары, фронтовик

улының фоторәсеменә карап, аның белән сөйләшә башлады:

– ...Кырык бишнең кышында үлгән хәбәрен килсә дә, күңел, никтер, ышанмады, балам! Әле менә хәзер дә бит үзенә, исән дип уйлап, хат язганнар... Их, белергә иде синең язмышыңны, кайларда гына югалдың икән?!

Бабамның шулай өзгәләнүе, әбиемнең әрнүле, сурәтләп биргесез моңлы карашы әле хәзер дә бик ачык булып күз алдымда тора, сүзләре исә, набат булып, колагымда кабат-кабат чыңлый...

Гомерләре буе сугышны ләгънәтләп һәм улларын көтеп (әлеге хат күңелләрендәге Өмет утын дөрләтеп кенә җибәрде!) яшәде ике өлкән зат. Әмма изге теләкләренә барыбер ирешә алмадылар—уллары белән кавышу шатлыгын татый алмыйча, бер-бер артлы җир куенына керделәр. Бабамның үләр алдыннан әйткән сүзләре шул булды:

–Тәки кайталмады улыбыз... Вакыт табып, Миннегаян абыеңның язмышы белән син дә кызыксын әле, олан!

Ил агасының—яраткан бабам Ибраһим Ситдыйк улының гозерләп әйткән васыятен үтәдем. Каһарман якташлар эзеннән СССР (Россия) Оборона министрлыгының Үзәк архивында кат-кат булуым чорында гвардияче Миннегаян Ибраһимовның да сугышчан юлы белән җентекләп таныштым.

...16нчы армиянең танкка каршы ата торган 289нчы артиллерия полкы составында дошманга каршы көрәшеп, Мәскәү янындагы сугышларда зур батырлык үрнәкләре күрсәтә Миннегаян абый. Архив документларыннан күренгәнчә, 1941 елның 25 октябрендә алар полкы оборона тоткан участокка—Спасс-Рюховское һәм Ивлево авылларына таба дошманның 80нән артык танкы, дүрт дистәгә якын бомбардировщигы һәм ике батальон күләмендәге пехотасы һөҗүм итә. Көчләр тигез булмаса да, безнең артиллеристлар каушап-калтырап калмыйлар. Ике сәгатьтән артык дәвам иткән каты бәрелеш вакытында дошманның 59 танкын, 5 самолетын һәм бер батальон пехотасын юк итәләр. Нәтиҗәдә, фашистлар чигенергә мәҗбүр булалар. Шушы гаять авыр шартларда Миннегаян абый хезмәт иткән орудие расчеты да, төз атып, дошманның 6 танкын яндыра.

«...Пушканы корып торучы иптәш Ибраһимов шушы житди-кискен көрәштә үзен искиткеч батыр, тәвәккәл, житез һәм иң кыен вакытта да каушап калмый торган салкын канлы, аек акыллы сугышчы итеп таныты,—диелә 16нчы Армия командующие—генерал-лейтенант Рокоссовский, артиллерия генерал-майоры Казаков һәм Хәрби Совет әгъзасы Лобачев кул куйган Бүләкләү кәгазендә.— Ватаныбызның курку белмәс улы Гаян Ибраһимов «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүгә тулысынча лаек» *(33 фонд, 682524 тасвирлама, 239 эш, 505 бит).*

Шулай итеп, абыебыз «немец илбасарларына каршы көрәш фронтында совет командованиесенең сугышчан заданиеләрен үрнәк төстә үтәгәне өчен», Көнбатыш фронт Хәрби Советының 1941 елның 5 ноябрендә игълан ителгән 0280 номерлы приказы нигезендә, беренчеләрдән булып, сугышчан бүләккә лаек була. Гаян абый хезмәт иткән 289нчы артполк исә Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә һәм ул тиздән «танкка каршы ата торган 1нче гвардияче полк» дип үзгәртеп йөртелә башлый. Мәскәүне саклаганда «гвардияче» дигән гаять мактаулы исемгә иң беренчеләрдән лаек булган әлеге данлы полк артиллеристлары алда торган хәлиткеч сугышлар барышында да үзләрен арыслан йөрәкле батырлар итеп таныталар. Белорус Клецко, дариец Гасаниев, казакъ Турсункулов, рус Романов, украин Попович һәм башкалар, ингә-иң торып, дошман юлына, мәңге бирешмәс алмаз кыядай, торып басалар. Күрсәткән батырлыклары өчен, аларның күкрәкләрендә хөкүмәтебезнең югары бүләкләре балкый. Татарстаннан килгән сугышчылар да республикабыз данын югары йөртәләр. Мәскәү янындагы сугышларда Арча районының Шушмабаш авылыннан килгән Гыйльметдин Шиһапов–Ленин ордены, Актаныштан Мәгариф Галиәхмәтов, Әлмәттән Мансур Галәветдинов исә Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнәләр.

Гаян абый да «Мәскәү оборонасы өчен», икенче тапкыр «Батырлык өчен» медальләренә лаек була. Соңгысы аңа Пушай торак пунктын һәм Орша шәһәрен азат иткәндә күрсәткән батырлыклары өчен бирелә. Архив документларыннан

күренгәнчә, Миннегаян абый үзенең расчеты белән әлеге торак пунктларга иң беренче булып бәреп керә һәм, төз атып, дошман пулеметчыларын, миномет батареясын һәм күпләгән солдатларын юк итә...

Мондый мисалларны аның сугышчан тормышыннан байтак китерергә мөмкин. Күкрәгендә Ватаныбызга карата тиңсез мәхәббәт, дошманга каршы чиксез нәфрәт хисләре кайнаган гвардия өлкән сержанты—орудие командиры Гаян Ибраһимов, фашист-илбасарларның күпләгән җанлы көчләрен һәм техникасын юк итә-итә, Көнчыгыш Пруссиягә кадәр озын сугышчан юл үтә. Һәм 1945 елның 26 гыйнварында, ныгытылган шәһәр-крепость Кенигсбергны алу өчен барган сугышларда, батырларча һәлак була. Нибары 23 яшендә...

* * *

—...Миңа нәкъ 20 яшь тулган көнне үлгән икән Миннегаян абыегыз,—диде, күзләрен мөлдерәтеп, әниебез Гөлзәйнәп, аңа бертуган абыйсы турында хәрби архивтан алып кайткан документларның күчермәләрен күрсәткәч.—Өйләнгән булса, балалары—дәвамы калыр иде!.. Хәер, ятимнәрнең, тол хатыннарның да язмышлары бик үк җиңелдән түгел шул...

Һәм ул яңадан үзенең бертуганы Бибимәгъшия апа турында сөйләп китә. Апасының ире Кадыйр Газизов, 1941 елның көзендә фашистларга каршы көрәшкәндә, Молдавия җирендә һәлак булгач, аңа бердәнбер кызы Гарифәне ялгызы карап үстерергә туры килә (уллары Камил исә бик яшьләй вафат була). Ничек итсә-итә, әмма чын кеше итеп үстерә кызын Бибимәгъшия апа. Гарифә башта Мамадыш районының Уразбахты авылында—«8 нче март» колхозында сыер савучы булып эшли. Мактаулы исеме, фотосурәте район һәм республика газеталары битләрендә еш балкый аның. Аннары ул, кияүгә чыккач, тегүче һөнәрен үзләштереп, Пермь өлкәсенең Губаха шәһәрендә, соңгы елларда исә—лаеклы ялга киткәнче—Түбән Кама каласындагы Яшьләр ательесында бик күп кешеләргә игелекле хезмәт күрсәтә. Ире Габделфәрт тә, шофер буларак, нык билгеле, булдыклы шәхес... Өчесе дә бер түбә астында гомер кичергәч, шатлыкларын да, кайгыларын да тигез бүлешеп яшиләр алар. Бибимәгъшия апа да, Гарифә дә үзләре өчен иң кадерле кешеләрдән саналган Кадыйр Газизов белән Миннегаян Ибраһимовны һәр көнне иртә-кич үз догаларыннан калдырмыйлар, аларның соңгы фотосурәтләренә, тирән юксынусагыну хисләре белән, кат-кат багалар...

Нәкъ шундый ук сүзләрне Хәбибҗамал әбиебезнең якын туганы Искәндәр солдатның сөекле хәләл җефете Зарифа апа Ибраһимовага карата да әйтергә була. Ул да иреннән бик яшьләй, ике баласы белән тол калды. Шөкер, уллары Фаяз белән Гаяз йөзгә кызыллык китермәделәр—тәртипле, тәүфыйклы, иманлы булып үстеләр. Һәр эшкә дә куллары ябышып тора иде аларның. Егет булгач, үзләренә тиң ярларны—Нурлыхода белән Сабира кебек сөйкемле, уңган, ачык йөзле авыл кызларын сайладылар. Киленнәр исә, итәк тутырып, берсеннән-берсе булдыклы, тырыш балалар үстерделәр. Эчке эшләр органнарында эшләгән Фаязы озак еллар дәвамында инде Соколка бистәсендә яши. Нократ белән Чулман кавышкан урында!.. Ә атказанган игенче буларак танылган Гаязы әти-әнисе корган төп нигезгә—серле-сихри Аккош тавы итәгендәге биниһая кадерле урынга ныклап урнашты. Шушы тау буеннан Зарифа апаның да бер дә китәсе килмәде. Ирен өзелеп сагынган мизгелләрдә, тау янәшәсендәге урман буена барып, күнелен җыр белән юата иде ул:

*Ак күгәрчен, күк күгәрчен*
*Оча урман итәкләп.*
*Сукыр булсаң да кайт, җаным!!—*
*Үзем йөртәм җитәкләп...*

Юк шул, күпме генә көтсә дә, кайтмады Искәндәре. Башка бик күпләр кебек, сержант И. Ибраһимов та, дәһшәтле дошманга каршы тигезсез көрәштә, бүгенге якты көннәр хакына шәһит китте. Татарстанда чыккан «Хәтер Китабы»ның 16нчы

томында, 104нче биттә мәңгелеккә урын алган аның йөрәккә үтә якын исем-фамилиясе...

Шул ук томда әтиебез Әхмәтсафа Мостафинның, абыебыз Миннегаян Ибраһимовның да туган-үлгән көннәре һәм күмелгән урыннары күрсәтелгән. Әйтик, әтиебез турында китапта: «... 1943 елның 15 октябрендә һәлак булды. Псков өлкәсенең Невельский районындагы Горушки авылы янында күмелде»,—диелә (Безнең бәхеткә, әтиебез, мең үлемгә үч итеп, исән калган!). Миннегаян абыебызның мәңгелек тукталыш тапкан урыны, изге кабере исә хәзерге Калининград өлкәсенең Полесск (элекке Лабиау) шәһәре үзәгендә...

Фашист снаряды 1945 елның 26 гыйнварында гвардия өлкән сержанты Миннегаян Ибраһимовның туп расчетында хезмәт иткән дүрт кешенең гомерен берьюлы өзә. Архив документларыннан күренгәнчә, яу кырында абыемның якын сугышчан дусларыннан—башкорт егете Гомәр Дүшәнбаев, рус халкы вәкилләре Петр Жевлев, Василий Янков батырларча һәлак булалар.

Заманында шул хакта «Советский патриот» газетасында «Завещание Деда» дигән язмамны (1989 ел, 8 февраль саны) бастырган идем. Әлеге очерк, ничектер, мәрхүм Гомәр Дүшәнбаевның улы Рәфикъның күзенә чалынган. Һәм ул, адресымны шул газета редакциясе аша тиз генә соратып алып, мина бик тә дулкынландыргыч хат юллаган булган (әлеге язмамда аның әтисе турында да җылы итеп әйтеп үткән идем). Ни кызганыч, иске фатирыбыздан күчү сәбәпле, ул хат мина бик соң килеп ирешә. Рәфикъ туганкай белән күрешергә-аралашырга өлгерми дә калдык—ул кинәт кенә үлеп тә киткән икән...

Шулай да күнелемдә якты бер теләк яши: заманында Гомәр һәм Рәфикъ Дүшәнбаевлар гомер кичергән нурлы төбәккә—Башкортстанның Зианчура районындагы Тазлар авылына бик тә барып чыгасым, анда яшәүчеләр белән якыннан аралашасым-дуслашасым килә. Зиратларына барып, игенче-музыкант әтисен гомере буе сагынып-өзелеп көткән Рәфикъ туганкайның, аның якыннарының каберләре алдында башымны иеп, дога кыласым, Миннегаян абыебызга тормыш бүләк иткән үзебезнең Мамадыш төбәгенең изге туфрагын шунда саласым килә. Әйдә, тагын да ныграк туганлашсын әле ике җөмһүрият туфрагы! (Монарчы инде Башкортстан туфрагын—Рейхстаг түбәсенә Җиңү байрагын беренче булып менгезеп кадаган легендар милләттәшебез Гази Заһитов кабереннән (Мишкә районының Яна Кош авылы зиратыннан) үз кулларым белән алган бинипая калерле туфракны фронтовик әтием Әхмәтсафа Мостафа улының каберенә 2000 елның октябрь аенда сипкән идем...)

Әлеге зарури теләгемне Башкортстанның халык шагыйре—Дүшәнбаевлар яшәгән төбәктә туып-үскән мөхтәрәм милләттәшебез Марат ага Кәримов та ихлас күңелдән хуплады һәм, җай чыгу белән, үзләренә кунакка килергә чакырды...

* * *

...Яу кырыннан кайткач, Миннегаян абыем ныклап төпләнергә тиеш булган йорт нигезе янында уйланып утырам. Буш нигез, бомба төшкән чокырдай, күңелгә шом һәм моң салып, каралып тора... Кулымда—бабам белән әбиемнең исән чакта төшкән фоторәсемнәре. Алар, җыйнак кына өйләренең капка төпләренә чыгып басканнар да, зур өмет белән, олы юлга карап торалар. Бабамның сугыш кырында имгәнгән уң кулы, канаты каерылган бөркетнеке кебек, салынып төшкән. Карашы—житди, иреннәре, нәрсәдер әйтергә теләгән сыман, бераз ачылган. Ак яулыклы әбием дә, сул кулын кашлары өстенә куеп, юлны күзли. Улларын көтәләр...

**Шаһинур МОСТАФИН,**
*эзтабар язучы.*

# КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ-ПЕДАГОГ, ЧЫН ХАТЫЙП

Минем кулымда—Казан дәүләт университеты профессоры, филология фәннәре докторы Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловның олуг бәйрәме—тууына җитмеш ел тулу уңае белән «Идел-Пресс» басмаханәсендә дөнья күргән «Хатыйп Миңнегулов турында» дигән китап (2009, 584 б.). Бу җыентыкка татар, төрек, әзербәйҗан, рус, эстон, башкорт, чуаш һәм башка милләтләр галәмәләренең, язучыларының, зыялыларының Х. Миңнегуловның фәнни-педагогик һәм җәмәгать эшчәнлеге хакында эчтәлек һәм жанрлар ягыннан төрле-төрле булган язмалары: биографик мәгълүматлар, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренә, монографияләре, дәреслек-хрестоматияләренә карата бихисап унай бәяләмәләр урнаштырылган; Мәскәү белән Санкт-Петербург, Россиянең төрле төбәкләрендә, чит мәмләкәтләрдәге дәрәҗәле конференция, симпозиум, форумнарда ясаган чыгышлары мактап телгә алынган. Күренекле профессорның халкыбызның мәдәни-рухи үсешенә керткән тырышлыгы, эчтәлекле һәм җанлы лекцияләре, студентларга кешелекле мөнәсәбәте күп санлы мәдех-котлауларда, рәхмәт сүзләрендә чагылыш тапкан; гомер һәм хезмәт юлындагы әһәмиятле даталар да рәсми оешмалар, җәмәгатьчелек һәм коллегалары тарафыннан алкышлап каршы алынган. Китапта урнаштырылган—Хатыйп Йосыф улының гаиләсенә, якын туганнарына, нәсел-нәсәбенә караган, төрки-татарларның мәдәният, фән, әдәбият һәм сәнгать дөньясының асыл затлары белән шәхсән җылы аралашу, бәйләнешләр шаһиты булган рәсемнәр дә зур кызыксыну белән карала. Җыентыкның азагындагы гуманитар фәннәр өлкәсендә эшләүчеләр, студентлар, әдәбият сөючеләр өчен бик тә кирәк булган Хатыйп Миңнегуловның хезмәтләре библиографиясе, аның эшчәнлеге хакында санап бетергесез язмалар теркәлгән. Алар белән танышып чыккач та, Хатыйп Йосыф улының әдәбиятыбыз тарихын, аның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләрен өйрәнүдәге хезмәтләренең мәһабәт бер тау булып калкып, күтәрелеп торуына тагын бер кат инанасың, сокланасың һәм горурланасың! Шуңа күрә дә мин аның Башкорт дәүләт университеты доценты Рәүф Идрисовка биргән интервьюсендә «Гомер бушкарак үтте шул» дигән фикере белән килешмәс идем. Чынбарлыкта исә ул—көнне төнгә, төнне көнгә ялгап мәдәни-әдәби мирасыбызны өйрәнгән һәм аны халкыбызга җиткерү өлкәсендә ару-талуны белмичә эшләгән галим. Кайсы гына газета-журналны ачып карама, анда Хатыйп Миннегулов язмасына тап буласың, радио белән телевидениедән дә аның көр тавышы еш яңгырар. Менә гаиләбез—ирем Зөфәр Рәми, киленебез Илсияр Рәмиева белән Истанбул каласындагы мөселман мәдәниятенең гыйлем хәзинәсен туплаган Ислам китапханәсендә утырабыз, утыз томнан торган «Төрки дөньясы әдәбиятлары тарихы, энциклопедиясе, антологиясе» томнары сәхифәләрен актарабыз һәм, югарыдагы фикеребезне раслагандай, адым саен диярлек Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов мәкаләләренә юлыгабыз. Төркиядә басылган язмаларының исәбен галимнең әле үзенең дә белеп бетергәне юк; әлегә алар аның хезмәтләре библиографиясенә дә кертелмәгән. Әйтергә кирәк, энциклопедияләр өчен белешмә-мәкаләләр язу бик тә четерекле, вакыт күп сорый торган авыр эш. Аның «Әдәбият белеме сүзлеге», «Ислам на европейском Востоке» дигән энциклопедиядә, «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә дә күп санлы мәкаләләре бар. Галимнең уңышлары бары тик әдәбият кысалары белән генә чикләнми, билгеле. Ул—гуманитар фәннәрнең барысына да үз өлешен кертүче, универсальлеккә һәм энциклопедик киңлеккә омтылучы галим. Хатыйп Миннегуловның татар халкы рухи юлдашына әйләнгән 34

китабы, 650 фәнни мәкаләсе—мона ышандырырлык дәлил. Татар халкының мәдәни һәм әдәби тормышындагы вакыйгаларны Хатыйп Йосыф улы Миннегулов кебек үтемле һәм өлгер чагылдырып баручы, безнең заманның елъязмасы вазыйфасын үтәүче башка әдәбиятчыны мин белмим.

Зәй районының кечкенә генә Апач дигән авылында туган Хатыйп Миннегуловлар гаиләсенең тормышлары җинелдән булмый. Йорт хуҗасы Йосыф абзый җир өстендә йөрүче дүрт баласын, ә берсен хатыны карнында калдырып, Ватан азатлыгын сакларга дип сугышка китә һәм шул заманның үлем хәбәрләрендә традицион штампка әйләнгән сүзләр белән язылганча, Белорус фронтында утыз дүрт яшендә «батырларча һәлак була». Ятим калган Хатыйпка әле бу чакта биш яшь тә тулмаган була. Ачлык, хәерчелек хөкем сөргән бу авыр елларда утыз ике яшьтә итәк тулы балалар белән калган Гайнелхәят апа дүрт йөрәк җимешен исән-имин саклап кала, бер кызы исә нинди дер каты чирдән кинәт кенә үлеп китә. Фидакяр ана балаларының дүртесенә дә югары белем бирә, барысын да Кеше итә. Ике югары уку йортын тәмамлаган олы улы Миргалим танылган диңгез капитаны, Севастополь хәрби-диңгез училищесе укытучысы, кыз туганнары—Гөлнур элемтә бүлеге житәкчесе, ә өздереп гармун уйнаучы, шигырьләр язучы Хәнифә Россия Федерациясенең атказанган укытучысы, Хатыйп исә Казан дәүләт университетының профессоры булып житешә. Әнкәсенең рухи бөеклеге алдында Хатыйп Йосыф улы һәрвакыт баш иеп яшәде һәм яши. Бу турыда ул болай дип язды: «Әнкәй безнең өчен гадәти Ана гына түгел, ата да, президент та, «политбюро» да, прокурор да булды. Аның һәр сүзе, һәр ым-карашы безнең өчен катгый закон иде. Ул безне гаять кыен елларда да ашатты, киендерде, үстерде, укытты, тәрбияләде, гаделлеккә, үз хезмәтебез белән көн күрергә, кешеләрне рәнҗетмәскә, тыйнаклыкка, туганлыкның кадерен белергә өйрәтте». Әниләрен Олуг Зат дип кабул иткән балалары исән чакта Гайнелхәят абыстайга бик тә кадер-хөрмәт күрсәтәләр. Хатыйп исә, кадерле әнисе вафат булгач та чыккан «Дөньяда сүземез бар...» исемле китабын Гайнелхәят Шәйхелислам кызының якты истәлегенә багышлады...




Яшь Хатыйпның белем баскычлары буенча акрын-акрын югарыга үрмәләве, һәрвакыт диярлек укуын хезмәт белән аралаштырып баруы үзенә күрә гыйбрәтле бер тарих. Башлангыч белемне үз авылларында алгач та (1946—1950), күршедә генә урнашкан Пидәр (Федоровка) авылында җиде сыйныфны тәмамлый. Мәктәптә укыган елларда ук әнисенә колхоз эшләрендә булыша, аның белән бергә урак та ура. Хатыйпның бик тә укыйсы килә. Әмма якын-тирәдә урта мәктәпләр юк, гаиләләренең матди хәле дә авыр. Менә беренче сентябрь көне житә. Балалар мәктәпкә бара. Укуын дәвам итә алмауны авыр кичергән Хатыйп лапаска чыгып өзгәләнә-өзгәләнә елый. Шуннан бер ел колхозда эшләргә, хайваннар карарга, көтү дә көтәргә туры килә ана. Ниһаять, яшүсмер үзләреннән 25 чакрым еракта урнашкан Сарман районының Иске Кәшер авылындагы урта мәктәпкә юл тота. Үзе ясаган чабатаны киеп, бүреләргә очрый-очрый ике урман аша чыгып, Апач белән Иске Кәшер арасын өч ел буена таптый. Иске Кәшердә ул фатирда яши, ачлы-туклы гыйлем эсти. Авылына әнисе янына кайта алмаган, бер тәгам ризыксыз калган көннәрнең берсендә Хатыйп янәшәсендә гаиләсе белән рәхәтләнеп ашап-эчеп утырган, ә аңа бер чынаяк чәен дә кызганган фатир хуҗасы: «Алабуганың китапханә техникумында укыганда, безнең белән синең кебек берәү ач укыды да, уку йортын тәмамлаганнан соң үлеп китте»,—ди. Кара кан булып сава бу сүзләр Хатыйп йөрәгенә! «Бу кадәр фәкыйрьлектә үскәч, озак яшәп булмас» дигән фикер аның аң төпкелләренә шомлы кисәтү сыман сенеп, әдәбиятчылар термины белән әйтсәк, куркыныч эчтәлекле архетип сыман XXI гасыр башына аяк басканчы эзәрлекләп килә.

1957 елда Иске Кәшер урта мәктәбен «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамаласа да, матди кысынкылык аркасында Х. Миннегуловка шул ук елда Казанга килеп югары уку йортына кереп белем алырга мөмкинлек булмый. Ашыйсы ашлар, эчәсе сулар аны комсомол путевкасы белән Урта Азия якларына китереп чыгара. Таҗикстанда яшәп, мамык җыюга катнаша, уран табу һәм эшкәртү заводында эшли, политехникумның геофизика бүлеген укырга керә. Әмма әнисенең авыру хәбәре килгәч тә, ул туган авылына әйләнеп кайта, колхозда эшли, урман кисә, клуб мөдире була.

Бары тик 1959 елда гына Х. Миннегуловка Казанга килергә һәм университетның тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем алырга мөмкинлек туа. Ләкин университетта да тыныч кына укырга насыйп булмый әле аңа. Ул заманнарда татар теле һәм әдәбияты укытучыларына кытлык булу сәбәпле, алар төркемендәге студент халкын читтән торып уку бүлегенә күчереп, милләтәшләребез яшәгән төрле төбәкләргә тараталар. Х. Миннегулов исә Пенза өлкәсендәге Качкару авылына барып чыга. Ә инде университет тәмамлаганның соңында өч ел Сарман районының Чукмарлы урта мәктәбендә укыта, директор була, район партия оешмасында төрле җаваплы эшләр башкара. 1966 елда Казан университеты аспирантурасына кабул ителсә дә, бер елдан аны татар әдәбияты кафедрасына укытучы итеп билгелиләр.

Менә кырык елдан артык ул шушы кафедрада эшли. Татар әдәбияты тарихы һәм аның Шәрекъ әдәбиятлары белән бәйләнешләре хакында чын «хатыйб»ларча— ораторлык сәнгатенең югары дәрәҗәсендә лекцияләр укый, вакыт агышын да оныттырып, ардыртмыйча, талчыктырмыйча әдәби материалны шәкертләре аңына сеңдерә. Лектор буларак аның үз-үзен тотышында кул житмәслек кеше итеп күрсәтү чире дә, үз-үзенә соклану, гашыйк булу кебек нарциссизм чире дә юк. Шуңа күрә студентлар да аны үз итәләр. Кайбер мөгаллимнәр шикелле зачет-имтиханнар вакытында ул студентларны тыңлаусыз булганнары өчен «бирәм әле кирәгегезне» кебек сүзләр белән куркытмас та, өркетмәс тә. Күренекле профессор шәкертләре белән үзе арасына «кытай диварлы» да куеп маташмый, аларның барысына да, аеруча кыз балаларга игътибарлы булып, кешелекле караш күрсәтә. Бу уңайдан шуны да әйтеп китәргә җөрьәт итәм: аның бәхетсезлеккә очрап авырып киткән кызы Гөлназны аякка бастыру өчен түккән көчен нинди генә бизмәннәргә салсаң да үлчәп бетерерлек түгел. Ата кешенең мондый изге гамәлләре, рухи бөеклеге алдында үзеннән-үзе баш иелә, аңа карата хөрмәт хисләре уяна.

Профессорның Хатыйп дигән исеме дә җисеменә һәм тарихи асылына туры килә. Гарәпләрнең антик дәвере дип саналган исламга кадәрге җаһилият дәвере шигъриятендә «хатыйблар» дип, җәмәгатьчелек фикерен бергә туплап, кабиләдәшләрен әйдәп баручыларны, иҗтимагый-сәяси, рухи-әхлакый мәсьәләләрне ялкынлы хотбә-вәгазьләре белән үз кавемнәренә җиткерүчеләрне санаганнар. Өстәвенә, «хатыйблар» шагыйрьлек сәләтенә дә ия булганнар. Бу сыйфатлар Хатыйп Миннегуловка да хас. Яшьлегендә ул район матбугатында байтак кына шигырьләрен дә бастыра. Шигърияттән аерылмау аның бүгенге яшәеше өчен дә хас. Еш кына ул үзенең лекция һәм чыгышларын мөсәҗҗәгъ нәсер (рифмалы, ритмлы проза) белән бизәр, шигъри мисаллар, хикмәтле сүзләр, мәкаль-әйтемнәр белән үреп бирер.

1999 елдан бирле профессор Х. Миннегулов татар әдәбияты теориясе һәм тарихы кафедрасы мөдире вазыйфасын үти. Үзе кебек, ул кафедра әгъзаларыннан да тырыш хезмәт, аеруча, фәнни эш планнарыбызны үтәүне таләп итә. Фәнни хисаплар биргәндә без, советлар чорындагыча, юморны да катыштырып, ярыш нәтиҗәләрен тикшерәбез, кырыкмаса кырык яктан үзебезне үлчибез, алдагы еллар белән дә ничек эшләгәнебезне чагыштырып карыйбыз. Кафедра мөдиренең таләпчәнлеге нигезендә бер хакыйкать ята: фән белән шөгыльләнмисең икән укытуның сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмый.

Х. Миннегулов тәрҗемәи хәлендәге авыр мизгелләрне, бигрәк тә аның балачак һәм яшьлектәге фәкыйрьлек белән үткән елларны искә алгач та һәм дә аның фәнни-педагогик эшчәнлегендәге, холкындагы аерым сыйфатларга күз ташлагач та, безнең күз алдыбызга үзаны (самосознание) көчле булган, армый-талмый



*КДУның татар бүлегенә 60 ел. Сулдан уңга: шагыйрә, аспирант Л. Янсуар, язучы К. Миңлебаев, галим Ә. Нигъмәтуллин (Уфа), шагыйрә Л. Газизова, язучы М. Хәбибуллин, галимнәр Х. Миңнегулов һәм А. Әхмәдуллин. 2004 ел.*

гыйлем эстәгән, сынмыйча, сыгылмыйча, гайрәт белән алга—идеалына таба хәрәкәт иткән зур Галим образы килеп баса. Күкләрдән иңдерелеп, тумыштан ук бирелгән мондый био-психологик сыйфатларның мәдәни-иҗтимагый җирлектә үсеп китүен философлар «теләк-омтылыш» дигән төшенчә (категория) белән үлчиләр. Дөрес, Х. Миңнегуловның гыйлем эстәү дигән олы юлда күргәннәрен, яшәү өчен тартыш-көрәшләрен төрле методологик принциплар: Фрейд психоанализы (кешенең интеллектуаль хезмәте—сублимация җимеше), Ницшеның (көчле ихтыярлы кеше), марксистик идеология (кеше—социаль зат, иҗтимагый продукт, хезмәт җимеше), дини карашлар (мәрхәмәтле, игелекле кеше) күзлегеннән дә аңлатып булыр иде. Галимнең «эго»сына нинди генә тәгълиматлар күзлегеннән якын килсәк тә, аның көчле импульслы үзаңы, миңлеге үз халкының, ул яшәгән, эшләгән тирәлектәге кешеләрнең, гаиләсенең мәнфәгать һәм ихтыяҗлары белән тыгыз үреп бирелгән. Аның үз йөзе, үз олуг «Мин»е булган милләт хадиме икәнлеген «Хатыйп Миңнегулов турында» дигән китапта замандашлары тарафыннан әйтелгән сүзләр дә раслый.

Профессор Хатыйп Миңнегулов—иң элек урта гасыр татар әдбияты буенча зур белгеч. Ул аның һәр үсеш баскычын—борынгы төрки дәверне дә, Болгар-Хәзәр, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын да, XVII һәм XVIII гасырлардагы әдәби барышны да биш бармагыдай яхшы белә. Урта гасыр татар әдәбиятын гомумфилологик яктан өйрәнүгә, андагы күренекле шагыйрьләр иҗатын монографик планда яктыртуга, бу чор татар һәм Шәрекъ әдәбиятлары өчен хас сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләрен күрсәтүгә ул аеруча зур өлеш кертте. Моңа дәлил итеп аның кайбер китапларының исемнәрен атау гына да җитә: «Шәрекъ һәм урта гасыр татар әдәбиятындагы кысалы кыйссалар» (1988), «Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан» (1999), «Дөньяда сүземез бар...» (1999), «Гасырлар өнен тыңлап...» (2003)... Шуны да искәртергә кирәк: Х. Миңнегулов җитмешенче елларда ук Алтын Урда дәвере шагыйрьләре Сәйф Сараи белән Котб иҗатларын Шәрекъ Ренессансы кысаларында Сәгъди Ширази һәм Низами Ганҗәвиләр белән чагыштырып, шактый зур эш башкарган иде. Сиксәненче-туксанынчы еллар дәвамында ул «ак таплар» белән тулып яткан Алтын Урда чоры әдәбиятын өйрәнүне тагы да көчәйтә һәм киңәйтә төште. Гасырлар һәм дөньяга карашлар алмашкан дәвердәге иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр Х. Миңнегулов кебек галимнәргә Алтын Урда тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын тикшерүгә табу салган ВКП(б) Үзәк комитетының 1944 елгы 9 август карарын кире

кагарга мөмкинлек тудырды, урта гасыр татар әдәбиятын өйрәнгәндә бер чордан икенче чорга кискен сикерүләр, өзеклекләр бетерелде, ә Алтын Урда чоры әдәбияты исә, сәнгатьчә фикерләү чылбырының бер буыны буларак, мәктәп һәм югары уку йортлары программаларында тиешле урынны алды.

Профессор Х. Миңнегуловның фәнни эшчәнлегендәге югары ноктаRarның берсе—«Татар әдәбияты һәм Шәрекъ классикасы» (1993) исемле монографиясе. Хезмәт китап булып басылып чыккач та (1994), аңа Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе бирелде. Төрки-татарларның унбиш гасырдан артык диярлек әдәби барышын тарих хәрәкәте, дәүләтчелек, этнослар, мәдәниятлар, халкыбызның килеп чыгышы, гарәп, фарсы, төрки әдәбиятлар белән тыгыз мөнәсәбәттә яктырткан бу хезмәт җәмәгатьчелектә дә зур кызыксыну уятты. Россиянең төп әдәби-фәнни басмасы «Вопросы литературы» журналында да ул татар әдәбиятының Шәрекъ традицияләре белән тыгыз бәйләнеш хосусыятләрен объектив чагылдырган хезмәт буларак мактап телгә алынды.

«Татар әдәбияты һәм Шәрекъ классикасы» исемле монографиясенең кыйммәтле ягы—аның басылып чыгу белән фәнни-гамәли әйләнешкә кертелүе, югары уку йортларының татар һәм рус филологиясе факультетларында дәреслек вазыйфасын башкаруы, мәктәпләребез өчен яңа программалар, дәреслек-хрестоматияләр төзү, ярдәмче әсбаплар язу өчен нигез булуы. Әмма аның әһәмиятен бары тик шушы аталган гамәли бурыч һәм максатлар белә генә чикләп кую бик үк дөрес булмас иде. Киләчәктә бу китапта тупланган бай фактик материал татар әдәбиятының үсеш кануннарын һәм бәйләнешләрен өйрәнүче яңа буын әдәбият галимнәре өчен таяныч булачак. Шәхсән, мин үзем Х. Миңнегуловның шушы китабыннан файдаланып, гарәп әдәбиятының даһие Мәгарри иҗаты һәм татар әдәбияты темасына фәнни-теоретик җегәрле диссертация дә язылыр әле дигән өметтә калам.

Х. Миңнегуловның кайсы гына китабын алып карама, аларның һәрберсендә Урта гасыр һәм Яңа заман татар әдәбиятының Шәрекъ әдәбиятларының өч юнәлеше—дини-әхлакый, суфыйчылык һәм дөньяви Ренессанс әдәбиятлары белән чагыштырып өйрәнелүгә зур урын бирелә.

Мәгълүм ки, Октябрьгә кадәрге әдәбиятыбызның барлык әсәрләре диярлек ислам дине фәлсәфәсе белән сугарылган. Урта гасырлар, XIX йөз һәм XX гасыр башы татар әдәбиятының Коръән тәгълиматы белән берегеп үсүен күрсәтүгә багышлап, галим җегәрле генә хезмәтләр язды. Мәктәп, гимназия укытучылары аның «Коръән һәм татар әдәбияты» дигән рисаләсен бик кирәксенеп һәм яратып кабул иттеләр. Х. Миңнегуловның татарларда ислам диненең таралу тарихы, мәдәниятыбызга һәм әдәбиятыбызга йогынтысы, Коръән тәрҗемәләре хакындагы чыгышлары һәм мәкаләләре төрек укучысына да килеп ирешә. Бу юнәлештәге эзләнүләрен ул бүген дә дәвам итә. Соңгы дистә ел эчендә галим күпсанлы чыганаклар буенча Таҗетдин Ялчыголның тормыш һәм иҗат юлын тәфсилле өйрәнде, хатыны Рәмзия Садри кызы белән бергәләп, аның дини-суфыйчыл эчтәлекле атаклы «Рисаләи Газизә» китабының текстологиясен булдырып, төпле шәрехнамәләр белән «Мирас» журналы аша һәм күләмле басма китап рәвешендә халыкка җиткерде.

Әйе, профессор Х. Миңнегулов—күренекле текстолог та бит әле. Төрле почерктагы, өслүбтәге гарәп хәрефләре белән язылган, борыңгы төрки сүзләр, гарәп-фарсы алынмалары белән тулган урта гасырлар әдәбияты буенча кулъязмаларны күзләрне бетерә-бетерә уку, аңлашылмаган сүзләргә тәрҗемәләр, аңлатмалар бирү, искәрмәләр язу—укучы күз алдына китерә алмаслык авыр эш һәм күп вакыт сарыф итүне сорый торган хезмәт. Корама, катнаш тел белән язылган текстлардагы ислам дине төшенчәләренә эчтәлекле комментарийлар бирү тагын бер кат галимнең текстология өлкәсендә дә фәнни әзерлекле, эрудицияле галим булуы турында сөйли.

Егерменче гасыр азагында СССР таркалгач та, дөньяның төрле кыйтгаларына таралган татар әдипләренең һәм зыялыларының мирасын Ватанга кайтару мөмкинлеге туды. Кытай, Төркия, Германия, Финляндия һәм Японийдә яшәгән Гаяз Исхакый, Сәгадәт Чагатай, Ләбиб Каран, Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Минһаҗ Исмәгыйли кебек шәхесләрнең мөһаҗирлектә язылган әсәрләре Х. Миңнегулов тырышлыгы белән татар матбугаты битләрендә һәм монографик

хезмәтләрдә дөнья күрде, аларның әдәби-мәдәни эшчәнлеге хакында бай мәгълүмат бирелде. Ул XX гасыр башындагы Ренессанс әдәбиятыбызның нигез ташларын салучы Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлек дәвере иҗатын һәм публицистикасын өйрәнү буенча бәһалап бетермәслек игелекле эш башкарды, берничә китап һәм монография язды, 50 гә якын мәкалә бастырды *(Исхакый мөһаҗирлектә, 1999; Гаяз Исхакый. Ислам мәмләкәтләрендә, 2003; Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты, 2004; Чит илләрдәге татар әдәбияты, 2007; Янапар тарихы. История Актукова, 2008)*.

Профессор Х. Миннегулов—кин колачлы тикшеренүче. Ул урта гасырлар турында гына түгел, яңа заман татар әдәбияты турында да иркен фикерли. Аның XIX йөз суфыйчылык шигъриятен, дөньяви эчтәлектәге реалистик мәгърифәтчелек поэзиясен һәм прозасын өйрәнүгә керткән өлеше дә зур. Сиксәненче еллар башында язылган, университетның фәнни эшләр конкурсында беренче премиягә лаек булган «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» һәм «XIX йөз татар хрестоматияләре» бүген дә студентларның кулыннан төшми. Татар әдәбиятының алтын дәвере—XX гасыр башы, аеруча аның рухи аталары Габдулла Тукай белән Гаяз Исхакый хакында аның күпсанлы мәкаләләре, хезмәтләре язылган. Совет чоры һәм бүгенге әдәби барыш турында да мәкаләләре (К. Нәҗми, А. Гыйләҗев, Ә. Синегул, Ә. Рәшит, К. Булатова, Р. Гаташ) басылып тора. Әле менә күптән түгел аның ике шәкерте—Афзал Таһиров һәм Татарстанның халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмов турында диссертацияләр яклаган Рәҗәп Бәдретдинов белән Резеда Ласкова фән кандидатлары булдылар.

Галимнең әдәбият теориясе, бигрәк тә аның шәркый жанрлар, традицияләр, образ-сурәтләр, мотивлар турында әдәбият белеме сүзлекләренә, энциклопедияләргә язган мәкаләләре дә игътибарга лаек. Мәсәлән, минем үземә аның халкыбызның сәнгатьчә фикерләвендә «игү ат» мотивын тикшергән, ягъни җирдә кеше булып яшәгәндә изге гамәлләр кылырга чакырган мәкаләсе ошый.

XX гасыр азагында илдәге сәяси-иҗтимагый вәзгыять, идеология үзгәргәч тә, милли мәгарифебез дә янарыш юлына басты, Х. Миннегулов та татар һәм рус мәктәпләренең 5, 9, 10 сыйныфлары өчен дәреслекләр язу, хрестоматияләр төзү эшенә алынды һәм аларның берничә басмасы дөнья да күрде. Урта мәктәпнең 9 нчы сыйныфы, гимназия, көллият, махсус уку йортлары өчен язылган дәреслекнең фактик материалга бай, теоретик күзәтүләрнең төпле булуын аерата билгеләп үтәсе килә. Хәзерлекле әдәбият укучысы өчен анда материалны сайлап алу, проблема кую, иҗади эш итү мөмкинлекләре бик тә зур. Элгәресе еллардагы дәреслекләрдән аермалы буларак, бу дәреслектә урта гасыр татар әдәбияты үсеш-үзгәрештәге дәвамлы бер процесс рәвешендә чорларга бүлеп укучыларга тәкъдим ителә. Кайбер альтернатив дәреслекләрдә урта гасыр татар әдәбияты бүген дә өзек-төтек өйрәнелә, теге яки бу чордагы аерым шагыйрьләр иҗатларын яктыртуга гына игътибар юнәлтелә. Хатыйп Миннегулов язган дәреслек исә урта гасырлардагы әдәби барышны бөтен тулылыгында һәм бербөтен буларак күзалларга мөмкинлек бирә.

Мәдәниятыбызны, әдәбиятыбызны өйрәнүдәге уңышлары өчен филология фәннәре докторы, профессор Хатыйп Миннегулов күп кенә дәрәҗәле һәм мактаулы исемнәргә, бүләкләргә лаек булды. Ул—Россия гуманитар академиясенең хакыйкый әгъзасы (1996), Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе (1994, 2005), Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт бүләге лауреаты (1995), Россия Фәннәр академиясенең гыйльми стипендиаты (1994—1996), Халыкара ел кешесе (Англия, Кембридж, 1998), Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты (1998), Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләк иясе (2006), Халыкара казакъ-төрек университетының (Төркестан) шәрәфле профессоры (2004), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1996 елдан) һ.б. Киләчәктә дә ана яраткан һөнәре—әдәбият фәне өлкәсендә яңадан-яңа ачышлар ясарга, бүгенге көндә басылып чыгуны көтеп ята торган әзер һәм җитди хезмәтләрен җәмәгатьчелеккә җиткерергә, лаеклы бәяләнүгә, сәламәтлектән аерылмыйча, җан тынычлыгы белән яшәргә, иҗат итәргә, халыкчы, милләтче галим-хатыйп булып, бәрәкәтле гомер кичерергә насыйп итсен!

**Резеда ГАНИЕВА,**
*КДУ профессоры*

## Илдар Зарипов



Рәссам, нәкышче Илдар Касыйм улы Зарипов 1939 елның 15 ноябрендә Казан шәһәрендә туа. Ул станлы нәкыш һәм монументаль бизәү өлкәсендә үзенең хезмәтләре белән танылган иҗатчы. Эшчән һәм энергияле Илдар, В. Суриков исемендәге Мәскәү художество сәнгате институтын тәмамлаганнан соң, Татарстан һәм Россия Федерациясенең иҗат дөньясына кыю үтеп керә.

Аның беренче әсәрләре үк композиция һәм миллилекешелекле колорит ягыннан тамашачыларның игътибарын шундук үзенә җәлеп итте. Бөтенесен санап тормастан, «Туган авылда» (1982), «Казан чибәре—Зөлфия» (1984) һәм «Кырлай моңнары» (1986) полотноларын әйтеп китү дә җитә.

Илдар Зарипов иҗатының тагын бер төп үзенчәлеге—образларның барлык халыклар өчен дә универсаль һәм шул ук вакытта үтә дә милли булуында. Аның күп кенә картиналары Мәскәүнең Третьяков галереясында, Санкт-Петербургтагы Рус музеенда һәм Россиянең башка зур музейларында саклана.

Ул—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1976), РСФСРның атказанган рәссамы (1986), Россиянең халык рәссамы (2002).

## Равил Фәйзуллин



Равил Фәйзуллин—бүгенге татар әдәбиятын әйдәп баручы шәхесләрнең берсе. Ул 1943 елны Балык Бистәсе районының Балтач (Юлсубино) авылында туган. Үткән гасырның 60нчы елларында Казан университетында филологик белем алган, сонрак татар фольклоры буенча аспирантура тәмамлаган.

Равил Фәйзуллин иҗаты аның иҗтимагый эшчәнлегеннән аерылгысыз; үзе әйтмешли, «яшьтән үк көрәшкә кереп», ул байтак җаваплы эшләр башкарды. Әлмәт Язучылар берлеге җитәкчесе (1968—1972), Татарстан Язучылар берлеге җаваплы секретаре (1973—77), 1989 елдан бүгенгәчә «Казан утлары» журналының баш мөхәррире.

Ул, шагыйрь, галим һәм публицист буларак, төрле телләрдә 50дән артык китап чыгарды. Аның 5 һәм 6 томлык «Сайланма әсәрләре» ике тапкыр дөнья күрде (1992—2001 һәм 2005 еллар).

Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Равил Фәйзуллин күпсанлы дәрәҗәле исемнәр һәм бүләкләр иясе. Кайберләрен санап үтәргә була: Ул—Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (язучылар арасында иң яшь лауреат, ул ана 34 яшьтә лаек булды). 2007 елны Татарстан Фәннәр академиясенең почетлы (шәрәфле) академигы итеп сайланды.

**Альфред ӘБДРӘШИТОВ,**
*скульптор*

# ЯЗЫЛМАГАН ДРАМА

Хәтердә: безнең күрше авылның читендәге бер урамында караңгы төннәрен электр баганаларының берсендә дә ут булмый торган иде. Электрикның гамьсезлегеннән түгел, шул урамда яшәүче шук малайларның эше: өлкәннәрнең калхуз кырларыннан нидер чәлеп кайтулары күренмәсен, янәмәсе.

Фаил Шәфигуллинның әсәрләрен кабат укып утырганда кылт итеп әнә шул, әллә кайчан онтылган малай-шалай шуклыгы искә төште: Әмирхан Еники язмышлый, кешене «рухи азатлыкка һәм фикри хөрлеккә сусатып» яшәткән тоталитар системаның караңгы мохитендә генә яшәп киткән язучы Фаил Шәфигуллинның, багана очындагы электр лампалары шикелле берәүләргә юл яктыртып, икенчеләргә кырын эшләрен күрсәтеп, «комачаулаган» кыю әсәрләре өчен үч алдылар да инде өлкәнрәк «шук малайлар»...



Караңгы авылдан чыккан Фаил Шәфигуллинга язучылар юлы дигән мәртәбәле һәм чиктән тыш җаваплы трактка күтәрелеп кушылу җиңел бирелми: аның балачак еллары гына түгел, үсеп балигъ булгач та шактый гомере «кыен ашап» уза. 1939 елда дөньяга беренче аваз салган малай дүрт яше тулар-тулмас әтисез кала: Яшел Үзән төбәгендәге (элекке Норлат районы) Карашәм авылының абруйлы колхозчысы Хафиз абзыйны, сәламәтлеге житмәү аркасында фронтка алмасалар да, 1943 елда каһәрле сугыш афәте барыбер аны куып тота—ул, рәтле ир-атсыз хәлгә төшкән авыл халкы мәнфәгатен кайгыртып йөргәндә, кышкы буранда адашып, ике үпкәсенә дә салкын тидерә һәм шул чиреннән котыла алмыйча дөнья куя. Шунлыктан Фаилгә жиде сыйныфлы мәктәпне тәмамлауга, сыек буыннары катмас борын, жин сызганып, калхуз эшенә жигелергә туры килә. Ә өч елдан, кечкенәдән тынгысыз җанлы булган Фаил, хыялында булган аргамаклар ялына ябышып чабасы урында, карлы-буранлы Коми урманнарында агач кисә. Аннары, Биектау ягындагы кыска курслы механизаторлар мәктәбендә «корыч аргамакларны жигәргә» өйрәнеп, Сталин «курортларында» бер аягын калдырып кайткан Ибраһим Салаховның туган ягында, Казакъстанның Күкчәтау төбәгендә, дала йомраннарын куркытып сызгырта-сызгырта, трактор белән чирәм жирләр күтәрә. Анда үз буразналарын сызгач, Ерак Көнчыгышка—жир читендә урнашкан Находка портында—башта кара эшче ипиен кимереп карый, аннан соң, болай да каты сөяләнеп беткән учларына игәү тотып, корыч каезлый, ул да канәгатьләндермәгәч, резинләнгән киндер робалы балыкчыларга ияреп, сейнер палубасына менә һәм, тәвәккәлләп, исеменә жисеме туры килмәгән Тын океанның холыксыз кочагына ташлана. Анда балыкларның көмеш тәңкәле ташкынын билдән суга батып аралый-аралый, аратирә тралга эләккән фил хортумы шикелле тыгыз тәнле капшавычларының аскы ягына вакуум ясаучы жиз төймәләр тезгән сигезаяклар белән дә сугышырга туры

килә аңа—авыл егетенә кызык! Әмма кендек каны тамган туган-үскән ягы жирсетә бит 23 яшендә Жир йөзенең алтыдан бер өлешен аркылыга-буйга тәпиләп диярлек йөреп чыккан егетне... Шунадыр инде, аның диңгезләрдә йөргәндә язылган беренче шигырьләрендә давылларның дәһшәтле үкерүләрен Идел-дәрьясының, тыйнак кына ярларга бәрелеп чупылдавы басып китә, ә туган якларына кайтып төшкәч, ул болайрак язачак:

*Бер бит шигырем суга төште минем,*
*Йөргән чакта диңгез яры буйлап.*
*Зәңгәр язуларны юып алгач,*
*Зәңгәрләнде диңгез гүя ныграк.*
..............................................................
*Чайкалды да әкияттәге сыман*
*Төсен бозды зәңгәр киңлек менә:*
*«Мин музыка язам,—диде диңгез,—*
*Юләр малай, синең сүзләреңә.»*

Ниһаять, Фаил Шәфигуллин 1962 елда Яшел Үзәнгә кайтып төшә: ирек сөюче акчарлаклар монда да «нибуч кайтырсың шулай!»—дип чыелдыйлар, тик сәйярне үги ана кебегрәк каршы ала йомшак учы белә кечкенәдән башын сыйпап үстергән төбәге. Күп йөрү, күп күрү генә аз, имеш, белемең—ташка үлчим, дип маңгаена бәреп әйтәләр «диңгез бүресенә». Янә бераз белем эстә, янәсе. Эстәргә тек, эстәргә: Фаил Шәфигуллин, электр белән эретеп ябыштыручы булып эшли-эшли, иң элек кичке мәктәпне ерып чыга, аннары, читтән торып укып, Казан университетының журналчылар әзерләүче факультетын тәмамлый. Менә хәзер диңгезче румбасы, кыйлдин-быйлдин килеп, йә диңгезгә, йә Карашәменә күрсәтеп тинтерәтми аның җанын, хәзер ул тулаем гәзит-журнал эшендә. Хәер, университетны тәмам иткәнче, 1970 елда ук, «Казан утлары» журналына чакырып алына инде ул: менә кайда кирәге чыга аның бай тормыш тәҗрибәсе! Җилкәләрен баса язган шушы «йөге» хәлиткеч роль уйнагандыр инде: аны, ияләшеп килгән урыныннан кубарып, мөстәкыйль эшкә—сүнәр-сүнмәс пыскып кына чыгып яткан яшь язучыларның «Идел» альманахына җаваплы редактор итеп тәгаенлиләр. Ә Ходай бирмеш гомеренең соңгы елларында (1975-82) Фаил Шәфигуллин «Чаян» журналы редакциясендә әдәбият һәм тәрҗемә бүлеге мөдир-мөхәррире вазифаларын башкара.

Усал язмышы язучыга гомеренең 12 елын гына яраткан хезмәтенә «тәгаенләп» калдырган булган икән. Гәрчә булачак юмор-сатира остасы, танылган прозаик һәм шагыйрьнең бу хезмәтен алдагы эзләнү чорларыннан аерып карарга кирәкми дә—ул һәрчак башимәс характерлы Карашәм егете булып кала.

Фаил Шәфигуллинның кадерле Карашәме белән горурланып сөйләгәне хәтердә янара: зур иконалар-хачлар күтәреп, татарларны чукындырырга чыккан миссионерлар авылдан-авылга кумәкләшеп йөри башлагач, Карашәм халкы бердәм сәнәкләр, чалгылар тотып каршы төшкән һәм тегеләрне үз авылларына кертмәгән икән заманында. Менә нинди гаярь ул безнең Карашәмебез, дип «әрмәнски» борын канатларын лачын коштай киергән иде дустыбыз.

«Безнең Карашәмебез» дигәннән, Фаил Шәфигуллин, гомумән, «минем» дип авыз тутырып әйтерлек жирлеге булганда да «безнең» кебек уртаклыкны белдергән алмашлыклар куллана иде. Кайбер яшь каләм ияләре, матбугатта бер-ике кечтеки әсәре күренүгә, «халкым минем», дип дәшеп вәкарьләнә башлый, Фаилнең иҗатында андый урынсыз купшы сүзләрне очратмыйсың: тәкәбберлекне жене сөймәде! Ә без үзебез аны, юмор өлкәсендәге уңышларына ишарәләп, үзара:

—Кайчан эрерәк күләмле әсәрләргә күчәсең инде, «татар Чеховы»?—дип шаяртабыз.—Ул гомергә «Чехонте» булып йөрмәгән әнә, повестьлар да язган, драматурглар бакчасында да үз кишәрлеген булдырган.

Юк, юмор-сатирага гына кендеге берекми Фаил Шәфигуллинның: һәр танылган язучы кебек үк, ул да иҗатын тезмә әсәрләрдән, ягъни шигырьдән башлап җибәрә.

Беренче шигырьләре көндәлек матбугат битләрендә 1958 елда ук күренә башлый анын (билгеле булганча, Фаилне бертуган Шәүкәт абыйсы—балигъ булгач, профессиональ дингезче юлын сайлаячак һәм һәвәскәр маринист-рәссамга әвереләчәк кеше—шигырь язып котыртып, бик кече яшьтән әдәбияткә гашыйк итә) һәм Язучылар берлегенә Фаил нигездә шагыйрь буларак кабул ителә. Ул үзе исән чагында өч шигырь җыентыгы бастырып чыгара, аның сүзләренә Фасил Әхмәтов, Зиннур Гобәйдуллин, Мирсәет Яруллин кебек «маститый» аһәнсазлар көйләр иҗат итә, Рафаил Сәхәбиев кебек атаклы җырчылар да анын серле шигырьләрен укып композиторга әвереләләр. Фаил Шәфигуллинның тагын бер гаять дәрәҗәдә киң колачлаган иҗат өлкәсе бар, ул да булса,—балаларга-яшьләргә багышланган төрле жанрдагы бик күп әсәрләре.



*Фаил Шәфигуллин һәм Мәгъсум Хуҗин.*

Фаил Шәфигуллин югары эрудицияле язучы иде: анын әсәрләрен укыганда моны һәрдаим тоясын. Ул, мәкаләләрендәме, хикәяләрендәме, повестьларындамы булсын, фән дөньясына кагылса, чәчләренә кырау төшкән галим-голәмәнен күп мәгълүматлы булуы белән исләрен китәрә; тарихка чумса, тарих фәнендә азау тешләрен сындырган профессорларны гаҗәпләндерә; музыка сабантуена чыкса, аһәнсазларны профессиональ биеклектә фикер сөреше белән әсирли; рәсем сәнгате карурманнарына керсә ул, беркайчан «өч каен арасында» адашып йөрми... Чөнки аның иманы камил: чын язучы, милли аһәнле талантка ия булуы өстенә, беренчедән, бай тормыш тәҗрибәсе җыйган: икенчедән, киң эрудицияле; өченчедән,—чын милли рухлы тәрбия алган булырга тиеш. Фаил Шәфигуллинның үзенә шушыларның барысы да олаулап бирелгән иде! Ә инде бәһаләп бетергесез андый рухи хәзинәләрне нәрсәгә сарыф итәргә дип, баш ватасы юк иде аның: балаларга да, өлкәннәргә дә тигез өләште ул рухи байлыгын. Бигрәк тә балаларны, яшьләрне үз итте ул һәм алар өчен, алда китерелгән язучы кредосына хилаф кылмыйча, вакытын да, куәсен дә җәлләмәде. Фаил Шәфигуллинның күпчелек китапларына «Урта һәм өлкән яшьтәге мәктәп балаларына» дигән җөмлә сугылган. Авторнын «Әлфинур» дигән бәяненнән алып, «Ак маңгайлы бүреләр»енә кадәр барысы да, яшь укучының кабул итү куәсен күз уныннан ычкындырмыйча һәм шул ук вакытта аны күпкырлап рухи баетуны-үстерүне максат итеп куеп, чиксез ярату хисе белән, аның ин-иң гүзәл уй-тойгыларын, матур теләкләрен, борчылуларын-шатлыкларын тирән аңлап, чын халыкчан тел белән югары сәнгатьчә язылганнар. Аеруча, Фаил Шәфигуллинның дингезгә, дингезче булып үсүгә багышланган әсәрләре мавыктыргыч мажаралы сюжетлары, геройларының эчкерсезлеге, тәвәккәллеге, матур максатлы булулары, теленең нечкәлеге-нәфислеге һәм байлыгы, халыкчан рухлы, тормышчан чынлыгы белән сугарылган булуы яшьләр игътибарын җәлеп итә. Егерменче йөзнең икенче яртысында татар әдәбиятенә Фаил Шәфигуллин белән Миргазиян Юныс дәһшәтле океан сулышы алып килделәр, әдәбиятның офыгын киңәйттеләр.

Әмма Фаил Шәфигуллинның иҗаты классика дәрәҗәсенә камилләшеп күтәрелүе юмор-сатирага багышланган йөзләгән хикәяләрендә ныграк ачылды, шикелле: ул үзе исән чагында укучылары ничек йотлыгып кабул итүләрен күреп калды. Моның

белән язучының бүтән жанрларда язылган әсәрләре калышрак дияргә теләмим, әлбәттә. Башкалары да язучының егәре зур перспективалы икәнлеген тулысынча исбат иттеләр. Антон Чеховны бөтен Рәсәй зыялылары «Чехонте» итеп кенә кабул кылган чакта беренче күптомлыгының калын-калын китаплары чыга башлагач, өнсез калалар: «Чехонте» дигәннәре Лев Толстойлар белән янәшә басып торырлык зур язучы икән ләса! Фаил Шәфигуллинның «Күзгә карап» дигән юмор хикәяләре җыентыгы кулларына килеп кергәч, безнең татар зыялылары да әнә шундыйрак халәт кичерделәр шикелле. Татар телендә 12 мең данәле тираж белән басылган бу китап бик тиз арада кибет киштәләреннән шәхси китапханә шүрлекләренә күчеп урнаштылар. Озакламый ул китабы, тәрҗемә ителеп, урыс телендә ярты йөз меңлек тираж белән чыкты (ни кызганыч, авторның үзенә аны кулына тотып карау насыйп булмаган икән). Әдипнең әсәрләрен танылган нәфис сүз осталары сәхнәләрдән, радиодан, телетапшыруларда яңгырата башладылар. Бигрәк тә, язучының якташы Рәшит Сабиров аның әсәрләрен яхшы башкаруы белән киң танылды. Укучылары арасында: «Их, Фаил Шәфигуллинның хикәяләрен, Чеховның әсәрләре кебек киногa төшереп карыйсы иде»,—дигән фикерләр ишетелә башлады.

Сәнгати көчле тәэсир итүенең сере нидә икән соң Фаил Шәфигуллин әсәрләренең? Бай автобиография, сүз дә юк, язучыга ышанычлы таяныч: тик, В. Гёте әйтмешли, «Кеше үзенең шәхси кичерешләрен генә чагылдыра икән, ул әле шагыйрь түгел. Дөньяны үзләштереп, аны сәнгатьчә гәүдәләндерсә, шагыйрьгә әверелә.» Менә, мисалга, Фаил Шәфигуллинның «Бәхет дингезе астында» дигән саллы гына күләмле бәяненең финалы: әсәрнең төп каһарманы Рәсим, диңгез буе сопкасына менгән дә, түбәнгә карап тора. Аста кечкенә, тып-тын култык җәйрәп ята. Юк, тып-тын ук түгел икән лә, кыялар арасыннан диңгез җиле үтеп кергәндә җыерчыклана икән суның йөзе. Ә салкын җил гел зур диңгез ягыннан исә. Әкренләп Рәсимгә тиктормас диңгез үзе шикелле үк тынгысыз бер малай булып тоела башлый, ә култык, мөгаен, аның өчен кайгырып йөзен отыры җыерчыклата-җыерчыклата борчылучы әниседер. Әнисен борынгы тау тезмәләре белән уратып алынган иске йортта ялгызын гына калдырган да диңгез-малай, еракларга чыгып тайган. «Әнисе кызганыч диңгезнең: шәрә таулар арасында бер ялгызы сагышланып яши»,—дип тәмамлый автор әсәрен. Көтелмәгән метаморфоза белән тетрәндереп нокта куя автор. Әнә шулай нокта куя белүе түгел микән Фаилнең сихри серләренең берсе?

Фаил Шәфигуллинның «Күзгә карап» дигән җыентыгына тупланган кыска-кыска хикәяләрендә иҗади осталыгы тагын да ныграк ачылган. Әдипнең иң хөрмәт иткән язучыларының берсе А. П. Чехов: «Яза белүче—язучы түгел, сыза белүче—язучы»—ди торган булган. «Суы» калмасын. Тик суларын чыгарып түккәндә, чаманы югалтып, кадерле баланны да ялгыш чүплеккә ташлама! Чыгарып ташламый Фаил Шәфигуллин «Кадерлесен», ә тыгыз фикерлеккә ирешә: укучы хыялында төрле ихтималлар тудыра торган кыска бөтенләй көтелмәгән кыска дәвам һәм парадокслы кыска финал. Меңләгән укучыга яхшы булган таныш «Сафура, Бәкер һәм трактор», «Өйдә тәртип бетте», «Үгет» кебек шактый күп санлы шедеврлары әнә шундыйлардан.

Үз иҗатын әдәбият дөньясына файдалы булган җәмәгать эшләреннән дә аерып карамый иде Фаил Шәфигуллин: ул күп еллар Язучылар берлегенең «Тынгысыз каләм»ен үз көче белән генә диярлек чыгарып килде. Әдәбияттан ераграк торучылар өчен ачыклап үтим, дивар гәзите ул, ягъни «эстингәзитә» генә. Масштабы кечтекилегенә карамагыз, бик тә абруйлы матбугат иде ул! Аның диварга эленгәнен түземсезләнеп көтеп алалар язучы һәм язучы булырга омтылучы агай-энеләр, чиратка басып, кем әйтмешли, укыйлар—газета үзе берничә аршинлы булса да, урын җитми иде укучы агай-энеләргә! Менә кайда әдәбият хәрәкәте ачык шәйләнә иде Фаил Шәфигуллин заманнарында… «Фали дус»—без аңа үз итеп шулай дәшәбез—үзе дә шунда «Әпкәли Требкәле»дан, чарланып, зур Фаил Шәфигуллинга әверелде. Анда басылып чыгуын ташка басылуга караганда мәртәбәлерәк саныйлар иде олпат-олпат язучылар: кайберәүләр шул чорда диварга эленгән «Тынгысыз каләм»не, урлап алып китеп, әлегә тиклем шәхси архивларында саклыйлар. «Әсәрләре» шунда чыгуга

ирешкән булса, әлбәттә. Сонрак, Фаил Шәфигуллин «Чаян» редакциясенә күчкәч, әдәби хәрәкәтнең бер өлеше дә шунда күченде: иҗатлары бераз сүлпәнләнебрәк торган Нури Арслан шикелле әдәбият арысланнары да, Камил Кәримов төсле каләм тибрәтә генә башлаучылар да Фаил Шәфигуллин янында җанланып күтәрелеп киттеләр.

Фаил Шәфигуллинның тагын бер матур хыялы бар иде: пьеса язарга теләде ул. Ә иң башта—аргамаклар турында язачак! Аннары күз күрер, янәсе...

Ләкин өлгермәде.

Фаил Шәфигуллинның, бервакыт ачылып китеп, диңгездә йөргәндә «яшел нур» дигән бер серле яктылыкны күрергә хыяллана идем, дип сөйләгәне бар. Гаҗәеп матур бер могҗиза ул һәм бары тик диңгездә генә, анда да бик сирәк була торган штиль вакытында, кояш диңгез офыгы артына чумып беткәндә кинәт, күк гөмбәзе астыннан лазер нуры сыман офыктан ямь-яшел нечкә җеп булып сузылып, ялт итеп ала да, шулай ук кинәт сүнә. Аның, ничек яралганын физиклар, күп еллар төрле фаразлар кылып тикшереп карасалар да, һаман аңлата алмыйлар. Ә тәҗрибәле диңгезчеләр «бәхетле язмышлы кешеләр күзенә генә күренә ул», диләр. Фаил Шәфигуллин шуны күрергә насыйп итмәде, дип үкенә иде...

Мәгәр шулай да, Фаил Шәфигуллин искиткеч бәхетле язучы: аның үз әсәрләре, «яшел нур» кебек сихри сер булып калып, меңәрләгән укучыларына шатлык өләшә һәм өләшәчәк.

**Ризван ХӘМИД**

---

## Бер хикәя

*Фаил Шәфигуллин байтак еллар дәвамында Татарстан Язучылар берлегендә чыгып килүче «Тынгысыз каләм» стена газетасының мөхәррире булды. Шул вакытта төрле тәхәллүсләр (псевдонимнар) белән бик күп хикәяләр һәм хикәячекләр язды. Әмма язганнарының барысын да пөхтәләп җыеп бармаган ул. Безнең өйдә саклануы «Фаил архивы» папкаларында әлеге «Түзә шагыйрь башлары»ның беренче бите юк иде. Аны безгә, тагын кайбер әсәрләре белән бергә, радиодан «Йомрыбаш» көлке тапшыруларын алып баручы язучы Заһид Мәхмүди бирде.*

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.**

# ТҮЗӘ ШАГЫЙРЬ БАШЛАРЫ

...Егерменче гасырда хәзерге кебек унҗиде әдәби журнал юк иде әле. Шул берләнбер «Казан утлары».

Егерменче гасырның җитмешенче еллар башында «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөдире И. Юзеев дигән шагыйрьнең бер көнне шигырь укып дөнья шаулатканы бик нык хәтергә сеңеп калган. Ул чагында редакциядә ун шигырь уку бик зур геройлык иде инде ул! Ни өчен дисәгез, бүлек мөдиреннән эш көне менә болайрак уза торган иде.

Иртә белән сәгать тугыз тулар-тулмас редакция бүлмәсенә тәмәкече кеше килеп керә. И. Юзеев белән кул биреп күрешә. Хатынының, әнисенең, бала-чагаларының, туган-тумачаларының хәлен бик тәфсилләп сораша. Әле бу вакыт И. Юзеев биш кенә юл шигырь укырга өлгергән була. Әмма тәмәкече кешенең сорауларына җавап бирә-бирә, әлеге биш юл шигырьдә ни турында сүз барганлыгын хәтердән чыгарып җибәрә. Тәмәкече кеше тәмәкесен тартып бетереп, саубуллашып чыгып киткәч, гәҗит укучы керә (өенә бер гәҗит тә яздырмаганлыктан, ул гәҗитне редакциягә килеп укый). Үзе бертуктаусыз И. Юзеевка сораулар яудыра, теге яки бу вакыйгага карата аның мөнәсәбәтен сорый. Гәҗит укучы чыгып киткәч, И. Юзеев әлеге шигырьне янабаштан укырга керешә. Ләкин керешеп кенә кала—ишектән эшләпәле кеше килеп керә. Ике арада кызыклы һәм шигърият өчен бик файдалы әңгәмә башлана.

—Ябыгып киткәнсең әле син.

—Шулаймы?!.

—Элек таза идең.

— Э...

—Монда эшлисеңмени?

—Әйе.

— Өстәлең зур икән.

—Зур.

—Шигырь укыйсыңмы?

—Әйе.

—Ләбибә килмәдеме әле?

—Юк шул.

—Нигә килми икән?

—Белмим.

—Гариф үзендәме?

—Белмим.

—Бикләнеп утырадыр, шәт.

—Шулайдыр.

Эшләпәле кеше чыгып киткәч, И. Юзеев тагын өстәленә иелә. Бусагада күзлексез ханым күренә.

—Гафу итегез, сез Нури Арсланов буласызмы?

—Илдар Юзеев мин.

—Гариф үзендәме?

—Белмим.

—Телефон номеры элеккечәме аның?

—Элеккечә.

Күзлексез ханым И. Юзеевны яңа шигырьләр алып килдем дип сөендерә. Хәзер үк укып-танышып чыгуын һәм журналның бер айдан чыгасы санына тәкъдим итүен үтенә. Сүз уңаенда үзенең редактор белән таныш булуын да искәртеп куя. Аның шигырьләрен укыгач, И. Юзеевның эченә җылы йөгерә, маңгаеннан борчак-борчак тир бәреп чыга.

Күзлексез ханым чыгып киткәч, И. Юзеев берничә минут ишеккә карап утыра. Тирләгән маңгаен сөртә һәм янә алдында яткан шигырьгә текәлә.

Ишек шакыйлар. Яшь кенә малай керә. Әдәби консультант Г. Рәхим фатихасы белән килгән икән. Шигырьләре, һичшиксез, дөнья шаулатырлык, имеш. Утыралар. Укыйлар. И. Юзеевның тагын маңгае җылына. Тик күнеле боз кебек. Яшь шагыйрь ачулана, үпкәли. Ишекне бик каты ябып чыгып китә.

Ниһаять, ишекне шакымый-нитми генә олы шагыйрь керә.

Өстәлгә төргәк куя. Сибгат Хәкимгә укыттым, яхшы шигырьләр дип әйтте, ди. «Арпа» дигәнен генә бирсәң ярый, бирмәсәң ярый, дип әйтте, ди. Минемчә, бирергә кирәк, үземә бик ошый «Арпа», ди. Шигырьләремне Шәйхи Маннурга укытсан, риза-бәхил түгел, ди.

И. Юзеев сәгатенә карый. Бәхеткә каршы төшке аш вакыты житкән икән. (Кыздырылган тавыклар, кызыл балык, кара икра кебек ризыклар сирәк була торган иде ул чагында ашханәләрдә). И. Юзеев олы шагыйрь белән саубуллаша да, ярый, ярый, фәлән агай, дип, буфетка борчак боткасы белән сыер ите ашарга китә.

Ул ашап килгәндә инде аны бүрекле берничә кеше көтеп утыра, һәркайсынын редакциядә моннан алты-жиде ел элек жибәрелгән шигырьләре ята икән. «Н. Арсланов үч итеп басмый яткырды, син объектив, эчкерсез, нәзберек шагыйрь, Илдар энекәш; табып журналга басыйк әле шул шигырьләрне», диләр. Бүлмәдә берничә минут кәгазь бураны уйнап алганнан соң, ниһаять, тегеләрнең шигырьләре табыла.

«Бармактан гына суырып язылган икән шул болар»,—ди И. Юзеев шигырьләрне укып чыккач. Тегеләр ант итәләр. Без аны йөрәктән чыгарып яздык, диләр. Берсе: «Кәжүнни гонорар жәлме әллә сина?»—дип әзрәк балавыз да сыгып ала.

Бүрекле кешеләр артыннан ишек ябылырга өлгерми, бусагада олы яшьтәге яшь шагыйрә пәйда була. «Тынла әле, Илдар,—дип кычкыра олы яшь шагыйрә, ишектән керә-керешли үк,—Чаллы турында поэма яздым». Олы яшь шагыйрә, идән уртасына басып, югары пафос белән 2700 строфаны шытырдатып укып чыга да пальтосын салып чөйгә элә һәм янәдән укырга тотына:

Чаллы ул—таш кала,
Чаллы ул—яшь кала.
Керешен бетердем,
Поэмам башлана...

Бер караганда, И. Юзеев күзләрен ачкан килеш черем итә сыман, икенче караганда, ник туганына үкенеп утыра шикелле.

Олы яшь шагыйрә киткәч, ишектә тәмәкече кеше күренә. И.Юзеевнын йөзенә нур инә, күзләре яктырып китә.

Тәмәкече кешенең гаилә, бала-чагалар, мәктәп, дача турындагы сорауларына бик рәхәтләнеп жавап бирә ул.

Сәгать кичке алтыны суга.

Өстәл өстендә укылып бетмәгән өч бит шигырь ята.

*1973, октябрь.*

Миргазиян
Юныс

# ЧАКРЫМНАРЫН ЮГАЛТКАН МЕҢ ЧАКРЫМ...

*Ак песиле таллар, йөгреп килеп,*
*Чәчәкләрен сузды язларның;*
*Кар астында челтер чишелеп китте*
*Ак биләве умырзаяның...*
(«Язгы моң»)

*Син урыска урыс ул үстердең,*
*Үзбәк табып бирдең үзбәккә;*
*Яһүдләргә—яһүд, казакъларга —казакъ,*
*Кыргызларга кыргыз—буләккә.*
(«Интер-ана»)

Равил Рахмани—әдәби җәмәгатьчелеккә күпкырлы әдәбият белгече, талантлы һәм таләпчән нәшрият редакторы буларак танылган шәхес. Әле үзгәртеп корунының беренче



елларында ук татар телендә башлап дин китаплары чыгаручы да ул булды. Моңа кадәр аның нечкә лирик, масштаблы фикер йөртүче шагыйрь-философ икәнлеген якын дуслары гына белә иде. Реклама һәм иерархия золымында яшибез бит. Иҗатына һәм үзенә реклама ясауны, абруеңны әдәбият бүләкләре белән күтәрүне оештырып җибәрергә теләмисең икән—бигайбә, билгесезлектә томалана бир...

Шагыйрьнең «Мең чакрымга мең чакрым» исемле җыентыгы[1] басылып чыкканга тиздән ике ел тула. Вакытлы матбугатта китапка багышланган күп кенә мәкаләләр, ел йомгакларында, 2008 елда үткән язучылар корылтаенда Рахманинын уңышлары турында кайнар фикер алышулар да булмый калмас дип ышанып йөри идем. Өметләрем акланмады. Батулланың «Ватаным Татарстан», Айдар Хәлимнең «Мәдәни җомга» гәзитәләрендә басылган мәкаләләреннән тыш, китап хакында башка фикер ишетелмәде, бәя-язмалар күренмәде. Рецензия авторларының икесе дә—милләт өчен янып-көеп яшәүче олы каләм ияләре. Алар, һичшиксез, зур бәягә лаек булмаган иҗат турында язып тормаслар иде. Мина калса, «Мең чакрымга мең чакрым» шикелле китап чыгу—чыннан да, әдәбиятта, бигрәк тә хәлсезләнеп, укучыларын югалтып бетерә язган татар әдәбиятында еш була торган вакыйга түгел.

[1] Равил Рахмани. «Мең чакрымга мең чакрым». Казан: ТКН,2006.

Әдәбият сөючеләрнең һәм әдәбият белгечләренең болай битараф калуларында, мөгаен, тирәндәрәк яткан житдирәк сәбәпләре бардыр ...

Иң әүвәл татар китабының бүгенге укучысын күз алдыбызга китереп карыйк. Әдәбиятыбызның алтын чоры вәкилләре—Тукай, Дәрдемәндләр, көмеш чоры корифейлары—Такташ, Туфаннар тәрбияләгән китап яратучылар белән чагыштырсак... бүгенге китапның укылу бушлыгында жан биреп ятуы йөрәкне кысып тота. Әмма телен, рухи байлыгын, гореф-гадәтен югалтып бетерү чигенә якынлашкан, диненең бары тик ритуал өлкәсен генә кайтара алган үз милләтебезнең бүген нинди хәлдә икәнлеген, киләчәктә аны ниләр көткәнлеген тирәнрәк аңлау өчен дә чорыбызга лаек китапларның һәрвакыт янәшәндә торуы сорала... Дөрес, безнең инде күптән мондый колачлы һәм әрнүле китапны кулыбызга алганыбыз юк шикелле. Бәлки, чын шигърияттне онытып та бетергәнбездер?.. Югыйсә, бүгенгелекнең иң хәлиткеч проблемаларын, тулаем алганда, милли дөньяны җыентыгына сыйдырырга көче житкән яңа шагыйрь килүен күрми калырга тиеш түгел идек кебек...

*«Кем соң мин?» дип уйланмаска иде,*
*Үткәннәрне белмәскә иде;*
*Киләчәк дип кабынмаска иде,*
*Утка кабат кермәскә иде!*

Тормыш-көнкүрештә нәфес колы булуны, икейөзлелекне, тез чүгүне, ялагайлану-ярашуны үз итә алмавы, кыйбласыннан тайпылмаячагына тирән инануы тудырган бу шигырьне.

*Кырык буын бабай исеменнән*
*Әҗерләрен тутырып түләрмен:*
*Җир өстендә соңгы татар булып*
*Йөзләренә төкреп үләрмен!*
(«Үземне битәрләү»)

Әлеге шактый кискен яңгыраган шигырь юлларының да нәкъ менә Равил Рахмани тарафыннан әйтелүе, беренче карашка, берникадәр гаҗәбрәк тә тоела. Аның чамасыз тыйнаклыгы, әдәплелеге, гадәттә, күпләргә гап-гади юашлык кына булып күренә. Авторның тормышта кешегә юл биреп, һәрчак диярлек арткы рәттә калуы тирәнгә яшерелгән әхлак пружинасы барлыгын тоя алмаучыга мескенлек булып кабул ителергә дә мөмкин. Әмма, белүебезчә, әхлак кануннарын саклауда, дөреслеккә омтылуда Равил—чиктән тыш үҗәт һәм үзсүзле шәхес.

Шунысы да кызык, Рахмани шигырьләрен ун яшеннән яза башласа да, укучы хөкеменә аларны кырык ел гомердән соң, ягъни 2006 елда гына аерым китап рәвешендә тәкъдим итте. Ә бит ул 28 ел Татарстан китап нәшриятында эшләп, үз каләмдәшләренең 300 китабын редакцияләп чыгарган әдәбият белгече. Өч йөз китап! Һәрберсендәге күпме уңышлар, осталык-кимчелекләр... Кимчелекләрдән гыйбрәт ала белү осталык үрнәкләреннән өйрәнүгә караганда да файдалырак түгелмени кайчакта?!. Һәрхәлдә, «Мең чакрымга мең чакрым» китабы авторның талантын һәм тәҗрибәсен бергә туплаган көчле бер импульс тәэсирендә барлыкка килгән дип уйларга кирәк. Без бит моңа күнекмәгәнбез. Каләм осталары татарның классик такмагындагыча «бии-бии остара...» Рахмани исә—«как снег на голову».

***

Рахманиның иҗатына анализ ясаганда күз буяу чиктән тыш авыр, хәтта мөмкин дә түгел. Шигырь юлларында очраган ихлас фикерләре, тирәнгә үтеп, минем зәңгәрсу хыялларымда кабат яшәү булып кабына...

*Боз сахрасын, утлы очкын сибеп,*
*Ялкын итте сөю бураны...*
*Күңел кошым, җимреп тар читлеген,*
*Уятмакчы сайрап дөньяны!*
(«Язгы моң»)

Тау сыртында, дала киңлекләрендә җилдә тирбәлеп утыручы чал чәчле кылганнары ирексездән уйланулар дөньясына алып кереп китә:

*Туган җирдән куганнармы,*
*Тамырданмы корганнар...*
*Ярдан чыккан дәрья булып*
*Дулкынлана кылганнар.*

Беренче карашка, шушы унбер сүздән торган ике җөмләдә дала үләненнән башка бернинди сүз-сурәт, белешмә-информация дә юк сыман. Икенче караштa инде күз алдыбызда тынгысыз кылганнар диңгезе бәргәләнә, колагыбызда ярсу кылганнар җыры шавына кушылып, ерак бабаларыбызның гайрәтле ташкын булып Азия далаларыннан Идел буе, Дон, Днепр киңлекләренә үтеп керүе, юлында каршы торуларны да сизмичә, дала җиледәй Әдрән диңгез буйларына, Атлантика ярларына барып җитүе, «Идегәй» дастанында сурәтләнгән ирек һәм сокландыргыч батырлыклар—барысы да кино экранындагы төгәллек белән күз алдыбыздан үтеп тора. Ерак гасырлар агышын шулай гади үлән аша җанландыра алучы нинди сихри-тылсымлы көч соң ул? Бу—туган тел тылсымы, шигъри сүз хикмәте! Ул безне тарих чиксезлекләренә алып чыгып кына калмый, тынчу, кысан таш кетәкләрдә көн күрүебез, автомобиль төтене сулап яшәвебез белән дә тоташтыра.

*Дәртле, тере дә җырлары...*
*Тора тоташ моңнардан.*
*Дала буйлап ятып үкси*
*Күңелләре тулганнар...*

***

*«Кемнәр идек?.. Кем булдык...»—дип*
*Башын чайкый кылганнар.*
(«Кылганнар турында җыр»)

Җыентык авторы бу поэманы (күләме белән түгел, эчтәлеге белән) «Табигатьнең үтә сизгер бер иркәсе—Кызыл китапка кертелгән «Кылганнар турында җыр» дип атаган. Эш исемдә генә түгел, әлбәттә, хикмәт—фикер байлыгында!

Минемчә, талант ул—вөҗдан егәре, җан сизгерлеге; дөреслекне тою, аңлау белән генә чикләнмичә, аңа омтылышың синә чиксез зыян китергән очракта да туры юлдан тайпылышсыз баруыңны дәвам итү үҗәтлеге.

Сүзләре көй-музыка булып күңелдә дулкынландыргыч хис-халәт уяткан шигырьләр җыентыкта тоташтан диярлек дәвам итә. Китапны ябып куйганнан соң да, аларның йомшак аһәңе күңелдә яшәвен, сине озатып йөрүен туктатмый.

Бүгенгелекнең милләтебез алдына китереп куйган катлаулы, кискен проблемалары аз түгел. Автор аларның шактыен уртага салып, үз шигъри күзаллавын кыю рәвештә укучысына җиткерергә омтыла.

Мәкалә алдына эпиграф итеп алынган «Интер-ана» шигыре үзәк проблемаларның берсе—татар милләтен җилтерәтеп ассимиляция инкыйразына алып килгән гаҗәеп бер тискәре сыйфатын чагылдыруы белән игътибарга лаек:

*Син иблискә иблис табып бирдең,*
*Үзең күптән... калдың гыйбрәткә!*

***

*Ана исме—бөек!*
*Үз халкына*
*Хезмәт итәр бала үстерсә!—*

дип тәмамлый шагыйрь әлеге әсәрен.

Катнаш нихаклардан нигәдер татар тумый. Моның сәбәбе—урыс булып яшәүнен җинелрәк һәм отышлырак булуында. Дөрес, тоташтан урыс кына тумый катнаш никахлардан... Шактый гына процент милләтсез, динсез, денсез маргинал-манкорт та туа. Мондыйлар носари да, мөселман да түгел. Катнаш никахларнын төп куркынычы да нәкъ менә шунда. Мондыйларны урыслар «без рода, без племени» дип атап йөртәләр һәм «без бога в голове» дип тә өстиләр. Федор Достоевский нәкъ шушындыйлар турында: «Если у человека нет бога, он начнет разрушать»,—дип кисәтеп калдырган.

Милләт проблемасы бүгенге көндә, әлбәттә, тагын да нечкәрәк социаль проблемалар белән дә килеп тоташа:

*Бу хәлләрне күреп, аһ, күргәнче,*
*Тумышымнан сукыр булсамчы...*
*Исерек, пычрак урыс мунчасында*
*Татар хатыны бүген—мунчачы.*

(«Татар хатыны»)

Башкаларга да шулай микән, бу юлларны укыганда мин авыр, мәсхәрәле газап кичерәм. Күрәбез, бу инде хакимият тирәсендә коерык болгап, дәүләт премияләре алу өчен урыс шагыйрьләренен тәлинкәләрен ялап, колониаль бәйдә яшәү «горурлыгын» дога иткән кайбер «бөек» шагыйрьләребез такмагы гына түгел. Рахмани гасырлар буе бәгъребезгә тоз салып торган хакыйкатьне күреп зар елый һәм безне дә елата. Әгәр без, милләт буларак, сөйрәлеп кенә булса да шушы көнгә килеп җитә алганбыз икән, безне туган телебез, Ислам дине һәм татар хатынынын изге, шифалы тәрбиясе саклап калган!

***

Әрнеткеч шигырьләрдән соң, мин җыентыкнын һәр бүлегендә очрап торган, күнелгә бал да май булып яткан моңлы лириканы кайта-кайта укыйм...

Күр, автор үзенең җир йөзендәге иң ләззәтле яну—мәхәббәт тойгыларын әнә ничек шагыйрәнә сурәтли алган:

*Килде җиргә серле нуры,*
*Рәсмең иңде җаныма:*
*Бар җиһанга балкып тулдың,*
*Сызып гел югалдың да...*

(«Айларым, йолдызларым...»)

Укуымны дәвам итсәм, күп тә үтми кабат үземнең утлы ялкында калуымны абайлап алам:

*Туган якның һәрбер үләне*
*Әлсерәгән чакта тузанда,*
*Күл суларын эчкән болытлар*
*Дәррәү кубып кая кузгала?..*

М. Лермонтовнын «Тучки небесные, вечные странники...» сүзләреннән башланган сокландыргыч шигырен, Х. Туфанның тоткынлыкта болытлар аша

туган иленә җибәргән сәламе—«Агыла да болыт агыла» шигырен—укучы яхшы хәтерлидер дип ышанам. Лермонтовтан һәм Хәсән Туфаннан соң болытлар турында тетрәндергеч яңа сүз табып булмый да торгандыр дип йөри идем. Таба алган бит Рахмани!

*Яумасагыз, булыр ышыгы...*
*Ут табасы кызган—сез кирәк!*
*Туган җирне саклый алмагач,*
*Сезнең булу—ул буш сүз, димәк?!.*

***

Җыентыкның өченче бүлеге «Кеше хакы—Алла хакы» дип атала. Әдәбиятыбыз өчен өр-яңа булган бу темада Рахмани әлегәчә билгесезлектә кала килгән төрки-татар тәгълиматын яктырта.

Без озак еллар адәм баласының төп вазыйфасы—күзеңне бет басканчы бил бөгү, сугышта исә шәрә күкрәк белән амбразура каплау дип инанып яшәдек. Бу хакта китап укучыга да гел тукып тордык. Шунлыктан, кешеләр арасындагы яңа төр мөнәсәбәтләрне үзәккә куеп яктырткан әлеге карашны бүгенге укучының бик үк аңлап бетермәве дә мөмкин.

Уй-фикерләрем балачактагы якты хатирәләремә барып тоташа. Пропаганда күзлегеннән караганда «артта калган кара халык» яшәгән газиз Исергәбебездә язгы кытлыктан безне инеш балыгы коткара иде. Тоткан балыкны бүлешкәндә ялгыз яшәүче картларга, гарип-горабага, ятимнәргә өлеш чыгару мәҗбүри канун дәрәҗәсендә иде. Ул чакта бу безгә йола булып та тоелмаган. Без аңа әһәмият тә биреп тормаганбыз: ничек инде карт-корыны, гарипләрне, ятимнәрне өлешсез калдырып булсын! Инештә балык житәрлек, сөз дә ал... Җиләге дә урман тулы, баланы да, чикләвекләре дә.

Җыентык авторы «хак» терминының эчтәлегенә шәрехләп аңлатма бирүне кирәк тапкан. Ул аның: «дөрес», «гадел», «хокук», «вәкаләт» шикелле җәмгыяви, шәхесара мөнәсәбәтләрне аңлаткан киң мәгънәле сүз икәнлегенә тукталып, бу сүзнең егермедән артык мәгънә белдерүен ачыклый. Шунысы игътибарга лаек: урыс телендә ул сүзләрнең эквивалентлары юк. Телебездә урысчага тәрҗемә ителми торган сүзләр шактый. Ә инде Сәиф Сараилар яшәгән, «Идегәй» туган чорлардагы сүзләргә килсәк, аларның урысча тиңдәшен табу тагын да катлаулырак.

***

Өченче бүлек милләтнең әхлакый кануннарын сурәтләүгә багышланган. Без, татарлар, бүгенге көндә ике конституциягә, Рәсәйнекенә һәм үзебезнекенә буйсынып яшәгән булып саналыбыз... Татарстанның конституциясе Мәскәү белән озак тарткалашу шартларында әмәлләнде. Ә Рәсәй чынбарлыгы һич тә конституциягә сыймый. Социализм аталамы яшәү ысулы, әллә капитализммы, көнкүрештә һәрхәлдә степанразинлык хөкем итә. Татарстанга урысның яулап алган җирләрен сакларга китерелгән өлкән абзыкайларга конституция гомер гомергә «как дышло». Ә татарларга? Борынгы бабаларыбызның тормыш-көнкүрешендә исә хаклар кодексы, һәрхәлдә, конституция матдәләре ролен уйнаган. Аны, яшәеш агымына тәңгәлләштереп, күп буыннар катнашында милләт үзе төзегән. Үтәлешен дә үзе күзәтеп, тикшереп торган. Шунлыктан аның эчтәлегендәге матдәләр яшәеш тәҗрибәсенә туры килгән. Тормышта һәркемнен үз өлеше барлыгы, өлешнең катгый хокукы, шәхес өлешенә кереп бер-береңне рәнҗетмәскә тиешлелек, кеше өлешенә керүнең гөнаһ кына түгел, ярлыкаусыз җинаять икәнлеген саклау—кыскасы, һәрбер Хак гаделлек нигезендә, аңа кул тигерергә тыелу тәэсирендә яшәгән... «Мең чакрымга мең чакрым»да Рахмани шул кануннарны һәркем аңларлык дәрәҗәдә шигъриләштереп бирүгә ирешә.

Рәсәй шартларында законның көчсезлеге урыс дәүләтенең туктаусыз сугышып

торуына бәйле. Сугыш шартларында нинди закон саклау булсын! Тынычлыкта да Рәсәй сугыш канунында яши. Һәр чиновник—командир. Ә командир приказы—үтәлергә тиеш.

Хаклар бүлеге адәм баласының фани гомере, аның ахирәтлеге, табу-югалтулары, тормышка ашмый калган хыяллары, уй-теләкләрен колачлый алган. Җыентыкта әдәби «мин» белән янәшә милләт кичерешләре, ватан язмышы, иман хөкеме һәм туган тел тәкъдире тоташ бер агым булып сурәтләнеп бара.

Җыентыкның өченче бүлеген, бәлки, үзен генә аерып алып махсус өйрәнергә, ана аерым анализ ясарга кирәктер? Бу өлештә, чыннан да, милләтебезнең киләчәгенә бәйле чиктән тыш җитди проблемалар ята.

***

Дүртенче бүлек «Кеше бәясе» дип атала. Заман бәяләре гаҗәп дәрәҗәдә тотрыксыз:

*Бу дөньяның кайда асыл йөзе?*
*Алдан йөри Иблис хәйләсе!*
*Шаулап торган шайтан базарында*
*Сукыр бер тиен кеше бәясе...*
(«Кеше бәясе»)

Дүртенче бүлеккә Мәскәүгә багышланган 21 шигырь кергән. Мин—алтмыш дүрт ел урыс арасында. Шуның илле өч елын Рахманинның егерме бер шигырендә сурәтләнгән калада яшим. Дөрес, сәләтең һәм теләгең бар икән, бу калада тамак туйдырырлык эш табып була. Мәскәүнең атаклы музейлары, күп санлы театрлары, китапханәләре ярдәмендә белемеңне, культураңны үстерә аласың. Шуңа карамастан, син монда чит, ят кеше:

*...Кайсы кемгә нинди яла яккан?..*
*Тагын нинди салым түләнмәгән?*
*Безнең тормыш һаман көйләнмәгән.*
*Без тынычта яшәп өйрәнмәгән...*
(«Чиркәүләр»)

Сүз дә юк, Җир шарындагы соңгы колониаль держава (махсус урысча бирәм: держава—держать, ычкындырмыйча учлап тотып тору), әшәкелек үзенчәлекләре аның пайтәхетенә тупланган. Мәскәү—матур һәм әшәке, бай һәм хәерче, культуралы һәм кыргый, аң-белем һәм мафия башбаштаклыгы оясы. Аны аңлый алмаган һәм аңларга тырышмаган кешенең югалтулары чиктән тыш зур. Чакрымның соңгы өлешенә калган рухи мохитта шоу-бизнеснең акча суырырга көйләнгән азгын бандитлыгы милли аһәннең соңгы сыныкларын талап алып тора. Җыентыкка кергән шигырьләр тоташтан диярлек шигъри газаплар кичереп уйланган фикер-тойгылардан тора. Монда чынбарлыкның җете һәм тере сурәтләре.

***

Җыентыкның соңгы бишенче бүлегенә керешер алдыннан башыма бер уй килде: җыентыкның эчтәлеген «Бөтендөнья татар конгрессы» корылтаеның көн тәртибе итеп куясы иде. Анда, минемчә, нәкъ шушы мәсьәләләр буенча фикер алышу булырга тиеш тә. Әмма бу... утопия. Конгресс—чиновниклар сәясәте карамагында. Алар мондагы проблемаларны күтәреп чыкмаячаклар. Без Рәсәй шартларында, империя золымында яшибез. Корылтайның, җыелышның, утырышның, кинәшмәнең көн тәртибенә һәр очракта колониаль сәясәт кереп оялый. Без инде аңа күнеккәнбез, шунлыктан, тоя да алмыйбыз. «Тотса мәскәүләр якан!» аяусызлыгы...

*Язмыш кук тузгыган саллар да:*
*Бурәнә артыннан бурәнә...*
*Суларда шом салып йөрәккә,*
*Богаулы аяклар тирбәлә.*
*Башлар юк... баш аста—куренми,*
*Каплаган бурәнә гәүдәне...*
*Һавадан тәпиләп дулкында*
*Агыла шәһитләр кәрваны.*
(«Көзге яңгыр» )

Татар тарихы, шул исәптән Рәсәйнен уз тарихы да «йөрәкләрдә бетмәс тирән җөй!» калдыруын азлар гына белә. Чын татар тарихы—халык җырларында. Алар әкренләп югала баралар. Аларда чагылган тетрәндергеч чынбарлык Рахманиның шигырьләрендә яңгырый.

***

Сүз Рахманиның халык җырларына тиң шигъри тел-стиле турында гына барса, китапның эчтәлеге җиңел аңлашыла дип әйтер идем. Әмма эчтәлек-фикернең төбенә төшеп житү шактый катлаулы. Өстәге беренче катламнан астарак өстәмә мәгънә—аннан да тирәндәрәк мәгънә тагын да көчәя. Ниһаять, иң тирәндә бары тик милли горурлыгын югалтмаган, иманын сатмаган шәхес кенә төшенә алырлык яна катлам. Алардан да тирәнрәктә киная—подтекст ята... Авторның күнел түренә аның озак еллык күзәтүләре, янып-көеп йөрүләре, милләт язмышына җан атып яшәве тупланган.

*Тагын күпме янасың бар:*
*Язмыштан көенәсең?*
*Корам диеп җимереләсең,*
*Җиңәм дип җиңеләсең?..*
(«Тагын күпме?!»)

Урыс философы Ильин татарны «блуждающий атом» дип атаган. Дәүләтчелеген югалтканнан соң, үз кыйбласыннан мәхрүм калып, татарның адашып йөрүе Рахманиның шигырьләрендә рефрен булып яңгырап тора.

*Яшьлек ул—чәчәге язмышның,*
*Соңыннан өлгерә җимеше...*
*Йозактай келт итеп ачыла булмышың—*
*Йә бар син, яки юк син, Кеше?!*

Мин инде күптән онтологик яшәеш терминына туган телебездә гадирәк, аңлаешлырак эквивалент эзлим. Жыентык авторы әнә шул шактый катлаулы сүзне таба алган. «Булмыш»—нинди тирән мәгънәле һәм шул ук вакытта гап-гади, көндәлектә кулланыла торган, көндәлек кулланыштан төшеп калган сүз! Жыентыкта андый сүзләр еш очрап тора. Шигырь юллары тудырган мелодия ләззәте белән генә канәгатьләнеп калмыйча, сүзләрнең күбесен күнелеңнән ирексездән кабатлап йөрисең.

Рахмани шигырьләренең кыйммәт ягы—мәгънә тирәнлегендә, аларның чынбарлыкны мул, төгәл сурәтли-яктырта алуында гына түгел, милләтнең иң кайнар, хәлиткеч проблемаларын көн тәртибенә куя алуында.

*Исән ич аларның үз халкы—*
*Ник үсә чит телдә мең ятим?..*
*Чыгарыр хөкемен чал Тарих—чын хаким:*
*Бармы ул, юкмы ул Милләтең!*

Шушындый дүртьюллыкларны дога итеп укып йөрерлек. Мин аларны сайлап тормыйча гына алып, мисалга китерәм дә, уйга калам. Шул кадәр кискен, хәтта аяусыз янгырыйлар бу сүзләр. Нилектән? Чөнки ул шигырь сүзләрендә бәгыренне көйдерерлек иҗади яну бар...

***

Прозада сюжетлары үзара тоташ әсәрләрне "метароман" дип атыйлар. «Мең чакрымга мең чакрым»ны исә "метапоэма" дип атап булыр иде. Җыентыкның финалында да шул исем белән аталган триптих бар. Ул китапның фикри үзәгенә әверелеп—шигъри ачкыч ролен үтәве белән игътибарга лаек:

*Чү, энекәш, кызулама,*
*Бу үрләрне мен акрын...*
*Кара: алда нинди киңлек—*
*Мең чакрымга мең чакрым!*

***

*Сулы халык—коелы халык,*
*Аптырамый моң юкка;*
*Моңлы халык—илле халык,*
*Юк, төшмәс ул коллыкка!*

(«Кәрвансарай»)

Китапның доминант идеясе һаман кинәя, ул яна күренешләрдә, яна фикерләрдә дәлилләнә. Үтәли яңгырашлы лирик герой кичерешләре, уй-фикерләре җыентыкның сюжет эчтәлегенә кушылып тора. Бу хәле дә—һичшиксез, Рахманиның татар шигъриятендәге зур уңышы.

Автор триптихтан соң тагын «Казан—бәхет капкасы», «Бөтендөнья сабантуйларының башкаласы—Казан», «Татар иле», «Кичке дога» кебек шигырьләрен өстәгән. Әкренләп моның да серенә төшенәбез кебек. Чит илләр Рәсәй дәүләтен «Мәскәү» дип кенә атап йөртәләр. Рәсәйнең сиксән процент финанслары башкалада әйләнә. Эшмәкәрлекне пайтәхет хәрәкәткә китерә. Сәясәт монда туа. Әмма егерме беренче гасырның иң кискен проблемасы—носарилык белән Ислам культурасының үзара каршы торуы монда түгел—Казанда сизелә. Казан—Гареб һәм Шәрык мәдәниятлары очрашкан кайнар, капма-каршылыкны иңнәрендә тотып торган четерекле бер урын. Без моны аңларга тиешбез. Заманында безнең дәүләтчелегебезне җимерсәләр дә, Казаныбыз шанлы исемебезне саклап торырга тырыша. Безнең киләчәгебез Казанга бәйле. «Кичке дога» шигырендәге изге өметләребезне Хак Тәгалә ишетер дип ышаныйк!

# БОЛГАР–ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ

*Археолог, тарихчы Альфред Халиковның (30 майда туууына 80 ел тула) ошбу китабы 1992 елда Казанда рус һәм татар телләрендә нәшер ителде («Казань» нәшрияты).*




*Кереш сүзендә автор болай ди: «Бу мәсьәлә белән байтак тикшеренүчеләр шөгыльләнгән. Шулар арасында тарихчы С. Б. Веселовский үзенең «Ономастикон. Борынгы рус исемнәре, кушаматлары һәм фамилияләре» (М. 1974), тел белгече Н. А. Баскаков күрсәтеп үтелгән «Төрки чыгышлы рус фамилияләре» (М. 1979) исемле китапларында бу мәсьәләрне җентекләп өйрәнәләр. Ләкин алар бу мәсьәләгә төрле фәннәр нигезендә якын килләр: беренчесе тарихчы буларак, икенчесе—филолог. Җитмәсә, бер-берсенең хезмәтләрен дә белмәгәннәр. Алар башка кайбер белгечләрнең хезмәтләрен дә кулланмаганнар, шулай ук XV-XVII йөзләрдәге Писцовый кенәгәләр материаллары, бигрәк тә Казан, Казан өязе буенча, файдаланылмаган. Без төрки чыгышлы рус фамилияләре тупланмасының тулырагын тәкъдим итәбез һәм Болгар, Казан, татар-мишәр фамилияләренә игътибарны мөмкин кадәр күбрәк юнәлтәбез».*

*Бу хезмәткә карата да фикерләр бертөрле генә түгел. Фамилияләрнең кайберләре тупланмага дөрес кертелмәгән диючеләр бар. Берәүләр, фамилияләрне тәшкил итүче исемнәрнең зурлыгына исе китеп, горурлык кичерсә, кемнәрдер, милләтеннән йөз чөергән шәхесләр нәфрәт хисе генә уята ала, шуңа күрә мондый китап чыгарга тиеш түгел иде, дип тә әйтәләр.*

*Ни генә булмасын, без бу фамилияләрне белергә тиешбездер. Алар рус тарихының да, татар тарихының да бер өлешен тәшкил итә. Күпмедер дәрәҗәдә алар татар кавеменең генетик егәр кимәлен дә чагылдырадыр әле.*

*Биредә исә 500 фамилияле тупламнан сайланмалар бирелә.*

**АКСАКОВЛАР**. XV йөз урталарында Аксаковларга Клязьма елгасы буендагы Аксаково авылы бирелә, XV йөз ахырында «Новгородка күчереләләр». Бу Аксаковларның нәсел башы Иван Аксак (оныклары Шадра Иван белән Обляз Иван). Иван Калитада мең башы Юрий Грункның оныгының малае була (Зимин 1980, 159-161). Бәрхет китабында (БК II, 296, № 169) язылганча, «аксак» кушаматлы Иван Федоров Урдадан чыккан Вельямин улы булган (Веселовский 1974, 11). Аксаковлар Литвада да яшәгәннәр, алар анда XIV йөз ахырларында барып чыккан булырга тиеш (B., D.[1] 1986, 22). Аксаковлар арасында язучылар, публицистлар, галимнәр бар. Алар Воронцовлар, Вельяминовлар белән туганлыкта (РБС[2] I, 96-107). *Аксак, оксак*—төрки-татар сүзе аксак.

[1] B. D. – Borawski P.,Dubiski A. Tatarzy Polscy. Dzieje,obrzedy,Tegenbey, trabycje. Warszawa, 1986.

[2] РБС – Русский биографический словарь.

**АЛЯБЬЕВЛАР.** XVI йөздә рус хезмәтенә кергән Александр Алябьевтан (РБС II, 80);1500 елда рус хезмәтенә кергән Михаил Олебейдан башлана (Веселовский 1974, 231). Али бей—«олы бай» (Баскаков 1979, 182). Нәселләрендә хәрбиләр, чиновниклар, шул исәптән танылган композитор һәм А. С. Пушкинның замандашы А. А. Алябьев.

**АНИЧКОВЛАР.** XIV йөздә Урда дәүләтеннән чыккан кешеләр дип уйланыла (БК II, 282, № 100; Загоскин[3] 1875, №2). Блоха белән Глеб Аничковлар беренче тапкыр 1495 елда Новгородта искә алыналар (Веселовский 1974, 14). *Энис/энич*—«дус» дигән мәгънәне аңлаткан гарәп-төрки сүзләре (Гафуров[4] 1987, 125). Соңрак алар арасыннан галимнәр, публицистлар, врачлар, хәрбиләр чыга (РБС II, 148-150).

**АПРАКСИННАР.** Чыгышлары 1371 елда Алтын Урдадан Ольг Рязанскийга күчкән Солохмир (Солых Әмир) оныгы Андрей Иванович Апракстан (ОГДР[5]11,45; 111,3). XV—XVI йөзләрдә Апраксиннарга Рязань тирәсендә биләмәләр бирелгән. Федор Апраксин 1610—1637 елларда Казан Сарае Приказында дьяк хезмәтен башкарган. Хитров, Ханыков, Крюков, Вердерников (к.) кебек боярлар белән тугандаш. Н. А. Баскаков (1979, 95) «Апракс» кушаматының төрки сүз икәнлегенә өч төрле аңлатма китерә: 1. «әкрен, тыныч»; 2. «тузгыган чәчле», «тешсез»; 3. «мактанчык». Россия тарихында алар Петр I тарафдарлары, генераллар һәм губернаторлар буларак билгеле.

**АРАКЧЕЕВЛАР.** XV йөз уртасында хезмәткә русларга күчеп, Василий II нең дьягы булып киткән чукындырылган татар кешесе Аракчей Евстафьевтан (Веселовский 1974, 14). Казан татарларында «аракы әзерләүче, көмешкәче, эчкече» мәгънәләрендә кулланылган «аракычы» кушаматыннан ясалган (Баскаков 1979, 115). XVIII-XIX йөзләрдә Александр I нең вакытлы хакиме, граф, биләмәләре Тверь тирәсендә булган (РБС II. 261-270).

**АРДАШЕВЛАР.** XVII йөздән дворяннар. Нәсел башлары Казаннан чыккан Ардаш исемле кеше. Нижний Новгород губернасында җирләре булган (Веселовский 1974, 15). Бу нәсел кешеләре арасында Ульяновларның туганнары, галимнәр бар (ИЭ 1,715).

**АРСЕНЬЕВЛАР.** XVI йөздән дворяннар. Нәселләре Дмитрий Донскойга хезмәткә күчкән Ослан (Арслан) морза малае Арсенийдан башлана (к. Ждановлар, Сомовлар, Ртищевлар, Павловлар). Чукынганнан соң Арсений Лев Прокопий исеме кушыла (ОГДР V, 28-29; БК II[6], 282). Кострома төбәгендә утарлары булган. Нәселләрендә А. С. Пушкин дуслары (к. Арсеньев К. И.) хәрбиләр бар (РБС II, 315-324).

**АРТЮХОВЛАР.** 1687 елдан дворяннар. Фамилияләре төрки артык/артук/артюх сүзләреннән (Баскаков 1979, 169).

**АХМАТОВЛАР.** 1582 елдан дворяннар (ОГДР V, 52). Казаннан чыккан кешеләр дип уйланыла, чөнки 1554 елда Кашира тирәсендә Федор Никулич Ахматов теркәлгән (Веселовский 1974, 17). Ахмат-Әхмәт—типик төрки-татарлар исеме (Баскаков 1979, 176). 1283 елда ук Курск җирендә бесермән (ихтимал, болгар-мөселмандыр) Әхмәт исеме телгә алына (ПСРЛ[7] 25, 154). Ахматовлар—XVIII-XIX йөзләрдә хәрбиләр, дингезчеләр, Синод прокуроры (РБС II, 362).

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

[3] Загоскин Н. А. Очерки организации и происхождения служилого сословия в допетровской Руси. Казань, 1883.
[4] Гафуров А. Имя и история. М.,Наука, 1987.
[5] ОГДР – Общий гербовник дворянских родов Российской Империи. (I–XX). СПБ, 1797– 1842.
[6] БК,II – «Бархатная книга». Родословная книга князей и дворян Российских и выезжих. Часть II,М., 1787.
[7] ПСРЛ – Полное собрание русских летописей. Том 9.,СПб. 1856; Том 25., М. –Л.,1949; Том 29., М.,1965; Том 34., М., 1978.

## Шәрыктән кайткан кушамат

XIX гасырда безнең авылда Бикмәмәт исемле кеше яшәгән. Ул озак еллар буе Ташкент, Бохара якларында сәяхәт итеп йөргән. Хәтта Иран белән Әфганстанга да барып чыккан. Мәдрәсәләрдә укыган, белем эстәгән, озак еллардан соң авылга ачлангач килеш әйләнеп кайткан ул. Шулай да бөтенләй буш кул белән үк кайтмаган, кушамат ияртеп кайткан. Аңа исеме белән түгел, «Кури» дип кенә дәшкәннәр. Безнең әти бу кешене еш искә алып сөйли иде. Ул аңа әнисе ягыннан туган тигән.

«Кури» абруйлы кушамат (исем?) булган күрәсең. Бервакыт мин Татарстан радиосыннан Әфганстанда Әхмәт Кури исемле министр барлыгын ишеттем.

## Дәрестәге концерт

Мин 45 ел буена укытучы булып эшләдем. Шул еллар эчендә йөзләрчә дәрес бирдем. Бу дәресләр арасында гадәти булмаганнары да бар иде. Шуларның берсе бүген дә исемдә саклана.

Әллә темасы бик авыр булды, әллә ял итмәгәнгә инде, бу дәресне үткәргәндә бик нык арыдым. Күреп, сизеп торам, укучылар да арыганнар. Класста бик матур җырлый торган бер кыз бар иде. Шуна әйтә куйдым:

—Йә, наным, җырла әле!

Укучы торып басты да, сыздырып җибәрде. Миңа да рәхәт булып китте, укучылар да иркен сулыш алдылар.

Шул чагында класс ишеге ачылып китте. Аннан коридорны тутырып басып торучы башка класс укучылары күренде. Алар безнең дәрестәге «концертны» тынлыйлар иде. Менә шулай итеп укучылар берничә генә минут булса да ләззәтле ял кичереп алдылар.

Бу көннән соң күп еллар үтте инде. Ә бу кыз сәхнәне үз итте. Җырчы-артисткага әйләнде.

## Кем келәме?

Мин үзем генә яшим. Йортымның тыкрык ягына кибет салдылар. Ул минем йортка терәлеп үк тора. Ике араны минем урам ягындагы бакчамның тимер рәшәткәләре генә аерып тора. Менә шул рәшәткәгә бер көнне зур келәм чыгарып элделәр. Ул анда бер җәй буе, бер кыш буе торды.

Һәм... Ул күп сүзләр китереп чыгарды. Кибеткә килгән әбиләрнең кайберләре «Ник тота икән ул аны монда? Ник алып керми икән?»—дигән. Икенчеләре исә, «Бер малае кайтарып куйгандыр да, үзенең генә алып керергә көче житмидер»,- дип «аныклык» керткән. Күрше урамда яшәүче бабайлар да битараф калмый. «Келәмне генә алып кермәс инде. Ул бакчасындагы чүп үләнен дә утамый бит»,- дигәннәр алар. Бервакыт сбербанкка пенсия алырга кергәч, бер яшь кенә ханым:

—Абый, ул келәм синекеме соң? Урлап та китмиләр үзен,—диде.

Шушы бер келәм никадәрле сүз китереп чыгарды! Һәм барысы да минем хакта. Берсенең дә башына кибеттә эшләүчеләр чистарту өчен чыгарып элгәннәрдер дигән уй килмәде.

Көннәрдән бер көнне келәмне рәшәткәдән алып, кибет идәненә кертеп җәйделәр.

**Мөнәвәр ЮНЫСОВ,**
*укытучы-пенсионер.*
*Апас районы, Апас авылы.*

# ИКЕ КИТАП ҺӘМ БЕР ХИКМӘТ

Татар теле буенча остазым, мәрхүм Аяз Гыйләжев белән яна танышкан чак... Чәй эчеп, гәп корып утырабыз. Мин әле ул вакытта нибары 25 яшемдә. Әдәби әсәр тәрҗемә итү уема да килеп карамаган. Сүзне сүзгә ялгар өчен генә, остазыма: «Кайсы әсәрегезнең төрек теленә тәрҗемә ителүен теләр идегез?»—дигән сорау бирдем. Ул, җавабын алдан ук әзерләп куйган төсле:«Өч аршын җир повестен» диде һәм берничә елдан мәңгелек йортка күчеп тә китте. Мәрхүмнең вафатыннан соң мин әлеге сүзләрне үземә әйтелгән васыять дип кабул иттем һәм үз-үземә бу әсәрне тәрҗемә итәргә сүз бирдем. 2005 елда тотынган эшне Ходайның рәхмәте белән 2007 елда төгәлләдем. Аннары Төркиядәге «Сөтүн» нәшриятына җибәрдем, бик яратып кабул иттеләр һәм 2008 елда бастырып та чыгардылар.




Ул көннәрдә күнелемә кинәт кенә шундый уй килде һәм мине таң калдырды. «Өч аршын җир» 1962 елда иҗат ителгән, 2008 елда төрек телендә төрекчә нәшер ителәчәк. Ягъни 46 елдан соң. Ә минем туган шәһәрем Каһраманмараш Төркиянең 46нчы регионы... Әсәр басылып чыкты. Мин титул битен укып барам: әлеге китап та нәшриятның 46нчы китабы булып чыккан икән...

Хәзер төрек теленнән татар теленә тәрҗемә ителеп, күптән түгел генә басылып чыккан атаклы төрек шагыйре һәм язучысы остаз Нәҗип Фазыл Кысакүрәкнең «Мәрхәмәт» («Рәис Бәй») әсәренә күчик.... Әсәрнең тәрҗемә ителүе 2005 елда ук туган хыял иде. Ходайның рәхмәте, әлеге хыялны Казан университетының Көнчыгыш институты тюркология кафедрасы мөдире, оста тәрҗемәче доцент Асия Рәхимова ханым чынга ашырды һәм әсәр Төркия Мәдәният министрлыгы иганәчелегендә «Тамга» нәшрияты тарафыннан бастырып чыгарылды.

«Мәрхәмәт» («Рәис Бәй») әсәре 1963 елда язылган һәм ул 2009 елда татар телендә Татарстанда дөнья күрде. Шул ук 46 елдан соң... Остаз Нәҗип Фазыл Кысакүрәк тумышы белән Истанбулдан булса да, төп чыгышы белән Каһраманмараштан. Һәм ул шуның белән гомер буе горурланып, «Мин Каһраманмарашлымын» дип яшәде...

Миңа болар ап-ачык Аллаһның хикмәтедер... Татарлар әйтмешли, «Өстән кушылган нәрсәләр...» Галәмдә бер нәрсә дә очраклы түгел...

Соңгы сүз буларак бер нәрсә өстисем килә. Үктәбер инкыйлабыннан соң төрек теленнән татар теленә тәрҗемә ителеп, Татарстанда басылып чыккан драма әсәрләрен без очратмадык. Димәк, әлеге хезмәт төрек милләтеннән татар милләтенә 80 елдан соң ирешкән тәүге бүләк...

**Фатих КУТЛУ**

## Дамир Гарифуллинга 70 яшь



Берәүләр аны шәҗәрәләр төзүче Дамир Гарифуллин буларак белсә, кемнәрдер исә робагыйлар иҗат итүче, танылган җырлар авторы—шагыйрь итеп кузаллый. Кечкенәдән китапка, китапларның да әле ниндиенә—ерак чорларга барып тоташканнарына мөкиббән егетнең тарихчы-фольклорчы, әдәбиятчы, хәтта дин белгече («Ислам» белешмәләр сүзлеге,—1993, авторларының берсе) булып китүе гаҗәпмени. Бай тормыш тәҗрибәсе туплаган гаять кызыклы шәхес ул Дамир Гарифуллин. Тормышның, яшәешнең иң тирән, мәгънәле катламнарына «төшеп» иҗат итүе дә аны Мөхәммәд пәйгамбәрдән (с.г.в.) башлап бүгенге көннең күренекле кешеләре, әдәбият-сәнгать әһелләренең шәҗәрәләрен тупларга этәргеч биргәндер. Төбәк-район тарихлары да аның игътибарыннан читтә калмый. Мөселман дөньясында җиде буын ата-бабаңны белү, киләчәк буыннарга белдереп калдыру, шәҗәрә агачын төзү—борынгыдан килә торган күркәм гадәт, милли үзаңны уяту да изге гамәл санала. Дамир Гарифуллинның «Шәҗәрәләр». 1 китап (2002) әнә шундыйлардан: Республикабызның беренче президенты М. Шәймиев, Тукай, Рәмиевлар, И. Шакиров һ.б.—җәмгысе 31 шәхеснең нәсел-нәсәбе яктыртыла әлеге китапта.

Д. Гарифуллин иҗатының икенче төп тармагы—робагыйлар. Ул аларны яратып «Уйлануларымның каймагы» дип атый. Ерак гасырларда яшәп иҗат иткән Гомәр Хәйям, Әбугалисина, Сәйф Сараи, Галишер Нәваи традицияләрен дәвам итеп робагыйлар язу хәзерге татар шагыйрьләре иҗатында да күркәм күренеш. Шигъриятнең тирән фәлсәфә, фикер-уйлануларга нигезләнгән бу төренә элгәррәкләрдән Акмулла, Тукай, Туфаннар, бүгенгеләрдән Т. Миңнуллин, Г. Мөхәммәтшин, Р. Гаташ, М. Мирза һ.б. бик яратып мөрәҗәгать иткәннәр һәм итәләр.

«Тормыш тәҗрибәсе тудырган фикерләрнең робагыйларда йөрәккә ятышлы сүзләр аша бирелүе таң калдыра»,—дип яза Д. Гарифуллин «Мең дә бер робагый» дип исемләнгән китабының (2001) кереш сүзендә.

Билгеле хакыйкать, шагыйрьләрнең күпчелеге авылда туа. Тукай Кырлаен зурлаган кебек, Дамир Гарифуллин да үзенең Сарманына иҗатында зур урын бирә. Бу очракта аның «Сарман энциклопедиясе» үзе генә дә ни тора. Ә инде «Күкрәп яшә, Сарманым», «Чыгарсынмы каршы алырга?» җырлары әле бүген дә җырчыларыбыз игътибарында.

Дистәләгән китап авторы Дамир Гарифуллин бәлки әле нәкъ менә Сарман ягында туып-үсүе белән дә бәхетледер. Аның автобиографиясенә күз салсаң, 1939 елның 5 маенда туган егет бәхет эзләп еракларга китми. Хәрби хезмәттәге вакытын санамаганда, тормыш тәҗрибәсен туган төбәгендә ала, туган ягына хезмәт итә, төпләнеп яши, шунда иҗат белән шөгыльләнә. Авыл хуҗалыгы инспекциясендә җир төзүче инженер ул, партиянең Сарман район комитетында пропагандист-инструктор да, район һәм өлкә газеталарынын махсус хәбәрчесе дә, «Сарман» газетасы редакторы да булып эшли. Матбугат өлкәсендәге тырыш хезмәте өчен 1988 елда «Атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек була.

1992 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Д. Гарифуллин балалар өчен дә иҗат итә, ул нәниләргә багышланган берничә китап авторы да. Соңгы елларда «Норильлаг токтыны», «Ике су үзәнендә», «Робагыйят» исемле китаплары дөнья күрде.

## Мансур Сафинга 60 яшь



Шагыйрь, прозаик һәм тәржемәче Мансур Габдулла улы Сафин 1949 елның 11 маенда Кемерово өлкәсенең Анжеро-Судженск шәһәрендә шахтер гаиләсендә туа. Балачак һәм мәктәп еллары Татарстанның Мамадыш шәһәрендә уза. Урта мәктәпне тәмамлагач, Оренбург зенит-артиллерия училищесында хәрби белем алып, Совет Армиясе сафында хезмәт итә. Әмма әнисе Әминә апа фабрикада эшләгәндә инвалидлыкка дучар булу сәбәпле, армиядан китәргә мәҗбүр була. 1970 елны Мамадышта педагогик курслар тәмамлап, берникадәр вакыт укытучы булып эшләгәннән соң, Казан дәүләт университетының физика факультетына (радиофизика һәм электроника бүлеге) укырга керә. Университетны тәмамлагач, Казанда радиоинженер, Мамадышта райком инструкторы, Сергеев Посадта хәрби офицер, КамАЗда автомеханика заводы директоры урынбасары булып эшли. 1995—2000 елларда Чаллыда чыгып килгән «Аргамак» әдәби-нәфис журналының баш мөхәррир урынбасары, 2000- 2002 елларда Чаллы дәүләт педагогия институтында укытучы, 2003—2004 елларда «Казан» әдәби-нәфис журналының бүлек мөдире була.

М. Сафинның беренче шигырьләре һәм мәкаләләре 1966 елда Мамадышта «Коммунистик хезмәт өчен» һәм Куйбышевта «За Родину» газеталарында дөнья күрә. 1970—80 елларда аның әсәрләре, тәржемә һәм тәнкыйть мәкаләләре дистәләрчә күмәк җыентыкларда, Мәскәүдә чыгучы газета-журналларда («Новый мир», «Литературная Россия», «Культура», «Детская литература» һ. б.) басылып чыга.

1994 елны аның бер-бер артлы «Хәерле иртә» (шигырьләр), «Надежда, Вера и Любовь» (шигырьләр), «Край былинный, Мамадышский» (тарихи очерклар), «Эдуард Касимов. Живой памятник» (тәржемәләр) исемле китаплары нәшер ителә.

Мансур Сафин 1997 елда Язучылар берлегенә кабул ителә. 1999 елда Казан дәүләт университетының филология факультеты аспирантурасында укып, «Татар поэзиясендә пейзаж образлары системасы» дигән темага кандидатлык дессертациясе яклый.

Бүгенге көндә ул ике дистәдән артык китап авторы. М. Сафин рус һәм татар телендә яза, шуна күрә тәржемә өлкәсендә дә актив эшли. Аның тәржемәсендә русча матбугат битләрендә Утыз Имәни, Гали Чокрый, Бакый Урманче, Г. Афзал, И. Салахов, Р. Вәлиев, А. Хәлим, Ф. Бәйрәмова һ. б. әсәрләре, ә татар телендә М. Цветаева («Канатлы күнел», 2008), Н. Рубцов («Монлы йолдыз», 1999), В. Высоцкий («Ярсу йөрәк», 2008); И. Бунин, С. Есенин, В. Хлебников, Б. Пастернак һ. б. әсәрләре дөнья күрә.

Мансур Сафин туган як тарихын өйрәнә, археолог буларак борынгы Болгар, Биләр, Алабуга, Кирмәнчек, Чаллы шәһәрләрен казуда катнаша, алар турында фәнни-тарихи очерклар яза.

Балалар язучысы буларак, М. Сафин унлап китап нәшер итәргә өлгерде. 2000 елда ул балалар әдәбияты өлкәсендәге уңышлары өчен Татарстан Язучылар берлегенең Шәйхи Маннур исемендәге премиясенә лаек булды. Шулай ук аның иҗаты Э. Касыймов һәм Е. Уткин премияләре белән дә билгеләнде.

2007 елның 26 апрелендә аның тырышлыгы белән Чаллы әдәбият тарихы музее оештырылды һәм уңышлы эшләп килә.

Соңгы елларда язучының «Мамадышка мәдхия. Ода Мамадышу», «Казанские стансы», «Челны мои былинные» исемле шигырь китаплары дөнья күрде.

***Редакция коллективы юбилярларны ихлас котлый, аларга исәнлек-саулык, яңа иҗат уңышлары тели!***

# И

**ИБРАҺИМОВ** Илфак Мирза улы (псевд. Мөхәммәт Мирза) (1.3.1953, Актаныш р-ны Чалманарат ав. туа), шагыйрь. Казан мәдәният ин-тын тәмамлагач (1975) Актаныш районында эшли: җирле радиотапшырулар редакторы (1975-79), ВЛКСМ райкомының 1 нче секретаре (1979-84), район эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары (1984-96), район администрациясе мәдәният бүлеге мөдире (1996-2001). 2001-2005 елларда ТР мәдәният министры урынбасары. 2005 тән ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. «Кәккүк тавышын санадым» (1994), «Турайгыр» (1998), «Киек каз юлында» (2003), рус теленә тәрҗемәдә «Дорога к тебе» ( «Сиңа кайтыр юлым», 2006), «Тере су» (2007) исемле шигырь җыентыклары авторы.

Әд.: Шагыйрьҗан Л. Шагыйрь буласың килсә—бул! // Казан утлары. 1998. №11; Акмал Н. Шигырьне сагыну // Казан утлары. 2003. №11.

**ИБРАҺИМОВ** Лев Николаевич (22.2.1816, башка мәгълүматлар буенча 1818—1867дән соң), шагыйрь, педагог. Н.М.Ибраһимовның улы. 1837 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң 1 нче ирләр гимназиясендә укыта. 1832—34 тә «Заволжский муравей» ж—лында языша, соныннан башкала матбугат чараларында «Санкт—Петербургские ведомости» (1837), «Библиотека для чтения» (1839) һ.б. 1841 дә Казанда аның беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә. Рус фольклор поэтикасына мөрәҗәгате И.ка зур уңыш китерә. «Җаныкаем, чибәр кыз...» («Ты душа ль моя, красна девица...») исемле танылган шигырьләренең берсенә комп. Н.И.Бахметьев музыка яза, соңыннан А.Ф.Львов та музыка яза һәм ул популярлашып китә. Җыр, романс стилендә язылган «Кара урман шаулый...» («Шумят, шумят во сыром бору...»), «Кыңгырау» («Колокольчик»), «Романс», «Күзләр» («Очи») (соңгысына 1856 елда комп. Н.Кравцов музыка яза) шигырьләренә эчкерсезлек, гадилек һәм аһәңлелек хас. Казанда югары даирәләр вәкилләренә эпиграммалар язып таныла. 1844 тә Казаннан китә. Пермь губернасында тау эшләре чиновнигы булып хезмәт итә. 1866 да Түбән Тагилга күчә, бөлгенлеккә төшә. 1867 дә Кынов приход уч—щесендә укыту өчен рөхсәт алырга тырышып карый. Алдагы язмышы билгесез.

Әсәр.: Стихотворения Льва Ибрагимова. К., 1841.

Әд.: Аристов В.В. Два забытых поэтических имени // Казанские находки. К., 1985; Русские писатели: Библиогр. словарь. М., 1992. Т.2.

*Автор: М.М.Сидорова.*

**ИБРАҺИМОВ** Рәшит Габдрахман улы (28.7.1927, Ульяновск өлкәсе хәзерге Чынлы р-ны Кәшә ав. туа), язучы, пилот, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Богырыслан гражданнар авиациясе уч-щесын тәмамлый (1953). 1953-86 елларда Казан аэропортында эшли: По-2, Ан-2, Ли-2 самолётлары пилоты, Ил-14, Ту-124 корабльләре командиры. Авиация тарихына караган, очучы профессиясенең романтикасын чагылдырган «Көмеш канатлар» (1971), «Алтын йолдызлы лачын» (1987), «Ерак илләргә сәяхәт» (1990), «Канатлыга—зәңгәр биеклек» (1995), рус телендә «Эпопея маленьких «ТУ»шек» (ж. «Казан», 1999, №3-4) исемле балалар өчен хикәяләр җыентыклары авторы. И.нең күп әсәрләре автобиографик характерда. ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

Әд.: Хәмитов М. Көмеш канатлар // Казан утлары. 1972. №1; Әхмәтсафа Ш. Рәшит Ибраһимовка—70 яшь // Казан утлары. 1997. №7.

**ИБРАҺИМОВ** Фәрит Таҗетдин улы (13.2.1893, Лаеш өязе Шетнев Чирмешәне а.—1943, хәзерге Үзбәкстан Респ., Сәмәрканд өлкәсе Хәтерче а.), шагыйрь. 1 нче бөтендөнья сугышында катнаша. 1916 елдан Пермь, Ташкент, Пишпек мәктәпләрендә мөгаллимлек итә. Ташкентта Коммунистик ун-т тәмамлаганнан соң шунда һәм Сәмәрканд Коммунистик ун-тында укыта. 1924 тә Казанда рабфак тәмамлый һәм янә Үзбәкстанга китә. Шигырьләрен «Аң», «Сөембикә», «Ак юл», «Балалар дөньясы» ж-лларында, «Кояш», «Сибирия» г-таларында бастыра. 1912 дә беренче «Уйларым», «Өмидемнең нурлары» исемле шигъри җыентыклары дөнья күрә. И.—татар фольклор әсәрләре нигезендә язылган «Авылым» (1916), «Халык арасында» (1918), «Өрәк» (1918), «Төшләр» (1918) исемле поэмалар авторы. Аерым шигырьләре «Милли моңнар» (1919), «Табигать моңнары»

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

(1919), «Көрәш җырлары» (1923) исемле күмәк җыентыкларда урын алган. Алар ш.у. «Татар поэзиясе антологиясе»нә (1956, рус. телендә 1957) дә кергән.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Г. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

*Автор: Ф.И.Ибраһимова.*

**ИБРАҺИМОВ** Хәбир Кәбир улы (19.11.1958, Апас р-ны Борнаш ав. туа), язучы, драматург. Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1980). 1985-88 елларда Казан үзешчән сәнгать йортында эшли. 1990-94 тә «Татарстан» ДТРКсында телевизион тапшырулар мөхәррире. 1994-99 да «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» газеталары, «Татарстан» ж-лы редакцияләрендә хәбәрче, әдәби мөхәррир булып эшли. 1999-2001 дә Татарстан китап нәшриятында, 2001 дән «Идел» ж-лы редакциясендә бүлек мөхәррире, бер үк вакытта 2006 дан ТР Язучылар берлеге идарәсендә әдәби консультант. «Аһән» (2001) исемле шигырьләр, «Йокыга талган гүзәл» (2002) повесть һәм хикәяләр, «Газиз ярым» (2007) пьесалар җыентыклары дөнья күрде. Анын пьесалары буенча куелган «Артык гомер» (1993), «Төнге шаяру» (1994), «Кызыма килер йөз кеше» (1995), «Газиз ярым» (1997), «Бәхетле килен» (1997), «Җиденче кияү» (2005), «Ялгыз каен күзе» (2007) спектакльләр Татар драма һәм комедия т-рында, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Минзәлә, Оренбург театрларында, Уфа «Нур» т-рында куелды. И. сценариесында ТРТ каналында «Ялгыз тәкрарлек» (2002) телефильмы төшерелде.

Әд.: Зәйдулла Р. Лирика—шигъри сурәт, мон // Идел. 1990. №2.

**ИБРАҺИМОВА** Саимә Ибраһим кызы (1.3.1928, Сарман р-ны Зур Нөркәй а.), тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1974). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1950). 1954 елга кадәр мәктәптә укыта, шуннан сон Татарстан китап нәшриятында (1954-57), «Азат хатын» ж-лында (1957-60), «Яшь ленинчы» (1960-83), «Дөнья» (1992-95), «Мәдәни җомга» (1995-97) г-таларында, «Сөембикә» (1998-2006) ж-лында мөхәррир булып эшли. Рус теленнән татар теленә Р.Л.Стивенсонның «Хәзинәләр атавы» романын («Остров сокровищ», 1971), Я.Козакның «Марьяна Радвакова» (1965), С.Григорьевның «Александр Суворов» (1975) повестьләрен, А.П.Чехов, А.Зегерс, А.Гайдар хикәя һәм повестьләрен; татар теленнән рус теленә Д.Аппакова хикәяләрен (1957) тәрҗемә итә. Казан ханбикәсе Сөембикә турында «Сөембикә ханбикә» (2001) исемле китап төзүче.

Әд.: Ахунжанов Г. Җыйнак, табигый тел белән // Казан утлары. 1976. №4; Туфитуллова Р. Саимә Ибраһимовага—70 яшь // Сөембикә. 1998. № 3.

**ИБРАҺИМОВА** Фатыйма Исхак кызы (15.3.1928, Бөгелмә кантоны Кирлегәч а.), әдәбият галиме, текстолог, филол. фән. канд. (1969), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998). Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1952). 1962 елга кадәр урта мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укыта. 1965-2000 дә ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. М.Җәлил (т. 1-4, 1975-76), Г.Камал (т.1-3, 1978-81) әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә катнаша; М.Гафури (т.1, 1980; т.4, 1988), Ф.Әмирхан (т.1, 1984), Г.Ибраһимов (т.9, 2000), Г.Исхакый (т.8, 2001) әсәрләренең аерым томнарын басмага әзерли. «Балалар әдәбияты» (2004) хрестоматиясен төзүче. Хезмәтләре татар балалар әдәбияты тарихына, татар язучыларының 20 йөз башы әдәби мирасына карый.

Хезм.: Заман белән бергә. К., 1971; Сабыйларны үз итеп. К., 1998; Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. К., 2003 (автордаш).

**ИВАНОВ** Сергей Николаевич (11.4.1922, Петроград—5.4.1999, С.-Петербург), әдәбият галиме, тәрҗемәче, филол. фән. д-ры (1969), проф. (1970), Үзбәкстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Ленинград ун-тын тәмамлаганнан сон (1951) 1953 елга кадәр Бохара пед. ин-тында, 1953-96 елларда Ленинград ун-тында эшли (1972-88 дә төрки филологиясе кафедрасы мөдире). Хезмәтләре төрки тел белеменә, тюркология тарихына, төрки классик әдәбият поэтикасына, шигъри тәрҗемә теориясенә карый. Әбелгазый Баһадур ханның «Төркиләр шәҗәрәсе» («Родословное древо тюрков»), Й.Баласагунинның «Котадгу белег» («Игелекле белем»), А.Нәвоиның «Лисан ут-тайр» («Кошлар теле»), үзбәк шагыйрьләре шигырьләрен, Кол Галинең «Кыйсса–и Йосыф» («Сказание о Йусуфе») әсәрен, Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасын («Шурале») һ.б. әдәби ядкарьләрне өйрәнә һәм рус теленә тәрҗемә итә. Н.Ф.Катановның тормышы һәм иҗаты турындагы китап авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Әд.: Советские тюркологи. М., 1989. Т.1.

*Автор: В.Х.Ганиев.*

**ИДЕЛБИКӘ** (псевд., чын исем-фамилиясе Лена Биньямин кызы Садыйкова–Сабитова) (19.8.1930, Башк. АССР, Мәчетле р-ны Яна Мөслим а.), шагыйрә. 1973 тә Ульяновск пед. ин-тын

тәмамлый. 1946-85 елларда Ташкент, Новокузнецк, Ульяновск шәһәрләрендә техник–картограф, техник–чертежник булып эшли. Матбугатта 1990 елларда басыла башлый. Беренче шигырьләре «Сембер язлары» (1995) исемле күмәк җыентыкка керә. «Мәхәббәтнең мең фасылы» (Ульяновск, 1997), «Бәхеткә үс, кеше» (Ульяновск, 2000), «Дөнья авазлары» (2003), «Дороги и думы» (Горно–Алтайск, 2005, рус теленда), «Күнел күккә омтыла» (2007) шигъри җыентыклар авторы. И.нең лирик героинясына камиллеккә омтылу, хатын–кыз зирәклеге хас. Вакытлы матбугат битләрендә әдәби-публицистик мәкаләләр б-н чыгышлар ясый.

Әдәб.: Мулланурова Р. Мәхәббәтнең мең фасылы // Сөембикә. 1998.№ 11.

*Автор: Р.Р.Мусабәкова.*

**ИДЕЛЛЕ** (псевд., чын фамилиясе Усманов) Газиз (Габделгазиз) Сәлах улы (26.12.1905, Әстерхан—27.7.1985, Казан), язучы. 1923 елда Свердловск индустриаль техникумына укырга керә. Аны тәмамламыйча «Сабан һәм чүкеч» газетасы редакциясендә эшли башлый: мәкаләләр, очерклар, фельетоннар яза. «Шәпи агай» исемле сатирик ж-лда да әсәрләрен бастыра. 1926 елдан Казанда яши. Татарстан ҮБК ы аппаратында эшли, 1929 дан республика вакытлы матбугатында: «Безнең юл», «Атака» ж-лларында, «Кызыл Татарстан» газетасында җаваплы сәркатип, «Совет әдәбияты» ж-лында редактор, Татарстан радиокомитетында баш мөхәррир. 1930-40 елларда Совет Армиясендә хезмәттә. Бөек ватан сугышы елларында фронт газеталарында эшли, туган илне дошманнардан саклаучылар турында хикәя һәм очерклар цикллары бастыра. 1949-57 дә ТАССР Язучылар берлегендә әдәби консультант. «Пумала башлар» (1930), «Икмәк һәм хатын» (М., 1931), «Тормышка мәхәббәт» (1959), «Ул көннәр» (1967), «Күргәннәрем, белгәннәрем» (1975) хикәя җыентыклары, «Дәүләт Бәдриев» (1936; Татар академ. т-рында 1937 куела) драмасы, «Язучы һәм аның китабы» (1964) исемле әдәби-тәнкыйть мәкаләләр җыентыгы авторы. А.Фадеевның «Разгром» («Тар-мар», 1933), П.Павленконың «Счастье» («Бәхет», 1950) әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1937 дә нахакка гаепләнә, 1939 да аклана.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1955; Беренче зур сәяхәт: Истәлекләр, очрашулар, уйланулар. К., 1980.

Әд.: Әпсәләмов Г. Газиз Иделле // Совет әдәбияты. 1956.№3; Ишморат Р. Каләмдәш дустыбыз // Социалистик Татарстан. 1975. 31 дек.

**ИЗМАЙЛОВА** (Мирзаянова) Нурия Халит кызы (1.1.1950, БАССРның Шаран р-ны Базги ав. туа), шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1972-78 елларда Башкортстан китап нәшриятында җаваплы мөхәррир. 1981-82 дә Мәскәүдә «Наука» нәшриятында эшли. 1996 дан АКШта яши. «Яратам» (1981), рус теленә тәрҗемәдә «Ива на ветру» (М., 1986), «Минем җәй» (1987), «Җирдә» (1993) җыентыкларына кергән шигырьләрендә кешеләргә, мәхәббәткә ышаныч, өмет хисләре чагыла. Эмиграциядә язылган әсәрләрендә («Язылмаган хатлар», 2003; «Адашкан», 2004 җыентыклары) туган җирне юксыну, читтә яшәгән кеше хисләре калкурак гәүдәләнеш тапкан, әчке бер драматизм белән сугарылган.

Әд.: Вәли М. Америкада татар әдибәсе //Казан утлары. 2001.№9.

**ИКСАНОВА** (Гарипова) Илсөяр Вазыйх кызы (7.2.1966, Лаеш р-ны Татар Сараланы ав. туа), шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлый (1988). «Яшь ленинчы» (1989-91), «Шәһри Казан» (1991-97) газеталары, «Ялкын» ж-лы редакцияләрендә эшли. 1999-2003 тә «Салават күпере», 2003тән «Сөембикә» ж-лларында бүлек мөхәррире. «Ышанасы килә» (1990), «Кышкы канәферләр» (2000), «Син язган язмышым» (2003) , «Кырык кыл» (2008) исемле шигъри җыентыклар авторы. И.ның шигырьләрендә лиризм, хатын-кызның бай күңел дөньясын нечкә тоемлау өстенлек итә.

**ИЛЬЯС** (Ильясов) Габдулла (1905-1938), язучы. 1927-32 елларда кызылармиячеләр тормышы турында «Штык» повестен(1931), «Фонтан» (1927), «Промыселлар чатында» (1928), «Получка» (1929), «Тимер адымнар» (1929), «Көләч иртә» (1931), «Хикәяләр җыентыгы» (1932) повесть һәм хикәяләр җыентыкларын бастыра. Мәскәүдә яшәп, андагы пролетар язучылар ассоциациясенең (МАПП) татар секциясе әгъзасы булып тора.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## Кремльгә жыенам...

Үткенлек бар иде анысы. Бер җәйне «Таткниготорг» хезмәткәрләрен, Казан кибетләрендә китап сатучы кызларны житәкләп, Октябрь районына уракта булышырга алып киттем. Чирмешен һәм Сөлчә елгалары арасындагы сазлыкка урнашкан Сахаровка авылында яшәдек.

Көннәрдән бер көнне ындыр табагына бер кеше килеп керде. Өсте-башы пычранып беткән. Таныдым тегене—Татарстан Югары Советы Президиумы Рәисе Гали абзый Динмөхәммәтов иде ул.

—Егетләр, машина батты, чыгарырга булышсагыз икән,—ди бу гозерләнеп. Бер көтү чуаш малайларын ияртеп, киттем артыннан. Норлатка (Октябрь районы) кайтышлары икән. «Победа» машинасы—ишегенә тиклем сазга чумган. Кая ул чакта житәкчеләрнең тән сакчылары, озата йөрүчеләре?!

—Тяж ташыгыз, малайлар, тяж кирәк, тяж,—дип өйрәтеп торды дәүләт житәкчесе.

Кечкенә генә буйлы, ак чәчле, көмеш тешле бу агай сөйләшергә бик тә каты мишәр иде. Ә үзенең гадилеге әллә кайдан сизелеп тора. Чыгардык «Победа»сын. Киемнәребезнең карарлыгы калмады.

—Шәп егет икәнсең! Пиджаксыз калдың менә. Кремльгә кер әле минем янга,—дип чакырды ул мине...

Әле һаман да жыенам шунда.

## Кызларыбыз өметле—тагын кил!

М. Жәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында жырчы Мөнир Якуповның шаулаган еллары иде. Аның турында очерк язарга бардым. Баш режиссер Нияз Даутов үзе кабул итте. Н. Даутов—урыс-татар сәхнәсендә онытылмас образлар тудырган легендар шәхес. Бигрәк тә «Евгений Онегин» операсыннан Ленский партиясен башкаруы белән дан казанды ул. Шуның өстенә, татар операсы өчен биниһая күп талантлы жырчылар тәрбияләде. Яшь жырчы турында режиссер тәфсилләп сөйләде. Соңыннан «Ул—каеннар иленнән» дигән әлеге очеркым аерым жыентыкка да кереп китте.

Миңа Нияз Курамша улының һәрбер яшь жырчы турында ниндидер эчке жылылык белән, аталарча кайгыртып сөйләве ошады. Аннары ул үсеп килүче яшь артисткаларның исемнәрен тезеп китте: Зилә Сөнгатуллина, Клара Хәйретдинова, Венера Ганиева, Рәхилә Сибгатуллина, Разия Үзбәкова һәм башкалар. Саубуллашканда маэстро наказын да житкерде.

—Кызларыбыз өметле, тагын кил!—дип чакырып калды. Ул чакта аны үземчәрәк аңлавыма бүген дә елмаеп утырам менә. Кызлар исә, чыннан да, остазларының өметен акладылар.

## Көчеккә мәдхия

Дөнья иркен, Казан шәһәре шәфкатьле булды яһүдләргә. Үзләре дә моның кадерен яхшы белде, бишкә бөгелеп сәламләде, дустанә яшәде. Хәтта татар кызларына өйләнделәр. Кайдан килеп төпләндегез безнең якларга, дип төпченмәдек.

Леонид Топчий бар иде тагын. Урыс телле талантлы яһүд шагыйре. Хатыны—татар Фәридәсе. Топчий чын Суворов инде менә! Озын буйлы, какча йөзле. Җәй икән, һәрчак ап-ак күлмәктән йөрер. Теге генерал шикелле, бер күзенә кыйгачлап, кара тасма бәйләп куйган. «Әнә, пират килә»,—дип шаярталар дуслары. Үпкәләми. Охшашлыгы бар бит... Сорый бездән:

—Дай пять рублей?

Бирәбез. Һәм ул «пятьләр»не беркайчан да кире сорамыйбыз. Миңа шунысы гаҗәп: яһүд башы белән нигә шул тиклем эчә икән шагыйрь? Эчте, әмма исереп, тәмсезләнеп йөрмәде. Бу «хитроумный» кавем арасында Топчий шикеллеләрне бүтән очратмадым.

Нәрсә ул биш-ун сум?! Шагыйрьдән берәр шигырь укыту да җитә безгә. Сүз тәмен белүдә артистларның бер якта торсын—менә дигән декламатор!

—Топчий, укы әле ни дә булса,—дибез.

Һай, ничек кенә укый диген! Сергей Есенинның (аның иҗатын тулаем яттан белә) «Әниемә хат», «Эт турында җыр» дигән шигырьләрен Топчийдан да аһәңле, тәэсирле итеп укучыны мин белмим.

*Утром в ржаном закуте,*
*Где златятся рогожи в ряд,*
*Семерых ощенила сука,*
*Рыжих семерых щенят.*

—Дай пять?—ди тагын. Бирәбез, бирми нишләтәсең...

Инде ана икеләтә рәхәт.

## Камыт белән бию

Дөбьяз янындагы Чыршы авылының хәзерге бабай-әбиләре хәтерлидер әле клубларындагы төнге тамашаны. Ул чакта аларга нибары 18-20 яшьләр булгандыр...

Октябрь инкыйлабына чаклы ук «Сәйяр» труппасында уйнаган атаклы артистыбыз Касыйм ага Шамилнең «Камали карт» спектакленнән соң яшьләр клубта төн авышканчы түгәрәк уен ясады. Баянчыбыз ошады үзләренә. Бар иде шундый оста—Татарстанның атказанган артисты (бик сирәкләргә тәтеде бу исем ул чакта) Габдулла абзый Халитов, заманында радиокомитет штатында баянчы булып тора ул. Татарстанның 10 еллыгы исемендәге клубта дары заводы эшчеләренә һәм бөтен бистә халкына мәдәни хезмәт күрсәтә. Ә хатыны Маһруйбикә апа исә спектакльләрдә гел төп рольләрне башкара. Гаять талантлы актриса иде.

Шулай итеп, шул: яшьләрнең табан асларыннан ут чыкты (Дөбьяз ягына хас нәрсә бусы) ул төнне. Әмма туктау юк. Баянчыбыз Габдулла абыйны (яше 70тән узган инде) шыбыр тиргә батырдылар. 80дәге Касыйм ага Шамилне дә һич кызганмыйлар, уртага алып бөтерделәр. Тәмам җөза бирәләр.

—Мин әтәч булып кына кычкыра беләм,—ди карт артист.

—Давай.

—Даю, кикрикүк!

—Булмады, кыска чыкты.

—Биесен, әйдә!

Касыйм аганы баянчыбыз коткарды.

—Хатынны сиңа биреп торам, Шамил абый, икәүләп биегез,—ди Халитов.

К. Шамил театр уйнарга алып йөри торган камытын киеп, айгыр булып кешни-кешни бии. Ире рөхсәт иткәч, Маһруйбикә апа айгырның байталына әйләнә.

Артист халкы юлын-әмәлен таба шул.

**Госман ГОМӘР**

# ДЖЕНТЕЛЬМЕН

ШАЯН ХИКӘЯ

«Илле алты, илле жиде, илле... Юк, хәл бетте! Шунын кадәр текә итеп ясамасалар бу баскыч басмаларын!.. Илле тугыз, алтмыш... тагын икене генә атлыйм да... Ай, алла... Ох-х!»

Мәннан кайчандыр туйларына бүләк ителгән «ярты гектарлы» келәмне нәфрәт белән ватык лифт ишеге төбенә атып бәрде: «Көя кискере! Үтил! Тәк, ничәнче кат булды инде бу? Алтынчы икән. Ярар, яртысыннан күбрәге үтелгән икән инде, ял итеп алырга да була.»

Мәннан пычрак уртасында аунап ятучы ата дунгызга охшап калган келәм өстенә менеп атланды. Бөтен дөньяга ачулы иде ул бүген: ишеге чалшайган ватык лифтка да, сыртларын кабартып көпә-көндез чинашып утыручы мәчеләргә дә. Бигрәк тә газиз хатынына үпкәсе зур иде аның. Бүген менә ял көне булуга карамастан, тан тишегеннән уятып өйне жыештырта, кабахәт! Нәрсә_генә эшләмәде инде бүген Мәннан. Унитаз белән ванналарны да ялтыратты, люстраларны сөртеп төште, хәтта тәрәзәләргә кадәр юдырды бит теге аждаһа.

—Кабахәт!—дип сүгенде Мәннан, кайсыныңдыр чүп чиләге артына яшереп калдырган тәмәке төпчегенкабызып. Март аенда тәрәзә юалармыни?! Шунда салкын тидерсән?! Тигән дә бугай инде, йөткертә... Әллә тәмәкедән генәме! Нинди сигарет сон бу? Тьфү, үләт! Әллә нинди черегән мүк тәмнәре килә моннан. Кемдер тарта бит әле шуны. Житмәсә «төпчеген» яшереп маташкан, ахмак! Пачкасы белән калдырсан да тимиләр мона!

Мәннан «төпчеккә» төкерде дә лифт эченә ташлады. Чырае жимерелгән лифт шуны гына көткән кебек «Әэжүж-мәәжүж» тавышлары чыгарып аска төшеп китте. Бер-берсенә сокланып, чинашып утырган мәчеләр котлары очып чүп чиләгенә кереп качтылар. Мәннан, озак уйлап тормастан, чүп чиләген мәчеләре белән бергә лифт артыннан озатты. Башына чиләк төшеп аңын жуйган лифт яман ыңгырашып тынып калды. Бераздан мәчеләрнең мәхәббәт жырлары шахта төбеннән ишетелә башлады.

«Гашыйкларга кайда да жәннәт!» дип уйлады күңеле күтәрелгән Мәннан һәм келәмне күтәреп өскә менеп китте.

Алтмыш бер, алтмыш ике... Житенче катта яшәүче күршесе аякларын кин жәеп, йозак тишегенә ачкычын тыгып азаплана иде. Ниһаять тишеген тапты, ахры, куанычыннан ишек төбенә үк сузылып ятты. Вәт, бәхетле жан, рәхәтләнеп ял итә, ә мин һаман өй жыештырам, дип уйлады Мәннан.

Тәмам хәлдән таеп фатир ишеген ачканда хатыны Мәннанга яна эш әзерләп куйган иде.

—Мә, түгеп кер!—диде хатыны, чүп чиләге сузып.

—Бая ник бирмәден?—дип чәрелдәде Мәннан.

—Кая бирим? Авызыңа каптырырга идемени? Келәм күтәргән иден бит,—диде тегесе. Аннан соң йомшый төшеп:—Бая тулмаган иде әле ул,—дип өстәде.

—Әле дә тулмаган, иртәгә чыгарырмын,—дип киреләнде Мәннан.—Кеше

инде рәхәтләнеп ял итә. Әнә жиденче каттагы урыс күрше аягында да басып тора алмый, ә мин әле тәгам да капмаган.

—Ярар, менә чүпне генә түгеп кер дә, бүтән эш кушмам,—диде хатыны,— син дә табынга утырырсың.

—Чынлапмы?—диде Мәннан, ышанмыйча.

Хатыны җавап бирмәде. Тиз генә барып суыткычны ачты да, берьюлы ике шешәне муеныннан сөйрәп чыгарып өстәл уртасына утыртты. Берберсенә бәрелгән шешәләр чыңы туктаганда, Мәннан өченче катны узып киткән иде инде. Сарай капкасы төбендә утыручы хәерчеләренә алтын тәңкәләр сипкән юмарт Бохара әмире кебек, кара каргаларга бәрәңге кабыклары сипте дә, март кояшыннан күзен кыса төшеп, подъезд ишеге төбенә килеп басты. Дөнья матур, дөнья кин! Ләззәтле минутларны юри суза иде ул. Ә-ә, туктале, почта әрҗәсен карарга кирәк. 350 граммга кадәр әйбәт укый ул, хәрефләр дә берәр генә булып күренә. Тәк шту бөтен гәҗит-журналларны карап чыгарга була. Ә инде 350 граммнан соң укылган материаллар буенча хатын белән фикер алышу башланачак. Ул чагында инде күз кирәкми—баш кирәк! Ә Мәннанда баш бар, Аллага шөкер! Юкка гына 59 нчы размер кими ул.

О-о, минем пропагандистларым? Тә-әк, «Чаян»да килгән икән. Жиденче каттагы күршенекен дә алыйк әле, урысча да хәреф таныйбыз. Ана барыбер «общественный агитатор» кирәкми бүген. Бу ни бу?! Мәннанның аяк астына тирбәлә-тирбәлә кәгазь кисәге килеп төште. Алып караса—телеграмма. Унлап-суллап яңагына суккан кебек дүрт кенә сүз язылган иде. «Приеду понедельник. Твой Тузик».

Мәннанның тез буыннары йомшап, лифт ишегенә барып сөялде бичара. Эчке якта үзәкләрне өзәрлек итеп мәчеләр чинаша иде. Белә Мәннан Тузикның кем икәнен. Тәүзих ул. Шәрипов Тәүзих. Хатынының беренче мәхәббәте. Мәктәптә укыганда үчекләп Шариков Тузик дип йөриләр иде. Картаеп беткәч, читтән торып институтка укырга керде. Надан! Әле һаман бетерә алмый. Менә шуңа күрә Мәннан инде сигезтугыз ел рәттән язын-көзен унбишәр сутки утырып чыга. Теге Тузикның сессия вакытына туры китереп хатыны утырта. Аннары, фатирда икәү генә калып, рәхәтләнеп типтерәләр икән. Башта Мәннан берни белми иде. Үзе пенсиягә киткәндә, участковый милиционер әйтеп калдырды. Срогыннан алда чыгармасын дип, теге Тузик колхоздан кәрәзле бал ташыган, ысбулыч!

Берсен-берсе уздырып, тагы мәчеләр чинаша башлады.

Ю-ук, бу юлы миннән жинел генә котыла алмассыз! Мәннан ике баскычны бер итеп өскә йөгерде. Тугызынчы катка менеп житкәндә анын 59 нчы размерлы башында өр-яңа план өлгергән иде. Ничава, ул Тузикның койрыгын төптән кыскартып, танавын төя-төя бульдог ясап җибәрербез! Менә дигән эт туе әзерлим әле мин сиңа!

Ул кергәндә табын инде әзер иде. Озак итеп һәм күп итеп ашады да ашады ул. Хатыны берничә тапкыр шешәләрне Мәннан алдынарак шудырып карады, тик тегесе урындыктан-урындыкка күчә-күчә өстәл тирәли әйләнә бирде.

—Син нәрсә, авырыйсыңмы әллә?—диде хатыны, түземе бетеп.

—Эһе!—дип кикерде тамагы туйган Мәннан,—тәрәзә юганда салкын тигән бугай.

—Әйдә, менә җылытып берәр стакан эчеп җибәр, шундук үтеп китәр.

—«Эпитет» юк, ятып кына торам.

Мәннан гәзитләрен алып диванга сузылып ятты. Озак кына ачылмаган шешәләргә карап утырганнан соң хатыны Мәннан янына килеп кулын маңгаена куеп карады.

—Чыннан авырыйсың син, Мәннан, бөтен йөзең ап-ак.

Култык астына градусник куеп карадылар—36,6. Ләкин хатын бирешмәде.

—Врачка күренергә кирәк сина. Әйдә, иртәгә минем таныш врач янына барыйк әле, карасын,—диде ул, ирен юмалап.

Ә-ә, унбиш сутгы барып чыкмагач, бүлнис калдымыни? Беләм мин синең ул врачынны, теге юлы да дизентерия тапты ул миннән. Сабан туена кадәр бикләп яткырдылар. Мин чыкканда теге Тузикның сессиясе әллә кайчан беткән иде инде.

—Ярар, жаным, борчылма. Үтте бугай инде,—диде Мәннан тыныч кына. Мәннан тынычрак булган саен хатыны капкынга эләккән тычкан баласыдай бәргәләнә иде. Бүлмә буйлап кая барып бәрелергә белми аптырап йөргәннән соң, ул юри Мәннанның инде биш елдан бирле үстерә торган кактусын идәнгә тәртеп төшерде. Бусы инде чамадан тыш иде. Мәннан «Ванька-встанька» кебек итеп диваннан сикереп торды. Ул арада хатыны да тәрәзәләрне киереп ачып, күршеләргә ишеттерер өчен үпкәләренә күп итеп һава жыеп өлгергән иде. Хатынының чыраена басарга дип алган кактусны әйләндергәләп торганнан соң, Мәннан чәнечкеле бичара гөлне сак кына телевизор өстенә куйды.

—Ярар, алай бик бетерешмә,—диде ул, тыныч кына.—Мин барын да беләм.

—Нәрсә беләсең?—дип чинады хатыны.

—Менә телеграммасы. Иртәгә килеп житәчәк.—Мәннан телеграмманы хатынына тоттырды.

—Курыкма, йөзенә кызыллык китермәм,—дип дәвам итте ул. Ашаганнан соң «әппәр» дә итә белмәгән инглизләрдән безнең кай жиребез ким. Менә дигән джентельмен булырмын!

—Нинди Тузик? Мин берни белмим! Ялгыш килгән бу,—дип, хатыны бичара кәгазь кисәген теткәләп тәрәзәдән ташлады.

Ир белән хатын көне буе бүтән берни сөйләшмәделәр. Коточкыч зур давыл алдыннан була торган тынлык урнашкан иде өйдә. Йокларга да аерым яттылар.

Иртә белән эшкә китәр алдыннан Мәннан хатынына күз салды. Тегесе берни булмагандай кухняда бөтерелә иде.

—Син шулай да вокзалга төш инде, матур итеп каршы ал, яме. Ирләрнең аздан да күңеле була бит аның,—диде Мәннан, тыныч кына. Бармый калсаң, минем турында да әллә ниләр уйлар. Ире бигрәк көнче икән, каршы алырга да жибәрмәгән, дияр. Теге зәңгәр плащыңны киярсең, яме, сиңа бик килешә ул. Менә мә, акча да калдырам, чәчәк алырсың. Бәхетле хатын-кызның кулында әбәзәтелни чәчәк булырга тиеш. Акчаны жәлләмә, розалар ал, фатир өчен авансгтан түләрбез әле.

Мәннан, 59 нчы размерлы бүреген башына элеп, ишекне ачты, тик нидер исенә төшеп янә туктады.

—Ә-ә, ни... алай-болай соңрак кайтырга уйласаң, кыенсынып торма, яме. Мин ишекне өстәге йозакка гына бикләрмен. Үзең ачып керерсең, мине уятып торма.

Кухня ягыннан корбаны өстенә очып килүче аш тәлинкәсе, ябылып өлгергән ишеккә бәрелеп, чәлпәрәмә килде.

—Бергә—ноль!—диде Мәннан, ватык лифт ишеге төбендә утыручы ата мәченең башыннан сыйпап.

Мәннан эштән кайтканда хатыны өйдә утыра иде. Мәннан чынлап торып гажәпкә калды.

—Нишләп бик иртә кайттың, әллә ачуланыштыгызмы?—диде ул, хатынының чәченнән сыйпап.

Тегесе күзеннән зәһәр очкыннар чәчеп, нидер әйтергә дип озак кына азапланганнан соң, әллә нинди ямьсезләнеп ванна бүлмәсенә кереп китте.

—Болай ярамый бит инде, бәгырь кисәгем,—диде Мәннан, ачык калган ишектән узып.—Үз-үзенне бетермә син, ике күзем. Сәламәтлегенә зыян килүе бар. Мин бит сине бик яхшы анлыйм. Беренче мәхәббәтен... Әллә нигә бер очрашасыз... күрешәсең килә. Тик син мине дә аңларга тырыш инде, пажалысты. Яртышар ай таш идәндә аунавы миңа да рәхәт дисеңме?! Яшь чагым түгел бит, болай да билләрем сызлый. Мин бит сиңа бер сүз әйтмим, теләгән җиренә бар, теләгән вакытында кайт,—диде ул, хатынына чишенергә булышып.—Әй-й, онытып та торам икән, әле менә иртәгегә театрга ике билет алып кайттым. Мәхәббәт турында диделәр. Рәхәтләнеп карарсыз.

Хатыны бөтен гәүдәсе белән сизелер-сизелмәс кенә калтырана башлады.

—Анда яктыртучы булып минем таныш мужик эшли. Билетларны да ул алып бирде. Иң әйбәт урыннар, ди... Өченче рәттән. Интегеп рәт араларында эзләп йөрисең дә булмый, сез кергәнче үк урыннарыгызны прожектор белән яктыртып куярмын, диде.

Хатын әллә хәле китеп, әллә аягы таеп, ваннадагы суга егылды.

—Чү-ү!—диде Мәннан,—саграк бул, тәнең күгәреп чыга күрмәсен, ире кыйнаган, дип уйлар.—Тә-әк!—дип сузды ул, хатынының шәрә гәүдәсенә сокланып,—фигураларың Аллага шөкер, кызларныкы кебек. Менә юынып чыккач, чәченә бигуди куярбыз. Яле, менә бу агарган чәчләренне генә йолкып атам да... Вә-әт, булды. Иртәгә матур итеп бизәнеп-ясанырсың. Тырнакларыңны буяп җибәр. Бөтен театр халкы «аh!» итсен. Күрсеннәр Мәннан хатынының нинди икәнен! Түлке сөяркәнә дә әйт инде, пажалысты, матур итеп киенеп барсын, яме. Мин анда сөйләшеп куйдым, бер прожектор спектакль буе сезгә яктыртып торачак.

Хатын, учы белән авыз-борынын каплап, су төбенә китте. Мәннан ванна төбеннән күтәрелгән куыкларга чиртә-чиртә сабыр гына хатынының чыгуын көтте. Ниһаять, тыны беткән хатын өскә калыкты.

—Ай, алла-а!—диде Мәннан, юеш чәчен рәтләгән хатынын баштанаяк күздән кичереп.—Бу нәрсә бу, карчык?!

Хатыны пыялаланган күзләрен Мәннанга төбәде.

—Бер дә үзенне карап йөрмисең инде! Култык асларыңны әйтәм. Миңа нинди булсаң да ярый, ә ул бит сөяркә кеше. Шапшак хатын икән дип уйлар. Кая әле минем лезвий, хә-әзер үзем бөтен җирләренне рәтләп бирәм...

Кинәт хатын, яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып бер чинады да, тилебәрән орлыгы ашаган Су анасы кебек Мәннанга ташланды. Мәннан «каравыл» кычкырып, коридорга чыгып йөгерде.

Ватык лифт ишеге төбендә утыручы ата мәче, Мәннанга атланып чыгып килүче шәрә хатынны күреп, үз теләге белән кире шахтага сикерде. Тавышка күрше-күлән җыелды. Хатынны туктатырлык түгел иде. Милиция чакырып, көч-хәл белән Мәннан өстеннән кубарып алдылар.

Хатынын унбиш тәүлеккә озатканнан соң, Мәннан шахтага сикергән ата мәчене өенә алып керде.

—Нокаут!—диде ул, мәченең башыннан сыйпап,—көчләр тигез булмау сәбәпле икенче раундтан соң чиста җиңү Мәннан абзаңа бирелде!

Ата мәче, Мәннанның җиңүеннән бик канәгать калып, сөяркә өчен дип әзерләнгән каймакны «сыптыра» иде.

**АМАНУЛЛА**



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!



Камил
Кәримов*

# ЯШЕЛ ЧИТЛЕК

ХИКӘЯ

Алар инде үзләренең өченче көзен каршы алырга җыена. Җәйнең соңгы ае коры килде быел—көн кызулыгы нарат күләгәсендә дә сизелә. Ләкин балаларның үсеп җитүенә караганда салкын көннәр бик якын инде.

Узган ел да шулай булды... Август челләсе янган учак шикелле дөрләп торды-торды да тоташ яңгырлар килеп сүрелдереп куйды. Чыланган туфрак,юеш урман барыбер җәй уртасындагы кебек шакыраеп кибә алмый инде аннан соң.

...Үткән җәйдә алар өч кенә бала үстерде.

Быел яз көне,алар башка керпеләргә дә хас хәстәрлек күреп,наратлык белән болын тоташкан җирдә бурсыклардан бушаган бер өнне үзләренә оя итеп сайлаганнар иде. Болын тирәсендә ризык табу җиңелрәк—юллар такыр, үләннәр коры һәм сирәк, бөҗәкләр күбрәк, җиләкләр тәмлерәк... Ләкин бу тирәдә кешеләр күбәя башлады. Әле кар сулары бетеп җир ныгып та өлгермәгән иде,кешеләр килеп,болында казыклар кагып йөренә башладылар, өзлексез ызгыштылар, күч күтәргән кырмыска оясы шикелле кайнашып төзелеш материаллары ташыдылар. Кешеләр көне-төне белән бу тирәдә шулкадәр күбәя—кичекмәстән ояны күчерергә кирәк иде. Ләкин ана керпе йөкле иде. Шуңа күрә мондый җәйлы ояны ташлап китәргә һаман тәвәккәлли алмадылар.

Аларның биш баласы туды—биш шәрә керпе.

Бәхеткә каршы,кешеләр урманны бик борчымады,вакытлары бик тар иде бугай—һәркайсы ашкынып дача төзи. Бу ояда,балаларның күзләре ачылганчы гына, ике-өч атна яшәргә туры килер әле. Аннан соң күченерләр—урман калын,биш балалы керпе гаиләсе генә сыяр.

Алар,үч иткәндәй,ауга парлашып киткән иде. Төн шундый тыныч,җылы. Оя эченә ай яктысы төшеп калды... Кыр тычканнарын куа-куа шактый юл үттеләр. Кинәт аларның оясы янындарак үкергән тавыш ишетелде. Кайтсалар... оя өстенә кара,шыксыз олы машина баскан да бер яшь наратны тамырлары белән йолкып маташа. Ике кеше төз наратның каерылган ботакларын

* Камил абыегыз Кәримов 18 яшендә менә шундый иде.

өзә, ай яктысында балталарының йөзе елкылдый. Авыр машинаның арткы көпчәге астында оя, ә ояда күзләре дә ачылмаган, әнәләре дә тырпаймаган биш бала...

* * *

Алар шул төнне үк, балалары күмелгән ояны ташлап, нарат урманының иң түренә күчеп килделәр. Машина көпчәге менә алмаслык биек төп астына оя корып, янә бала көтә башладылар. Һәм бүтән керпеләрнең балалары, оялары белән хушлашып пар-пар таралышкан чакта, табигать аларга тагын... җиде бала бүләк итте...

...Нарат урманында көзнең сары яктылыгы сизелми, шуңа күрә ана керпе көн саен диярлек каенлы аланга барып килә.

Каеннар көзне алданрак тоя, аларга карап башкалар да, җәйге мәшәкатьләрдән тизрәк арынып, кышка хәстәрлек күрә башлый... Китәр кошлар төркемнәргә оеша, җанварлар өн тирәнәйтә... Һәм ана керпе дә, үз парын ашыктырып, калынрак итеп яфрак коелган чокырда кыш кичәрлек урын сайлар. Ә балалары... Алар да парлашып таралышыр, монысына инде аларны өйрәтеп торасы юк—табигать тәрбияләгән гадәт. Бер баласы—бишенче малае гына так калыр һәм үзенә пар эзләп китәр. Урман эченәрәк үтсә, әлбәттә, табар ул аны. Ана керпе балалары тәпи йөри башлаганнан бирле урман авызына чыкмады. Әгәр бу җиде шаян йомгак урман авызына юнәлсә, шундук аларның юлларына аркылы төшеп: "Фырт! Фырт!" иткән тавыш чыгарып, кире ояга—ягъни нарат куелыгына таба куалый торган иде. Урманнан чыгарга ярамый, анда үлем көтә, хәтәр сагалап тора. Балаларның җидесе дә шуны нык хәтерләп калырга тиеш, аларның балаларының балалары да онытмаслык булсын.

Көндез алар—тугыз җан иясе—гел бер тирәдә, оя яныннан ерак китмичә генә җир иснәүдә. Өйлә вакытында кинәт әлсерәп, энәләрен артык тырпайтмыйча гына, бөтенесе бер кучкә оешып дигәндәй, ял итәләр. Кичләрен исә төрлесе төрле тарафка тәгам эзләп чыга. Җәй ахырында тамак туйдыруның һич кыенлыгы юк: томшыгыңны җилгә каршы күтәрсәң, тәмле гөмбә исе килә, ә гөмбә булган җирдә һәрвакыт бөҗәк бар. Дөрес, хәзергә баллы гөмбәләр генә чәчелеп үсә. Килер шундый чак: усак, каен, нарат гөмбәләре, гөреҗдәләр баш калкытыр, майлы гөмбәләр кабарыр, һәм керпенең гаиләсе, шул гөмбәләр тирәсендә чемченеп йөри торгач, шактый ризык табып, симергәнче сыйланыр. Симергәнче—кышкы йокыга җиткәнче.

Мәгәр әлегә җәй бирешми әле.

Җиргә коелган ылыслар шакыраеп кипкән, атлаганда чыртлап сынып кала, йөргәнең әллә кайдан ишетелеп тора. Ипсезрәк бассаң—ылыс тәпигә кадала да, керпе кисәк авыртудан сискәнеп читкә сикерә. Һәм шундый кыштырдау куба—җирдәге дошманнарың гына түгел, һавадагы козгыннар да ишетер...

...Ояның авызы кояшка карый, шуңадыр, иртүк бөркүләнә. Аннан соң кысан да. Җиде бала әти-әнисе тирәли кысылып ята торгач, кайчак берсенең энәләре икенчесенә чуалып бетә, балалар укмашып, куба алмыйча изалана. Шуннан әниләре пошкыра-пошкыра көч-хәл белән оя авызына чыга, ә аңа, тигәнәктәй сарылып, җиде бала ябышкан була. Балалары инде үз тамакларын үзләре туйдырырга өйрәнеп килә. Шулай да көн эсседә алар бик ялкауланалар. Әниләрен яңгыр суларыннан бушаган коры канауга тәгәрәтеп төшерәләр дә комсызланып имәргә ябышалар. Көн озын, һава эссе, төнге ау бик кыска—әниләренә бу хәтле гаиләне туйдырырлык сөт каян килсен. Тамаклары кибә торгандыр шул.

Коры канау буйлап түбәнгә йөгерсәң, чишмә челтерәп ага, әллә ни ерак та түгел, әйләнеп килгәнче ярты сәгатьлек юл. Туйганчы су эчсәң, балаларга җитәрлек сөт төшәр иде. Әтиләре күз-колак булып торыр иде әле.

Чишмә суы артык киң җәелеп акмый. Аның бу яры тау сыман текә иде, бик сакланып кына төшәргә туры килде. Су янына ук килеп баскач та ул,

үзенең сусавын тыеп, бермәлгә иснәнеп торды—ят ис килә кебек тоелды аңа. Шикләнүе заяга булмаган икән—агымсуга карап бераз атлауга, тәмәке төпчегенә юлыкты. Ул кинәт сискәнеп аякларына басты да үрелеп-үрелеп тагын һаваны иснәде.—Юк, кеше-мазар күренми. Тәмәке төпчеген узып агымга каршы шактый менгәч, түзмәде: ниһаять, урман чишмәсенең чеплә ярсуыннан ашеренеп аккан салкын суына телен тидерде.

Керпеләр суны мәче шикелле тел белән эчә. Бик сусаган чакларда, һай, озак чупылдатырга туры килә керпеләргә.

* * *

Ул әле суның түмен дә тоеп өлгермәде. Кинәт колак тондыргыч гөрелте ишетелә башлады, ишетелде генә түгел, бик тиз якынайды да ул. Кичекмәстән качып өлгерергә кирәк иде. Ана керпе җәһәт кенә өскә үрмәләде. Кабаланып атлагангамы, әллә ярның текәрәк җире туры килдеме—аяклары чалынды. Менеп җитәм дигәндә генә баскан җирдә яр ишелде дә, ул балчык түмгәге сыман су уртасына тәгәрәп барып төште, анда да түше белән түгел, чалкан ятты. Аяклары белән күпме генә тыпырчынмасын, башын ничаклы гына боргаламасын, гәүдәне әйләндерер өчен таяныр урын юк иде. Җитмәсә, суы да сай булып чыкты, ул энәләре белән ләмгә кадалды, ә гөрелте, көчәйгәннән-көчәя барып, ниһаять, кып-кызыл мотоциклга әверелде дә су читенә үк килеп тукталды. Бик оста туктады, алгы тәгәрмәче аз гына кыймшана калса, алар инде өчәүләшеп—кыз, егет һәм мотоцикл—керпе өстенә килеп төшәселәр иде.

—Хәзер, мин сине сугарам,—диде кыз.

—Миңа су кирәкми,—диде егет.

—Урманда башкасы юк,—диде кыз.

—Аның каравы портфельдә бар.

—Кирәкми. Мин аның өчен килмәдем,—диде кыз.

—Барыбер түгелмени?—диде егет.

—Түгел. Син мине табигать кочагына дип алып килдең. Ә үзең әллә ниләр сөйли башладың.

—Минем кочак та табигатьнекеннән ким түгел.

—Тагын шундыйрак берәр сүз әйтсәң, кайтам да китәм!

—Җәяүме? Юлны белмисең, вәт!

—Менә шушы суга ияреп китәм, йә берәр авылга барып чыгар, йә зуррак елгага. Шәһәр дә ерак түгел моннан,—диде кыз.

—Алайса, мин сине агачка бәйләп куям.

—Куркыныч кеше икәнсең син.

—Тугыз ел бергә укып, шуны белмәдеңме?

—Бүген белгәч тә җиткән, әле соң түгел...

—Соң инде.

Егет "эһ" дигәнче кызны беләгеннән эләктереп алды да кулларын каерып җиргә егып салды һәм, кызның кайсы җиреннән үбәргә белмәгәндәй, әле битләренә, әле иягенә, маңгаена үрелде. Үзе ашыгып-ашыгып нидер әйтеп калырга, нәрсәгәдер ышандырырга тырышты. Җөмләләре өзек-өзек, сулышы еш-еш иде аның.

—Бу безнең соңгы каникул... Киләсе җәйгә син миңа тәтемәячәксең. Хәзер ычкындырмыйм... Аннан соң хет теләсәң нишлә.

— Җүләр мин, җүләр, сиңа ышанып... Җибәр, юкса кычкырам! Ачуымны чыгарма, юкса берәр хәл эшлим үзеңә.

—Эшләгән диярләр.

Ике арада аңлаешсыз һәм шыксыз тынлык урнашып алды.

—Абау, су эчендә әллә нәрсә чыпырдый. Елан бака тотты бугай.

—Китче, каян килсен монда елан?—диде егет сагаеп.

Ул, кызның сүзенә ышанырга теләмәсә дә, әлеге тавыш белән кызыксынмыйча булдыра алмады һәм, максатын онытып, тиз генә ярдан төште. Әгәр кыз шушы

минутта аннан котылыр өчен генә ялганлаган булса, егет икеләтә усаллык белән һәм кире уйланырлык урын калдырмыйча, яңадан кызга ташланачак иде... Чыннан да, су эченә чалкан капланып, ярдәмгә интегеп яткан керпене күргәч, җиңел сулап куйды ул:

—Мишәйт итеп йөри шунда...

—Ә ул мине коткарырга килгән,—диде кыз, үз сүзенә үзе ышанып.

—Коткарды ди, аягына да баса алмаган килеш.

—Коткарды, коткарды, коткарды,—диде кыз көйсез генә такмаклап.—Ә хәзер мин аны коткарам.

Кыз кроссовкаларын да салып тормыйча керпе янына кереп басты, аның йомры тез астына чаклы тартылган ак гольфасына су сеңде. Керпене песи баласын иркәләгәндәй сыйпый-сыйпый кулына алды ул.

— Ничек пычранган. Хәле беткән, күптән интегә бугай,—диде кыз.

—Аны төлке тәгәрәтеп төшергәндер әле.

—Төлкедән түгел, синнән куркып төшкән ул,—диде кыз, ачуланып.

—Китер әле монда.

Керпе егет кулына күчте. Кулына дип, кыз шикелле кушучлап тотмады ул аны, ә бер генә энәсеннән, чеметеп күтәрде. Авыртуга чыдамыйча, чәнечкеле йомгак тагын да ныграк кысылды, кечерәеп калды. Егет аны суның тирәнрәк төшенә ыргытты да туп юган кебек әйләндерергә кереште.

—Нишләтәсең, керпеләр су яратмый бит,—диде кыз, өзгәләнеп.

—Яратмаса суга төшеп ятмасын иде. Кем кушкан...

—Ул—ана керпе.

—Бәлки, атадыр.

—Ата керпеләр сусамый. Ризыктагы дым җитә аларга.

—Отличниклар барысын да белә инде... Ә мин әйтәм, бу—ата керпе, күрәсең киләме?

—Оятсызланма.—Кыз борылып басты.

—Син хаклы, ана керпе бу,—диде егет бераздан.

—Димәк, балалары көтә аны,—диде кыз, яңадан егеткә текәлеп.

—Ниткән бала тусын ди бу чәнечкедән?

—Күрәсең ич—энәләре соры төстә, яшь керпе түгел инде ул. Җибәр син аны.

—Җибәрмим. Өйгә алып кайтып туныйм да бүрек тектереп киям. Бер кеше дә урламый торган бүрек булачак ул.

—Җибәр.

—Җибәрсәм нишләрсең?

—Керпе сөенер,—диде кыз.

—Ә син?

—Мин дә.

—Су уртасында басып тору килешә сиңа, чиләнгә охшыйсың. Кая, бер үбеп алыйм әле!

—Якын килмә!

Кыз капылт кына су төбендәге лайны учына алды да үзенең маңгаена, битенә, иягенә сылады.

—Мә, үп!

—Фу, дура!

Егет, кесәләрен актара торгач, җептән үрелгән сетка чыгарды да керпене салып һавада әйләндерә башлады. Керпене түгел, кызны үчекләве иде үзенчә. Янәсе, кызганасыңмы, кызгансаң—ялын, бәлки, кайбер шартларда, син дигәнчә булыр.

—Нишләтәсең, башы әйләнә бит!—дип өзгәләнде кыз.

—Йомгакның башы буламыни?!—Егет әйләндерүен белде.

—Син үзең башсыз! Туктат, үтерәсең мескенне.

Кыз түзмәде, судан атылып дигәндәй чыкты да, лайга баткан кроссовкаларын

лычтырдатып егет янына ашыкты.

Ә теге керпене һаман әйләндерә, урыныннан очып китә алмаган ватык вертолет шикелле,"р" авазы кергән сузынкы тавыш чыгарып әйләндерә. Кыз, аны туктар дип ышанып,әкренләп-әкренләп якыная торды. Кыз якыная,ә теге туктамый,кыз якыная,ә сыңар канат әйләнә дә әйләнә. Кыз якынайды... һәм яңагына кисәк кенә керпе килеп томырылгач,чайкалып артка чигенде,абынды, ләкин егылмады.

—Ой!—кыз ике кулы белән ике яңагын каплады. Дөрес,керпенең йөзәрләгән энәсе аның бер генә яңагын иләкләгән,ләкин ул,егетне күрмәс өчен,күзләрен капларга теләгән иде. Сул уч төбеннән кан саркып чыкты.

—Гафу ит,сизми калдым,якын килмәссең дип уйлаган идем.

—Ә мин сукмассың дип уйлаган идем.

—Гафу ит,авыртамы?—Егетнең тавышында икеләнү сизелде.

—Тавышыңны да ишетәсем килми. Керпене үтердең.

—Хәзер беләбез аны.—Егет керпене сыйпап күрсәтмәкче иде,бөгәрләнгән йомгак үзалдына кисәк сикереп куйгандай итте.

—Ай, ой-ой!—Егет кычытканга чагылган баладай уч төбен ялый башлады.

—Шул кирәк сиңа,дошман!—диде кыз,нәфрәтләнеп.

—Үлмәгән дидем ич. Берәр төлке йә бүре тәпиен сузса, керпеләр гел шулай—энәләре белән чәнчеп-чәнчеп ала. Иммунитет, рефлекс, саклану чарасы. Йә,ярый,кайтыйк тизрәк,битеңә йод сөртәсе бар.

—Матаеңа бүтән утырасым юк.

—Ашыгырга кирәк,каның агып бетсә...

—Үләрмен ичмасам,—диде кыз ышандырырлык итеп.

—Киребеткән. Үҗәт Хан кызы. Синең үлемеңдә минем гаебем булмас. Пока!

Егет керпеле сетканы рульгә бәйләде дә агачлар арасына кереп югалды. Мотоцикл артыннан томанга охшаш, әмма әче, зәңгәр төтен өермәсе генә бөтерелеп калды... Беркавымнан соң егет тагын чишмә янына сугылды,кызны тагын бер кат сынап карарга иде,ахры,исәбе,ләкин кыз анда юк иде инде.

* * *

Урман аша олы юлга чыкканчы мотоциклга шактый сикәлтә кичәсе бар иде әле. Руль уйнаклаган саен, сеткадагы керпе як-якка бәрелде. Җитмәсә, урманнан кыйный-кыйный озаткандай, яшь наратларның түбәнге ботаклары әрсез мотоциклны,гамьсез егетне һәм шул исәптән керпене дә уңлы-суллы камчылый иде.

Ниһаять, асфальтка чыккач кына мотоцикл тигез гүләп җәһәтрәк йөгерә башлады. Керпенең энәләрен аралап бөркү җил агымы килеп бәрелде. Бөркү булса да ул рәхәтләндереп, тәндәге бөтен авыртуларны онытырлык итеп җиләсләндерә иде. Тора-бара урман манзарасы өчен таныш булмаган ят тавышлар ишетелде. Баштарак машина,трактор гөрелтесе,аннары трамвай тыкылдавы, җан өшеткеч гудоклар, этләр өрүе һәм керпе өчен иң хәтәре—күпләгән кешеләр сөйләшүе артканнан-арта,көчәйгәннән-көчәя барды.

Өйгә кайту белән егет шәрран ярып мактанырга тотынды:

—Нинди оригиналь мәче алып кайттым, күселәрнең, тычканнарның җан дошманы—тере керпе.

—Шул гына җитмәгәние,өйне абзарга әйләндердең инде,—дип каршы төште хатын-кыз тавышы.—Аквариум дидең—карышмадым,попугай сорадың—сүз әйтмәдем,керпең нәрсәгә кирәкте тагын?

—Яшәп карасын. Кызык ич,бөтен кешегә дә эләгә торган нәрсә түгел.

Аны сеткадан идәнгә селкеп төшерделәр. Кечкенә тәлинкә белән сөт куйдылар һәм, диванга утырып, керпенең ачылганын көтә башладылар. Өй эчендә бөркү тынлык урнашты, ачык балкон ишегеннән урам тавышы гына

гөрелдәп тора иде. Аның бик нык тамагы кипкән иде, ул бит әле урман чишмәсеннән дә туйганчы су эчеп өлгермәде. Тәлинкәдәге сөт исе бөтен куркуны җиңәргә мәҗбүр итте.

Иң әүвәл башы җанланды,әкренләп гәүдәсе язылды. Һәм чәнечкеле йомгак күз алдында сөйкемле җан иясенә әверелде. Ул, тәлинкәгә алгы тәпиләрен тидермичә генә үрелеп, сөтне иснәде. Аның әле бервакытта да сөт эчеп караганы юк иде, алай да бу ак сыеклыкның бик тәмле икәнлеген исеннән сизенде ул.

Рәхәтләнеп сөт эчкәч, яңадан йомгакка йомарлануын кирәксенмәде, үзен иреккә чыккандай хис итеп, буяулы шома идән буйлап аулак почмак эзләп китте. Шулчак баш очында ялгыз кош тавышы ишетелде, ләкин урмандагыча түгел, ниндидер ят сайрау иде бу—сакау сандугач шикеллерәк интегә, әллә кылана шунда...

—Гел сөт белән генә яшәр дисеңме?—Хатын-кыз тавышы йомшарды.

—Без ашаган аңа да ярар әле,—диде егет тавышы.

—Урманда кешечә яшәп яткан дисеңме?

—Филләрне дә кеше кулыннан ашарга өйрәтәләр.

—Нилләр белән туена икән соң бу дүрт аяклы кактусың?

—Белмим,—диде егет тавышы.

—Нәрсәгә генә укыталар соң сезне?

—Һәрбер җәнлекнең ашказанын өйрәнә башласаң, мәктәптә ун гына түгел—утыз ел укырга кирәк.

—Белгән кеше барысын да белә... Шалтыратып сорап кара әле.

Егет телефонга ябышты. Шактый көтеп тә җавап ишетелмәгәч, ышандырырлык итеп әнисенең авызын япты:

—Урманнан кайтып җитмәгән әле ул.

Керпе идән ырмавы буенча чабып диван астына кереп качты. Ошамаслык урын түгел икән—караңгылыгы да җитәрлек, юылган такталардан чын агач исе аңкып тора.

Нинди генә ис юк монда... Кайчандыр, шушы бердәнбер аулак урында песи дә яшәде. Бик күптән түгел әле. Пәрәвезгә ябышып калган каурыйлар да артык нык кибеп өлгермәгән. Кем каурые соң бу? Песи дигәнең диван астына берәр тавыкны сөйрәп керә алмагандыр. Аннан соң, каурыйлары бик вак, йомшак, төрле төстә. Бүлмәдәге яшел читлектә тыпырчынган ялгыз кош күз алдына килә. Песине дә каядыр олактырдылар.

Төтене чыгып тормаса да, якында гына, күздән яшь агызырлык һәм баш әйләндергеч көек исе килә. Керпе аны да эзләп тапты—(тәмәке төпчеге җыя торган тәлинкә сыман нәрсә иде бу) ул аны ачу белән этеп җибәрде, диван астыннан төрткәләп чыгарырга иде исәбе, ләкин савыт, тактага бәрелгәч, әйләнеп кенә капланды. Керпе үзалдына кинәт сискәнеп куйды, әлеге савыт шакмаклы-шакмаклы таш гөмбәзне хәтерләтсә дә, кайчандыр аның җан иясе булганлыгы сизелеп тора!.. Керпене үз язмышы ачындырды—ни көтә икән аны? Мөгаен, бу өйдән исән-имин килеш чыгып котылучы юктыр...

Ишек ябылды.

Әнисен озаткач, егет, ишекне ике йозагына бикләп, диван почмагына килеп утырды.

—Әй, аяклы кактус, чык әле монда, чәнечкеләреңә бигуди куям. Төпчек савытын әнигә күрсәтә яздың бит. Ул аның нәрсәдән ясалганын белми әле.

Егет идәнгә ятып керпене эзләде, тик тапмады, тегесе, алдан ук саклык чарасы күреп, диван астына кагылган аркылы такта өстенә менеп качкан иде. Шуннан соң егет ташбака кабырчыгыннан ясалган төпчек савытын үрелеп алды.

Өйгә тагын да зәһәррәк булып теге көек исе таралды...

Беркавым утыргач, егет балкон ишеген ачып җиләтергә теләде.

Пәрәвез оясындагы тутый кош мамыкларын тибрәндереп, җылымса

җил килеп керде. Җил генә түгел, урам исе: җәйге иркенлек, җан рәхәте, сөенеч—һәммәсе дә бар анда. Шушы җилгә каршы атласаң,һичшиксез ирекккә чыгарсың шикелле...

Ул кыр тычканнарын кугандагыча җитезлек белән ачык ишеккә ыргылды һәм,тәбәнәк бусаганы атлауга балкон рәшәткәсе аша упкынга охшаш бушлыкка очты. Бераз очып, астагы балконнан тарттырылган кер бавына бәрелгәч, ул, читкә атылып, чәчәк түтәленә барып төште.

Җиргә бәрелгәч,авыртудан хәлсезләнгәндер,аның инде тыгыз йомгак булып йомарланырлык хәле юк иде. Ул өнсез калды.

Егет өченче каттагы балконга чыгып карагач,чәчәк түтәлендә өнсез яткан керпегә кул гына селтәде. Җитмәсә,телефоны да шылтырый.

—Тыңлыйм,—диде егет,иренеп кенә.

—Керпене миңа бир әле,—диде кыз,ялынмыйча.

—Ә-ә,кайтып җиттеңме? Җәяүле кешегә биш сәгатьлек юл икән.

—Бир керпене.

—Ул үз-үзенә кул салды.

—Ничек?

—Өченче каттан,балконнан сикерде. Урыны чәчәктә булсын.

Сөйләшү өзелде. Егет кулындагы трубкада кыска гудоклар гына ишетелеп калды.

Керпе озын кышкы йокыдан уянгандай әкрен генә күзен ачты. Бөтен тәне изелгән сыман, аяклары гәүдәгә буйсынмый, бик нык изалана торгач кына түшенә ята алды һәм ышанмаслык хәл: аяк астында көпшәк җир—купшы урманнарда гына очрый торган хуш исле кара туфрак иде! Ул,үз күзләренә үзе ышанмыйча, борыны белән күккә чөя-чөя, пыр туздырып, җир казырга кереште. Казый торгач, аннан зепелдәвек канатлы зур яшел коңгыз да актарып чыгарды. Нәкъ үз урманындагыча! Димәк—ул иректә! Сөенеч—зур көч икән, ул мыркылдый-мыркылдый энәләрендәге тузанны какты. Аның хәзер урманга чабасы, ятим калган җиде баласы һәм ялгыз әтиләре янына ашыгасы килде... Ләкин юлы бик кыска булып чыкты: әлеге урман туфрагы буй җитмәслек рәшәткә белән уратып алынган иде. Бәлки, эзләнә торсаң, керпе сыярлык кына юлы табылыр да, тик анда—рәшәткәнең теге ягында, шомартып җәелгән чем-кара таш юл, хәвеф-казадан качып котылырлык куе куаклыклар да,һич югы карчыгадан котылыр өчен посып калырлык кулагә дә күренми. Ә иң хәтәре—таш урамда килбәтсез нәмәрсәләр үкерүе,теге егеткә охшаш кешеләр йөренүе. Димәк,караңгы төшкәнне көтәргә туры килә... Ул әрекмән яфрагы астына яшеренеп җиргә елышты. Бертоташтан ярты гомерен йоклап үткәрә ала торган җан иясе өчен әлеге тынычлануны йокы дип атасаң күбрәктер,черем итү генә бу—аның да иң кыскасы...

Егет,кызның өйгә кермәслеген белепме,әледән-әле балконга чыгып чәчәк түтәлен күзәтте, дөресрәге—кызның килүен көтте... Ә бер чыгуында ни күрсен—чәчәк түтәле актарылган,керпедән җилләр искән! Димәк,сиздерминтми генә кыз алып киткән.

Башка вакытта егет өченче кат кына дип тормас,лифт көтәр иде,бу юлы баскычлар буйлап йөгереп төште. Алай ук ашыгасы калмаган икән,кыз бакча янында иде әле,куллары буш.

—Кая соң ул? Мине юри чакырдыңмы?—диде кыз,бөрчек-бөрчек кутырлар белән сипкелләнгән сул яңагын каплап.

Кызны күрүгә,җикеренер өчен тирән итеп сулыш алган иде егет, кирәге чыкмады.

—Эт алып китте аны,—диган булды.

Кызның күзләре йомылды,иреннәре тартыша башлады.

—Җылама! Ерак китә алмагандыр. Һәм ул, зәһәр сызгырып, туп тибеп йөргән малайларга дәште:

—Керпе күтәреп киткән җан әсәрен күрмәдегезме?!

Тегеләр җавап бирәсе урынга, тупларын онытып егет белән кыз янына өерелделәр.

—Алайса, исән?—диде кыз, елмаюын яшерә алмыйча.

—Кем белгән инде аны.—Егет рәшәткәне атлап чәчәк түтәле тирәли эзләнергә кереште. Малай-шалай, артык якын килергә куркып кына, егетне күзәтте, мажара көтте...

Мажара, чәнечкеле йомгакка әверелеп, әрекмән яфрагы астында ята иде. Егет аны кулына алырга уйламады да, аяк очы белән типкәләп тәгәрәтеп китерде.

—Сатам, кайсыгыз ала?—диде егет.

—Мин,—диде тупны алып килгәне.

—Ун тәңкәсе кесәмдә, әтидән сорасам, тагын өсти.

—Аукцион!..—диде егет, алыш-бирешне уенга борып.—Ун

сум—бер, ун сум—ике...

Малайлар муен күтәрә алмаслык булып авырайган башларын аска иделәр.

—Берегезгә дә юк!—диде кыз өзгәләнеп,—үзем алам!

—Акчагамы?—диде егет, башкаларның да көлгәнен көтеп.—Шушы шаһитлар алдында: "Яратам!" дип бер әйтсәң, керпе—синеке.

Малайлар кызның дәшми торуына хәйран калды: вәт җүләр кыз, бушлай керпе бирәм дип торганда... Сорасын иде ул менә, алардан—хор белән яңгыратып: "Яратабыз",—диярләр иде.

—Юк!—диде кыз.

—Юкмы?!—егет кесәсеннән зажигалка алып кабызды, газдан яна торган икән, ялкынын зур итеп ачты. Сул кулы белән керпене бер энәсеннән күтәреп уң кулындагы ялкынга якынайтты.

—Тимә!.. Яратам!!!

Бу изге сүзне ничә төрле мәгънәдә әйтергә мөмкин икән...

—Күрдегезме, лампочка борыннар, апагыз мине өзелеп ярата...—диде егет шамакайланып,—ә хәзер сыпыртыгыз моннан, юкса кулымда ут уйнап тора.

Малайлар, керпе гамен тиз генә оныта алмасалар да, туп артыннан йөгерешергә мәҗбүр иделәр. Егет аларның ераграк китеп таралышканнарын көтте. Аннан соң башындагы кепкасын салды. Иләмсез озын козыреклы зәңгәр кепка өч яшьлек керпе өчен тап-таман гына иде.

—Кара син бу аяклы кактусны, нәкъ минем баш чаклы икән.

—Әйткәч, керпе синеке, дидең...

—Яратам, дигән сүзең ышандырмады мине.

—Инде кая алып киттең?

—Зоомагазинга. Сатам мин аны, ичмасам сигаретлык акча тияр. Артымнан йөрмә!

Сәер хәл, әмма кыз калмады, киресенчә, үҗәтләнеп тагылды. Кимсенүләр, рәнҗүләр баштагы мәлне генә кыен икән ул, ә бер ияләнгәч, исең дә китми, әрсезләнәсең... Кешенең асылы шулайдыр: коры күлмәгенә сыңар тамчы яңгыр тамса, кабаланып ышык урын эзли башлый, әгәр ул ачык кырда яңгырга юлыкса, киемнәрем җебеп тәнемә ябышты дими, юлын дәвам итә.

"Зоомагазин"да җәй көне кеше азрак була, һәркем табигать кочагында—тоткындагы җәнлекләр, кош-кортлар белән күңел юатыр чак түгел. Сатучы ханым кереп-чыгып йөргәннәргә игътибар итәргә дә теләми, син ул бала-чаганы сатып алыр өчен керә дип беләсеңме? Каникулның соңгы көннәрендә шәһәр эчендә "кысылып" калганнары "Зоомагазин"ны "зоопарк" итә. Өендә мәче асрарга да курыккан мещаннар өчен күз явын алырлык нәрсәләр бар монда...

Кыз әллә ник ошатмады бу кибетне. Моңарчы кереп күргәне юк иде—эче тулы сагыш икән моның... Әнә, кенәриләр сайрый-сайрый саргаешып беткән. Африкадагы кардәшләрен сагынып тутый кошлар көн ягына баккан. Диңгезен оныткан бәләкәч дуңгызлар чөгендер кимерә. Тимерчыбыктан эшләнгән

ялтыравык читлектә сувенир кебек ак тычканнар, бүрек чаклы ялгыз ташбака ята... Аквариумны исә, кибетнең бер ягына стена итеп, баскычлап өйгәннәр. Йөзәрләгән микрокомпрессор ясалма балыклар өчен һава өрдереп тора. Ә бу якта сатылырга дигән буш читлекләр, заводның үзеннән, сыйфат билгесе сугып, калын кәгазьгә төреп пөхтәләп китерелгән. Нindиләре генә юк—кечкенәсе, зуррагы, тагын да зуррагы, хәтта кеше сыярлыклары да бар! Хәер, бу кибет үзе дә зур пыяла читлеккә охшатып салынган.

—Керпе сатам арзанга гына,—дип башлаган иде егет.

Сатучы ханым балыкларга җим сибеп йөргән җиреннән тукталып калды.

—Апа, ала күрмәгез зинһар, ул аны урманнан урлап апкайтты,—дип, кыз кенәриләрне сайравыннан туктатты.

—Керпе, дим, сатам.

—Урман җәнлекләрен товар итәргә рөхсәт кәгазебез юк.

—Күп сорамыйм, арзанга гына...

—Бар әле, баш авырттырып йөрмә, гарык бүген, илле мең үрдәк саттык.

Кошлар гына сайрашып торырга тиешле кибеттә әйткәләшү ишетеп, чаршау артыннан бер агай ишелеп төште.—Өстендәге кара халаты ерткаланган, чәче керпе сыман.

—Кая, нәрсә? Керпеме? Күрсәт, аягы бар микән?—Керпе агайның кулына күчте.—Тәк, әпәйт тәки корткычлык. Син, малай актыгы, боларның особый исәптә икәнен беләсеңме?! Кызыл китапның иң беренче битендә алар хәзер. Анда әйтелгән: Даурск керпеләренә кагылырга ярамый, сан ягыннан бик нык кимеделәр, диелгән. Шушы кәгазьгә адресыңны яза тор, хәзер мин сиңа Кызыл китап алып чыгам.—Һәм агай ашыкмыйча гына чаршау артына кереп чыкты. Аның уенча, егеткә кибеттән чыгып качарга вакыт җитәрлек иде.

—Ә син ник качмыйсың?—диде агай ялгыз калган кызга.

—Сез алдашасыз,—диде кыз үҗәтлектән усаллыкка күчеп.—Даурск керпесе Биектау урманында яшәми. Аны оясында ятим балалары көтәдер. Бирегез, илтеп куям.

—Мена монысына рәхмәт. Миңа үпкәли күрмә тагын, егетең белән бүлешә алмаганыгыз өчен генә артисләнүем. Урманга, дим, бүген өлгерерсең микән?

—Өлгерәм, өлгерәм. Көн озын әле.

Керпене кыйгач яулыгына төреп алгач, кыз сөенеченнән әлеге агайга рәхмәт әйтергә дә онытты.—Теге егет минем егетем түгел, мин аны куралмыйм, гомумән, икенче мәктәпкә күчәм әле, дип тә өстәмәкче иде, ярар, әйтеп тормады инде.

Электр поездына утыргач, кыз баштарак, эче пошып, гел тәрәзәдән як-ягына карангалады, мотоцикл белән кемдер куалый чыгар кебек тоелды аңа. Поезд, кызның күңелен тойгандай, тизлеген арттырды.


Күпме генә эзләсә дә, кыз теге аланны таба алмады. Инде күк гөмбәзе йолдызлар кабынганны көтә. Агач арасында күләгәләр күбәйде—арттан кемдер ияргән, ә алда кемдер сагалап торадыр шикелле. Тирә-як шом белән тулды. Урман эче көнне төн белән алыштырырга әзерләнә иде.


Артык эзләүдән мәгънә юк. Кыз керпене җиргә куеп бераз читкәрәк китеп басты.

Ә керпе озак көттермәде, яшел читлеккә охшаса да урманның игелегенә ышанды, тиз арада язылып, тирә-юньне үрелеп-үрелеп иснәде дә күз алдыннан юкка чыкты... Аңа әле таң атканчы күп нәрсәләргә өлгерәсе: әтиләрен эзләп табасы, җиде баланы имезәсе, куркыныч турында кисәтәсе, тамак туйдырасы һәм, ниһаять, тагын чишмә буена төшәсе бар. Ә иң мөһиме—ояны күчерәсе бар. Ояны күчерәсе, урман төпкеленә, кешеләрдән ераккарак...



*Бу шигырьне язучы кыз мин булам—Алсу Нургатина. Аксубай районының Иске Ибрай авылында яшәп ятмыш. 9 А сыйныфында укыйм. Китаплар укырга бик тә яратам. Хыялым—журналист булу.**





## *Куен дәфтәренә*

**Мәхәббәттә сагыш сөенеч белән гел янәшә була.**

**Үсмер егетләр юньсез киңәшләрне яратып тыңлый.**

*Публий*

**Бушлай килгән нәрсә кайчакта аеруча кыйммәткә төшә.**

*А. Эйнштейн*

**Мәхәббәттән курку—тормыштан курку. Тормыштан курыккан кеше исә—3/4 кә үле кеше ул.**

*Б. Рассель*

**Дустыңны мактаганда үзеңне мактыйсың.**

**Дуслары булган кешенең дусты юк.**


*Фукидид*

**Үткәндә матур мәхәббәте булмаган кеше—кызганыч. Ләкин шундый мәхәббәте булып та саклый алмаган кешеләргә караганда аңа биниһая җиңел. Чөнки ул мәхәббәтнең татлыдан татлы кичерешләрен белми, чөнки ул мәхәббәтнең тетрәткеч бәхетеннән гафил.**

*Ш. Хөсәенов*

* Алсу да, Камил абыйсыннан күрмәкче, үзенең «яшь чактагы» фотосын җибәргән. «Хәзер фотога төшәргә яратмыйм», — ди. Бу яшьтә кызлар көзгедәге сурәтләреннән гел кимчелек кенә эзлиләр шул!

## «Мәдәният» чайнворды




1. Автор имзасы.
2. Хыялый әсәрләр язучы.
3. «Мокамай» поэмасының авторы.
4. Бас тавышлы бу мәшһүр җырчыга Казанда һәйкәл куелган.
5. Г. Бәширов романы.
6. Симфоник оркестрда әйдәп баручы музыка коралы.
7. Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе Абрек...
8. «Язгы җилләр» романы авторы.
9. Яшьләр журналы.
10. Мембраналы бәрмә музыка коралы.
11. М. Җәлилнең көрәштәше, шагыйрь.
12. СССРның халык артисты, тәрҗемәче.
13. Шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе.
14. «Соңгы хат» мелодрамасы авторы (исеме).
15. Җырчы Фәхри Насретдинов тавышы.
16. Язылган яки әйтелгәннәргә кыскача йомгак.
17. «Ак дулкыннар», «Синең эзләр» җырлары авторы, композитор.
18. Парлы бал биюе.
19. Актерга пьеса сүзләрен әйтеп торучы.
20. «Казан утлары» журналы баш мөхәррире, халык шагыйре (исеме).
21. Кавказ халкының җитез биюе.
22. Кәрим Тинчурин пьесасы.
23. «Этил суы ака торур» романы авторы (исеме).
24. Тыныш билгесе.
25. Операда ялгыз җыр.
26. СССРның халык рәссамы, академик.
27. Сәнгать техникасын яки эш-һөнәрен камил белүче зур оста.
28. Китап текстының өске өлешендәге бизәк.
29. «Сары чәчәк ата көнбагыш» драмасы авторы (исеме).

Төзүчесе–**З.ХИСАМОВ,**
*Буа.*

***Җаваплары 182 биттә.***

* * *

Исәнме, "Ак җилкән"!

Синең чыкканыңны көтә-көтә, әбием әйтмешли, көтек булдым инде... Журнал килә, әти дә, әни дә рәхәтләнеп укыйлар, мин көткән нәрсә генә һаман юк та юк.

Мин маҗаралар яратам, ләкин алар хәзерге сериаллардагы кебек булмасын, күңелгә-җанга да нәрсәдер бирсен, мине каядыр дәшсен иде. Әллә үзем уйлап чыгарып язасы инде.

Тормышым матур да кебек, ләкин чын тормышым әле башланмаган да бугай. Менә иртәгә яки берсекөнгә нидер булыр да, мин дүртка-бишкә укучы "тәртипле" Лилиядән чын Лилиягә әйләнермен кебек.

Әти дә, әни дә, абый да (ул миннән 12 яшькә олы!) мине гел бәләкәйсетәләр, алар өчен мин һаман да шул бакчага йөргән Лилия бугай әле.

Абыйның китаплары арасында Жюль Верннның "Капитан Грант балалары"н күреп алдым да, укып бетергәнемне сизми дә калдым. Сизми калдым дип, өч көн рәттән укыдым инде мин аны. Дәресләрне дә юньләп әзерли алмадым, математичка белән химичка "өчле" куйдылар.

Мин үзем дә хыялда каядыр сәяхәткә чыгып китәм. Китәм дип, китәргә телим, ләкин хыялда гына да тәмам чыгып китә алганым юк әле, чөнки кемнәр белән чыгасымны белмим. Безнең класс кызлары белән юлга чыгарлык түгел, аларга бөтенләй башка нәрсәләр кирәк шул, ә малайлар...

Берсе белән хәтта Антарктидага да барыр идем мин, бернинди салкынын да тоймас идем. Ләкин ул да шул компьютерына кадалып утырудан башканы белми.

Әлләниләр язардай булып тотынган идем дә, берни дә яза алмадым!

Әллә нинди генә бер кыз инде мин шунда, соңгы вакытта үземне үзем дә аңлап бетермим әле... Кая барып чыгар инде бу Лилия дигән кызый!

**Лилия М.**
**Чаллы кызы.**

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*

---

***181 биттәге чайнворд җаваплары:***

1. Автограф; 2. Фантаст; 3. Такташ; 4. Шаляпин; 5. «Намус»; 6. Скрипка; 7. Абзгильдин; 8. Нәҗми; 9. «Идел» ; 10. Литавра; 11. Алиш; 12. Шамуков; 13. Вәлиев; 14. Вахит; 15. Тенор; 16. Резюме; 17. Еникеев, 18. Вальс; 19. Суфлёр; 20. Равил; 21. Лезгинка; 22. «Американ»; 23. Нурихан; 24. Нокта; 25. Ария; 26. Якупов; 27. Виртуоз; 28. Заставка; 29. Аяз.

## Фатих Кутлу



Татарстан Язучылар берлегенең географик колачы, масштабы зур: аның әгъзалары Татарстаннан тыш хәзерге Россиянең байтак төбәкләрендә дә шактый—Мәскәү, Уфа, Чиләбе, Ульян, Перьм, Төмән, Ижау, Саранск һ. б. Чит илләрдә дә юк түгел алар—Англиядә, Казакъстанда, Кырымда, Төркиядә... Язучылар берлеге тарихында сирәк күренеш: без күптән түгел төрек милләтеннән булган каләмдәшне үз сафларыбызга алдык. Ул—Фатих Кутлу. Фатих Кутлу 1975 елны Төркиянең Кахраманмараш шәһәрендә туган. Үткән гасырның 90 нчы елларыннан башлап аның тормышы Татарстан белән бәйле. Ул—1999 елны Алабуганың педагогия институтын тәмамлый. Анда, өлкән укытучы буларак, студентлар укыта, сонрак, Казан мәктәпләрендә төрек теленнән дәресләр бирә. Татар кызы Гөлшатка өйләнеп, балалар үстерә.

Без аны татар-төрек әдәбиятларының арадашчысы итеп беләбез. Ул А. Гыйләжевның «Өч аршын җир» повестен, Р. Вәлиевнең «Васыять» җыентыгын, байтак татар шагыйрьләренең әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә итте. Шул ук вакытта Ф. Кутлу кайбер төрек әдипләренең дә әсәрләрен татар укучысына ирештерде.

Татарстан Язучыларының 20 нче март ахырында үткән идарә утырышында, Берлекнең Кабул итү коллегиясе карары нигезендә, Фатих Кутлу (тәкъдимнамә бирүчеләр—Хатыйп Миңнегулов, Разил Вәлиев, Искәндәр Гыйләжев) Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.



*Ватан сугышында катнашкан бер төркем татар язучылары. Беренче рәттә (сулдан уңга)—Әдип Маликов, Сибгат Хәким, Мәхмүт Хөсәен; икенче рәттә—Шәйхи Маннур, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй, Вадим Земной; өченче рәттә—Мөнир Мазунов, Әхмәт Исхак, Шәрәф Мөдәррис. 1948 ел.*



*Җитмеш елдан артык әдәбият-сәнгать, фән-гыйлем, гомумән, китап үзәге булган данлыклы Матбугат йорты. Хәзер ул тузган бина исәпләнә, буш тора, алдагы язмышы безгә нәмәгълүм. Бауман, 19. Рәсем 1989 елда төшерелгән.*



*Очрашулар еш булган заманнар!.. Сулдан уңга—Шәриф Биккол, Хәсән Туфан, Зөһрә Ибраһимова, Сергей Васильев. 1976. Уфа.*



*Кардәшләрне каршылау күренеше. Башкортстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре. 1988 ел. Мәләвез.*



*Иҗатларын балалар әдәбиятына багышлаган язучылар—Ләбибә Ихсанова, Җәүдәт Дәрзаманов. 2001 ел.*



*Шагыйрь Нури Арсланов (сулда) һәм язучы Фаил Шәфигуллин. 1979 ел.*

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2009 елның икенче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. «Казан утлары»ның индексы **73210**. Татарстанда ярты елга язылу бәясе физик затлар (аерым кешеләр) өчен **254 сум 10 тиен**, юридик затлар өчен **283 сум 80 тиен.**

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

**Ф.СП-1**

Почта России

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ **журнал** | **73210** (индекс издания)

***"Казан утлары"***

(наименование издания) | количество комплектов:

на 20 09 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал | **73210** (индекс издания)

***"Казан утлары"***

(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___руб.___коп. | количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___руб.___коп. | |

на 20 09 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

# ҺӘР КЕШЕ УКЫСЫН ИДЕ

«Казан утлары» журналының 4нче санында **«Мәкруһлар»** язмасының ахыры басылып беткән. Ул инде узган ел ноябрь аенда басыла башлаган иде. Бик гыйбрәтле язма, мин аны һәр татар зыялысына, галименә, милләтчесенә, дин әһеленә укып чыгарга тәкъдим итәр идем!

XX гасыр урталарында Зөя якларында көчләп чукындырганнан соң янадан исламга кайткан татарларның башыннан үткән ачы язмыш тасвирлана анда. Аларның күбесен сөрген, төрмәләр, Себер көтеп торган... Әмма бу татар ирләре Себер китсә киткән, диннән китмәгән! Хатыннары да алар артыннан үз теләкләре белән жәяүләп Себергә чыгып киткәннәр.

Элек Турухан крае дип аталган, хәзер Красноярск крае булган бу якларда хәзер дә кырыклап татар авылы бар, дин өчен Себер киткән татарларның нәселе яшәп ята монда. Аларның кайберләре белән минем үземнең дә очрашканым булды.

Бу язманың авторы—**Тәфкил Вафин**, ул үзенең Себергә сөрелгән Сабит бабасы турында архив материалларына таянып шушы уникаль хезмәтен язган. Аны ничек тә урыс теленә да тәржемә итәсе иде! Һәм татарчасын да, урысчасын да аерым китап итеп бастырып чыгарасы иде. Мондый хезмәтләр көн саен тумый, автор моның өстендә алтмыш ел буе эшләгән.

Рәхмәт, Тәфкил ага, мәңгелек хезмәт язып калдыргансыз! Моның буенча әле романнар, драма әсәрләре язылыр, фильмнар төшерелер, иншаллаһ!

Милләткә гыйбрәт булсын өчен, шушы хезмәттән бер авыл хатынының төрмәдәге иренә язган хатын мисал итеп китерәм: «Сез ки хәләл жефетем Фәтхуллага без хәләл хатыныннан—Гарфижамалдан күптин-күп сәламнәремне язам. Фәтхулла, жаным, үтенеп сорыйм синнән, Гайфулла кебек үзенне чукындырып хурлыкка кала күрмә. Бөтен авыл халкы сина кяфер дип әйтер. Битенә төкererләр. Әгәр син урыс буласың икән, ул вакытта бу якты дөньяда чыннан да ни өчен яшәргә? Бу якты дөньяда яшәүнең кызыгы калмый. Әгәр дә сине Себергә жибәрәләр икән, мин дә синнән калмыйм, синең белән бергә барам. Артыннан калмыйм. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте зур, ташламас. Ичмасам, кызыбыз авыл халкы каршысында хур булмас. Минем хатыным бар дип әйт. Өмет баглыйм сина, Фәтхуллам!»

Бу юлларны еламыйча укып булмый.

Урыныгыз жәннәттә булсын, газиз милләттәшләрем!

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА**

# İçtimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### КАЛАЛАРГА БАШ КАЛА

Апрельнең беренче көннәрендә мәркәзебез Казан рәсми рәвештә Россиянең өченче башкаласы дип танылды. Роспатент башкалабызга шул турыда товар билгесен тапшырды.

Мәгълүм булганча, инде Казаныбызның меңьеллыгын билгеләп үткән тантаналарда ук элеккеге президент Владимир Путин Татарстан мәркәзен «Россиянең өченче башкаласы» дип атаган иде. Бу исем берничә тапкыр халыкара күргәзмәләрдә дә үзен аклады.

Мәскәү, Санкт-Петербург кебек эре шәһәрләр янәшәсендә Казан лаеклы урын били, сәясәт һәм икътисадта, милләтара һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләүдә әһәмиятле роль уйный.

«Әлеге исемгә ия булу Евразия дәүләтләре белән элемтәләрне ныгытуга Татарстан кертккән өлешне тану ул,—диде Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Би-Би-Си» радиосына биргән әңгәмәсендә.—Безнең өчен бу абруй да, Казанның Европа дәрәҗәсендәге тормышка омтылуын күрсәтү мөмкинлеге дә».

Россиянең өченче башкаласы булырга дәгъва кылган тагын бер шәһәр—Түбән Новгород исә «Идел буе башкаласы» исемен йөртәчәк.

### ҖИҢӘБЕЗ, ТАНЫЛАБЫЗ!

12 апрель Татарстан спорты тарихында онытылмас көн саналырга лаек: ул көнне Казанның «Ак Барс» хоккей командасы Континенталь хоккей лигасы кубогын, икенче төрле әйткәндә, Гагарин кубогын яулады. Татарстанны дөньяга танытуда зур сәхифә бу. Шулай итеп, хоккейчылар да футболчыларның батырлыгын кабатлады. Башкала командаларының икесе дә—«Ак Барс» та, «Рубин» да Россия чемпионы хәзер.

### «ЕФӘК ЮЛЫ» БЕЗДӘН БАШЛАНА

Быелның 5 сентябрендә «Ефәк юлы-2009-Дакар сериясе» дип аталган халыкара авторалли Казан шәһәрендә старт ала. Мондый югары дәрәҗәдәге ярыш Казанда әле беренче генә тапкыр уздырыла. Раллида 100 җиңел һәм 50 йөк автомобиле катнашыр дип фаразлана. Оештыру комиссиясе әгъзаларын да кушып, Казанда 900ләп кунак көтелә. «Раллиның маршруты инде 90 процентка расланган»,—диде «КамАЗ-Мастер» командасы директоры Семен Якубов. Старт 5 сентябрьдә Казанда бирелеп, финиш—13 сентябрьдә Төркмәнстанның Ашхабад шәһәрендә булачак. Ралли Татарстан, Оренбург өлкәсе, Караком чүле һәм Казакъстан шәһәрләре аша узачак. Гомуми маршрут—4350 чакрым. Ярышта катнашучылар Казанда 1 сентябрьдә җыйнала башлаячак. Ралли барышында аларга 5 самолет, 8 вертолет хезмәт күрсәтәчәк (ТВ-трансляция, медицина ярдәме һ. б.). Барлык автомобильләр һәм башка техника «Ривьера» отеле территориясендә тупланачак, матбугат үзәге дә шунда урнашыр дип көтелә.

### КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

27 мартта—Бөтендөнья театр көнендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Яңа татар пьесасы—2008» конкурсына йомгак ясалды. Бу бәйге инде 6 нчы ел рәттән үткәрелә һәм быелгысына 55 эш тәкъдим ителгән иде.

Мәртәбәле жюри әгъзалары шулар арасыннан иң яхшыларын сайлап алды.

Жюри рәисе Миркасыйм Госманов иң элек 6 ел дәвамында барган конкурска йомгак ясап: «6 ел эчендә конкурска 335 әсәр тәкъдим ителде,—диде.—Алар арасында театр сәхнәләреннән төшмичә уйнала торганнары да байтак. Шушы еллар эчендә 55 әсәр махсус бүләккә лаек булды Алар арасыннан 20гә якын әсәр бүгенге көндә Татарстанда һәм аннан читтәге 31 сәхнәдә уйнала. Соңгы елларда 35 яшькә кадәрге авторларга аерым номинация билгеләнде. Былтырдан балалар өчен язылган сәхнә әсәрләре өчен дә аерым урын бирелә башлады. Әсәрләр арасында жанр һәм форма ягыннан яңалык булып торганнары да бар. Ул номинациягә «Башка формат» дип исем бирдек».

Быел жюри конкурста катнашкан 7 әсәрне билгеләп үтте.

35 яшькә кадәрге авторлар арасында Башкортстаннан Дилә Мөхәррәмованың «Без үскәндә биш кыз идек» пьесасы иң яхшысы дип табылды.

Туфан Миңнуллинның «Читлек» пьесасы балалар өчен язылган әсәрләр арасында җиңү яулады. 3 нче дәрәҗәдәге бүләк исә

«Татарча өйләнү» пьесасы өчен Ркаил Зәйдуллага тапшырылды. 2 нче урынга «Ай, без идек, без идек» пьесасы өчен Чаллы шәһәреннән Зөләйха Минһаҗева лаек булды.

Иҗади эзләнү, яки «Башка формат» номинациясендә Сөмбел Гаффарованың «Аэропорт. Кораб» пьесасы иң үзенчәлекле әсәр дип тәгаенләнде.

Беренче урын исә «Туганнар-тумачалар» пьесасы өчен яшь драматург Илгиз Зәйниевкә бирелде.

Татарстан Мәдәният министрлыгы үзенең махсус бүләген «Сәйдәш вальсы» пьесасы өчен Фәнәвил Галиевкә тапшырды.

Үткән елгы ярышка йомгак ясау белән бергә, инде бүгеннән башлап киләсе ел өчен шундый ук конкурс игълан ителә. Авторлар моңа кадәр беркайда да басылмаган пьесаларын икешәр данәдә псевдоним белән тапшырырга тиеш. Исем-фамилиясе, үзе турында мәгълүмат аерым конвертта җибәрелергә тиеш. Конкурс ике этапта узачак. Җиңүчеләргә бүләкләрне киләсе елда Халыкара театр көнендә тапшыру каралган. Соныннан аларның пьесалары махсус җыентыкта бастырылачак.

## ЯҢА МИНИСТР БИЛГЕЛӘНДЕ

17 мартта ТР Президенты Минтимер Шәймиев указы белән, Мәгариф һәм фән министры вазифаларына КДУ профессоры Альберт Гыйльметдинов билгеләнде.

Альберт Харис улы (27.07.1956) Казанда туган. Физика-математика фәннәре докторы (1999).

А. Гыйльметдинов 1982 елдан КДУда эшли. 1994 елдан аналитик спектроскопия лабораториясе мөдире. Бер үк вакытта (2000 елдан) гомуми физика кафедрасы профессоры. 2007-2008 елларда ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары булып эшли.

Профессор А. Гыйльметдинов дөньяга танылган белгеч. Ачышлары өчен Atomic Spectroscopy Award халыкара премиясе (1995), заманча спектроскопиягә нигез салучы Йоханус Маркус Марси исемендәге медаль (1998) белән бүләкләнде.

## «ЕЛ ТАТАРЛАРЫ» БИЛГЕЛЕ

Һәр елны уздырылучы «Ел татары» бәйгесенә йомгак ясалды. Быел «Ел татары» исеменә төрле номинацияләрдә Гөлнара Сәмитова (спортчы), Рената Литвинова, Альберт Әсадуллин (артистлар), Әлбир Крганов (Чуашстан республикасы мөфтие), Миркасыйм Госманов (академик) кебек шәхесләр, Бөтендөнья татар яшьләре форумы лаек булды. Җиңүчеләр исемлегендә «Матбугат» сайтын булдыручы Данил Сәфәров та бар. Мәскәүдә яшәүчеләр үз бүләкләрен алдылар инде. Тиздән башкалабызда Казан һәм Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче лауреатларны бүләкләячәкләр. «Ел татары» бәйгесен «Татарлар» бөтендөнья татар порталы оештыра. Җиңүчеләр интернетта тавыш бирү юлы белән билгеләнә.

Моннан ике ел элек журналыбызның баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин да бу дәрәҗәгә лаек булган иде.

## ИНСТИТУТКА—АКАДЕМИК ИСЕМЕ

Россия Мәгариф академиясенең «Казан һөнәри белемле педагогикасы һәм психологиясе институты» учреждениесенә Россия Мәгариф академиясе академигы Мирза Мәхмүтов исеме бирелде.

2008 елның мартында арабыздан киткән Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтовның исеме педагогия фәне һәм мәгариф практикасы тарихына проблемалы укыту концепциясенә нигез салган күренекле галим, һөнәри белем бирүдә инновацион технологияләрне керткән талантлы оештыручы, СССР Педагогика фәннәре академиясенең һөнәри-техник педагогика фәнни-тикшеренү институтын оештыручы һәм аның беренче директоры буларак кереп калды.

Мирза Мәхмүтов 18 ел дәвамында Татарстан АССРның Мәгариф министры вазифасын башкарды, 20 ел буе Республика Югары Советы депутаты булып торды. Ул—Татарстан Фәннәр академиясен оештыручыларның берсе, аны гамәлгә куючы академиклар һәм президиум әгъзалары сафында булды.

М. Мәхмүтов житәкчелегендә 43 кандидатлык һәм 11 докторлык диссертациясе яклады. Ул—500дән артыграк фәнни эш авторы. Аның хезмәтләре БДБ халыкларының күп кенә телләренә, шулай ук гарәп, инглиз, немец, испан, кытай, фин, болгар телләренә һ. б. тәрҗемә ителгән.

Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов шактый еллар «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы булып та торды.

## «СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫНДА ЯҢА БАШ МӨХӘРРИР

«Сөембикә» журналына баш мөхәррир итеп Ләйсән Рәфикъ кызы Юнысова билгеләнде.

Л. Юнысова 1994 елны Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый. Студент чакта ук «Ялкын» журналында эшләп ала. Аннары Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтында аспирантурада укый. Казан милли-мәдәни үзәгендә хезмәткәр, «Татэнерго» ачык акционерлык җәмгыятендә матбугат үзәгенең сектор мөдире була.

Ул—«Кирелегем» / «Категория состояния» дигән, татар һәм рус телләрендә чыккан шигырь китабы (2007) авторы.

## ТУКАЙГА—ЧӘЧӘКЛӘР

Апрель—сөекле шагыйребез Габдулла Тукайны дөньяга бүләк иткән һәм аны, татар халкының бәгыреннән өзеп, бакыйлыкка алып киткән ай. Күркәм гадәт буенча, Казанның Яңа татар бистәсе зиратында быел да хәтер янарту мәрәсиме үткәрелде. Анда әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, мәдәният хезмәткәрләре, дин әһелләре һәм шигырь сөючеләр катнашты. Хәтер җыенына килүчеләр алдында Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов, Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе, шагыйрь Разил Вәлиев, Мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигъмәтуллина, Тукай җәмгыяте рәисе, профессор Хатыйп Миннегулов, шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Лена Шагыйрьҗан, Зиннур Мансуров, Г. Тукайның Казандагы әдәби музее директоры, шагыйрь Рамис Аймәт, композитор Ренат Еникеев, актер Әзһәр Шакиров һ. б.лар чыгыш ясады.

Тукай каберенә чәчәкләр куелды. «Хәтер» мәчетенең имам-хатыйбы Харис хәзрәт Салихҗан шагыйрь рухына дога багышлады.

## ӘДИП ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казанның 17 нче татар гимназиясе базасында татар әдибе, галиме, публицисты һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тормышына һәм иҗатына багышланган республика күләмендәге фәнни-гамәли конференция узды. Әлеге җыен язучының тууына 122 ел тулу уңаеннан оештырылды.

Конференциядә мәктәп укучылары һәм укытучылар, студентлар, Татарстан Республикасы лицейлары, гимназияләре, вузлары педагоглары, фән һәм мәдәният эшлеклеләре катнашты. Җыен вакытында татар һәм рус филологиясе, тарих һәм мәдәният, музей педагогикасы, балалар һәм яшьләр өчен иҗат эшләре буенча секцияләр эшләде. Иң яхшы чыгышлар исә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы дипломнары белән бүләкләнде.

## КАҺАРМАН ШАГЫЙРЬ ТУГАН ҖИРДӘ

Каһарман шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 100 ел тулуны әдипнең туган авылы—Башкортстан Республикасы Бишбүләк районы Ает мәктәбендә зурлап билгеләп үттеләр. Бу тантанага Казаннан да кунаклар кайтты. Укучылар һәм укытучылар алдында Фатих Кәримнең кызы Ләйлә Кәримова, якташы, «Азатлык» радиосының Казан студиясе мөдире, Россия татарларының милли-мәдәни мохтарияте Советы рәистәше, үзе дә шушы Ает мәктәбен тәмамлаган Римзил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев чыгыш ясадылар. Укучылар Ф.Кәримнең шигырьләрен сөйләделәр, җырларын җырладылар. Шулай итеп, Бәләбәй шәһәрендә үткәрелгән «Илһам чишмәләре» дигән төбәкара шигырь фестиваленең рухы Аетка күчте. Бу фестивальдә быел да Фатих Кәрим исемендәге премия лауреатлары игълан ителде. Алар арасында Ләйлә Кәримова да бар. Ул бу бүләккә каһарман шагыйрьнең истәлеген мәңгеләштерү һәм иҗатын пропагандалауда зур хезмәт куюы өчен лаек булды. Ләйлә Фатих кызы премияне Ает мәктәбенә тапшырды.

## ЖУРНАЛИСТЛАР КИҢӘШ-ТАБЫШ ИТӘ

Әлмәттә Татарстан Журналистлар берлеге президиумының күчмә утырышы булып узды. Күренекле галим, педагог, дин эшлеклесе һәм публицист Ризаэддин Фәхреддиннең Кичүчат авылындагы музеенда аның тууына 150 ел тулу уңаеннан фәнни-гамәли конференция белән башланган утырыш аннары Әлмәтнең үзенә күчте. Нефть төбәгендәге журналистлар алдында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, КДУның журналистика һәм социология факультеты деканы Васил Гарифуллин, «Республика Татарстан» газетасының баш мөхәррире Александр Латышев һ. б. чыгыш ясады. Заманында «Вакыт», «Шура» кебек газета-журналларда бүген дә сокланып укырлык публицистика үрнәкләре иҗат иткән Ризаэддин хәзрәт иҗаты белән танышкан каләм ияләре бүгенге журналистиканың ниндилеге, аның үсеш юллары һәм киләчәге турында сүз алып барды.

## ФИЛЬМ ДӨНЬЯ ГИЗӘ

IV Халыкара «Алтын Мөнбәр» мөселман кино фестивалендә приз алган Татарстанның тулы метражлы нәфис фильмы «Өч аяклы ат» (әсәр авторы Айдар Хәлим, куючы режиссеры Нурания Җамали, продюсеры Илһам Сафиуллин) Чаллы концертлар залында, Казан милли-мәдәни үзәгендә, авторның туган авылы Кәркәлетамакта, укыган авылы Олы Кәркәледә (Башкортстан, Миякә районы), фильмда төп рольне башкарган яшь актер Илназ Хәлиуллинның туган авылы Суыксуда (Татарстанның Биектау районы) күрсәтелде.

Меңләгән тамашачылар катнашкан бу очрашуларда фильмда уйнаган күренекле актерлар Әзһәр Шакиров, Ирек Баһманов, Наил Шәйхетдинов, режиссер Нурания Җамали дистәләгән сорауларга җавап бирде, бу сөйләшүләр һәркайда Татарстан кинематографиясенең киләчәге, бүгенге татар сәнгате, мәдәнияте һәм мәгърифәтенең торышы турындагы кызыклы фикер алышуларга әйләнде.

Чаллы хакимиятенең мәгариф идарәсе карары белән «Өч аяклы ат» шәһәрнең балалар сәнгате үзәгендә алдан төзелгән график нигезендә барлык мәктәп укучылары өчен күрсәтелде, фильмнан соң фикер алышу үткәрелде, махсус иншалар язылды, бу иншалар «Көмеш кыңгырау» балалар газетасында басылып барды.

Фильм «Татарстан—Яңа гасыр» каналы буенча да күрсәтелде.

### МӨСЕЛМАН КИНОЛАРЫ

Россия Ислам университетында «Исем кушу», «Никах» һәм «Җеназа» кебек мөселман тәртип-йолаларына багышланган документаль фильмнар циклын төшерү тәмамланды.

Якын араларда әлеге өч фильмны тәкъдим итү булачак. Моннан тыш, мөселман фильмнары проектын дәвам итү дә күздә тотыла. Бу фильмнарны төшерүнең төп максаты—дин кардәшләребезгә тормышта еш кулланыла торган мөселман тәртип-йолалары турында киң мәгълүмат бирү һәм аларны өйрәтү. Фильмнар барысы да режиссер Рәмис Нәҗмиев җитәкчелегендәге профессиональ төркем тарафыннан эшләнгән.

### КИМЕНДӘ—БИШ КАНАЛ

Татарстанда бу ел ахырына һәр кеше телевизордан кимендә 5 каналда тапшырулар карый башлаячак. Узган ел бу мөмкинлектән халыкның 73 проценты гына файдалана ала иде. Кабель телевидениесе белән тәэмин итү 58 проценттан 64 процентка җиткереләчәк. Чыбыклы радио аша 3 программа тапшыруларын (шул исәптән—«Яңа Гасыр») тыңлап булачак.

ТР Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Фәрит Фазылҗанов әйтүенчә, республикадагы Интернет тизлеге буенча Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән нык калыша, ә түләү, киресенчә бермә-бер югары. Интернет хезмәте күрсәтүчеләргә быел Интернет тизлеген 2 мбит/с дәрәҗәсенә күтәрү, түләүләрне киметү бурычы куелган.

### «ТАТАР КЫЗЫ—2009»

Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклаучы, милли йолаларны дәвам итүче кызлар кемнәр алар? «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә узган «Татар кызы—2009» бәйгесендә башкаларга үрнәк булырлык кызларны сайладылар. 7 туташ үзләренең уңган-булганлыкларын, җитез-тапкыр булуларын күрсәтте.

Чынлыкта татар кызы нинди булырга тиеш? Киләчәктә гаилә учагын сакларга әзер булган, шул ук вакытта җәмәгать эшләрендә дә актив катнашучы, сылу, зирәк, моңлы, игымлы, зыялы... Бәйгенең абсолют җиңүчесе Совет районының 125нче мәктәп укучысы Миләүшә Хәмидуллина булды.

«Татар кызы» бәйгесе быел 10нчы тапкыр уздырылды. Башка еллардан аермалы буларак, быелгы чарага үткән елларда җиңгән кызлар да чакырылган иде.

### НОРЛАТЛЫЛАРГА—БҮЛӘК

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы генераль директоры, тарих фәннәре кандидаты Ислам Әхмәтҗанов авылдашларына менә дигән бүләк ясады. «Язмышым минем—Норлат» дип исемләнгән бик затлы, зәвык белән эшләнгән китап дөнья күрде. Буа районындагы Норлат авылы—өч гасыр ярымлык үткәне булган, күренекле шәхесләр биргән данлы төбәк. Китапта авылның үткәне, бүгенгесе тарихи язмаларга нигезләнеп тасвирлана. Авыл тарихын барлау, китаплы булу фикере исә норлатлыларның моннан өч ел элек үткәрелгән җыенында әйтелгән була һәм теләк гамәлгә ашты. Ислам Әхмәтҗанов, авылдашларын кунакка чакырып, яңа гына «табадан төшкән» китапны бүләк итте. Китап шул ук Норлатта туып-үскән «Татспиртпром» берләшмәсе генераль директоры Рәшит Шәйхетдиновның финанс ярдәме белән дөнья күргән.

### ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮ

В. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать академиясенең Казан филиалында «Россиядә сәнгать белемен үстерү перспективалары» дигән фәнни-гамәли конференция узды. Аның башкалабызда үтүе очраклы түгел, чөнки сәнгать училищесы шушы өлкәдә белем бирү буенча Идел буе төбәгенең методик координация үзәге булып тора. Беренче мәртәбә шундый конференция 2000 елда узып, анда бары дүрт училищедан гына студентлар һәм укытучылар катнашкан иде. Быел исә биреге Россиянең 16 төбәгеннән җыелдылар. Шунысын да әйтергә кирәк, башкалабызда Мәскәүнең Суриков исемендәге сәнгать институты филиалы әле беренче елын гына эшли. Аның скульптура бүлегенә быел алты студент кабул ителгән.

Конференциядә Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институты ректоры Анатолий Бичуков чыгыш ясады. Андагы күргәзмәгә уку йортлары студентлары эшләгән 90 картина куелган иде. Аны ачу тантанасында ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

Катнашучылар бүгенге көндә сәнгать белеме бирү турында лекцияләр тыңлаганнан соң, үзара фикер алыштылар, тәкъдимнәрен җиткерделәр.

## БҮЛЕККӘ—15 ЕЛ

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең опера һәм камера музыкасы бүлеге 15 еллыгын билгеләп үтте. Ул бүген дә халык җәүһәрләрен пропагандалау эшен дәвам итә. Моңа Татарстанның халык артисты Р. Маликов, Г. Ибушев, Л. Маслова хезмәтләре дәлил. Алар башкаруындагы халык җырлары, опера һәм романсларны тамашачылар яратып кабул итә. Бүлекнен балалар белән эшләве дә мактауга лаек. Соңгы елларда алар башкаланың нәни тамашачылары белән генә аралашып калмыйча, авылларга, районнарга да еш чыга башладылар.

## КҮРГӘЗМӘНЕ КҮРЕГЕЗ

24 апрельдән 15 июньгә кадәр Дәүләт Көнчыгыш музеенда «Татар шәмаиле: сүз һәм образ» дигән күргәзмә эшләячәк. Экспозициядә пыялада ясалган һәм басма шәмаилләр, рәссамнар Рөстәм Шәмсутов, Владимир Попов, Фирдәвес Гыйрьфанов, Салават Гыйләҗетдинов, Рамил Насыйбуллов, Рөстәм Мөхәммәтҗанов, Васил Ханнанов эшләре урын алачак. Моннан тыш, күргәзмәдә Бакый Урманченың да эшләре, шулай ук Дәүләт Сынлы сәнгать музеенда, шәхси коллекцияләрдә саклана торган шәмаилләр дә тәкъдим ителә.

## БАЯНЧЫЛАР ЯРЫШЫ

Арчаның Г. Тукай исемендәге педагогия көллиятендә Татарстанның халык артисты Рамил Курамшин исемендәге II республика баянчылар бәйгесе үткәрелде. Мәртәбәле конкурста Татарстанның, Россиянең төрле төбәкләреннән дистәләрчә баянчы катнашты. Осталар бәйге шарты буенча икешәр әсәр—Р. Курамшинның баян өчен махсус иҗат иткән бер әсәрен һәм үзе теләгән халык көен башкарырга тиеш иде.

Бәйгедә катнашып, Чаллыдан Айнур Шәрәпов, Гөлназ Мөдәррисова, Фәнис Арсланов, Арчадан Данис Мөхәммәдиев, Шамил Борһанов, Илнур Шәймәрданов, Лениногорскидан Любовь Еграшкина лауреат исеменә лаек булды.

Баянчылар конкурсы киләчәктә ике елга бер мәртәбә үткәреләчәк.

## ШИГЫРЬ ҺӘМ ҖЫР КИЧӘСЕ

12 апрельдә Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында (Павлюхин ур., 73) шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рафис Корбан шигырьләренә язылган җырлардан төзелгән концерт булды. Концертта Татарстанның халык артистлары Рафаэль Ильясов, Георгий Ибушев, Лидия Әхмәтова, Азат Тимершәех, Фәридә-Алсу дуэты, композиторлар Илгиз Закиров һәм Фәрит Хатипов һ. б. катнашты. Концертны Татарстанның халык артисты Рәшит Сабиров алып барды.

## КИТАП БУШЛАЙ ТАРАТЫЛАЧАК


Татарстанда начар күрүче һәм күрү сәләтен югалтканнар өчен дини китаплар нәшер иткәннәр. Аларны «Ярдәм» хәйрия фондының Мөселман китапханәсе чыгарган. «Намаз китабы» һәм «Мөхәммәт пәйгамбәр хәдисләре җыентыгы» китапханә әгъзаларына бушлай таратылачак. Әлегә китаплар рус телендә генә чыгарылган. Әмма тиздән татар телендәге басмалар да дөнья күрергә тиеш. Алга таба Мөселман китапханәсендә намаз вакытлары җыентыгы, зәкят, хаж, Ураза бәйрәме турындагы китаплар да нәшер итәргә җыеналар. Алар «Исламда тәүге адымнарым» исемле сериядә тупланачак.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә: "Иялэр иясе".* Рәссам **Әхсән Фәтхетдинов** эше.

*Дүртенче биттә:* шагыйрь **Идият Аширов**.

# Яңа китаплар




**Ризаэддин Фәхреддин.** Асар. 2 том.— Казан: Рухият нәшр., 2009.—340 б. Тиражы— 2000 данә.

Мәшһүр татар галиме, тарихчы, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» дип аталган дүрт томлы биобиблиографик хезмәтенең икенче томы чыкты. «Асар»ның бу томы 1904-1909 еллар дәвамында Оренбургта М. Кәримов басмаханәсендә нәшер ителгән булган.

«Асар» татар теленә тәрҗемә ителеп, хәзерге әдәби тел кагыйдәләренә яраклаштырылып, шул ук вакытта авторның стиль үзенчәлекләре сакланган хәлдә бирелгән.

«Асар»ның өйрәнү даирәсен киңәйтү максатыннан төп текст шулай ук рус теленә дә тәрҗемә ителгән.

Китапның фәнни мөхәррире—М. Госманов.

Төзүчеләре—И. Гыймадиев, Р. Миңнуллин, С. Баһавиева.




**Энгель Тагиров.** Народ в пути. История Татарстана в контексте мировой цивилизации. Казан: «Мәгариф» нәшр., 2008.—287 б. Тиражы—3000 данә.

Тарихчы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Энгель Таһировның бу китабы югары уку йортларында студентларга укыган лекцияләр тупламасыннан гыйбарәт. Ул анда Татарстан, гомумән, татар тарихын бәян итә. Туган халкының икътисадфәнен, мәгърифәт-мәдəниятен дөнья тәрәккыятенә зур өлеш керткән милләтләр белән янәшә куеп бәяли, фикерләрен фәнни дәлилләр белән раслый. Китап һәркемгә аңлаешлы, үтемле тел белән язылган. Мәктәпләрдә, югары уку йортларында укучылар өчен бу китап фәнни-методик хезмәт буларак әһәмияткә ия.



**Идият Аширов**

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)